ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.2001



# YAZUÇILARIBIZ ÇİT İLLƏRDƏ



Tatarstan parlamentı delegatsiəsenen Kanadağa vizitı waqıtında Dəwlət Sovetı Rəise **Fərit Məxəmmətşin** (urtada) həm Tatarstan xalıq deputatı, şağır **Razil Wəliev** (unda), Kanadadağı tatar cəmğiəte rəise **Talip Kudəki**. *Noyəbr, 2000 yıl.*



Qıtay xalıq respublikası, Şencan-Uyğır avtonom rayonı başqalası Ɵremçe şəhərendə, Tatar yaqtaşlıq cəmğiəte citəkçeləre belən oçraşudan son. Suldan unğa: professor **İlçe Sayrani**, akademik **Mirqasıym Ğosmanov**, bankir **Rinat Abdullin**, professor **Zarif Dulat**, tabibə **Rəğnə Aqmullina**, universitet uqıtuçıları **Nurbay** həm **İldan İsxaqov**. *Oktəbr, 2000 yıl.*

# Казан утлары
# Qazan utları

*2001*

2

(940)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Мирза Мәхмүтов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Албастылар. *Хыялый кыйсса* ... 5

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр ... 60

Якуб ЗӘНКИЕВ. Өтелгән мәхәббәт. *Роман* ... 67

Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА. Иделемә төшеп сулар алам. *Шигырьләр (Харрас Әюпнең кереш сүзе белән)* ... 114

Сәйдә ЗЫЯ. Булат һәм кызыл канат. *Хикәя. (М. Хуҗинның керeш сүзе белән)* ... 119

Мөхәррәм КАЮМОВ. Дастан. *Шигырьләр. (Р. Гаташның керeш сүзе белән)* ... 129

ДУСЛАР ЖЫРЫ

Сафуан ӘЛИБАЙ. Бергә-бергә Идел кичәек. *Шигырьләр* ... 125

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ләбибә ИХСАНОВА. Сез кабызган утлар ... 133

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

6 - Әнгам (Мал-туар) сүрәсе. *(Ахыры)* ... 149

ФӘН

Вил ГАНИЕВ. XX йөз татар әдәбияты. Тарихи-библиографик күзәтү ... 140

Шакир АБИЛОВ. Галишер Нәваи—төрки шигърият йолдызы ... 165

СӘНГАТЬ

Луиза ИЛЬЯСОВА. Жырлыйк Түмән көйләренә ... 159

КИТАП КҮЗӘТҮ

Фатих УРМАНЧЕ, Хужи МӘХМҮТОВ. Чорлар кичеп кайтты безгә шагыйрь ... 169

Шәйхелислам ШӘЯХМӘТОВ. Сафта калыр, сакта калыр! ... 172

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Фәнзаман БАТТАЛ. Сабакташлар. *Хикәя* ... 176

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Рафис КОРБАН. Ватан. *Шигырьләр* ... 182

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ

Рафаэль МОСТАФИН. Җәлилнең билгесез рәсеме ... 185

Дини бәйрәмнәребез һәм истәлекле көннәр ... 187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 189

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Г. ГИЛЬМАНОВ. Фантастическая повесть «Лесные демоны» *(окончание)*; роман Я. ЗАНКИЕВА «Опаленная любовь» *(продолжение)*; рассказ С. ЗИЯТДИНОВОЙ *(с предисловием М. Хузина)*; стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Ш. ЗИГАНГИРОВОЙ, М. КАЮМОВА.
«Песня друзей»: стихи башкирского поэта С. АЛИБАЯ.
«Литературная критика»: Л. ИХСАНОВА. «Огни, зажженные вами».
Коран на татарском языке.
«Наука»: историко-библиографическое обозрение В. ГАНИЕВА «Татарская литература XX столетия»; статья Ш. АБИЛОВА «Алишер Навои—звезда тюркской поэзии».
«Искусство»: статья Л. ИЛЬЯСОВОЙ «Тюменские мотивы».
«Книжное обозрение»: «Через века, через столетия»—статья Ф. УРМАНЧЕ и Х. МАХМУДОВА о книге С. Сараи; Ш. ШАЯХМЕТОВ рецензирует книгу Н. Наджми «Страницы души».
«Юмор-сатира»: Ф. БАТТАЛ. Рассказ «Однокашники»
«Мир малышей»: стихи Р. КУРБАНА.
«К 95-летию М. Джалиля»: Р. Мустафин. «Неизвестная фотография Джалиля».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: герой древнетатарского эпоса Чура Батыр —рисунок Ф. Халикова; писатель Якуб Занкиев.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": G. GILMANOV'S fantastic narrative «The forest demons»(ending); Y. ZANKIEV'S novel «The burnt love» (coninution); S. ZIATDINOVA'S story (with M. Huzin's preface); the verses of R. FAIZULLIN, SH. ZIGANGIROVA, M. KAUMOV (with R. Gatash's preface).
"Frends song": verses of Bashkir poet S. ALIBAY.
"Literary criticism": L. IKHSANOVA «The fires were lighted by you».
"Koran in Tatar language".
"Science": historian and bibliographian review of V. GANIEV. "Tatar Literature of XX century"; SH. ABILOV'S article «Alisher Navoi - the star of Turkic poetry».
"Art": L. ILIASOVA'S article «Tumen's motives».
"Book review": «Over the centuries, over the ages» - F. URMANCHI'S and H. MAKHMUDOV'S article about S. Sarai's book; SH. SHAIAKHMETOV'S review of N. Najmi's book «The soul's pages»
"Satire and humour": F. Battal's story «Class - mates».
"Commemorating the 95 th anniversary of M. Jalil": R. MUSTAFIN «Unknown photo of Jalil».
The diary of social and cultural life.
In our covers: The hero of anient Tatar epos Chura Batir - F. Halikov's picture; writer Y. Zankiev.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.01.2001 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8619 Заказ А-27
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.

**Галимҗан Гыйльманов**

# АЛБАСТЫЛАР

ХЫЯЛЫЙ КЫЙССА

## Икенче бүлек

### I

Урман—табигатьнең иң серле урыныдыр. Тормыш кебек. Үзе ымсындыра, үзе шомландыра. Керәсе дә килә, куркыта да... Нинди генә тереклек иясе юк анда! Куркак куяннан алып олпат аюга, явыз бүрегә кадәр яши урманда. Җитмәсә, төрле хәшәрәтләр—албастылар, шүрәлеләр, диюләр, ялмавызлар, убырлар да бар, имеш. Шул ук вакытта анда яшәүче изге рухлар—табигать ияләре—урманның саф, илаһи, изге хасиятләрен сакларга булышалар, ди.

Явызлык та, изгелек тә юлга ияләшүчән була. Чөнки юл—язмышлар очраша торган урын. Һәм, иң мөһиме, юлсыз урман, урмансыз юл булмый. Алар барыбер очрашалар. Алар очрашкан чакта башлана да инде яманлык белән изгелек көрәше. Бу көрәш, бу хәтәр яу үзәгендә кеше дә булса, табигать кануннарын тетрәндерерлек драма-язмышларны көт тә тор. Мари урманнарын урталай кисеп таш юл чаба. Июль уртасы. Чиллә күзе. Көн кызуыннан бөтен табигать әлсерәгән. Бу хәрәкәтсез яткан һәм дивардагы рәсем кебек катып калган табигать дөньясында тормышка, яшәешкә берләнбер ишарә—үз язмышына каршы ашыгып китеп баручы юлчы егет. Аны бу юлдан күңел тынгысызлыгы, җан газабы, бертуктаусыз сыкрап-сызлап торган рухы алып бара.

...Хәлимнең юлы уңды. Авылдан чыгып, ике-өч чакрымнар киткәч, аны атлы-арбалы бер юлчы куып житте. Уйлар дәрьясында берьялгызы калган Хәлим башта бу юлчыны бөтенләй искәрмәде. "Тр-р-р!" дигән тавышка сискәнеп читкә тайпылгач кына, исенә-аңына килеп, башын күтәрде. Пошкырынып басып торган кечкенә йөнтәс ат үзе бер жен-шайтан кыяфәтендә иде. Озын юлданмы, чиллә кызуыннанмы тир-күбеккә баткан бу атның яллары тәртипсез рәвештә як-якка тырпайган, колаклары гадәттән тыш зур, күзләре тышка бәреп, бүлтәеп чыккан, озын сакал-төкләр сырып алган аскы иреннәре килбәтсез рәвештә салынып төшкән, борын тишекләре киң ачылып, эссе тын-сулышы тирә-юньгә бөркелеп тора...

---

Ахыры. Башы 1 санда.

Исен жыеп өлгергән Хәлим, пар-бу бөркеп торган атны урап, арба ягына чыкты. Әмма, ике-өч адым атлауга, дертләп китте. Шикләнерлек тә шул. Кычкыртып килеп туктаган ат арбасында бер җан әсәре дә юк иде! Хәлим шомланып куйды: ат үзе "тпыру"лап кычкырмагандыр бит?

Шунда гына ул атның икенче ягында кыштырдап йөрүче картны шәйләп алды. Иске генә кәҗән кигән бу карт чып-чын Хозыр-Ильяс иде: сөт кебек ап-ак сакал-мыегы аңа илаһилык, серлелек, изгелек төсмере ягып тора. Башына кигән искерәк эшләпәсе астыннан күренеп торган чәчләре дә ак-бүз. Күзләре кечкенә, эчкә баткан, әмма бик тә мөлаем, ачык һәм иманлы иде аның. Аркалык бавын рәтләп булашкан юлчы карт Хәлимгә игътибар да итмәгән кебек. Менә ул атның алдына чыкты, кәҗән кесәсеннән ак чүпрәк чыгарып , атның дымлы күзләрен сөртте, аның яңагыннан сөеп куйды, шуннан соң гына, йөзеп, шуышып барган кебек кенә атлап, арба янына килде.

—Саумы, бабакай!—Кычкырып сәлам бирде Хәлим.

—Аллага шөкер, олан, үзең таза-саумы? Кая китеп барыш болай? Сөяк майлары эреп ага торган чак бит... Юлың да ерак икән...

—Минем кая барасын ничек белдең, бабакай? Мин бит кая барасымны әйтмәдем әле.

—Әйтәсе-нитәсе юк, бу юл бер генә урынга алып бара—алдагы гомереңә. Ә синең гомерең озын булачак, әмма дә озын булачак ул...

—Бик серле сөйләшәсең син, бабакай. Юраучы-фалчы түгелдерсең лә?.. Яисә берәр пәйгамбәр заты?

—Беләсең килсә, җир йөзендә һәр адәм баласы—Алланың бер колы, димәк, изге зат. Ә һәр изге затта пәйгамбәрлек бар. Җир пычрагына буяла барган саен кеше пәйгамбәрлектән ерагая, еш кына Аллаһы тәгалә биргән изге сыйфат-хасиятләрен бөтенләй югалта... Әйдә, олан, утыр, киттек. Сизеп торам, синең белән юл имин булачак. Әйбәт кешегә охшагансың... На-а, малкай!..

Кузгалдылар. Берара сөйләшми бардылар. Әмма Хәлимнең бик тә сөйләшәсе килә. Аңа аркасын куеп утырган бу юлчы картта ниндидер сер яшерелгән кебек. Тик нидән башларга соң сүзне?.. Орды-бәрде генә сөйләшеп утырып булмый бит инде. Ә! "Гомерең озын булачак",—дидеме әле? Каян белә ул? Пәйгамбәрен пәйгамбәрдер, тик каяндыр белә бит ул бу хакта...

—Бабай, ә, бабакай!

—Нәрсә, олан?

—Бая син минем гомер турында әйттең. Шаярттың гынамы, әллә чынлап та белеп әйтәсеңме?

—Күлеп сөйләшергә, шаярып юрарга ярамаган әйберләр бар, олан. Гомер дә шундыйлардан. Мин сиңа хак дөресен әйттем—гомерең озын булачак. Синдә илаһи тамга бар. Мондый тамга—озын гомер билгесе.

—Кайда ул, нинди тамга?

—Маңгаеңдагы минне әйтәм, олан.

—Бу минме?—Хәлим, үзе дә сизмәстән, бармак очы белән маңгаеңдагы миңенә кагылды.

Карт, кискен борылып, аның кулын тартып алды. Хәлим, хәтта, куркып китте. Картның шелтәле сүзен ишеткәч тынычланды тагы.

—Миңгә төртеп күрсәтергә ярамый. Яман күз тия. Синең бармагыңа карап, шайтани затлар илаһи тамгаңны таныйлар да, аның аша җаныңа үтеп керәләр, йөрәк-бәгыреңне кимерәләр, күңелеңне пычрата башлыйлар... Тәүбә-тәүбә, Алла сакласын...

—Бабакай, кызык бит, минем хакта тагын ниләр әйтә аласың? Әйт әле, менә мин кая барам?

Хәлим мәзәкчән генә сорашырга теләгән иде, юлчы картның җавабын ишеткәч, бөтенләй басылып, уйчанланып, хәтта куркып калды. Чөнки бу Хозыр-Ильяс аңа чын дөресен сөйләп бара иде.

—Син сөйгән ярыңны, хатыныңны, гаиләңне эзләп барасың. Әлегә

аның кайда икәнен белмисен. Урманның тап уртасында төшеп каласың да...

— Шулай да, минем булачак хатыным кайдан? Каян ул? Кем ул? Нинди?

—Ул синең белән бер авылдан. Авылның тап уртасында үсеп утырган агач ышыгында туган бер бала...

—Ә? Нәфисәме?

—Исеме-аты минем өчен караңгы. Кара чәчле, күк-зәңгәр күзле бу кызның йөзен генә күрәм. Ул синең өчен жан атып тора, кулында күкрәк баласы да бар... Әмма бу изге жан иясе кара сихер ихтыярында яши...

—Нәфисә бит бу, шулаймы?

—Әйтәм бит инде, мин аның йөз-кыяфәтен генә кузаллый алам. Калганын Аллаһы тәгалә белә. На-а, малкай!..

Ат тигез генә юыртуында булды. Таш юлдан кетердәп баручы арба тәгәрмәче көенә Хәлим үз тормышы, язмышы, киләчәге хакында уйлады.

Чынлап та, бу фалчы картның юравы Нәфисәгә бик туры килә. Авылның тап уртасында утырган тупыл агачы аларның йортларына терәлеп кенә үсә. Нәфисәнең көмәнле булуы да рас килеп тора. Менә хикмәт... Ниндидер кара сихер хакында да сүз катты бу сәер карт. Ә бит ул хаклы! Нәфисәләр нигезендә кара сихер бар дип сөйлиләр. Юк анысы, кычкырып, авыз тутырып әйтмиләр, әмма пышан-пышан гына күп сүз йөртәләр бу тупыл агачы хакында, аның янындагы йорт хакында...

Ә шулай да карт ялгышты! Хәлимгә Майядан башка беркем дә кирәк түгел. Хәтта Нәфисәгә дә суынды инде ул. Нәфисә хәзер кеше хатыны, гаилә иясе. Озакламый бәби табачак, тормыш мәшәкатьләренә чумып, Хәлим хакында бөтенләй онытачак. Хәлимнең күңелендә дә башка хис, башка гамь. Майя... Майя! Бары тик Майя гына аның күңелендә, Майя гына аның уйларында, аның язмышында... Барыбер табачак ул аны, бөтен урманны айкап чыгачак, бөтен дөньяның астын-өскә китерәчәк, әмма табачак, үзенеке итәчәк, авылына алып кайтачак, аның белән бәхетле тормыш корачак...

Хәлим, үзе дә сизмәстән, каты итеп кыскан уң учын ачып жибәрде. Жан бәһасенә торырлык кендек бөртеге урынында иде. Үз-үзенә гажәпләнде: күпме вакыт учында тотып йөри икән ул бу тән бөртеген. Кесәсеннән ап-ак кульяулык чыгарып, кендекне сак кына шуның өстенә шудырып төшерде, төреп, түш кесәсенә салды. Ничек куйдым икән дип, кесәсен тыштан сыйпап карады. Аннары тагын артка таба йөгерүче урман юлына, дөресрәге, аның борылыш саен киселеп төшә барган ерак очына текәлде.

Хәлимнең уй очлары төйнәлеп бетүен генә көткән кебек, карт тагын сүз башлады:

—Бу китүең белән ананны рәнжетмәденме соң, олан?

—Белмим, бабакай. Рәнжегәндер дә инде, мескенкәем. Әле кайчан гына бер ел югалып торган идем. Менә тагын китеп барам. Ул гына түгел, мин үземне үзем дә аңлап бетерә алмыйм шул. Кемдер, нидер мине дөнья буенча каңгырайтып йөртә кебек...

—Тәкъдир йөртә сине, тәкъдир... Тәкъдир сызыгыннан читкә китү кыен шул, ай кыен, олан...

—Беләсеңме, бабакай, мин бит Майя исемле бер кызны эзләп барам. Урманның караңгы төпкелендә сихерче карчыклар белән яши ул. Албастылар утарында. Бу да тәкъдирме?

—Албастылар, сихерчеләр дисең син... Ә бит чынлыкта албастылыр да, сихерчеләр дә юк, шулай ук фәрештәләр, изге рухлар да риваятьләрдә генә була. Барын бар алар... Тик, кешенең жан канатлары булып, аның ике ягында яшиләр. Кешенең асылы менә шушы ак-кара рухлар көрәшеннән тора. Албасты ягы жиңгән кеше тора-бара чынлап та бер явыз хәшәрәт кыяфәте алырга мөмкин. Фәрештәләр ягы жиңсә—ул Ходай

тәгаләнең җирдәге рухи илчесенә әверелә. Болары илгә, тормышка, инсаниятка иман индереп торалар, ачык, дөрес юл күрсәтәләр.

—Ә миндә кайсы як өстенрәк соң, бабакай?

—Синең фәрештәләрең көчле, иманың нык, күңелең чиста, саф.— Бераз тын торганнан соң, юлчы өстәп әйтеп куйды.—Табасың син бәхетеңне. Табасың да югалтасың... Синең бөтен гомерең табып югалтудан тора. Шуңа әзер бул, олан. Ә хәзер безгә аерылышырга туры киләчәк. Минем үз юлым, синең үз юлың...

—Кая барасың соң син, бабакай? Монда бит башка юл юк...

—Бар шул. Юллар күп. Күрә, таный гына белергә кирәк аларны. Тр-р, малкай...

Хәлим белән бергә карт та арбадан төште. Утырып килгән киндер түшәген шапылдатып кагып куйды, башка төенчекләрен рәтләштерде. Аннары, ялгыш кына табып алган кебек, каяндыр бер таяк тартып чыгарды. Артыш куагының кәүсәсеннән юнып ясалган таяк иде бу. Карт аны Хәлимгә төртте.

—Менә бу таякны ал әле. Ул кулыңда булса, күңелең тынычланыр. Каршыңа чыккан яман көчләр дә тукталып калыр. Артыш бу—яман рухлар сөймәгән җан күзәнәгеннән үсә диләр аны. Шуңа да ул безгә якын, үз...

—Нишләргә соң бу таяк белән?

—Юлчыга таяк кирәк. Синең юл таягың булсын ул. Куркыныч килә башласа, шушы таяк белән тирә-ягыңа боҗра сызып куй—берни дә булмас.

—Рәхмәт, бабакай, мин сине мәңге онытмам.

—Хуш иттек. Җаныңны сакла... Ә хәзер бар—үз юлыңда бул, тик артыңа борылып карама. Юкса юлың уңмас...

—Киттем, бабакай. Тагын очрашырга язсын!

Хәлим, алгарак талпынып, аркасындагы капчыгын рәтләп алды да, артыш таякка таянып, таш юл буйлап китте. Бик борылып карыйсы килсә дә, түзде, карамады, теге Хозыр-Ильяска сүз бирде бит. Ул шуңа гына аптырады: хәзер кая барыр соң бу карт? Кире борылырмы? Урманга кереп китәрме? Алай дисәң, як-якта юл-мазар күренмәде кебек...

Шулай да, бераз баргач, Хәлим борылып карамыйча түзә алмады. Артында берничә чакрымга сузылган буш юл күреп, тагын бер гаҗәпләнде. Юл читләрендә дә хәрәкәт күренмәде. "Хәерлегә булсын",—дип уйлап куйды ул. Һәм кызу-кызу атлап алга—язмышына каршы китте.

## II

Хәлим таныш багананы әллә каян күреп килде. Дөрес, урман эчендәге басу-кырга житкәч, ул бераз шикләнебрәк калды. Шул басумы соң бу? Чөнки быел бу ачык мәйданга бернинди иген унышы да чәчелмәгән иде. Шыксыз кыяфәттә караеп яткан басу тәнен тигәнәк, алабута, песи борчагы кебек чүп үләне сырып өлгергән, ара-тирә былтыргы салам өемнәре генә, караеп, күңелне шомландырып торалар. Юл читендә үсеп утырган ромашкалар рәте, ап-ак тасма булып, юлны бу ямьсез, күңелсез дөньядан бүлеп, саклап тора кебек.

Багана тирәсендә дә үзгәреш. Былтыргы яшел хәтфә келәм—тигез, йомшак чирәмлек урынында ниндидер чокыр чалыш авызын ыржайтып ята. Машина яисә трактор батып яткан, ахры, монда. Шактый интеккән булырга тиешләр. Әнә бит—баганаың бер чите умырып алынган. Әмма нык та утыртылган икән, "эһ" тә итмәгән, үз урынында утырып калган ул.

Хәлим багана йөзендәге сыр-тамгаларга күз салды. Санап чыкты. Артмаган... Монысы—хәерле фал. Ул кинәт кесәсенә тыгылды, пәке алып, берәр сыр уймакчы булды. Әмма шундук кире уйлады. Аның күрәчәк җәфалары шушы уентык-тамгадан торадыр кебек. Ул хәтта ашарга

да утырмады. Капчыгын салып, кулына берничә пәрәмәч белән әйрән шешәсе алды да тагын кузгалды. Бара-бара тамак ялгарга булды. Кайсы якка кереп китәргә икән?—дип баш ватып торасы юк. Хәлим теге елда ике зәхмәти карчыкка ияреп кереп киткән урынны яхшы хәтерли. Әнә ул—мәһабәт имән, аның янында кушкаен. Читтән караганда алар серләшеп торган кешеләрне хәтерләтәләр. Чынлап та шулаймы әллә? Кара сихергә эләгеп агачка әверелгән бәхетсез җаннармы алар? Юк ла... Ниндидер таныш түгел кошның тонык кына ишетелгән җыры сөйләшү галәмәте китереп чыгара икән.

Хәлим соңгы тапкыр юлның баш-башларына карап алды да тәвәккәл адымнар белән таныш имәнгә карап китте. Имән белән каеннан "корылган" тылсымлы "капка"ны үтеп, урман ешлыгына барып та керде. Күләгәдә рәхәт икән. Бөтенләй башка дөнья! Хәлим иркен сулап куйды. Чынлап та, ул карашларының тынычланып калуын, тәненә шифалы җиләс һава бөркелүен тойды. Дөрес, бераз шомландыра, сагайта, күнелне кузгата, хәтта җанны үрти бу урман дөньясы. Шулай да түзәргә, күнегергә була. Хәлим эчтән генә үз-үзеннән көлеп куйды: бер ел буе урманда шүрәле кебек яшәгән кеше ләса ул! Менә хәзер шикләнеп, күнелен кысып бара имеш...

Бераздан Хәлим тәмам тынычланып җитте. Йөрәге урынына утырды, кан йөреше тигезләнде, күнел ярларын каккан дулкыннар салмакланды. Ул урманга җентекләбрәк карап бара башлады. Иң элек аны алга әйдәп бара торган сукмак җәлеп итте. Хәлим шундук аңлап алды—моннан бер генә тапкыр үтмәгәннәр. Әмма кеше эзе күренми. Сынган чыбык-чабык, тапталган балчык, мүк-үлән дә күзгә чалынмый. Шулай да, үзенең кайсыдыр җирендәге тоемы беләндер сизенә: бу—чын сукмак.

Хәлим ике чукыр тавышына игътибар итте: "Клә-клә, клә-клә..." Бераз тынып торалар да тагын көйли башлыйлар: "Клә-клә, клә-клә, клә-клә..." Хәлимнең бик тә күрәсе килә иде үзләрен, чөнки юлда чукыр кошын очратуны халык изгелеккә, әйбәт юлга, уңышлы сәфәргә юрый. Бу фал хакында Ак бабайның такмагы да бар: "Чукыр-чукыр, бәхет чакыр",—дип әйтеп куя иде ул малайларча бер самимлек белән.

Ниһаять, Хәлим чукырларны эзләп тапты. Әнә алар—нарат куенында утыралар. Уттай янып торган кып-кызылы—әти чукыр, саргылт-яшел төстәгесе—әни чукыр. Томшык очлары ике якка аерылып тора. Үзара "клә-клә" дип сөйләшәләр. Ниндидер иркәлек, назлылык бар бу тавышта. Ә бит алар иң батыр, иң фидакяр җан ияләре дә. Нарат, чыршы күркәләре күп елны январь-февраль айларында ук бала чыгара башлый бу кошлар. Шуңа күрәдерме—алар яз чакыручы кошлар булып исәпләнә. Шул яклап та кешеләрнең чукырларга хөрмәте зур.

Хәлим чукырлар җырын озак тыңлап торды. Аларның тавышын башка кошлар җыры алыштырды, икенчеләрен өченчеләре, өченчеләрен дүртенчеләре... Ничек кенә хискә бирелеп, иләсләнеп барса да, Хәлим арудан котыла алмады. Җәйге кызу, ярты көнгә сузылган юл, һәр куагы, һәр ботагы белән алып калырга теләп, сырпаланган-сарылган урман нык арыткан иде. Ул, бер ачыклык сайлап, мүкле түмгәк өстенә утырды, аркасын, башын карт усак кәүсәсенә терәп, күзләрен йомды. Алга сузып җибәргән аяклары рәхәтләнеп китте. Хәлим тагын бераз капкалап алды, әйрән эчеп куйды. Биш минут кына утырып алам дисә дә, ярты сәгатьләп утырган икән. Бу вакыт эчендә бөтен тәне изрәгән, буыннары йомшарган, аң-зиһене ойый башлаган иде аның.

Кара исәп буенча, урман эченнән генә дә өч сәгатьләп килә инде ул. Тагын берничә сәгатьлек юл булырга тиеш. Туры барса инде. Ә читкә киткән булса... Бу хакта уйларга да курыкты Хәлим. Инде болай да кич житеп килә. Ничек тә төнгә калмаска иде! Хәлим куркуыннан сикереп торганын үзе дә сизми калды. Тизрәк китәргә кирәк, тукталмаска, башка бер дә тукталмаска!

Инде урманга алып кереп киткән сукмак та югалды. Тагын әллә

нинди сукмаклар да очраган кебек булды. Аларның кайсыдыр өзелеп калды, кайсыдыр урау якка каерылып калды. Хәлимнең урап йөрерлек вакыты юк иде, ул, ниндидер күңел тоемы буенча, туп-туры барды да барды.

Бервакыт аяк асты йомшый башлады. Хәлимнең күңеленә җылы йөгерде—сазлык бит бу, таныш сазлык! Әнә ул—пар-бу чыгарып яткан шомлы дөнья. Хәлим белә—сукмак сазлыкка керми, аны читләп кенә үтә, әмма барыбер дә янәшәдәге сазлыктан ишетелеп торган быгырдавык тавыштан тәннәр чымырдап ала, коты да табан астына төшеп китәм-китәм дип кенә бара... Бу быгырдавыкка сызгыру тавышлары кушыла, нидер чыелдап куя, кемдер җан төбе белән уфылдый... Сазлык тавышына күнегеп булмый—бу һәркемгә мәгълүм. Сазлык—хәшәрәт җан иясе кебек бит ул—хәзер йотарга тора. Аның сихеренә әләксәң... афәткә юлыгуыңны көт тә тор.

Ниһаять, сазлык артка табан шуышты. Кичке эңгер-меңгергә дә күп калмады. Черки котыра башлады. Хәлим, читкә тайпылып, сазлык читендәге бер түмгәктән учлап лайлалы ләм алды да йөзенә, җилкә-муен тирәләренә, кул артларына сөртеп куйды. Чебен-черкидән котылу өчен телсез әпәләр шушы балчыкны сөртәләр иде. Онытмаган икән. Бу кечкенә ачышына да сөенеп бетә алмады Хәлим. Инде менә ничәнче мәртәбә, үзенең сөйгәне—Майясы калган урман аланы, албастылар утары турында уйлады ул.

Бу бер ел эчендә ниләр генә булды икән анда? Ничек яшәделәр икән? Җитәрлек азык, ит-май, яшелчә, җимеш әзерли алдылар микән? Аты Аксай исәнме? Әпәләр ничек?

Ә Майя соң, Майя ни хәлдәдер!.. Онытмаганмы ул Хәлимен? Аның җан җылысын, тән назларын үз җанында, үз тәнендә саклый микән? Бу җылыны, бу назны сагына микән? Онытмагандыр... Сагынадыр... Көтәдер... Әллә көтмиме? Бер ел аз вакыт түгел шул... Күпме көтәргә була...“Килсәң, кендегеңне учыңа кысып кил,”—дигән иде ул хушлашканда. Инде көтә-көтә көтек булып беткәндер. Карчыклар гына үзенә берәр әшәкелек кылмасалар ярар иде!.. Ничек тә табарга, табарга кирәк!.. Тизрәк табарга...

Хәлим үҗәтләнеп такмаклый-такмаклый алга баруын дәвам итте. Күкрәгеннән, йөзен чәбәкләргә үрелгән куак ботакларын читкә этеп җибәрергә дә вакыты, хәле юк иде аның. Тәмам арыды. Кинәт туктап калса, бер урында басып тора алмыйча, хәлсезлектән җиргә ишелеп төшәр иде, мөгаен. Бердәнбер чара—ничек тә туктамаска, хәрәкәтләнергә, алга барырга, Майя белән аерып торган араны ничек тә киметергә, кыскартырга!..

Урманга карангылык иңә башлады. Кичке ябалак тавышлары ишетелгәләп кала, димәк, чынлап та, тиздән урман өстен кара пәрдә каплап алачак...

Хәлим тәмам тынычлыгын югалтты. Өлгерми бугай ул. Югыйсә, утарга чыгарга бик вакыт инде. Ялгышты микәнни?.. Бу хакта уйламаска тырышты. Дөрес бара ул, дөрес бара! Сизгер күңеле аны алдамас... Мәхәббәте, сагышы алдамас...

Йөгерә-атлый килгән җиреннән Хәлим, бер төпкә абынып, акрын гына сөрлегә барып, дымлы урман туфрагына капланды. Ачы итеп сүгенәсе килде аның. Хәтта елыйсы килде. Юк, аягының өзелердәй булып сызлавыннан түгел, чарасызлыктан, мескенлектән, ялгызлыктан, гомумән, язмышының ачы шаяртуыннан елыйсы килде. Күзләреннән ике тамчы яшь бөртеге бәреп чыкты; бу ике тамчы аның керфекләренә эленеп, җиргә төшергәме-юкмы дигән кебек, калтыранып торганда Хәлимнең аңын-зиһенен ачык, иртәнге нур кебек якты уй сызып үтте: “Тукта! Нәрсәгә абынды соң ул? Ә?! Киселгән агач төбенә?..”

Хәлим ничек торып басканын да искәрми калды. Килгән сукмагы буйлап кире китте.

Менә ул! Шул! Агач төбе! Берничә ел элек кисеп алынган агач төбе! Урманның бу төбәгенә аучылар сирәк керә. Урманчылар бөтенләй дә күренми. Мондый төпләр күп булса—димәк, утынга кискәннәр. Яисә йорт-кура өчен... Ә монда бер генә утар бар. Албастылар утары гына... Әһә! Менә тагын бер төп, менә тагын, тагын, тагын... Ә менә монысын янарак, быел яз гына кискәннәр. Телсез, чәнтисез танышы, әй лә, әткәсе кискән бит моны! Ул гына, агачны екканда, балтасын өч яклап чаба...

Хәлим сөенеченнән нишләргә дә белмәде. Борчу, зар тамчысы булып туган ике яшь бөртегенә башкалары өстәлде, шулай итеп, кайгы яшен шатлык яшьләре күмеп китте.

Башында кайнаган уйлардан Хәлим сискәнеп куйды: димәк, "сихер чиге" инде артта калган? Ул ачык хәтерли: урман кискәндә алар бервакытта да "сихер чиге"ннән узмыйлар иде. Нишләп һушыннан язып исермәде, аңын, зиһенен, хәтерен җуймады соң әле ул? Әллә... Әллә теге кендек тылсымы ярдәм итте микән? Хәлим, каударланып,түш кесәсен капшый башлады. "Төшеп калмаганмы?.. Юк, монда... Менә ул... Җан бөртегем... Газизем..." Хәлим, кульяулыкны чишеп, кендек бөртеген учына салды. Егылган жиреннән артыш таягын эзләп тапты да, кендекле йодрыгын түшенә кысып, тагын кузгалды. Күнеленнән дә, ан-зиһене белән дә албасты карчыклар зәхмәтенә әзер иде ул. Көн буе йөрүдән арган-талчыккан тәне генә сынатмасын. Хәлсезлектән калтырана башлаган бот-балтырлары, күп йөрүдән янып-шешеп чыккан аяк табаннары гына түзсен дә тын-сулышы гына өзелмәсен!..

Әлбәттә инде, аның килүен урман карчыклары күптән сизгән булырга тиеш. Әзерләнеп, бөтен сихер-зәхмәтләрен җыеп, туплап, аңа каршы юлга да чыкканнардыр... Алар инде ерак та түгелдер... Менә-менә каршыдагы агачлар артыннан килеп чыгарлар кебек... Хәтта, аларның аяк кыштырдатып килүләрен дә ишеткән кебек була Хәлим. Андый чакта ул туктап кала, бераз алга карап тора да тагын кузгала...

Урманга кичке эңгер-меңгер кереп тулды. Әмма июль яктылыгы тиз генә китәргә теләми иде, ул әле тагын бераз урманны, табигатьне, җир йөзен иркәләп торачак. Язган булса, шул арада Хәлим мари урманнарына кереп югалган утарга барып җитәчәк, Майясын күрәчәк, аны зәһәр тоткынлыктан азат итәчәк...

Ниһаять, Хәлим беренче "тере" сукмакка чыкты. Мал-туар эзе буенча, ис буенча, бүген булган хәлләрне күз алдына китерергә тырышты ул. Менә көтү кайта, аны каршы алырга чыккан Майя, утар капкасын ачып, сыерларны саварга алып кереп китә... Телсезләр көтү артыннан сүлпән генә кайталар-кайталар да үзләренең җиргә ингән караңгы, тынчу йортларына кереп китәләр...

Кинәт каршыдагы агачлар ешлыгында ике шәүлә күренеп калды. "Ниһаять!.. Менә алар... Нык торырга кирәк!.. Ничек тә аңны, зиһенне югалтмаска!.."—дип уйлады Хәлим; ул шулай үзен тынычландырды, күнелен ныгытты... Күкрәгенә кыскан уң кул учындагы кендек хакында уйлап алды, аннары кайчандыр ат саклаганда Ак бабай өйрәткән доганы пышылдады: "Бисмиллаһир-рахманир рахим. Әлхәм дәлилләһи раббил галәмин. Әррахмәнир рахим. Мәлики йәүмид дин. Иййәкә нәгъбәдә вә иййәкә нәстәгыйн. Иһдинә сыйратәл-мөстәкыйм. Сыйратәл ләзинә әнгамтә-галәйһим. Гайрил-мәгъдубигаләйһим вә ләд-даллин. Амин". Ниндидер бер илаһи балкыш булып, бу "Әлхәм" сүрәсенең мәгънәсе яшен тизлегендә ялтырап китте: "Барча галәмне асраучы Аллаһы тәгаләгә шөкерана кыйлабыз, дөньяда да, ахирәттә дә ул рәхимле. Кыямәт көнендә ул хуҗа. Сиңа гына гыйбадәт кыйлабыз һәм ярдәмне синнән генә сорыйбыз. Безне тугры юлга беркет. Яхшы бәндәләрең юлына. Үзең ачуланмыш булмаган бәндәләрең юлына һәм азмаган бәндәләрең юлына... Илаһи кабул ит..."

Хәлим тагы әллә нинди догалар укымакчы иде. Әмма ул, каушавын-

нан, бала чакта ятлаган догаларын онытып җибәрде, шулай да, тагын бер бик мөһим доганы исенә төшерә алды ул. Әнисе бу доганы аның күлмәк эченә бөти итеп тегеп йөртә иде. Балачак хәтере—мәңгелек хәтер. Хәлим әлеге доганы да хәтер савытының иң өстенә калкытып куйды: "Көль әгузе бираббил—фәләкый, мин шәрри мә халака вә мин шәрри гасикыйн изә вәкабә, вә мин шәррин-нә-ффәсәти филгөкади, вә мин шәрри хасидин изә хәсәд".

Мәгънәсен дә хәтерли Хәлим. Хәзерге халәтенә бу доганың бик тә туры килүенә сөенеп бетә алмады ул. Ә мәгънәсе болайрак бугай: "Әйт, сыгынамын таң раббенә. Аллаһы тәгалә яраткан нәрсәләрнең һәрбер явызлыгыннан вә караңгы кичәнең явызлыгыннан, тагын төенләргә өрүче сихерче хатыннар явызлыгыннан..."

Хәлим ниятләгән догасын пышылдап бетерә алмады, якындагы юан имән артыннан таныш ике шәүлә килеп чыкты. Килеп чыгулары булды, алдан килгәне кулындагы таягын сукмакка ташлавы булды. Хәлим бу сихерне белә иде. Таякны терелтеп, елан итеп җибәрүче сихерчеләр хакында аларның авылларында да риваятьләр йөри. Сихерче карчык таягы җиргә дә төшеп өлгермәгәндер әле, Хәлим үз кулындагы артыш таягы белән алдына чик сызып өлгерде.

Сихерче карчык кулыннан төшкән таяк шул ук мизгелдә кара еланга әверелде дә, боргаланып-шуышып, Хәлимгә таба килә башлады. Хәлим, әллә каушаудан, әллә куркудан, әллә кара елан карашыннан, тораташ булып катып калды. Әмма аның күңел почмагында калган бер якты өмет чаткасы аны агачка яисә ташка әверелүдән саклап тора иде. Бу өмет аның алдына сызылган сызык белән бәйләнгән, ахры. Елан күзенә карарга ярамаганын белә Хәлим. Әмма еланга карап өлгергән иде шул. Үз карашы белән тартып китергәндәй китерде ул еланны. Әмма, Хәлим алдында тырналган эзгә килеп җитү белән, елан туктап калды, икенче мизгелдә бөгәрләнеп, җыерылып килде дә, шул тылсымлы сызыкка борынын төртеп, бөтен буена сузылып ятты. Аннары тагын агач ботагына әверелде...

Елан артыннан кулларын алга сузып килүче карчыклар Хәлимне үзләренчә өшкерә башладылар. Хәлим хәйләгә кереште: аларның сихеренә буйсынган булып кыланды, үзе уң учына кысылган кендеген тоярга тырышты. Менә ул туктап калды, җансыз әйбер кебек бер ноктага карап тора башлады. Карчыклар, үзләренең кара эшләрен төгәлләп, икесе ике яктан Хәлим каршына килеп бастылар. Аннары, аны ике як беләгеннән тотып, күзгә төртеләм-төртеләм дип торган шомлы караңгылык эченә алып кереп киттеләр.

### III

Утарга дөм караңгыда кайтып керделәр. Хәлим тәмам хәлсезләнеп, егылыр хәлгә җиткән иде. Ул көч-хәл белән генә олы алачык каршындагы кое ялгашы янына килеп җитте, тезләнде, башын ялгаштагы җылымса суга тыкты.

Аңа кое янында озак юаныргa ирек бирмәделәр, тартып торгызып, этә-төртә алачыкның бер тар бүлмәсенә кертеп җибәрделәр. Хәлим, ярым һушсыз хәлдә, куллары белән капшап, кармап сәке кебек нәрсә эзләп тапты, аннары, аркасындагы капчыгын да салып тормыйча, гөрселдәп әлеге сәкегә ауды, шул мизгелдә тирән йокыга да талды.

Төшендә әнкәсен күрде. Сания яр буеннан ике ак каз куып кайтып килә. Тик шунысы: бу казларны ул һич кенә дә алып кайтып җиткерә алмый, җай чыгу белән, алар як-якка таралып китәргә генә торалар. Сабыр җанлы Сания моңа һич үртәлми, ачуланмый, һаман куа, үгетли... Менә, ниһаять, ул үз теләгенә ирешә: ике казны да җете яшелгә буялган капкаларына алып кереп китә... Капка алды буш кала, әмма каз каңгылдавы

әле бик озак ишетелеп тора. Бу тавыш бер көчәя, бер басыла, тагын көчәя...

...Төшендәге казларның ачыргаланып кычкыруына уянып китте дә инде Хәлим. Кайда ул? Нинди җирдә? Стенадагы тар тишектән төшкән көн яктысына карaганда, тaн атып килә. Бераздан аның күзләре бүлмә эченә тәмам күнегеп җитте, ул инде төрле озынлыктагы чөйләргә эленгән суган бауларын, кипкән үлән бәйләмнәрен дә шәйли... Ләкин, бүлмәгә күнексә дә, каяндыр ишетелеп торган яшь каз тавышына һич кенә дә күнегә алмый. Йөрәккә үтәрлек шомлы ачыргалану авазын нәрсәгә юрарга да белмәде ул. Юк, каз тавышы түгел бу, ниндидер урман кошы үзенең аһ-зарын җыр итеп көйли, ахры...

Уй-фаразларының очына чыга алмыйча яткан Хәлим тагын ойый башлады, бераздан тагын изрәп йокыга китте. Йокысы шулкадәр тирән иде ки, аның янына кереп, бөтен тән-шәрифләрен капшап, киемнәрен тентеп йөргән ике карчыкны күрерлек, тоярлык хәлдә түгел иде.

Карчыклар Хәлим янында шактый маташтылар. Күрәсең, алар ниндидер сер барлыгын сизенгәннәр, хәтта төгәл белгәннәр, әмма бу сернең төбенә төшә дә, очына чыга да алмыйлар иде. Үз булдыксызлыкларыннан гаҗиз булып, үртәлеп йөргән ике сихерче заты бу минутта дөньяның иң караңгы почмагыннан чыккан иң явыз җен-шайтаннарның да явызы булгандыр, мөгаен.

Карчыклар эзләгәннәрен таба алмадылар. Алар ис-аңнарына килгәндә, тышкы дөнья яктырып беткән иде инде. Уң йодрыгын күкрәк читлегенә кысып, изрәп йоклап яткан Хәлим бу юлы үзенең кара сихерне җиңеп чыгуын сизмичә дә, белмичә дә калды. Аның аруы шулкадәр көчле иде ки, өстеннән гыйфрит арбасы узса да уянмас иде. Әмма, шул ук вакытта, бернинди сихер-тылсым да, көч-куәт тә аның чытырдатып кысылган һәм таш кебек катып калган йодрыгын ачтыра алмас иде.

Ул шулай төшкә кадәр йоклады. Тагын шул ук төш: әнкәсе казлар куа. Тик бу юлы башкачарак. Капкадан кереп-чыгып йөргән пар каз артыннан бер бәпкә ияргән. Бу сары йомгак шулкадәр дә үзәк өзгеч тавыш белән чыелдап кычкыра, янына барып, учка алып, борын төбенә үк китереп: "Кычкырма инде, әнә бит әнкәң, әнә әткән",—дип әйтәсе, юатасы, иркәлисе-назлыйсы килә...

Хәлим, бөтен төш дөньясын яңгыратып торган бу каз бәпкәсе тавышына түзә алмады, борчылып, хәтта куркынып уянып китте. Уянуын-уянды, әмма барыбер бу тавыштан котыла алмады. "Акылдан шашам ахры, әллә тагын зәхмәтле сихергә юлыктыммы?"—дип уйлады ул. Хәтерен тикшереп карады. Барысы да истә. Гомеренең һәр дәвере, һәр тарафы, һәр чалымы күз алдында... Алайса, нинди тавыш соң әле бу? Нинди бәпкә чыелдый анда? Юк, бәпкә дә түгел бу... Кемдер елый ахры... Бала елый! Бала тавышы бит бу! Бала?..

Хәлим үз ачышыннан егылып китә язды. Торып баскан җиреннән кабат сәкегә утырды. Майя...Майя?.. Майя баласы бит бу! Майя белән Хәлимнең газиз баласы! Хәлим куанырга да, көенергә дә белмәде. Нишләп көенсен ди ул... Куанырга кирәк! Аларның газиз балалары бит ул! Майя... Майяның хушлашканда әйткән сүзләрен исенә төшерде Хәлим. "Миндә синең җан күзәнәгең, кан бөртегең, тән кисәгең кала",—дигән иде ул. Бала хакында әйткән бит аның Майясы! Туачак газизләре хакында... Аһ, ничек ул моңа башта ук төшенмәгән...

Хәлим, үзен кая куярга белмичә, бүлмә буйлап арлы-бирле йөренә башлады. Өзелеп-өзелеп Майяны, баласын күрәсе килде. Әмма ул, шул ук вакытта, үз акылы белән берни дә кылырга тиеш түгеллеген аңлый иде. Сихерче карчыклар аның серен белмәскә тиешләр. Белсәләр, бөтен хыяллары, ниятләре челпәрәмә киләчәк. Утар хуҗабикәләренең кереп алуын көтеп утырырга тиеш иде хәзер Хәлим.

Ә бала елады да елады. Ник елый соң ул? Ник юатмыйлар аны? Майя үзе кайда? Әллә, юатып та, бу бала, үзенең кечкенә йөрәге белән,

атасының якында, янында булуын тоямы? Кандаш җаннар бер-берсен тоя ди бит... Әнә ничек өзгәләнеп елый ул...

Хәлим бүлмә стенасыннан тишек-мазар эзли башлады. Юк, бернинди тишек-тәрәзә күренми. Урам якка чыга торган стенада гына, түшәм турысындарак, бер уентык шәйләнә. Яктылык та шуннан керә икән. Хәлим, ишек төбенә куелган ике бүкәннең берсен алып килеп, шуна менеп басты, үрелеп тышка карамакчы булды. Әмма берни күрә алмады.Колагын куеп тыңлады—берни дә ишетмәде. Әллә бер җан иясе дә калмаганмы бу утарда? Яшенә төелеп, җан ачысы белән елап яткан сабый баладан башка...

Хәлим түзә алмады, кендек итен кысып тоткан йодрыгы белән саман диварны төя-төя, идәнгә сыгылып төште, бөтен йөрәк әрнешен, күңел моңын, җан сагышын кушып, сулкылдап елап җибәрде...

## IV

Хәлимне өч көннән соң гына кереп алдылар. Дөрес, бу көннәрдә карчыкларның берсе аның янына кереп-чыгып йөрде. Сөт, икмәк калдырды, су кертте, ишек төбенә лакан чиләге куйды.

Өч көннән соң якты аланга килеп чыккач, Хәлимнең күзләре камашып китте. Хәтта... башы әйләнгәндәй булды, бер мәлгә исен югалта язды. Ишек яңагына тотынып, карашларын җиргә төшерде. Ничек сагындырган бу яктылык, кояш! Хода бәндәсенә кояш кирәк, ул бит кояш баласы, көн баласы. Аннан соң гына төн, караңгылык иярчене...

Күзләре көн яктылыгына ияләшә барган саен, Хәлим кое янында басып торучы хатын-кызны ачыграк шәйләде, торган саен ныграк күзаллый барды. Кояш чагылышы ул хатынның йөз-кыяфәтен аерымачык күрергә ирек бирмәсә дә, шундук искәрде Хәлим: бу—Майя! Аның сөйгәне! Хәләле! Кулында нәрсә соң аның?.. Бала? Хәлим белән Майяның газизе!

Хәлим, үзен-үзе белештермичә, алга омтылгандай итте. Әмма шунда ук үзен кулга алырга өлгерде. Ярамый! Әлегә ярамый. Карчыклар аны сынамакчы гына булалар бит. Шулай да, Хәлимнең Майяга, Майя кулында утырган сабый балага якынрак барасы килде. Бу якынаюдан нидер үзгәрер, дөресрәге, аның йөрәге урынына утырыр, күңеле тынычланыр, җаны сафланыр кебек иде...

Менә ул алга тайпылып китте, коега турылап бара башлады. Майя да, нидер сизенеп, алгарак омтылды бугай. Хәлим моны күрмәде, әмма сизенде. Аларга туры карарга курыкты ул. Тупырдап торган баласына караса, түзә алмас, сабырлыгын җуеп, шул якка ташланыр кебек иде. Менә ул кое буена барып җитте. Майяга җитәргә берничә адым гына калды. Майя үзе дә каршы килә башлады. Әмма ул ялгышты. Очраштык, күрештек дигәндә генә Хәлим кырт борылып кое янындагы ялгашка таба китте. Берни булмагандай, учына тутырып су алып эчте, аннары тыныч кына юына башлады.

Майя түзмәде, бөтен йөрәге, җаны белән:

—Хәлим!..—дип дәште.

Хәлим юынган җиреннән кинәт туктап калды. Менә ул, улак өстенә иелгән җиреннән башын борып, Майя ягына карады. Аннары, борчымагыз әле, дигән кебек, йөзен җыерып куйды да тагын юына башлады. Майя бу хәлне көтмәгән иде булса кирәк, бер кулы белән йөзен каплап, үксеп елап җибәрде дә йөгерә-атлый алачыкка кереп китте.

Хәлим, пошмас кыяфәттә, күңел күзе белән аны ишеккә кадәр озатып калды. Ишек шапылдап ябылу белән, аның болай да җәрәхәтләнеп, телгәләнеп беткән җан-бәгыре яшәешнең әллә кайсы гына караңгы төпкеленә убылып төшеп китте...

Хәлимне ашык-пошык кына ашаттылар да кырга алып киттеләр. Ике карчык артыннан ияргән Хәлим утардагы хәлләрне күздән кичереп, үзенең былтыргы тормышы белән чагыштырып, сынап барды.

Беренче карашка әллә ни үзгәреш күренми. Шул ук ике алачык, бура кое, жиргә сеңгән алачык келәтләр, мал утарлары, амбарлар, яшелчә бакчалары...

Шулвакыт Хәлим ат пошкыруын ишетеп калгандый булды. Әллә Аксаймы? Исәнме ул? Хәлим, карчыклар артыннан барган жайга, тайпылыбрак китте дә лапас, мал утары тирәләрен үрелеп карарга өлгерде. Менә хикмәт: кинәт лапас ишеге шыгырдап ачылып китте дә аның эченнән чаптырып бер ат килеп чыкты. Аксай? Аксай! Хәлим бер мәлгә тукталып калды. Аксай да Хәлимнең кайтуын сизенгән; әнә бит, койрыгын чәнчеп, утар буйлап чабып йөри, ара-тирә Хәлим ягындагы киртә койма янына якын ук килә дә шул киртәләргә арткы тояклары белән шакылдатып тибеп куя. Чыгарга, элекке хужасы янына килеп иркәләнергә, назланырга тели ул. Әмма Хәлим Аксай янына якын бара алмады, чөнки ул бу атны белүен, хәтерләвен карчыкларга сиздерергә тиеш түгел. Шуңа күрә, пошкырынып чабып йөргән атка бераз вакыт карап торды да, битараф кыяфәт чыгарып, ары атлап китте.

Әнә утын әрдәнәләре. Былтыргы утын да шактый калган икән. Әмма быел элеккечә күп итеп әзерли алмаганнар. Ярылып бетмәгән утын түмгәкләре чүмәлә кебек өелеп ята—аларны ярырга телсезләрнең көчләре житмәгән, күрәсең. Хәлим булмаган шул, былтыргы кебек, калын-калын утын кисентеләрен "эһ" тә итми ярып ташларга... Гомумән, утар бер ел эчендә шактый бирешкән. Түбәләр кылкаланган, күп урында киртә-коймалар авып-ватылып беткән. Бакчалар да начар эшкәртелгән... "Бераз булышып алмый булмас",—дип уйлады Хәлим. Ни дисәң дә, теге ике әпә ир дә, ахыр чиктә, сихерче карчыклар да жир бәндәләре бит. Әлбәттә, ул монда озак калырга жыенмый. Майя белән сөйләшеп-аңлашып алгач, беренче жай чыгу белән качып китәчәк. Майясы, баласы белән бергә китәчәк. Иң мөһиме, ул үз акылында, үз хәтерендә. Калганы аның егетлегеннән тора. Тагын... Теге кендек кисентесе генә янда булсын, төрле сихердән, афәттән саклап торсын...

Хәлим түш кесәсендәге төргәкне капшап куйды. Ул алачыкта ябылып яткан чакта ук кендек бөртеген кулъяулыгының бер очына чияләйләп төйнәп куйган иде. Беренче төндә, хәлсез-аңсыз ятканда аның артыш таягы да , күлмәк эченә тегелгән бөти язулары да серле рәвештә юкка чыккан, әмма учындагы кендеге ниндидер тылсым ярдәмендә сакланып калган иде. Әлбәттә, бу төнге тентүнең сихерче карчыклар эше икәнен белә Хәлим. Әмма бу турыда ныклап уйларга шикләнә. "Сихер турында уйласаң, шундук килеп таба ул сине",—ди иде Васимә карчык.

Хәлимнең сүзен жөпләгәндәй, биш-алты адым алдан баручы карчыклар дәррәү борылап карадылар. Хәлимнең йөрәге шау итеп китте, бөтен тәненә суык йөгерде. Әллә сизенделәрме? Майя әйтә иде бит, "уйлаганны да сизәләр", дия иде... Карчыклар кабат кузгалгач кына тынычланды Хәлим. Ул моннан соң сихерчеләр янында Майя хакында, качу хакында, авыл хакында уйламаска үз-үзенә сүз бирде, хәтта, ант иткәндәй: "Әгәр уйласам, якты дөньяны күрмим",—дигән хәтәр сүзләр дә пышылдады.

Ниһаять, алан буйлап үтеп, тар гына аралыктан күршедәге Күкчәчәк болынына чыктылар. Карчыклар Хәлимне печән чабучы әпәләр янына алып баралар икән. Аларны ерактан ук чамалап килде ул. Дөресрәге, ишетеп килде. Чалгы янаган тавышны танымыймы соң! Бераздан әпәләр үзләре дә күренде. Икесе аланның ике башында ашыкмый гына печән чабып йөриләр иде алар. Хәлимне башта үшән, бөкре һәм өрәк кебек кыяфәтсез карт ир ягына алып бардылар. Бермәл карашып торгач, Хәлим баш кагып кына исәнләште. Теге ир дә аңа баш кагып жавап кайтарды. Аннары жыйнаулап чәнтисез әпә ир янына киттеләр. Якынлашкан саен Хәлимнең йөрәге ешрак тибә, аяк буыннары йомшый, калтырана башлады. Аның болай да алжыган, талчыккан жаны тагын бер кысылып, әрнеп куйды. Әтисе бит ул аның! Әнә нинди хәлгә калган ул. Тагын да арыкланган, бетәшкән, бөкрәйгән. Чалгы тотуының да рәте юк. Арыган,

талчыккан кеше генә печәнне шулай килбәтсез рәвештә, бөтен гәүдәсе белән талпынып, алпан-тилпән килеп чаба. Чөнки аның беләк көче, буын көче беткән була.

Гәүдә белән ятып, менә-менә капланып төшәм хәзер, дигән кебек, бөкрәеп эшләп яткан әпә ир аларны башта шәйләмәде, уфылдап, ухылдап печән чабуын белде. Пакусын очлап чыккач, чалгысының сап ягын җиргә янтайтыбырак кадап, кесәсеннән агач саплы кайрагын чыгара башлаган иде, якынаеп килүче кешеләр төркемен күреп, туктап калды.

Хәлим үзен бик тиз кулга алды: әпәне танымаганга салышты. Шулай да, баягы ир белән күрешкәндәге кебек, килә-килешкә башын кагып куйды. Әпә аңа ачык елмаеп җавап бирде. Биленнән бөгелеп, баш иде.

Карчыклар чәнтисез әпә янында озак тормадылар. Нишләптер аның янына бармадылар да: утыз-кырык адымда тукталып, егылган үләнне караштыргандай иттеләр дә кирегә борылдылар. Хәлим дә аларга ияргә мәҗбүр булды. Тагын баягы ир янына килделәр. Карчыкларның берсе, ир кулындагы чалгыны алып Хәлимгә тоттырды да, үзен җитәкләп авыл ягына алып китте. Икенчесе, ымлап-ишарәләп күрсәтә-күрсәтә, Хәлимгә кайсы җирдән чабарга кирәклеген аңлатырга кереште. Аннары аның аңлаганын-аңламаганын да сорап та тормыйча, ашыга-ашыга утарга кайтып китте.

Шулай итеп Хәлим тоткынлыктан чыккан беренче көнендә үк үзенең иң яраткан, төшләренә кереп йөдәткән җирендә—Күкчәчәк аланында пәйда булды. Кем белән диген әле! Үзенең әткәсе белән! Әнә ул—күз күреме җирдә; җилдә тирбәлеп утырган гөлҗимеш куагы кебек, салмак кына селкенгәләп печән чаба... Ни хакта уйлый икән ул хәзер? Таныдымы үзенең газиз баласын? Кайчандыр хатыны көмәнендә яралгы хәледә генә калып, соңыннан, егерме елдан соң, бер ел буе үзе белән яшәгән Хәлимен, улын, нәсел дәвамчысын таныдымы?

Танымагандыр шул. Албасты карчыклар аның да бөтен аң-зиһенен, хис-хәтерен тартып алганнардыр, мәңгелеккә мескен, гарип, мәхлук язмышына дучар иткәннәрдер...

Хәлимнең бу бәхетсез, бичара адәми затка ничек кенә булса да ярдәм итәсе килде. Тик ничек? Әллә? Әллә, янына барып, барысын да сөйләп бирергәме? Үзе хакында, әнисе, авыллары хакында... Аннары килене Майя, оныгы... оныгы... (исеме ничек икән соң аның?) хакында. Нигә бу карчыклардан куркып торырга? Менә хәзер тәвәккәлләп әтисе янына барачак ул. Әнә теге пакусны гына чыгып бетсен дә...

Чәнтисез әпә үзенә таба килүче Хәлимне эшеннән туктап көтеп алды. Әмма каршы килмәде. Алар арасында бер кишәрлек ара калгач, әпәгә әллә нәрсә булды: ул, кеше аңламый торган ямьсез авазлар чыгарып, кычкырып-җикереп җибәрде. Тамак төбеннән чыккан кыргый тавышта бу кешенең бөтен җан ачысы төйнәлгән кебек иде. Менә шул төен чишелеп киткән кебек булды.

Хәлим бермәлгә аптырап, каушап калды. Туктады. Сынап карап тора башлады. Әпәдән бүтән төрле аваз чыкмагач, тагын ике адым атлады. Тегесе, ерткыч җәнлек кебек, тагын үкереп куйды һәм кулына үлән өстендә яткан чалгысын алды. Хәлим аңлап тора: "Тагын да якынрак килсәң, шушы чалгы белән башыңны кисеп төшерәм!"—дип яный иде аңа әткәсе. Нигә алай соң ул? Нигә улын үзенә якын җибәрми? Йөрмә монда вакыт уздырып, бар, эшлә, бәласеннән башаяк, диюеме? Үз улын карчыклар сихереннән саклап, йолып калырга тырышуымы?

Хәлим һич аңлый алмады. Шулай да әпәне үртәмәде, туктаган урынында багана кебек басып калды.

—Саумы, әткәй!..—дип эндәште ул, бераз сулышы тигезләнгәч.

Әпә дәшмәде.

—Әткәй, бу мин—синең улың. Кампәрледә калган Саниянең малае, синең бердәнбер малаең... Бу мин—Хәлим... Әткәй...

Әпә, пыяла күзләре белән Хәлим ягына караган килеш, дәшминитми тора бирде, хәтта, керфек тажларын да кыймылдатмады.

—Әткәй, исендәме—Кам-пәр-ле?.. Са-ни-я?.. Ә?—Ижекләп тә, хәрефләп тә әйтеп карады Хәлим, әмма әткәсенең зиһенен, күңелен уята алмады, ахры, ишеткәнен-ишетмәгәнен, хәтта, аның аңлаганын-аңламаганын да төшенә алмады ул. Бу хәлдән тәмам гаҗиз булган Хәлим тагын бер мәртәбә алга омтылып карады. Әпә тагын чыгырыннан чыгып ярсыды. Башта үзенчә нидер кычкырырга маташты. Аннары тоткан чалгысын читкә атып бәрде, ике кулын алга таба җилпеп, Хәлимне куа башлады. Болай да аңлата алмагач, бичара җан, кабаланып, каударланып чишенергә керешә, башы аша күлмәген салып атты, керләнеп, ямалып беткән ыштанын төшерде.

Хәлим ах итте. Чәнтисез әпәнең бөтен тәне тоташ җәрәхәт иде! Аяк балтырларыннан башлап муен, янак тирәләренә кадәр үлекле шешләр сибелгән, урыны-урыны белән ул шешләрдән эрен яки кан саркып тора...

Шунда гына аңлап алды Хәлим. Әпә аны үз янына шул шешләреннән шикләнеп китерми икән. Хәтәр авыру йоктырырмын дип куркадыр инде, мескен. Карчыкларның якын килмәүләре дә, икенче әпәнең читтәрәк печән чабып йөрүе дә аңлашыла хәзер... Димәк, бу хакта барысына да мәгълүм...

Хәлим нишләргә дә белмәде. Әткәсе тәнендәге шеш-җәрәхәтләр аның үз тәненә күчкән кебек булды, бөтен җире кызышып чыкты, хәтта, кычыта башлады...

—Әткәй, ни булды сиңа?—дип сорый алды ул бераздан.

Әпә, каккан казык кебек, шәрә тәнен күрсәтеп басып торуында булды.

—Әткәй, ник дәшмисең? Ничек ярдәм итим соң сиңа?—дип өзгәләнде Хәлим. Әмма якын барырга кыймады.

Шунда, шеш-җәрәхәтләр белән чорналып, өрәк кебек басып каткан әпәнең уң як күз төбендә бер энҗе ялтырап киткәндәй булды. Әйе-әйе, Хәлим аермачык күрде: энҗе бөртеге балкып китте! Юк ла... Күз яшедер ул... Әйе, күз яше! Җан түреннән тибеп чыккан сыңар күз яше...

Димәк... Димәк, әткәсе аны таныды... Таныды!

—Әткәй!.. Әткәем минем!..—Хәлим, ачыргаланып өзгәләнүен, тетрәнеп ярсуын баса алмыйча, ике учын күкрәгенә кушырып, яңа гына әткәсе чабып ташлаган печән өстенә тезләнде... Аңардан егерме-утыз адымнарда гына, тезләнеп, башын шешле, җәрәхәтле тезләренә бәрәбәрә аның әткәсе сулкылдый иде...

## V

Бу көннәрдә Хәлим бик авыр тойгы белән йөрде: аның өчен газиз булган ике җан иясе дә янәшәдә генә яши, әмма аларның берсе янына да якын барып булмый, дөресрәге, алар аның үзен якын китермиләр. Хәлимне күрү белән Майя читкә тайпыла, яисә бөтенләй дә алачыгына кереп китә. Әткәсе дә Хәлим күзенә күренмәскә тырыша, ул хәзер утар читендәге куышта ялгызы гына яши. Ашны карчыкларның берсе илтә. Шәүлә кебек, шуышып йөргәндәй дәшми-нитми, салмак кына хәрәкәтләнүче бу Хода бәндәсенә хәзер беркем дә игътибар итми, ахры; ул үзе белеп эшли, үзе теләгәнчә йөри, яши...

Бервакыт Хәлим шул куыш тирәсеннән йөреп килмәкче булды. "Хәле ничек? Берәр төрле ярдәм кылып булмасмы?"—дип уйлады. Көндезге авыр эштән соң сызланып, ах-ух килеп ыңгырашып яткан әткәсенең хәлен читтән үк тоеп, белеп, ишетеп килде Хәлим. Ул эчкә керергә уйламады да, өркетермен, унайсыз хәлгә куярмын дип курыкты. Бераз таптанып торды да китү ягына борылды. Шулвакыт куыш эчендәге ыңгырашу авазы аның зиһененә килеп иреште:"Улы-ы-ым-м!.. Улы-ы-

ым-м!" Хәлим, буыннары йомшап, егылып китә язды. "Улым" диме? Әллә берәр сер-сихер галәмәтеме бу? Бик теләсә, кеше үзе ишетергә теләгән сүзне ишетә ала, диләр бит...

Ынгырашу тагын кабатланды: "Улы-ым-м!.."

Хәлим мондый очракта нишләргә кирәклеген белми иде. Шулай да, куышка якынрак килде. Әмма куыш авызы чыбык-чабык белән томаланып куелган иде.

—Әткәй...—дип эндәшеп карады Хәлим. Бер мәлгә куыш эчен үле тынлык басты, аннары үзәккә төшәрлек ыңгырашу тагын кабатланды.

—Әткәй, хәзер мунча ягам, шунда чабып терелтәм мин сине... Бераз гына түз, яме. Мин хәзер киләм,—дип өзгәләнде Хәлим.

Ул утарда мунча ролен үти торган ерак алачыкка—яртылаш җиргә ингән бура йортка йөгерде. Ашыга-ашыга утын юнәтеп, ут дөрләтеп җибәрде, су ташып куйды. Аннары, мунча өлгергәнче янында булыйм, юата алган кадәр юатыйм, хәлен җинеләйтим дип, кабат әткәсе яшәгән куыш янына килде. Әмма ул килгәндә куыш буш иде инде: алдындагы чытырманлык юкка чыккан, эчтә дә җан әсәре күренми. Хәлим моны нәрсәгә юрарга да белмәде, яккан мунчасын да онытты, авыр уйлардан тубал булган башын түбән салындырып, үз торагына кайтып китте...

Майя белән янәшә яшәү Хәлим өчен тагын да газаплырак иде. Карчыклар бу яшь хатынның һәр адымын күзәтеп торалар кебек. Үзләре күзгә күренмиләр. Әмма Хәлим төгәл белә: алар кайдадыр шунда гына, якында гына... Һәр агач кәүсәсендә, шайтан таягы чәчәгендә, бура ярыгында күргәндәй була Хәлим аларның афәт аңкытып торган төпсез, шыксыз күзләрен... Майяга табан ялгыш кына бер адым атласа да, хәзер килеп чыгып өстенә ябырылырлар, үзләренең кара сихерләре белән изалап, харап итәрләр, йә булмаса, аждаһага әверелеп, бөтенләй кабып йотарлар кебек иде.

Бигрәк тә баласы өчен өзгәләнде Хәлим. Менә атнадан артык яши инде, ә сабыен, йөрәк маен бер генә тапкыр да күргәне юк. Ул аның малаймы, кызмы икәнен дә белми, хәтта. Хәер, кем булуындамыни хикмәт. Исән генә булсын, имин генә булсын, үзенеке генә булсын.

Шулай да, бер көнне Хәлимгә баласын кулга тотып карарга җай чыкты. Күкчәчәк аланында печән чабып йөргәндә чалгы канатын югалтты ул. Чапканда чабылган үлән коелып, чәчелеп бетмәсен өчен, чалгы өстенә бау белән тарттырылган агач җайланманы шулай диләр. Янасын эшләү өчен бау да, агач юну өчен пычак-мазар да юк. Хәлим, ике дә уйлап тормыйча, утарга кайтып килергә булды.

Көндезге утар тын. Чиллә эссесеннән бозаулар гына түгел, тавык, үрдәк ише кош-кортлар да ышыкка качып беткәннәр. Бер әрсез урман чыпчыгы гына кое янындагы ялгашта су чәпелдәтеп булаша. Ул да эссегә чыдый алмый күрәсең, шулкадәр дә мавыккан, булдыра алса, су төбенә төшеп утырыр иде, билләһи.

Хәлим үзләре яшәгән алачык янында өстәл кебек ят бер әйбер күреп алды. Өстәл дисәң өстәл түгел, күбрәк ялгашка охшаган, әмма бу ялгаш нишләптер дүрт аяк өстенә утыртылган. Кызыксынуын басып кала алмады, Хәлим шул ялгашка табан берничә адым атлады, үрелеп карады. Җаны белеп тартылган икән—бу бишектә бер сабый бала ята иде. Мыш-мыш килеп, изрәп йоклаган балага карап, онытылып, гаҗәпләнеп күпме торгандыр, хәтерләми, Хәлим берзаман алачык эчендәге кеше тавышларына сискәнеп, айнып китте. Әмма ишектә беркем дә күренмәде.

Әллә бала да үз янында басып торган җанның туган булуын сиздеме? Баштарак, көләргәме-юкмы дигән кебек, тыйнак кына елмаеп куйды, аннары киң итеп көлеп җибәрде. Түзеп тора алмады, Хәлим үзе дә авыз ерды. Соңгы вакытларда беренче мәртәбә елмаюы иде аның. Гомумән, бу елларда елмайганын-көлгәнен хәтерләми ул. Менә—көлә белә икән бит! Шатлануның нәрсә икәнен онытмаган ласа! Сәбәпчесе дә кем диген—үзенең йөрәк парәсе, җан бөртеге—газиз баласы...

Йокы аралаш елмаеп-көлеп яткан бала әтисенен үтә дә төбәп карап торганын сизде, ахрысы, кыймылдап куйды, аннары бөтенләй дә әйләнгәли, тибенә башлады, ак җәймә астындагы аяклары бер-ике мәртәбә җилпенеп уйнап алдылар да: "Менә, әтием, мин нинди, мә, бөтен жиремне күр, кара",—дигән кебек, җәймәне тибеп аттылар. Хәлим алдында, анын бәхет нуры юа башлаган авыр, тирән сагышлы күзләре каршында матур төшләр күреп елмая-елмая бер кыз бала ята иде. Бу жанлы курчакнын бөтен жирен дә шундук яратты Хәлим: әнисенеке төсле кап-кара, бераз көдрәләнеп торган йомшак чәч бөртекләрен дә, әтисенекенә охшаган почык борынын да, алсу алма кебек пешеп өлгергән пар битен дә, алга бүлтәеп чыгып, янәшә яткан пар гөлжимешкә тартым иреннәрен дә, мәхәббәтле иякләрен, оялчан тәнен, матур аякларын, хәтта, төймә кебек тезелеп киткән, берсеннән-берсе кечкенә аяк бармакларын да яратты, үз итте.

Бер генә үкенеч: күзләрен күрмәде. Күзләре нинди икән? Әнкәсенеке кебек, зур, матур микән, әткәсенеке кебек зәнгәр микән?

Шулвакыт бер галәмәт хәл булды: баланын күз кабаклары калтыранып алдылар да киң ачылып киттеләр: алар эченнән күк йөзе кебек саф, ачык якты зәнгәрсу дөнья балкып килеп чыкты... Хәлим, үзе дә сизмәстән, әнә шул сихри, тылсымлы дөньяга кереп чумды. Әмма, исен-аңын җуймады, өстәл-бишеккә үрелеп, сабыйны кулына алды. Соңгы өч елда беренче мәртәбә үзен бәхетле, бик бәхетле итеп тойды ул... Йомшак бишектә йоклап яткан бала кеше кулын шундук тоеп алды, ахры, йөзен чытты, нәни куллары белән борын тирәләрен ышкып куйды, кулларын, аякларын сузып киерелде дә шыңшып елап җибәрде. Хәлим өчен бу көтелмәгән хәл иде. Хәзер нишләргә? Кире куйса да кыен—бишегендә елатып калдырыргамы, кулда калдыру да куркыныч—күреп, ишетеп калулары бар. Хәлим, үзен-үзе белештермичә, әллә каян гына калкып чыккан инстинкт буенча, баланы үз кулында салмак кына тирбәтергә, селкетергә кереште.

—Ә-ә-ә-ә-ә... Ә-ә-ә-ә-ә...

Бала туктарга уйламады да, киресенчә, һаман ачыргаланып елады, ярсыды, хәтта, буылып-буылып, халык әйтмешли, зәңгәргә катып үкси башлады...

—Ы-ы-ы... Ы-ы-ы... Ә-ә-ә-ә-ә...

Шулвакыт бала тавышына алачыктан дәррәү Майя, анын артыннан ук теге ике карчык килеп чыктылар. Майя, бала күтәреп йөргән Хәлимне күргәч, җан тавышы белән кычкырып җибәрде:

—Гөләш! Нишләттеләр сине?! Балакаем!..

Йөгереп килгән уңайга Майя Хәлим кулыннан баласын йолкып алды, аннары, ана артын куеп, чын аналарча сөйләнә-сөйләнә, һаман елаудан туктый алмаган сабыйны тынычландыра башлады.

—Кызым минем... Тиделәрмени... җә инде, житте, житте... Син бит әнкәң белән... И җанашым-гөләшем минем... Җә, тынычлан, тынычлан...

Майя баласын тынычландырып булашкан арада, карчыкларнын берсе йөгерә-атлый Хәлим янына килде, усал күзләре белән бер сөзеп карады да, кискен генә кулыннан эләктереп, мал утарына таба өстерәде. Хәлим тагын бер мәртәбә Майяга, инде тынычлана башлаган һәм анасының күкрәгенә борын төртеп, шыңшып яткан сабыена каерылып карады, аннары, нәрсә булса да булыр дигәндәй, башын аска салындырып, карчык ихтыярына буйсынды.

Бераздан ул үзалдына усал мыгырданып барган җен карчыгын күрми дә, ишетми дә иде инде. Хәлим бу минутта җир йөзендәге ин бәхетле кешеләрнең берсе булгандыр. Ул үз бәгырь итен—газиз баласын табуга ирешге, аны кулына алды, күзләрен, йөзен күрде, бу йөздә таныш чалымнар күрде... Гөләш!.. Нинди матур исем биргән ана Майя. Гөләш!.. Башка беркемдә дә юктыр андый исем. Ә бит, чынлап уйласан, андый бала да, андый язмыш та юктыр бу дөньяда. Булмасын да! Кеше кешеләр арасында туарга тиеш, кешеләр арасында яшәргә тиеш, мәңгелек йортына

да кешеләр арасыннан китәргә тиеш. Гөләш тә кеше баласы, кеше ыруыннан, ул да—кеше бәгыреннән өзелеп төшкән җан бөртеге, тән күзәнәге... Юк, монда калдырмаячак аны Хәлим. Бу урман төпкелендә, албастылар утарында, сихер-зәхмәт дөньясында ул рухи гарип булып, кешеләргә чит-ят, кыргый бер зат булып үсәчәк. Ниндидер тылсымнар ярдәмендә илаһи табигать Майяны саф килеш саклап кала алган, Гөләшкә дә кара урман зәхмәте тимәс дип кем әйтә алыр? Юк-юк... Барыбер алып китәчәк ул үзенең газизләрен! Тизрәк Майя белән очрашу-аңлашу чарасын табарга кирәк! Монда озак калырга ярамый. Югыйсә, Хәлим үзе дә тиздән шушы урман сихеренә бирелә башлаячак, рухи сазлыкка батачак, зәхмәт чокырына убылып төшеп китәчәк... Бернинди кендек тә, тел очында йөргән догалар да саклап кала алмаячак аны...

Хәлим сөенеп куйды: әле ярый догалар хакында исенә төшерде. Соңгы вакытта Ак бабай өйрәткән дога-сүрәләрне бик сирәк кабатлый башлаган икән ул. Бу—күңелсез фал. "Бисмиллаһир-рахмәнир-рахим. Аллаһөммә әнтәс-сәламә вә мин кәс-сәламө тәбәрәкәтә вә тәгаләйтә йа зәлҗаләли вәл-икрам..."

## VI

Хәлим күңеленнән ничек кенә ашкынса да, баласын, Майясын алып, тиз генә качып китә алмады. Урмандагы бөтен кара һәм изге рухларны тетрәндергән бер фаҗига аны тагын кырык көнгә тоткарлап калды. Әмма бу вакыйга аңа Майя белән аңлашырга да ярдәм итте.

Июль аеның басынкы гына киче иде. Малларны җыеп, утарга кертеп яптылар. Бүген бу эшне карт әпә үзе генә башкарды. Карчыкларның берсе ана булышкалап йөрде. Әткәсенең күзгә чалынмавы Хәлим күңелендә шомлы уйлар уятты. Соңгы көннәрдә болай да өстерәлеп кенә йөри иде, әллә бөтенләй егылдымы?

Хәлимнең Аксай белән алып кайткан печәнен абзар артына өеп куясы бар иде, шуңа күрә, бик барасы килсә дә, әткәсе яткан куыш янына бара алмады. "Соныннан урап килермен әле",—дип уйлады ул.

Ләкин Хәлим сонарды. Бу мизгелдә әткәсенең куышына ут капкан иде инде. Аланны сискәндереп, чытыр-чытыр килеп янган коры каен кәүсәләрен әрсезләнеп ялкын ялый башлады, ниһаять әлеге чытырдавык тавыш, тагын да шомлырак янгыраш алып, Хәлимнең колагына, аннары ан-зиһененә килеп иреште. Аның сизгер йөрәге шундук тойды бу бәлане. "Әткәй?! Нәрсә булды?" дип уйларга да өлгерде ул, хәтта. Утар тирәсендә булашкан әпә дә, шунда гына сыер савып йөргән карчык та афәт исен сизделәр, ахры, тышка чыгып, чәнтисез әпә яшәгән куыш ягына карап тора башладылар.

Бу авыр халәттән иң беренче Хәлим айныды. Ул, кулындагы сәнәген бер як читкә атып бәрде дә әткәсе янына йөгерде. Әмма барыбер соңга калды. Куышны тулысынча ут-ялкын каплап алган иде инде.

Хәлим бара-барышка: "Әткәй!"—дип кычкырып җибәрде, янәшәдә яткан бер таякны алып, куыш киртәләрен таратмакчы, сүтмәкче, ут эченнән әтисен аралап алмакчы булды. Әмма янгын ана караганда күпкә көчлерәк иде. Хәлим ут чүмәләсенә өч-дүрт адымга да якын килә алмады. Дөрләгән ут кызуына күзләре шартлар дәрәҗәгә житсә дә, кулларындагы, йөзендәге соңгы төкләргә кадәр көеп бетсә дә, Хәлим ут белән көрәшен туктатмады. Ул моны инде әтисен коткарам дип тә түгел, бәлки, бөтен дөньяга, язмышына ачуыннан, эчке ярсуыннан эшли иде.

Шулвакыт куыш эченнән куркыныч инрәү авазы ишетелде:

—Улы-ы-м-м!... А-а-а!..

Җәй буе кибеп, тимәс борын чыртлап сынып торган каен ботакларыннан корылган куыш соңгы мәртәбә авыр итеп сулыш алды да әлеге ачыргалану авазы өстенә җимерелеп төште. Әпәнең тавышы басылды,

сулышы кысылды, тәне көйде, күрәсен, башкача жанлылык сизелмәде. Бөтен тирә-юньдә ут, бары тик ут кына тантана итә иде. Хәлим, чарасызлыктан нишләргә дә белмичә, эссе бөркеп торган мәһабәт учак алдына тезләнде, аннары, бөтен борчуын йөз җыерчыкларына чыгарып, бераз башын чайкап торды да, авыр кайгысына чыдый алмыйча, чирәм өстенә капланып төште... Аның артыннан килеп җиткән карчык белән әпә ир, бот чабып, ах-ух килеп, учак тирәсендә таптанып йөрделәр дә кабат утарга китеп бардылар. Әпә сөтле чиләк күтәреп кире килгәндә ут-ялкын афәте басылган иде инде. Шуна да карамастан, ул анда-монда калкынып алган ут-ялкын дулкыннарына сөт бөрки башлады. Кара сыер сөте утны баса, дигән халык юрамышын Хәлимнең дә ишеткәне бар. Ләкин соң инде. Хет алтын сыер сөте сипсән дә Хәлимнең әткәсе терелеп чыга алмаячак. Ул, әнә, төтен төчкереп, каралып-зәнгәрләнеп торган кисәүләр өеме астында җан очырып ята...

Хәлим шулай дип уйлап кына бетерде, куыш торган урынның нәкъ үзәк бер җирендә, нindидер утлы кисәү шартлап, шул урыннан елан кебек ялкын теле күтәрелде, ана ияреп, зәнгәр пәрдәгә төренә башлаган күк йөзенә эреле-ваклы очкын-йолдызлар көймәсе менеп китте...

Хәлим бөтен йөрәге, җан-бәгыре аша тойды: шул очкын- йолдызлар белән аның әткәсенең җаны Күккә—Тәнре катына юнәлде. Һәм ул, үзе дә сизмәстән, дога пышылдарга тотынды: "Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Йасин. Вәл-Коръәнил-хәким. Иннәкә ләминәлмөрсәлин. Галә сыйртыйм-мөстәкыйм. Тәнзиләл-газизиррахим. Литөнзирә каүмәм мә өнзирә әбәәүһөм фәһөм гафилүн..." Дога очын югалтмаска тырышып, Хәлим торып басты, аннары акрын гына атлап янгын урынына китте. Бая читкә атып бәргән таягын алып, пыскып яткан кисәүләрне актарырга кереште. Үзе дога пышылдый, үзе актара... Бу вакытта аны берәрсе күрсә, һичшиксез, тилергән, акылдан шашкан бер тиле бәндә дип уйлар иде. "Әләм йарау кәм әһләкнә кабләһөм минәл-коруни әннәһүм иләйһөм лә йаржигун. Вә ин көлләлләммә җәмигөлләдәйнә мөхдарун..."

## VII

Чәнтисез әпәнең янып көйгән мәетен Күкчәчәк аланы уртасында үсеп утыручы япанай карама агачы төбенә күмделәр. Ләхетне җиргә индергәндә утардагы барлык җан иясе килде. Бөтен эшне карт әпә белән Хәлим башкарды. Карчыклар бер читтәрәк, үзләренчә өшкеренә-төчкеренә, ниндидер мәҗүси догалар пышылдап тордылар. Ин артта, күкрәк баласын күкрәгенә кысып, Майя тора. Йөзен-күзен сөрткәләп алуына караганда, ул чәнтисез әпәнең фаҗигасен бик авыр кичерә иде. Шулай да, хатын бу кайгыны үз күнелендә генә кичерә, кешегә күрсәтми —акырып-бакырып та, үксеп елап та йөрми.

Мәет җир куенына индерелеп, кабер өстенә имән казык кадап куелгач, утар ияләре кайтып китте, Хәлим ялгызы торып калды. Ул, кыйбла якны чамалап, кабер читенә чүгәләде дә белгән догаларын укый башлады. Озак укыды. Хәтеренә уелып калган Коръән сүзләре беткәч, тагын бер мәртәбә кабатлап укыды, тагын, тагын... Күпме күбрәк укыса, әткәсенең җаны ахирәттә шулкадәр әйбәтрәк урнашыр кебек тоелды ана.

Үзе дога кабатлый, үзе уйлана Хәлим: "Кемгә кирәк булды икән әткәсенең үлеме? Карчыклargамы? Теге карт әпәгәме? Алай дисән, янгын чыкканда әпә дә, карчыклар да абзар тирәсендә булашалар иде... Әллә?.. Әллә үзен-үзе яндырып харап иттеме бу Хода бәндәсе? Авырту-ыңгырашу-ларына түзә алмыйча яисә башкаларга хәтәр афәт, зәхмәтле чир йоктырырга теләмичә үзенә ут төрттеме?"

Хәлим өчен болар сер булып калды. Ахыр чиктә, бу мөһим дә түгел иде. Әткәсе болай да тере мәет кебек яши иде инде. Китеп котылуы әйбәтрәктер дә... Тик менә болай китмәскә иде ана. Бәлки, берәр төрле

дәва табарлар иде... Тәкъдирне узып язмыш бавын кисү—ай-һай зур гөнаһ бит...

Хәлим, үзен кая куярга белмичә, ары бәрелде, бире сугылды, аннары Күкчәчәк аланы куенында тибеп ятучы чишмә төбенә барып утырды да, башын тез өстенә куеп, уйга калды. Уйга калды дип... Анын бу минутта уйларлык хәле-егәре юк иде. Теләге дә юк. Күнел елгасыннан ургылып аккан уй-хис ташкынын әйдәп барырлык, аны бер тәртипкә салырлык ярларның тәмам ишелеп беткән чагы... Йөрәгенең бер чите генә әрнепсызлап торган кебек. Бу әрнеш бер көчәя, бер басыла, бер көчәя, бер басыла...

Хәлимнең күнел офыгында бер-бер артлы әрнүле күренешләр калыкты. Җансыз, телсез бу манзараны төш дип тә, хыял-уйдырма дип тә, хатирә дип тә әйтеп булмас иде. Әнә—анын балачагы. Ат өстендәге бу чая малай—ул үзе... Янышнан әткәсе бара... Әнкәсе казлар куа... Нәфисә! Ул елый... Әллә көләме? Менә ул кинәт бер карчыкка әверелә дә, күзләрен акайтып, Хәлимгә килә башлый. Ат өркеп китә, Хәлим җиргә егылып төшә, әткәсе белән әнкәсе аның янына йөгереп киләләр... Аны торгызалар, җәрәхәтен имлиләр, башыннан, аркасыннан сөеп-иркәләп юаталар...

Хәлим кулбашында кемнендер кулын тоеп, сискәнеп китте һәм, алга тайпылып, торып басты. Анын каршында, күк-зәңгәр күзләре белән йотардай булып, Майясы басып тора иде.

—Майя?

—Хәлим...

—Майя, әткәй үлде бит...

—Беләм, Хәлим...

—Майя!..

—Хәлим!..

Шулай берничә сүз белән ымлашып алганнан соң, үз-үзләрен белештермичә, алар, ниһаять, аңнарына килеп, бер-берсенең кочагына ташландылар. Мәнгелеккә береккән кебек, аерылышып китә алмыйча, өзелеп сагынышкан йөрәкләре белән генә аралашып, аңлашып, бик озак тордылар. Майя, дымлы йөзен Хәлимнең кулбашына салган да, күзләрен йомып, сихри, хыялый дөньяга киткән. Хәлим исә уяу, бик уяу. Чөнки ул моның төш кенә булуыннан, күзен йомып алса да бу бәхетле күренешнең юкка чыгуыннан, тагын Майясын югалтудан курка. Бу сихри тынлыкны беренче булып Хәлим бозды:

—Әбиләр кайда? Килеп чыксалар...

—Тиз генә килмәячәкләр. Алар хәзер үз ояларында өшкеренеп утыралар. Әткәнненң рухына үзләренчә дога укыйлар... И Хәлим... Хәлимем минем... Ничек көттем мин сине!..—Майя, Хәлимгә сарылып, иркәләнеп сырпалана башлады, үзе исә бертуктаусыз аны үпте, назлады...

—Менә—килдем бит...

—Нигә шулкадәр озак килдең, Хәлим? Үлә яздым бит. Балам булмаса, сагынып үлә идем мин...

—Бала... Безнең балабыз... Мен-мен рәхмәтләр сина анын өчен, хәләлем минем.—Хәлим дә, Майясын кысып кочып, анын дымлы чигәләреннән, алсу йөзеннән шашып үбә башлады. Үзе һаман сөйләнүендә булды.—Беләсеңме, син мине бәхетле иттең, минем бит кызым бар, хатыным бар... Мин шундый бәхетле!..

—Гөләш анын исеме...

—Беләм, беләм, Майя! Гөләш! Нинди матур исем кушкансың син аңа!

Хәлим кинәт айнып киткәндәй булды, житди генә сорап куйды:

—Ник син миннән качып йөрдең, Майя? Мина шундый авыр иде...

—Ә үзең соң, үзең... Беренче көнне үк йөз чөереп киттең...

—Шулай кирәк иде, Майя. Мине бит әбиләрең гел сынап тордылар. Ул вакытта сине танысам, бүген бу урында басып та тормаган булыр идем.

—Ә мин чынлап та сиңа сихер кагылган дип уйладым. Әбиләр башта синең хакта икеләнсәләр дә, соныннан үзләре дә ышандылар бугай. Син аларны җиндең, Хәлим. Ничек булдыра алдың моны? Көч каян алдың?

—Кендектән, Майя. Син үзең минем арттан: "Учыңа кендегенне кысып кил",—дип әйтеп калган идең бит, хәтерлисеңме?

—Әйе шул, артык хикмәтле бу дөнья. Рухлар дөньясы, күнел дөньясы тагын да серлерәк, хикмәтлерәк...

Бераз сүзсез тордылар. Сөйләшкән сүзләрен тәртипкә салып бетерәсе бар иде шул аларның.

—Майя!—сүзне тагын Хәлим башлады.

—Әү...

—Әткәм хакында кайдан белдең?

—Син киткәч, мин бу кешенең сихерен җиңеләйттем. Зиһенен каплап торган сихер пәрдәсен күтәрдем. Ул шунда ук сине исенә төшерде һәм: "Улым!"—диде. Телен кайтара алмадым, әмма шушы сүзне ул гел әйтә иде...

—Ә чире? Каян эләккән аңа мондый хәтәр чир?

—Анысы әбиләр эше... Соңгы вакытта аларга баш бирмәде... Үзе мескен, үзе горур иде...

—Майя, ә ничек белдең минем үз акылымда, үз хәтеремдә булуымны?

—Бала янына килүеңнән үк сизенә башлаган идем. Бүген инанып җиттем. Сихергә юлыккан кеше болай өзгәләнми...

—Әбиләрең сизмәдеме соң?

—Сизделәр, Хәлим. Алар хәзер нык шикләнәләр. Сиңа барыбер монда озак калырга ярамый. Алар барыбер сине фаш итәчәк. Кендек көче—вакытлы гына. Ул көчне синең хисең җиңәчәк. Ә күнел хисен карчыклар бик тиз сихер белән каплап куячак... Хис кешенен Рухын йомшарта, аны көчсез итә.

—Майя, мин бит сезне алырга килдем.

—Беләм, Хәлим... Әмма бу мөмкин түгел.

—Мөмкин, Майя, мөмкин! Минем кендек тылсымым белән китәбез, менә үзең күрерсең...

—И Хәлим... Һаман шул беркатлы син. Ул бит сине генә саклый. Ул бит синең кендек. Безне кем саклар, кем яклар, ә, Хәлим?

—Анысы шулай да... Ләкин мин сездән башка беркая да китмим! Мәңгегә шушында калам.

—Алай димә, Хәлим. Син бит кешеләр арасында яшәү өчен тугансың...

—Ә син? Син соң кем, Майя?

—Белмим, Хәлим...

—Син дә кеше бит, ке-ше! Кызыбыз да—ке-ше! Без барыбыз да—ке-ше-ләр! Без монда калырга тиеш түгел! Майя!..

—Тик нишләргә соң, Хәлим?

—Җаен табарга кирәк, бәгърем. Сихер-зәхмәтне җиңәр көч бар ул. Мин моңа ышанам. Аллаһы тәгаләгә ышанам. Ул безне ташламаячак, Майя...

—Сезнең аллагыз әйбәт, Хәлим. Ул кешенең рухын сындырмый, аның күнелен богаулап, зиһенен томалап куймый... Мин бу карчыклар сихереннән шундый туйдым...

—Барыбер бер җаен табачакмын, Майя. Син белеп тор. Көтеп тор. Ә хәзер бар, кайт инде, карчыклар югалткандыр...

—Әйе шул...

Алар теләмичә генә аерылыштылар. Аерылып киткәч тә, Майя, кабат килеп, бер тән, бер җан булып Хәлимнең түшенә сарылды. Тагын бераз вакыт сыенышып тордылар. Аннары икесе ике якка китеп бардылар.

## VIII

Ике ятим жанның теләгән Ходай тәгалә ишетте булса кирәк. Ниһаять, көннәрдән бер көнне бу албастылар утарыннан качу өчен җай чыкты. Ә анынчы, өч атна буе Хәлим, ике карчык ихтыярына буйсынып, тугры кол кебек хезмәт итте—иртәнге таңнан алып кара төнгә кадәр эшләде, бөтен хуҗалыкны үз җилкәсендә сөйрәп барды. Берничә көн утын хәзерләгәннән соң, яландагы печән чүмәләләрен алып кайтып өйде, аннары бакчадагы чөгендер, бәрәңге ише үсентеләрнең төбен йомшартты. Ике-өч көн эчендә басудагы борчакны егып, бераз киптергәннән соң, суктырып өчен түбә астына ташып куйды. Хәлим үзенең серен беркемгә дә сиздермәде. Баштарак шикләнеберәк йөргән карчыклар, ниһаять, тынычландылар, Хәлим дә үз артында җан көйдереп калган утлы карашларны тоймый башлады.

Майя белән дә башкача күрешеп сөйләшә алмады ул. Ерактан гына күреп кала да күнеле җилкенә башлый. Әмма янына барырга кыймый, карчыклардан шикләнә. Болай да, очрашкан саен, күзләрен акайтып, сөзәрдәй булып карап китәләр. Кечке ашны да карчыклар әзерли. Майя үз бүлмәсендә бала карап кына яши. Сирәк кенә урманга җиләккә кереп чыга. Алачыкның аргы башыннан килгән җиләк исе генә (киптерер өчен киң тактага таратып куя аны Майя) шул хакта хәбәр җибәреп тора.

Менә шулай тыныч кына яшәп яткан көннәрдә, челләнең иң кызган бер мәлендә, уйламаганда-көтмәгәндә, әллә каян яшенле яңгыр килеп чыкты. Югыйсә, яңгыр булыр кебек тә түгел иде. Күк йөзендә болытның әсәре дә юк, һава коры, саф, кошлар биектә—Күк катында ук канат кагына. Күкчәчәк аланлыгындагы чишмә дә агышын үзгәртмәгән—салмак кына талпына-талпына агып ята...

Яңгыр көпә-көндез башланды. Әллә каян гына килеп чыкты ул кара болыт. Аның янына икенчесе, өченчесе өстәлде. Бераздан тонык кына гөрелте тавышы ишетелде... Каф таулары артыннан, юк, җирнең читеннән үк инрәп ишетелгән бу тавыш, бик тиз көчәеп, ярты сәгать эчендә шәһәрләр-кальгалар кырылуны, мәһабәт таулар җимерелүне хәтерләтеп якынлаша башлады.

Әллә каян гына җил килеп чыкты. Ул да, күктәге гөрелте тавышына тәнгәл рәвештә көчәя барып, урман эченә яшеренгән кечкенә аланлыкта хәтәр давыл уйната башлады, бераздан шомлы, сихри гарасат өермәсе куптарды.

Ниһаять яңгырга да чират житте. Беренче тамчы уң як чигәсенә килеп кунуга, Хәлим дертләп, хәтта чирканып куйды. Аның бөтен тәне җыерылып, җаны кысылып киткәндәй булды. Ниндидер хәтәр афәттән качкан кебек, сәнәген лапас эченә атты да алачыкка йөгерде. Караңгы бүлмәсенә кайтып кергәндә тышта коеп яңгыр ява башлаган иде инде.

"Хәзер Майя кайда икән? Баласы кайда икән?"—Хәлимнең башыннан шул уй китмәде. Урманда гына калмасын иде. Яшь аналарга аеруча ияләшүчән була диләр бит яшенне. Әнә ничек ялтырый ул, әнә ничек дер селкетә галәм арбасын; хәтта Җир кучәре дә, менә сынам, менә сынам дип, бөгелеп-сыгылып куя кебек.

Бөтен җәйгә бер генә була торган яшенле яңгыр шулай башланды. Андый яңгырлар берничә көн бара, аларда ниндидер үзгә, галәми, илаһи тылсым, хәтта, сихер була. Кешеләр бу хакта бик белмиләр, ә бит күп язмышлар шушы яңгыр вакытында хәл ителә. Чөнки бу яңгыр—Тәңренең Җиргә төшүе, кешеләр тормышына багып, андагы яманлыкның күбәя баруы өчен сыкрануы, үзенең илаһи ихтыяры белән, кешеләргә изге кануннар индерүе, гөнаһлы җирдә хакыйкать урнаштыруы...

Хәлим белә: бу—картлар сүзе генә. Әмма моңа бөтен җаны- күнеле, акылы белән ышанасы, хәтта, инанасы килә аның.

"Майя кайда икән соң?"—Хәлим тагын шул уйга әйләнеп кайтты. Бер мәл тәрәзә тишеге янында таптанып торды да, чыгып карап керергә

булды. Ишек төбендә эленеп торган кәжәнен ябынып, тышка ашыкты.

Бөтен дөнья карангыланып калган. Ара-тирә балкып алган яшен яктысында тоташ дивар булып янгыр ява. Хәлим, башын иеп, шул дивар эченә кереп китте. Карчыклар белән Майя яшәгән якка чыгып, тәрәзә тишеге янына килде, колагын куеп тынлап карады. Карчыклар өйдә. Аларнын козгын тавышларын берни белән дә бутап булмый. Әһә! Менә бала тавышы... Ә Майя кайда? Күпме генә тынлап торса да, Майянын тавышын ишетә алмады Хәлим. Димәк, кайтмаган әле. Ул, ике дә уйлап тормыйча, сукмак буйлап урман авызына табан китте. Карана-карана бара торгач, хәтсез киткән булып чыкты. Кирегә юлны югалтып, шактый әйләнгәләп йөрде, киеме сонгы жебенә кадәр чыланды.

Берничә сәгать янгыр астында йөргән Хәлимне карчыклар табып алмаса, нишләр иде икән ул. Бу юлы да “качкан” дип уйладылар, ахры, этә-төртә алып кайттылар да алачыкнын бер тар бүлмәсенә кертеп бикләделәр. Шулай итеп, Хәлим тагы ябулы калды. Юеш киемнәрен стена буена сузылган бауга элеп куйгач, такта сәкегә сузылып ятты ул.

Тышта янгыр көчәйгәннән-көчәя бара, күкрәү тавышлары тагын да шомлырак, куркынычрак янгыраган кебек. Төн буе яуды янгыр, икенче көнне көн буе, кич буе яуды. Хәлимне чыгармадылар. Көндезге якта бер мәртәбә ипи белән су кертеп куйдылар да оныттылар. Хәлимгә бөтенләй ямансу булып китте. Анын чын-чынлап елыйсы килде... Берничә минуттан ул, чарасызлыктан, көчсезлектән гажиз булган жан-бәгырен куенына кысып, дымлана башлаган керфекләрен дә сөртмичә, такта сәкегә чалкан яткан килеш, тирән йокыга талды.

Төн уртасында нindидер үтә дә көчле, шомлы күкрәү-шартлау тавышына уянып китте Хәлим. Сикереп торып утырды. Алачыкны яшен сукты, дип уйлады башта. Юктыр, алачыкка тисә, болай утыра алыр иде микән? Тик нәрсәдер булды монда. Хәлим шулай уйлап кына куйды, тагын нindидер шартлау тавышы, колагыннан кереп, бөтен жан-бәгырен ярып-янгыратып, табанына кадәр төшеп китте...

Бу юлы инде төгәл белә: якында гына нindидер каралты жимерелеп төште. Абзарларны гына сукмаса ярар иде. Аксае ни хәлдә икән? Бу янгыр дәрьясында карт әпә малларны жыя алды микән?

Ни хикмәт, баягы каты күкрәү сонгысы булып чыкты. Төн уртасында бөтен жир өстен дер селкеткән шартлау авазы—Тәнренен кешеләргә әйтер сонгы сүзе иде, ахры. Хәлим алачыкнын калын стеналары аша да сизеп тора: дөнья, табигать, күк йөзе тынычланып калды, янгыр басыла төште, жил-давыл урман эченә кереп посты...

Чыкылдап ачылган келә тавышына уянып китте Хәлим. Торып утырды. Такта сәкедә ятып, бөтен тәне сызлый... Шулай да сер бирмәде. Бөтен тән егәрен, рух ныклыгын туплап, карчыклар белән очрашуга әзерләнде. Тиз генә түш кесәсендәге кендеген алып, учына кысты. “И Ходаем, Тәнрем, әгәр булсан, сакла мине бу явызлардан, балам хакы өчен сакла!..”—дип уйлап та өлгерде хәтта.

Шулвакыт бүлмә ишеге шыгырдап ачылып китте һәм аннан, кем дисезме, Майя килеп керде. Бик борчулы иде анын йөзе. Бу төндә бер тамчы да күз йоммаганлыгы әллә каян күренеп тора. Әллә... Майя түгелме бу? Майя кыяфәтенә кереп, Хәлимне юри сынау өчен, теге карчыкларнын берсе килгәнме?

Хәлим, үзен-үзе белештермичә, артка табан чигенә башлады. Бераздан гына, тын-сулышын көйләп:

—Син кем?—дип сорый алды.

—Хәлим, әллә мине танымыйсын инде?

—Майя, чынлап та синме бу?

—Мин, Хәлим, мин булмый кем булсын. Уф!.. Әбиләр бер-бер хәл кылдымы дип котым очты.

—Майя, курыкмыйча ничек керә алдын монда? Күреп калсалар...

—Күрә алмыйлар инде алар. Бик хәтәр авыру—зәхмәт чире екты

аларны. Яшен зәхмәте. Сихер-догалары да коткара алмады.

—Ничек инде? Сихерчеләрне дә сихер ега аламы?

—Алмыйча ни! Күктәге баш Алла иң хәтәр сихердән дә көчлерәк бит. Менә шул Күк алласының ачуы килеп иреште әбиләргә. Иң элек кырдагы тупыл агачын бәрде, аннары сихер алачыгын яндырды.

—Ә? Теге зәхмәт оясынмы?

—Әйе, утарга бүген Күк каргышы төште. Ярый әле йортыбызны сукмады...

— Әбиләр ни хәлдә соң? Исәнме алар?

—Исәнлеккә исән дә... Әмма тиз генә аякка баса алмаслар, ахры. Икесе дә түшәктә. Аң-зиһеннәре таза, телләре дә бар, әмма буыннары юк. Тәннәре ут кебек, тән буе янып-кызышып чыктылар...

Шулвакыт Хәлимнең уянып кына килгән зиһенендә бер уй яктырып китте: "Качарга җай чыкты бит!"

—Майя, әйдә качабыз!

—Ә? Нәрсә сөйлисең син, Хәлим? Әбиләрне түшәктә калдырып ничек китим инде мин?

—Әллә шуларны кызганасыңмы? Күпме явызлык кылдылар бит алар безгә.

—Явызлыкка каршы явызлык дөрес түгел, Хәлим. Үзең бар, кит. Ә мин китә алмыйм. Күрә торып әбиләрне ачы газапка, аянычлы үлемгә дучар итә алмыйм. Алар бит мине табып алганнар, үстергәннәр, үзләренчә тәрбияләргә тырышканнар...

—Шул албастылар әткәмне харап иттеләр, мине бәхетемнән аерырга теләделәр... Юк, мин аларны бер тамчы да кызганмыйм, теләсәм дә кызгана алмыйм!..

—Кайчакта мин дә аларны күрәлмыйм. Әмма без бит кешеләр. Сихер-зәхмәт ияләре түгел. Без акыллырак, мәрхәмәтлерәк булырга тиештер. Ә, Хәлим?..

— Бәлки, син хаклыдыр да... Майя, кил әле, бер кочаклап сөйим әле үзеңне. Беркемнән курыкмыйча, шикләнмичә сөйим әле. Ничек сагындым мин сине!..

—Хәлим бер әйбер хакында сорасам, ачуланмыйсыңмы?

—Сора, Майя, сора... Нишләп ачуланыйм ди мин...

—Хәлим... Минем синең белән йоклыйсым килә. Ир белән хатын кебек...

—И Майя, бу хакта сорыйлар димени?! Бу бит Ходай тәгалә ихтыяры. Кил монда, мин дә сине өзелеп яратырга телим...

—Хәлим...

## IX

Сихерче карчыкларның авыруы көчле иде. Алар буынсыз-егәрсез булып бер атна чамасы яттылар. Бу атна эчендә Хәлим аеруча тырышып, бөтен көч-куәтен салып эшләде. Чөнки вакыт бик тар иде. Карчыклар аз-маз йөри башлауга, Майясы белән Гөләшен алып, авылга кайтып китәчәк. Аңа кадәр утарда кыш чыгарлык утын, азык-төлек, ит-мазар әзерләп калдырырга кирәк.

Җыелган борчакны суктырып, ашлык абзарына салгач та ауга чыгып китте ул. Юлы унды: капкынга берничә кабан дуңгызы эләккән иде. Соңыннан итләрен, тозлап, какларга элде. Сыер суйдылар. Бер сыер, бер бозау гына калдырып, әпәгә эшне җинеләйттеләр. Бу әпәнең үзенә алачыктан бүлмә бирделәр. Аныңчы Хәлим аны әйбәтләп мунчада юындырды.

Яшен суккан агач кыр уртасында ыржаеп тора иде. Хәлим шунда ук чокыр казып, анын кара корымга буялган кәүсәсен турап күмеп куйды. Зәхмәт оясын да, күнелгә шом салып тормасын өчен, җир астына яшерергә булды ул. Янган алачык кисәүләрен дә җир куенына индерде.

Өстенә утын әрдәнәләре өяргә дә иренмәде.

Шушы бер атна эчендә Хәлим утарга чын хуҗа булып алган иде. Майя, тугры хатын кебек, ире тирәсендә бөтерелде, аның һәр әйткәнен җиренә җиткезеп үтәп торды. Тегесен, монысын китерде, анда-монда йөгерде.

Алар хәзер өчесе бергә торалар. Бергә йоклыйлар, бергә ашыйлар. Чын гаилә кебек, чөкер-чөкер килеп, кич утыралар, газиз балалары тирәсендә мәш киләләр...

Бер атнадан авыру карчыклар стенага тотынып йөри башладылар. Әмма алар әлегә бик хәлсез иде. Зәхмәти сихерләрен җибәрерлек кенә түгел, керфекләрен күтәреп карарлык, авызларын ачып сүз әйтерлек тә хәл-егәрләре кайтмаган иде әле аларның. Ә күзләрендәге усаллык, явызлык—шул килеш! Әгәр булдыра алсалар—сикереп торырлар иде дә Хәлимне, Майяны төпсез зәхмәт чокырына ташларлар иде...

Моны Хәлим дә, Майя да сизенә. Хәтта, төгәл беләләр: карчыклар үзләренә хәл керү белән, сөяк-санакларын җыеп йөри башлау белән, рухи егәрләрен кайтару белән, иң элек Хәлимгә ташланачаклар... Шуңа күрә монда озак калырга ярамый. Тагын бер көн генә торыйк, тагын бер төн генә куныйк дип яши торгач, тагын өч көн үтеп киткән әнә. Карчыклар да үз-үзләрен белерлек хәлгә килделәр, тирә-якка мут карап йөри башладылар. Тизрәк ычкынырга кирәк моннан! Бүген үк китәргә!

Хәлим киту сәгате сукканын аңлады. Бу хакта Майяга әйтте. Майя бер сүз дә эндәшмәде. Димәк, риза. Аңа кыен икәнен аңлый Хәлим. Ул бит шушы аланнан, шушы утардан башка һични күрмәгән бер гөнаһсыз адәм баласы. Бөтен төбен-тамырың белән берегеп, озак еллар яшәгән төбәгеңнән, Ак бабай әйтмешли, үткән гомереңнән кубарылу рәхәт түгелдер шул.

Өчәүләп әткәләренең каберен карап килделәр. Хәлим, бер почмакка чүгеп, дога укый башлады. Майя, гомерендә беренче мәртәбә, кулын кушырып, үзалдына теләкләр теләп утырды. Янда гына, чирәм өстенә түшәлгән җәймәдә, балалары ята. Ул да нидер мыгырдана, сөйләнә, башын калкыткандай итә, торып китмәкче була. Әйе, нәсел дәвам итә. Аның бер очы җир куенында калган, икенче очы, әнә, тормышка яңа калкып килә...

Хәлим, Коръән телендәге догаларын укып бетереп, әтисенә үз телендә эндәште:

—Әткәй, без китәбез инде. Ачуланма, кырыгыңны көтә алмадык. Тыныч йокла. Гомер буе тынгысыз тормышта, зәхмәт чокырында иза чиктең, хәзер булса да тыныч яшә, җәннәт дөньясының бөтен рәхәтләрен күр. Рухыңны кайтарып тор, без аңа мәрхәмәт күрсәтербез, игелекләр кылырбыз... Хуш, әткәй...

—Хуш, әткәй,—монысын Майя әйтте.

—Онытма безне...

—Онытма...

—Ходай кушса, бер күрешербез...

—Күрешербез...

Шунда гына алар янәшәдә пәйда булган карт әпәне күреп алдылар. Тегесе, гаепле кеше кебек, алар артында бер мескен кыяфәттә басып тора иде. Иң гаҗәбе шул: аның моңсыз, җансыз күзләрендә мөлдерәмә яшь. Гомер буе сихер тоткынлыгында яшәгән бу бичара җан әллә берәр нәрсә сизенәме?

Хәлим, салмак кына кузгалып, әпә янына барды, иң якын кешесен сөйгән кебек итеп, аркасыннан кагып куйды. Аннары алачыкка төбәп китте. Аңа баласын күкрәгенә кыскан Майя иярде. Әпә кузгалмады. Хәлимнәр үр артына төшеп югалганда да шунда басып тора иде әле ул.

Ниһаять, җыенып беттеләр. Юлга икмәк-сөт төйнәделәр, алмаш киемнәр алдылар. Баланы аркага асып бару өчен, баулы әрҗә әмәлләделәр. Юлның озын, авыр буласын белә Хәлим. Шуңа күрә дә җентекләп, бөртекләп әзерләнде.

Майя, карчыклар белән саубуллашу өчен, соңгы тапкыр алачыкка кереп китте. Озак торды ул анда. Хәлим күңеленә шик керде: әллә тагын карчыклар сихеренә юлыктымы? Нигә болай озак тора? Ник чыкмый? Әнә бит—Гөләш тә тынгысызлана башлады. Әллә ул да берәр нәрсә сизенәме? Их, Майя...

Үзе керергә уйлаган иде, аның каршына йөгерә-атлый Майя килеп чыкты.

—Нәрсә булды, Майя? Ник озак тордың?

—Әбиләр пыр тузына. Әмма берни эшли алмыйлар—көчләре азрак. Шулай да, тизрәк китәргә кирәк, югыйсә аларның сихере безне куып житәчәк.

Соңгы мәртәбә аланга, утарга күтәрелеп карадылар да юлга кузгалдылар. Урманга керә-керә Хәлим иркен сулап куйды—ниһаять, котылдылар! Ул кинәт Майяга күтәрелеп карады: аның күзләре яшьле иде. Хәлим дәшмәде. Юатмады да. Әйдә, еласын. Ачы яшьләрен шушы зәхмәтле урманда калдырсын, яшь бөртеге белән бергә бөтен күңел ачысы, җан сагышы, йөрәк әрнеше тамып төшә диләр бит.

Майя—урман кызы. Аны урман сәфәре белән аптырата алмыйсың. Шулай да, берничә сәгать барганнан соң, утырып хәл алырга булдылар. Майя, Гөләшне имезеп алгач, куак ботакларыннан бишек ясап, бер агач төбенә салды, үзе, яфраклардан җилпуч әмәлләп, чебен-черки куып тора башлады. Хәлим дә, бер усакка аркасын терәп, аягын алга сузып җибәрде. Күзләрен йомды. Урман тавышына колак салды. Бигрәк тә бер кош аның игътибарын җәлеп итте. Бу бит урман тургае! Табигатьтәге иң серле кошларның берсе. Иң уңган, иң түземле, иң моңлы кош ул...

Ә бит бу кош җылы яклардан иң беренчеләрдән булып кайта. Кыш әле калын тунын салмаган, ә урман тургаеның тавышы чишмәдәй челтери башлый инде. Ул үзе сабан тургаена охшаган, әмма аннан кечерәк, ә башында коңгырт түбәтәе була. "Анысы илаһилык билгесе",—ди иде Ак бабай. Иң кызыгы: җәйге төннәрдә урман тургаен, урман кошы булса да, агач башында күрә алмассың. Ул бу вакытта ак болытлар янында. Табигатькә мәдхия җырлап оча. Ә көндезен җыр өчен вакытлары калмый бу кошларның. Көн буе алар бала тәрбияләү белән мәшгульләр. Шуңа күрә күк йөзенә кичкә табан гына күтәреләләр. Аларның җырлары да бишек җырын хәтерләтә. Әнә бит: "Әллү—лү—лү... Лү—лү—ли—ли..." Татарда да нәкъ шулай : "Әллү—бәллү—лү..." Гөләш тә ишетә бу җырны.Әнә ничек изрәп йоклый ул. Майя да оеп киткән... Башын каен кәүсәсенә терәп, онытылып йоклап утыра. Тукта! Күпме утырганнар соң алар монда? Кузгалырга кирәк. Урман тургае күккә менгән, димәк, тиздән караңгы төшәчәк.

Хәлим торып басмакчы булды. Тик ниндидер көч, янындагы усак агачына бәйләп куйган кебек, җибәрми тотып тора иде аны. Әллә?.. Әллә тагын сихер үтә башлаганмы аларга? Ничек тә ычкынырга кирәк бу каргалган урманнан!

Түш кесәсендәге кендеге урынында иде. Хәлим аны учына алып, сак кына кыскалап карады. Кабат урынына салып куйды. Аннары Майяны уятырга кереште. Әмма Майя тиз генә уянмады. Хәлимнең куркынып эндәшкән тавышына иң элек Гөләш уянды. Елый башлады. Хәлим нишләргә дә белмәде. Баланы юатыргамы, әллә Майяны уятыргамы? Тезендә йөреп, анда омтылды, монда омтылды, ни кызын тынычландыра алмады, ни Майяны аңына китерә алмады. Шулай да, кызының үксеп елавын ишетеп, Майя күзләрен ачты, тирә-ягына каранды, башын тотты.

—Ни бу, Хәлим? Башым әйләнә? Нигә елый бу бала? Кем баласы ул?

—Майя, әйдә, тор тизрәк. Киттек. Югыйсә харап булабыз...

Тиз-тиз генә җыендылар да тагын кузгалдылар. Исерек кеше кебек айкалып-чайкалып барган Майяга Гөләшне бирергә курыкты Хәлим. Бөтен булган төенчекләрен дә, баланы да берүзе күтәреп алга ашыкты.

Майя чак-чак ияреп бара. Ул һаман анына кайтып житмәгән, хәле-егәре дә соңгы көрчегендә... Ләкин туктарга ярамый. Майя моны гына аңларлык. Бу зәхмәтле урыннан ничек тә читкәрәк китәргә кирәк. Юлга, тормышка, кешеләргә якынаерга кирәк!

## X

Алар юлга килеп чыкканда, күк йөзен төн пәрдәсе томалап бетерә язган иде инде. Ниндидер хәвеф-хәтәрдән качкан кебек, йөгерә-атлый килеп менделәр алар юл өстенә... Майя урман зәхмәте шаукымыннан шактый айнып өлгергән, ә Хәлим, киресенчә, ару-талудан бераз мингерәүләнә башлаган иде. Ул юл өстенә менгәч тә як-ягына каранып алды, басып торган урынында ук такыр асфальт өстенә тезләнде, шул тезләнгән килеш, тоенчекләрен куйды, аркасындагы әржәсен чишеп ташлады. Чирәмлектә йомшаграк та, унайрак та иде, әмма Хәлимгә, юл читенә чыга калса, бу урман кабат суырып-тартып алыр кебек тоелды.

Майя белән дә сәер хәл. Ул, гомерендә беренче мәртәбә таш юл күргән кеше кебек, исе-акылы китеп аяк астына карап торды, аннары, баласын кочаклап тоткан килеш, йөгереп килеп, юл йөзлегенә сак кына үн учын куйды, әмма шундук кире тартып алды: асфальт өстеннән көндезге кояш җылысы китмәгән иде әле. Шул җылы асфальт куркытты, ахры, аны.

Ә Майя, чынлап та, мондый юлны беренче мәртәбә күрә иде. Үткән гомерен кара урман эчендә яшәгән бу Хода бәндәсе инде килеп кешелек дөньясында өр-яңадан туарга һәм яши башларга тиеш иде. Ә бу җинел түгел. Хәтта, мөмкин булмаган хәл. Майя менә шушы мөмкин булмаган хәл-әхвәлне кабул итәргә, акылын һәм зиһенен югалтмыйча, үткән белән киләчәк арасында яткан сихри чикне кичеп чыгарга тиеш иде.

Хәлим аңлый: туктап хәл алмыйча торып, авылга кайтып җитү хакында уйларга да ярамый. Ә хәл алу—төн уздыру дигән сүз. Әнә—Майя да талчыккан, телдән язган. Урмандагы шаукым да эзсез калмаган, ахры—күзләрендәге элекке нур сүнгән... Шулай да, алар исән-сау килеш олы юлга чыга алдылар. Бу сөендерә. Калганы... вак мәсьәлә. Тормыш акрынлап үз урынына урнашыр, авылга, әниләре янына кайтып җитсеннәр генә әле...

Хәлим, соңгы көчен туплап, чыбык җыярга кереште. Юлның тап уртасын чамалап, җыйган чыбык-чабыгын өйде дә ут төртте, учак тергезеп җибәрде. Шул учак янына бөтен булган кием-салымны түшәп, урын-җир әзерләде. Аннары юл читендә баласын кочаклап, оеп утырган Майя янына китте. Култык астыннан тотып, иплән кенә торгызды, баланы үзенә алды, учак янына алып килеп, түшәлгән киемнәр өстенә ятарга булышты. Газизләренен өстенә әржә төбенә түшәлгән иске генә япманы алып япты, ә үзе, аякларын чалыштырып, учак каршына утырды...

Әмма иркенләп утырырга мөмкинлек булмады. Бармак калынлыгындагы коры-сары ботак-чатакны учак шундук ялап куйды. Хәлим бу гуж учакка тагын азык эзләргә китте. Урманга керергә курыкты. Юл читендә генә йөрде. Берничә юан усак ботагы табып алды, соңгы яшенле яңгыр гарасаты сындырган, ахры, кайрыларында суты да кибеп бетмәгән.

Бу учак туймас тамак булды. Хәлим якын-тирәдәге бөтен ягардай әйберне ягып бетерде, әмма, утын юк дип кенә учакны сүндерәсе килмәде аның. Шушы учак сүнсә, әллә нинди афәткә юлыгырлар төсле тоела иде. Хәлим юл буенча алгарак барып килергә булды. Тагын бер мәртәбә Майяга, аның кочагында мыш-мыш килеп йоклап яткан сабыена карап алды да китеп барды. Арыган, буынсыз-хәлсез калган аякларын өстерәп хәтсез йөрде ул, шактый гына чыбык-чабык җыйды. Мавыгып китеп, ут турында да оныткан бервакыт. Исенә килеп, Майя калган якка караса... йөрәге жу итеп китте. Учак сүнгән, юлны дөм караңгылык чорнап алган!

Хәлим кулындагы нарат теркесен бер читкә атып бәрде дә туктаган урыннарына йөгерде. Каян гына табылгандыр ул көч дигәнең, күз ачып йомганчы элеккеге учак урынына килеп тә җитте.

Дөресрәге, килә-килә аптырап килде Хәлим! Нинди чүмәлә караеп тора сон юл уртасында? Ат бит бу! Арбалы ат! Кайдадыр күргәне бар анын бу йөнтәс атны, бу тылсымлы арбаны... Ә кешесе кайда?

Учак сүнмәгән икән. Шушы ат-арба гына каплап торган. Әнә—Майя тирәсендә кемдер йөри—ат ияседер инде. Нинди мәрхәмәтле юлчы куып житте икән аларны? Алай дисәң, атның торышына караганда, ул нәкъ Хәлим йөргән яктан килгән булырга тиеш. Ә ничек күрми калды сон аны Хәлим? Сәер бу, бик сәер...

Юлчы карт Хәлимне аяк өсте каршы алды.

—Ә-ә, сезмени бу, олан? Юл уртасында нинди адәм баласы мәрткә китеп ята дисәм, синекеләр икән... Әйдәгез, мин дә шул якка, алып кайта алган кадәр ияртәм. Җайлап утырт хатыныңны. Икегез дә иләсмиләс күренәсез... Менә шулай...

Хәлим ләм-мим эндәшмәде. Ул, хатынын, баласын арбага урнаштыра-урнаштыра, бер сөенде, бер сагайды. Кем бу? Нинди әкият карты? Нинди сихер иясе? Килгәндә дә шушы картка утырып килде бит ул. Әйе-әйе, каядыр юкка чыкты ул соныннан. Бик тә, бик тә сәер зат. Саграк булырга кирәк...

Ничек кенә шомланса да, сагайса да, бу юлчы картка иярүдән башка чара калмады Хәлимгә. Күңелендәге җирсүе, хатынын, баласын авылга исән-имин кайтарып житкерү теләге җиңде. Арбага урнашып, кузгалып киттеләр. Майя белән Гөләш һаман йоклыйлар. Хәлим үзе уяулы-йокылы бара. Бөтенләй йоклап китүдән курка. Кем белә... Нинди затка ияреп китмәссең төн уртасында...

Хәлимнең уйларын укып баргандай, юлчы карт әйтеп куйды:

—Бер дә борчылма, олан, барысы да әйбәт булыр. Мона кадәрен кичергәнсең, инде җиңелрәге килер...

"Нәрсә хакында сөйли ул, минем урман тормышымны, урман тарихымны белгән кебек сөйли бит бу!.. Менә әкәмәт..."—Хәлимнең уйлары төйнәлеп бетә алмады, картның йомшак тавышы бүлде:

—Теләгәнеңне таптыңмы инде, Хәлим балам?

Хәлимгә тагы да сәеррәк тоелды бу сорау. Каян белә ул анын исемен? Әкәмәт!..

—Каян беләсең минем исемне, бабакай?

—Һи, белми ни... Сине бу урманда һәр агач, һәр үлән белә бит. Һи-һи-һи...

Көлүендә дә нидер бар анын. Кеше көлүе түгел бу. Әмма тавышы йомшак, хәтта, рәхәт, шифалы... Күңелгә ниндидер тынычлык бирә торган тавыш. Әллә... әллә берәр изге рухмы бу? Шул ук Хозыр-Ильясмы? Теге вакытта да шикләндергән иде... Әнә бит—актан киенгән, чәч-сакаллары да ап-ак... Озынча йөзе дә серле-матур, ниндидер нур, яктылык сирпеп торган кебек...

Хәлим анын хакында уйламаска тырышты. Күбрәк уйлаган саен күңелне күбрәк шикләндерә. Хәтта, куркыта... Өйләре, әнкәсе хакында уйларга керешге ул. Ничек кенә яшәп ятадыр инде ана бәгырь? Улын югалтудан йөрәге телгәләнеп беткәндер, күңеле яшәү дәртен, жаны тынычлыгын югалткандыр... Чыгып китүе дә әллә ничек кенә булды шул. Әллә нинди бер көч сөйрәп диярлек өеннән алып чыгып китте ул вакытта. Майясы, кызы өчен купкандыр шул туган нигезеннән... Җан—җанны, кан—канны, тән—тәнне тарта, диләр бит...

Шушы бер ай эчендә Хәлим үзе дә өзелеп сагынды Кампәрлене. Хәтта, Ак бабай белән Васимә карчыкка кадәр сагындырды. Әллә ничек жирсеп сагынды ул бу юлы... Кызык тойгы—жирсү... Сагыну гына түгел, ә жирсү... Җир-Су дигән сүздәндер инде. Ә! Менә хәзер төшенде ул: бервакыт каз өмәсе вакытында Мәймүнә әби сөйләп утырган иде: һәр

жир-урынның, төбәкнең Жир-Су раббысе була. Бу алла рухы балага ана карынында чакта ук—эчкән суы, капкан ризыгы белән керә. Кендек каны тамгач, бала белән Жир-Су тагын да якынаялар, дөресрәге, Жир-Су яна туган имчәк баласын тулысынча үз яклавы астына ала, ә кеше, үз чиратында, бу илаһи көчнең чисталыгын, көрлеген, изгелеген сакларга тиеш була. Кешеләре көчле булса, Жир-Су да көчле була, имеш. Читкә киткәндә кеше үзе белән бер уч туфрак алса, Жир-Су мәрхәмәте озатып йөрер, юлы унар дип тә сөйләгән иде Мәймүнә карчык...

Илен саклап яуда үлгән батырлар каберенә туган жир туфрагы салганнар, туган төбәк чишмәсенең суын бөркегәннәр,—тыныч ятсын, үз Жир—Суы янында булсын, аңа теге дөнья тормышында ярдәмче булсын, дигәннәр...

Ә менә Хәлим үзе бу хакта оныткан. Кесә төбендә бер уч туфрак йөртсә—шулкадәр жәфага тарымас иде, мөгаен. Кем генә белеп бетерә язмышны... Күрәсе булгангадыр. Иң мөһиме—аның тормышы түгәрәкләнде хәзер: өйдә әнкәсе көтә, хатыны, кызы янында, кайту белән өй салып жибәрер, акылы да аек, кул-аягы, бавыр-йөрәге дә таз-сау... Тагын ни кирәк бу дөньяда?.. Тагын ни кирәк... ни кирәк...

Арба читенә аягын салындырып утырган Хәлим оеп киткәнен сизми дә калды. Аруы, талчыгуы шулкадәр көчле иде ки, ул салмак кына юыртучы атның пошкырынуын да, юлчы картның, ара-тирә, авыр сулап: "Йа Хода, ярлыка балаларынны..."—дип, үпкәдән чыккан уфтанулы тавыш белән әйтеп куюын да ишетми инде.

## XI

Күктәге кояш та, көне буе галәмне яктыртып, жылытып торганнан соң, хәл алыр өчен төнгелеккә офык артына кереп китә. Үз улларын өзелеп көтүче аналарның күзләре генә бер минутка да йомылмый. Саниянең дә, улы чыгып киткәннән бирле, юньләп-рәтләп йоклаганы, тынычлап яшәгәне юк. Күңелендә гел бер гамь—Хәлим гаме. Шуның белән тора, шуның белән ята. Ана кешегә күп кирәкмени? Баласының исән-сау булуы, имин, бөтен тормыш коруы, бәхетле булуы—шул да житә! Ә... Аз түгел икән шул бу... Күп икән шул, хәтта бик күп икән. Дөнья, тереклек, яшәеш дигәнең кешегә күрсәткән һәр игелеге саен әллә күпме борчу, кайгы, сагыш, югалтулар, күңел әрнешләре сорый, сорап кына калмый, таләп итә, яисә бәхетен күрсәтеп ымсындыра да, үксез-ятим итеп, кайчакта гарип-горәбә кыяфәтендә, ярты юлда ташлап калдыра...

Бөтен ышаныч—Ходайда. Сания соңгы көннәрдә дингә бирелде, кайчандыр теленә, жан-рухына кергән иман догаларын янартты, хәтта, Васимә карчыктан өйрәнеп, намазга утыра башлады. Шүрлегендә һәрвакыт Коръән тотты, бөтен тишек-тошыкка бөти яздырып тыкты. Бер жомгада, карт-корыны жыеп, Коръән укытып алды, авылның ак әбиләренә, хәергә дип, исле сабын таратып чыкты...

Ә беркөнне... Әллә нинди сәер хәлләр булды беркөнне. Әлеге дә баягы Хәлим-Хәлим дип инде...

Ул көнне кеше үз гомерендә бер-ике генә күрә торган яшенле яңгыр яуды. Давыл-гарасат кап-кара болытларны авыл өстенә куып китергәндә Сания бакчада булаша иде. Ниндидер хәтәр афәт булып, Алла каргышы булып килде бу яңгыр. Әле яңгыр тамчылары тама да башламаган чакта, Нәфисәләр йорты каршында үсеп утырган тупылны яшен бәрде. Кара көя-көя сынып төшкән бу мәһабәт агачның инрәү тавышын бөтен авыл ишетте. "Өйләрен генә сукмаса ярар иде",—дип уйлап өлгерде Сания. Шул якка табан барып килмәкче дә булган иде, Күк Тәңре утлы камчыларын шарт-шорт шартлата башлагач, кире уйлады, күкрәкчәсенә тегелгән дога-бөтиен капшый-капшый, ашыгып өенә кереп китте.

Тәрәз пәрдәләрен, өске чыбылдыкларын тартып куйгач та тынычлана алмады Сания. Ниндидер сәер янгыр иде бу. Аның өчен, Сания өчен генә явадыр төсле ул. Хәлиме хакында ниндидер әйбәт хәбәр-ым бирер кебек... Юк, алай гына да түгел, Хәлимнең язмышы хәл итәлә кебек бу яшенле, күкрәүле янгыр вакытында. Кайдадыр Хәлим кыен хәлдә калган да, ана ярдәм кирәк кебек...

Сания Коръән теле белән Ходай тәгаләгә ялвара башлады: "Сөбханәкә Аллаһөммә вә бихамдикә вә тәбәрәкәс-мөкә вә тәгалә җәддөкә вә лә иләһә гайрөк... Йа Раббым! Сакла минем газиз улымны, йөрәк парәмне, төрле сихер-зәхмәтләрдән, афәт-бәлаләрдән, аның-зиһенен уяу ит, күнелен сафландыр, яшәешенә шәфкать кыл, аны үзенә сыендыр... Йа Раббым! Ни генә теләсәң дә, Сиңа багышлыйм, Сиңа бирәм, улымны гына исән калдыр, иленә, йортына кайтар. Менә гомерем, менә кулларым—улым өчен гомерем дә, кулларым да җәл түгел, телисеңме, менә—күзләрем... Якты дөньяны күрүдән мәхрүм итсәң ит, тик улымны гына саклый күр берүк, и Раббым..."

Менә бит хикмәт нидә: өченче көнгә чыккач янгыр туктады. Әмма шул көндә үк Саниянең күз алдында кара божралар уйный башлады. Ул үзенең сукырая башлавын тойды. Ходайга илереп ялварган дога-теләкләре хакында уйлыйсы килмәде аның. "Күп елаудан күз алмаларым томалана башлады бугай инде", —дип котылмакчы булды. Әмма хәтеренең ерак почмагында сакланган теге янгырлы көнне ничек кенә онытырга теләсә дә, оныта алмады Сания. Әллә Ходай тәгалә ишетте микән? Улы хакында, күзләре хакында? Күзләре бәрабәренә улын саклап калырга телӛдеме? Шулай гына булса ярар иде! Хәлиме генә исән булсын иде! Исән-имин кайтсын иде... "Әнкәй, мин кайттым, китмәскә кайттым, ничек яшәдең?"—дип кайтып керсен иде...

Әмма Хәлиме кайтмады да кайтмады. Авыл башына чыгып сәгатьләр буе юл офыгына багып, мөлдерәмә карашлары белән суырып алырдай чаклары күп булды Саниянең. Юл тамагыннан көнгә ике-өч машина, яисә берәр мотоцикл шуышып чыга чыгуын. Ул шуларга каршы бара. Берәр мәрхәмәтле җан утыртып кайтмыймы аның Хәлимен?..

Әлеге дә баягы күршеләр бар. Шул ук Ак бабай кереп тора, Васимә карчык та юлны суытмый. Әш белән үтешли Нәфисә сугылып чыга. Анысы озак утыра. Кеше күзеннән дә курыкмый тагы. Ике-өч мәртәбә чәй эчмичә китми. Аның да бушаныр чагы житеп килә. Күп булса, ике айлап вакыты калгандыр. Кыз тели. Шул кыз, кыз дип хыялланып беткән. Исемен дә уйлап куйган—Гөләндәм. Исән-сау гына котылсын инде берүк. Кергән саен сүзен Хәлим хакында сорашудан башлый: "Кайтмадымы? Берәрсе күрмәгәнме? Хәбәр-хәтер юкмы?" Оныта алмый, мескен. Күнеленә нык кереп калган шул тегесе дә. "Кайтсын гына, мин аны тагын үземә каратам, без барыбер бергә булачакбыз",—ди, юләр хатын. Сания тирги башласа: "Шаярттым ла..."—дигән булып кылана. Анлап бетерә алмассың үзен: әллә дөресен сөйли, әллә шаярта... Хәлим кайткач, дуамалланып, берәр мөгез чыгарып куймаса ярар иде, Ярабби Ходаем...

Сания тәрәзә төбендә төне буе уйланып утырды. Бу кадәр сонга калганы юк иде әле аның. Ятыр иде дә—тәмам йокысы качкан. Югыйсә, кичә көндезен дә йоклап ятмады үзе... Күнел бит—нидер сизенә, ахры. Бәлки Хәлиме кайтып киләдер шушы таң бусагасында?..

Тәрәзәдән тәрәзәгә йөренгән Сания күзенә хәрәкәт-мазар шәйләнмәде. Ул бу юлы да: "Бүген дә кайтмады, ятып алырга кирәк, Ходай кушкан булса, иртәгә кайтыр",—дип, сөйләнә-сөйләнә утын сүндереп килде дә үзенең юка гына гәүдәсен калын юрган астына яшерде. Бөгәрләнеп яткан килеш, ничек тә йокларга тырышып, көчләп диярлек күзләрен йомды, дога пышылдады...

Шулвакыт тәрәзә артында ниндидер чит-ят тавыш ишетелеп китте:

—Тр-р!..

Сания сискәнеп торып утырды. Әллә өнендә төш күреп, саташып

ята инде? Тәрәзә янына барып, өске пәрдә итәген күтәрде, ут кабызырга яисә тышка чыгарга шикләнде, кайчакта җен-шайтаннар үзләренен яратмаган кешеләрен шулай чакырып, дәшеп чыгаралар, ди...

Шулчак "келт!" итеп капка келәсе күтәрелде. Анын артыннан ук шыгырдавык аваз капка ачылуын хәбәр итте. Саниянең йөрәге кысылды, җаны күнеленен ин ерак төпкеленә төшеп ятты. Нииндидер сихер галәмәтеме—капка ачылды, ләкин беркем кермәде. Ә! Әнә, керәләр икән... Нииндидер бала күтәргән хатын кереп килә... Кем ул? Андыймондый туганнары да юк шикелле... Кем булса да барыбер түгелмени? Җен генә булмасын.

Сания тәрәзә яныннан китәргә булды. Җеннәрне котыртып, үртәп тормасын әле. Белгән догаларын укый-укый, ишек катына барды, колагын куеп тынлый башлады. Әгәр чын булса, хәзер килеп шакый башлаячаклар. Шулай дип уйлап бетерүе булды, теге яктан ишек кага башладылар һәм шул шомлы дөбердәү артыннан ук таныш, газиз тавыш яңгырады:

—Әнкәй, бу без, ач ишегенне. Курыкма, Хәлим бу...

Сания, буыннары хәлсезләнеп, идәнгә утыра язды. Анын кинәт күңеле йомшап китте, күңеле генә түгел, буыннары йомшап, гәүдәсе сыгылып төште, егылмас өчен, ишек янагына тотынды. Ул шулкадәр дулкынлана иде, калтыранган куллары белән ишек келәсен күтәрә-күтәрә үпкәсеннән бер генә сүз кысып чыгыра алды:

—Хәли-и-и-м...

...Ана белән бала бик озак кочаклашып тордылар. Инде мәңгегә аерылмаска кушылган кебек иде алар. Хәлим әнкәсенен кулбашына маңгаен салып, тып-тын калган, ә Сания дәшми-нитми генә баласын сөя: әле чәчен сыйпый, әле аркасыннан шапылдатып кагып куя... Дәшәм дисә дә дәшә алмас иде, мөгаен, анын бөтен шатлык-куанычы күңел бусагасына килеп төялгән дә, элгәре җыелып каткан сагыш кантарларын куптара алмый газаплана иде бу минутта...

—Әнкәй, мин кайттым, ничек тордың?

—Хәлимкәем... Бәпкәччәем!.. И балакаем, тору дип әйтеп буламыни аны... Тормадым да, яшәмәдем дә, гел сине көттем. Күрергә генә булган икән бу өзелеп көтүләрем...

—Әнкәй, йә, елама инде. Насыйп иткәч, кайтасың икән ул...

—И-и, ишек төбендә тотам икән үзенне... Әйдә, улым, кер эчкә, хәзер утны көчәйтеп җибәрәм... Кайту шатлыгыннан чәйләр эчәрбез.— Сөйләнә-сөйләнә өйгә кереп китәргә җыенган Сания шунда кырт туктап калды:—Улым, син үзен генәме? Бая тәрәзәдә күзем ялгышты, ахры, тагын кемнәрдер кергән кебек булды.

Шунда Хәлим дә тәмам айнып житте. Чолан караңгылыгында керергә кыенсынып торган Маяны үрелеп, капшап табып алды да, бераз алгарак этеп, каушабрак сөйләп китте:

—Әнкәй, без монда күп әле. Менә—Майяны алып кайттым. Мин сиңа сөйләгән идем бит Майя хакында. Шикләнмә, син аны беләсен, ул минем хатыным хәзер. Майя, әйдә инде өйгә... Әнкәй әйбәт ул минем...

Сания чоланга чыкты.

—Әйдүк, кер балам, төкле аягын белән, димме... Бәй, баланң да бар ласа... Бир монда, үзем апкерәм, тупсаны шәйләп атла, абына күрмә берүк...

## XII

Сания, баланы түр түшәккә кертеп салгач та озак кына тынычлана алмады. Юк, бу тынгысызлык кинәт өйдә пәйда булган килене яисә сәләмә чүпрәкләргә төрелгән сабый бала белән тамчы да бәйләнмәгән; бу минутта анын сөенече бөтен борчу-мәшакатьләрен дә басып, күмеп киткән иде.

Өйгә кергәч, ул тагын бер мәртәбә кочаклап сөйде Хәлимен, анын

житү чәчләрен, күперә башлаган сакал-мыегын сыйпады... Үзе һаман сөйләнде:

—Кайттыңмы, улым?.. Кайтуың хакмы? Инде китмәскә кайттыңмы?..

—Бу мин, әнкәй. Мәнә, ышанмасаң, чеметеп кара. Ярый, утырыйк инде. Нык арытты, әнкәй, аяклар тотмый... Юл мәшәкатьлерәк булды шул...—Хәлим шунда күзләре белән генә Майяны эзләп табып, әнисенә дәште:—Әнкәй, бик тели идең, хәзер киленле дә булдың инде...

Баласы янында аптырап утыручы Майя, Хәлим сүзләрен ишетү белән, тагын да ныграк кыенсынды, нишләргә дә белмичә, идәннән карашын алмыйча, торып басты...

—И-и, менә бит ничек килә бәхет. Бер килсә өелеп килә диләр шул аны. Рас икән. Бер төн эчендә дөньям бөтенәйде дә куйды. Улым да, киленем дә үзем белән...

—Оныгың да, әнкәй...

—Ә? Әйе шул, бөтенләй баш миңгерәүләнгән, улым. Оныгым да бар бит әле минем.—Сания Гөләш йоклап яткан караватт янына килде.

—Утыр, балам, кил, и-и, бигрәк талчыккансыз, җир читеннән кайттыгызмы әллә?—Сөйләнә-сөйләнә, сөя-сөя Майяны түшәккә утырткач, бала өстенә иелде:

—Сабый сабый инде... Ике дөнья бер моржа... Әнә ничек изрәп йоклый. Бәй-бәй, Хәлим улым, тач син бит бу? Кем дип дәшим соң үзенә?..

—Гөләш, әнкәй, Гөләш...

—Ә? Гөләш? Матур исем, тик... малаймы, кызмы?

—Кыз, кыз... Син бит, әнкәй, гомерең буе кызларга кызыгып яшәдең. Менә кызлы да булдың...

—И-и, бәпкәччәем! Ничек матур йоклый бит, сабый... Үз өенә кайтты шул. Үз нигезендә йокы тәмле була бит ул...

—Әнкәй, без шундый нык арыдык, ятырбыз инде, яме. Калганын иртәгә сөйләшеп бетерербез. Әнә, Майяның да күзләре йомылган, урман сихереннән әле яңа котылып килә...

—Ә? Урман сихереннән?.. Ни дигән сүз ул, балам?..

—Озын тарих бу, әнкәй. Бер сөйләрмен әле. Ә хәзер ятыйк.

—Юк-юк, балам. Бер йотым чәй эчертмичә яткырмыйм. Әле дога кылырга да онытканбыз. Кайтуыгызны белдереп, өй нигезен бәхилләп куйыйк...

Сания, каршы урындыкка утырып, алдына учларын кушарып, дога пышылдый башлады, Хәлим дә, Хәлимнән күрмәк Майя да, дога укыган булып, учларын алларына җәеп куйдылар. Әнкәләре: "Амин!"—дип әйтүгә, битләрен сыпырып алдылар да Гөләш яткан караватка урын җайлый башладылар.

—Юк-юк, өчегезне дә бер караватка яткыраммы соң?! Баланы изеп-нитеп бетерер идегез бугай. Хәлим, бар, чоланнан үзеңнең бишегеңне алып кер, әнә теге кадакка элеп куй, менә бу җаймәне түшәп, бәллү әзерлә. Бар, тиз бул... И-и, Мәйя кызым, чак-чак утырасың бит... Тизрәк ятыгыз, алайса, качмас, чәең иртән эчәрбез...

...Иртән соң уянды Хәлим. Күзен ачкач, берни аңламыйчарак торды: "Кайда ул? Кем түшәгендә?" Ә! Караватт тирәсенә эленгән чаршауны төшергән икән әнкәсе. Эре чәчәкле чаршауга карап, бераз уйланып ятты да янында ятучы, матур елмаеп, төш дөньясында йөзүче Майяның өстенә япкалады, аннары мыштым гына торып утырды, чаршауны аралап, өй эченә күз салды.

Ә анда!.. Анда чып-чын бәйрәм иде! Иң элек Хәлимнең күз карашларын өй эчендәге аклык җәлеп итте. Өйләренең бу кадәр акка күмелгәнен хәтерләми ул. Тәрәзәләргә ак пәрдәләр, чыбылдыклар тартылган, каршы яктагы караватт өстенә ап-ак җәймә җәелгән, түшәмгә кадәр ап-ак ястык-мендәрләр өелгән. Агартылган мич өстендә—буйдан буйга—тагын ак чыбылдык. Ишек чаршавы да ак киндердән. Өстәлдәге

ашъяулык та, ризык өстенә капланган сөлгеләр дә ап-ак... Ара-тирә генә чигүләр шәйләнә. Иң кызыгы бу түгел әле. Өйнең тап урта бер жирендә бишек эленеп тора. Аның өстенә дә ак япма ябылган; япмада чигү: бер-берсенә сыенышып ике пар күгәрчен утыра, берсенең томшыгында—күк чәчәк, икенчесендә—ал чәчәк...

Әнкәсе өйдә юк. Тышта, бакчада йә кош-корт тирәсендәдер инде. Хәлим бүлмәгә узды. Өстәл өстендәге япманың бер читен ачып, бер бөртек бавырсак алды, аны аз-аз гына кабып, тәмләп ашап куйды. Бишек янына килеп, чыбылдыгын күтәреп карады. Ул Гөләшен чак таныды: элекке сәләмәләре юкка чыккан, үзе исә күзне камаштырырлык ап-ак бүз чүпрәкләргә төрелгән... Хәлим берара сокланып карап торды да: "Күз тидерәм бугай инде..."—дип чыбылдыкны ябып куйды.

Кинәт аның колагына мыш-мыш елаган тавыш ишетелде. Ул, үзе дә сизмәстән, тагын бишек чыбылдыгына барып ябышты: юк, бала тыныч ята, житмәсә, көлгән кебегрәк тә әле... Әллә Майя уянганмы? Хәлим, түргәрәк үтеп, караватларын кеше күзеннән яшереп торган чаршауны тартыбрак куйды. Шунда ук йөрәге "жу" итеп китте. Янындагы мендәрне кочаклап, Майя үксеп елап ята иде.

—Нәрсә булды, Майя, мин монда гына бит, югалттыңмы әллә?

Майя һаман тукталмады, чишмәдәй аккан күз яшьләрен юрган почмагына сөртә-сөртә, үзенең калтыравык иреннәре арасыннан берничә сүз кысып чыгарды:

—Хәлим... мин... мин.. курка-а-м!..

—И-и, юләрем минем. Син бит үз өеңдә. Минем өй—синең өй була инде. Беркем дә рәнжетә алмаячак сине монда. Әнкәй бик тә яхшы кеше ул минем. Менә үзең күрерсең...

—Хәлим... Гөл-гөл-гөләш кайда-а?..

—Һи, син аны хәзер танымыйсың да. Күрсәтимме? Йәле, күзләреңне йомып тор.

Хәлим бишектәге ак төргәкне тынычлана башлаган хатыны янына илтеп салды да, чын хужаларча сөйләнә-сөйләнә, мунча ягарга чыгып китте...

## XIII

Хәлимнең гаиләсе белән кайтып төшүе хакындагы хәбәр тыныч кына яшәп яткан Кампәрле авылын чыгырыннан чыгарды. "Килен" дип тә әйтмәделәр, "гаилә" дип тә... "Хәлим сихер ияртеп кайткан", диделәр. Менә шуңа түзеп кара инде! Йөрәгең-жаның булса, ничек түзмәк кирәк?! Саниягә дә сүз күп ишеттерделәр. Гайбәт сөйләп йөргән Хатирә карчык янына ул үзе китте. Тегесен барыбер иманга китереп булмады. "Малаең сихерчеләр белән бәйләнгән, сихер йортыннан кайткан, хәзер бөтен авылны мур кырыр инде",—дип чәпчеде дә чәпчеде...

Түбән очта яшәүче Оркыя карчык та: "Хәлим туганда ук сихер белән туган ие, шуңа да хәзер жennәр белән сөешкән..."—дигән сүз жибәргән. Сания аның янына барып та тормады. Йөрәгенә тагын бер тиргәш, каргыш аласы килмәде.

Ә беркөнне аларның капкасына деґет буяп киттеләр. Иртән, көтүгә сыер куып, урамга килеп чыкса, егылыплар китә язды Сания: олы капкаларына аркылыга-буйга иләмсез зур тәре сызылган! Яшенә тыгылып өйгә килеп кергәндә Хәлим аяк чабуын кыстырып тора иде. Әнкәсенең, нииндидер бәлагә очрап, кәефсез килеп кергәнен ул шундук төшенде. Чөнки, күнеле урынында чакта, өйгә керә-керешкә, улына берәр жылы сүз әйтеп куя торган гадәте бар аның.

—И-и, улым-улкаем!.. Йөзебезгә кара ягарга маташалар бит хәерсезләр... Капкабызга деґет буяп киткәннәр...

—Ә? Нәрсә-ә? Кем буяган? Нигә?

—Нигә булсын, шул сихер-зәхмәт диптер инде. Сүз йөртеп, Мәйянең урамга чыгарын калдырмадылар, инде өебезгә дә рәт бетте. Хет егылыплар гына үл!.. Каян, кемнән киләдер бу кадәр явызлык кешегә?!

Хәлим ни әйтергә дә белмәде. Нәрсә әйтсен ул? Әйтерлектән узган шул инде. Әле ярый Майя чоланда ята. Төнлә Гөләш елап-җәфалап чыкты. Майя, борчылып, бер тамчы йоклый алмады, менә әле генә икәүләп йокыга киттеләр. Авыр уфтана-уфтана урамга килеп чыкканда Хәлимнәр турысыннан көтү узып бара иде. Көтүче Мәннән карт шунда ук аңлап алды: бу йортка афәт кагылган, кара гайбәт ягылган... Дегетле капкага төбәлгән килеш, нишләргә белми торган Хәлимне ул тыныч кына узып китә алмады.

—Олан, бер дә борчылма, синең капкаңны буйыйбыз дип, үз җаннарын буяп киткәннәр алар кара дегеткә. Капканы чистартып та, алыштырып та була, ә менә пычранган күңелне юып, алыштырып булмый... Бер дә борчылма... Ходай тәгалә үзе хәл итәр, барысын да урынына куяр—хагын да, нахагын да...

Хәлим, әлбәттә, дегетне шундук кырып атты. Кырылган пычракны, чокыр казып, күмеп тә куйды әле. Ләкин аның күңеле кузгалган иде инде. Көн саен колак итен ашап торган ямьсез-шомлы сүзләр дә, бүгенге хәтәр вакыйга да тәмам тынычлыгын алды аның. Ул үзен кая куярга белмәде, ары барды, бире килде, эшенең дә рәте-чираты булмады, әле берсенә, икенчесенә тотынды—берсен дә ахырына кадәр башкарып чыгара алмады. Ниһаять, бөтен дөньясына кулын селтәп, Ак бабай янына кереп китте.

Бары тик ул гына нидер әйтер, Хәлимнең ярсу йөрәген, урыныннан купкан дуамал җанын ул гына тынычландырыр кебек иде.

Хәлимнең кайтуын тыныч кабул итүче бердәнбер кеше булгандыр бу дөнья карты. Васимә карчыкны исәпләмәгәндә. Бөтен авыл, пышан-пышан гайбәт сөйләп, Хәлим белән авыз чайкаганда, шушы мәрхәмәтле ике җан иясе генә алардан йөз чөермәде, бу Хода бәндәләрен язмыш төпкелендә ташлап калдырмады. Сания йортына төшкән тагын бер сынау итеп кабул итте Ак бабай Хәлимнең хатын, бала ияртеп кайтуын. Шуңа күрә, бернидән тайчанмыйча, вакыт тигән саен, Хәлимнәргә кереп йөрде, аларның юанычы, таянычы булды.

Кайтканнарының икенче көнендә үк никах укыттылар. Әлбәттә инде, Васимә карчыктан башка кеше кермәде. Укалап һәм сәйлән ташы тезеп чигелгән түбәтәен киеп кергән Ак бабай күз тидерерлек дәрәҗәдә ягымлы, мөлаем, якты иде. Ул инде иртән Хәлим белән күрешеп, сүз алмашып чыккан иде, кичкә табан никах ашына махсус ниятләп керде. Яшьләр кече якта—такта белән бүлеп алынган мич алды бүлмәсендә утырдылар. Өлкәннәр түр якта үз йолаларын башкардылар. Бер очтан баланың исемен дә, мөселман йоласы кушканча, иманга, Ходай тәгалә ихтыярына бәйләп куйдылар.

Хәлим баштарак Ак бабасына күңелен бик ачмады. Мулла кеше бит, дин әһеле, мәхәллә башлыгы. Урмандагы албастылар тормышы, мәҗүси гыйбрәтләр, сихер-зәхмәт хакында сөйләсенме ул аңа? Үзләреннән гайрәт чиктереп, соңгы таянычтан да мәхрүм каласы килмәде Хәлимнең.

...Бу юлы Хәлим барысын да сөйләп бирергә булды. Капкаларына сыланган дегетне ул үзенең күңелендә, җанында тойды. Чирканып, укшый ук башлады. Ак бабайның капкасына таянып бераз хәл алды да эчкә үтте. Карт, ишек төбе тулып яткан юкә тасмаларны тезенә җәеп, бау ишеп утыра иде. Хәлимнең агарып киткән йөзенә карап, шунда ук аңлады ул: нидер булган болар белән. Шулай да, тормады, Хәлимне тыныч кына көтеп алды. Тегесе, сәлам дә бирмичә, ухылдап күтәрмә баскычына килеп утырды, тагын бер мәртәбә авыр сулап куйды да ачудан, әрнүдән зәңгәрләнеп кысылган иреннәре арасыннан беренче сүзне өреп чыгарды:

—Булмы-ы-ый!..

—Нәрсә булмый, олан, ник сөмсерең коелды? Нишләп болай ачы таң белән фәрештәләр куркытып йөрисең?..

—Булмый, Ак бабай... Булмый!.. Яши алмыйм мин болай!.. Сүзләренә дә түзәр идем, нахагына да... Әнә бит... капкага дегет буяп киткәннәр... "Кара йөзле" булдык бит... Каргышлы булдык... Ничек яшәргә инде хәзер? Дөреслек кайда? Хаклык кайда?

—И-и, олан, олан. Дөреслек, хаклык дисең син. Дөреслек юк ул. Бары тик шәфкатьлелек кенә бар.

—Ничек инде—хаклык юкмы? Хаклык, дөреслек булмагач, иман, мәсләк, кыйбла да булмый бит...

—Юк, олан, хакыйкать—шул шәфкатьлелек ул. Кешеләр бер-берсенә шәфкатьле булсалар, изгелек кылсалар, бер-берсен кичерсәләр—иман шул инде. Ходай тәгалә барысын да күреп, сынап тора, барысын да үз урынына куя... Менә синең капкаңа дегет буяп киткәннәр. Син шуңа үртәлеп, ачуланып, тузынып яисә үпкәләп йөрисең, шуның белән үзеңә авырлык аласың... Чын күнелең, ихлас жаның белән ул мәнсез бәндәләрне кичер. Үз явызлыкларына үзләре абынып, жәфа, борчу кичерсеннәр, иманга килсеннәр... Син кичер аларны, Аллаһы тәгалә ихтыярына куй.

Тынып калдылар. Хәлим дә бераз тынычланды. Шулай да, буй-буй дегеткә буялган капкалары күз алдыннан китмәде, афәт галәмәте булып, болай да теткәләнеп-жәрәхәтләнеп беткән бәгырен тырнап торды. Шунда Ак бабай, Хәлимнең күңел бавын чишеп жибәргәндәй итеп, дустанә, йомшак-ягымлы гына сорап куйды:

—Нindirәк зат, каян соң ул—килен тиешле кешене әйтәм... Исеме... Маймы әле?

Хәлим аңлады. Ана шушы сорау гына кирәк булган икән. Бөтен күңел ачыгысын түгеп, чәчеп ташлар өчен, менә шулай ачы таң белән Ак бабай янына йөгереп керү кирәк булган икән... Тел ачкычы дигән нәрсә шулдыр инде. Ак бабай таба белде Хәлимнең күңеленә бу ачкычны. Ул баштарак кыенсынып, уйланып-сайлап кына, аннары бөтенләй туарылып, иркенәеп китеп, үзенең ике еллык тарихын сөйләп бирде. Бу—аның ике елга беренче мәртәбә онытылып, әле хыялыйланып, әле ачынып, өзгәләнеп, күңел дөньясының иң ерак офыкларын айкый-айкый, ин тирән төпкелләренә төшә-төшә хәтер юлларын барлавы иде. Шунысы кызык: нәрсә хакында гына сөйләсә дә, аның уй очы бер тарафка—сөйгәне, хатыны, хәләле Майя ягына алып китә; ул үзенең һәр сүзен—борчу-сагышмы ул, яисә өмет-шатлыкмы—шушы табигать кызы белән, сихерче карчыклар кулында тәрбияләнеп тә, сафлыгын, серлелеген югалтмаган илаһи зат белән тәмамлый иде.

## XIV

Беләм, укучы түземсезләнеп көтә инде: Майя белән ничек соң? Кайсы дөньяда ул хәзер? Нинди уйлар, кичерешләр белән яши? Авылга күнегә алдымы? Кешеләргә? Мин бу хакта язмадым. Әйе, мин аны борчырга кыенсыныбрак тордым, ахры... Майяның күңеле бу минутта тынгысызлана, борчыла, үз урынын таба алмыйча бәргәләнә төсле тоелды миңа.

Ялгышмаганмын икән.

...Майя авылга кайтуны бик авыр кичерде. Авылга килеп кергәндә үк, анда-монда җемелдәгән электр утларыннан өркеп калтыранган гәүдәсе белән Хәлимгә сыенып, куркынып килгән иде. Өйгә керүләр, Сания белән очрашулар, беренче төн—барысы да төштәге кебек кенә... Аруы житкән булгандыр—төнлә ул үле кебек йоклады. Иртән Саниянең йөрүенә уянып китте. Дөресрәге, уянып бетмәде, ярым йоклаган килеш, төш аралаш ниндидер ят-сәер, әмма искиткеч ягымлы тавыш ишетте... Кичәге тавыш бит бу... Шушы тавыш каршы алган иде аларны. Кем ул? Кичәге

очрашуны күз алдына китерергә тырышты Майя. Әллә ни майтара алмады. Нindидер атлы-арбалы картка утырып кайттылар, түбәле капкага керделәр, кемдер каршы алды... Ә-ә... Шушы тавыш иясе иде ул. Серле тавыш...

—И-и, сабыем минем... Онытым минем... Кызым минем... Йоклыйсыңмы... Йокла-йокла, ерак юлда талчыккансыңдыр шул... Хәзер мин сиңа кәҗә сөте җылытып бирермен...

Йокла, кызым, йом күзеңне,
Әлли итим үзеңне...
Кояш күзләрен ачканчы,
Ай балкытсын йөзеңне...
Әлли—бәлли... Әлли—бәлли
Әлли—бәлли, бәү...бәү,
Дәү әбием дип торырсың,
Үсеп житкәч дәү-дәү...

Майяның зиһененә дә тәэсир итте, ахры, бу бишек җыры. Ул, уянып та житмәгән килеш, кабат йоклап китте. Бу минутта аның изрәп йоклавы хәерлерәктер дә. Кинәт уянып, айнып китеп, торып утырса, болай да куркынып беткән йөрәге, күз алдында пәйда булган өр-яңа дөньяны күреп, шартлар дәрәҗәгә җитәр иде, мөгаен.

Мунча мичenә ут дөрләтеп кергән Хәлим Майяның кояшта янган зифа яңагыннан сөеп уятканда кояш шактый күтәрелгән иде инде. Бер сөенгән, бер куркынган Майя шунда ук иренең муенына сарылды. Хәлим дә аны кысып кочаклап алды һәм, күтәреп тора алмыйча, шулай кочаклаган килеш түшәккә авып төште. Алар, ниндидер сәер ымсыну белән бер-беренә табан тартылдылар, чәчләр-чәчкә ялганды, иреннәр иренгә кушылды...

Шул мәлдә Гөләш шыгырдый башлады. "Кхи-кхи-кхи..." дип ыңгы-рашырга керешкән кызларын шундук ишетеп-тоеп алдылар алар! Майя сикереп тормакчы булды. Әмма Хәлим аны үз кочагыннан ычкындырмады.

—Үзем...—диде дә, ялт кына торып, бишектәге сабый янына китте. Майя ул арада, стена ягына елышып, урын әзерләргә өлгерде. Хәлим Гөләшне алып килгәндә, ул, юрганын күтәреп, ире белән кызын үзенең җылы кочагына чакырып тора иде инде. Хәлим үз кочагындагы төргәккә хилафлык китермәс өчен, сакланып кына, терсәкләренә таянган килеш, шул ояга кереп чумды. Аннары кармаланып Майяның изүен ачты, аның тулышып торган күкрәген эзләп тапты, Гөләшнең мамык кебек йомшак йөзен, әнисенең исен сизеп, көпшәкләндереп эзләнә башлаган иреннәрен шул күкрәкләргә таба этте...

Өчәүләп мунча кереп чыктылар. Сания һаман күренмәде. Бик сорыйсы килсә дә, Майя аның хакында авыз ачып сүз катырга кыймады. Бу киеренкелек үзеннән-үзе хәл ителде. Алар чәй өстәле артына утыруга, Сания үзе кайтып керде...

—И-и, балакайларым, югалткансыздыр инде...

—Кайда булдың, әнкәй? Инде шүрли дә башлаган идек...

—Бәй, көтү кугач, мич булдырып кына йөри идем, урамда ыгы-зыгы башланмасынмы? Берәрсенә ут капканмы дип йөгереп чыксам, кем таба, кем чиләк кага-кага, пыр тузып авыл башына чабалар. Имеш, урман буенда ниндидер сихерче карчыкларны күреп калганнар. Ә сихер кырыктан гына курка. Кеше саны булып мин дә йөгердем...

Сания өстендәге сырмасын почмакка элде дә түргә узды. Кулын алъяпкычына сөртә-сөртә, Майяга табан килә башлады. Күрешергә кулларын сузды:

—Сөйләнеп торган булам тагы... Киленемне юньләп күргән дә юк бит әле. Төнлә төштәге кебек кенә күземә чалынып калган иде... Менә нинди икән син, Мәйя...

Алар—килен белән биянай—кулга-кул тотынышып, озак кына аерыла алмый тордылар. Сания Майяның аркасыннан сөеп сүзен дәвам итте:

—Хәлим син дип акылдан кала язды бит, кызым. Менә—насыйп иткәч, бергә дә булдыгыз...

Майя бу минутта нишләргә кирәген белми иде. Ул, башын аска иеп, кыенсынып басып торуында булды. Аны бу хәлдән Хәлим коткарды.

—Әнкәй, теге сихерчеләрне үзең күрдеңме соң?

—Күрүен күрмәдем. Ниндидер ике карчык диделәр...

Хәлим белән Майя, сискәнеп, бөтен тәннәре-җаннары тетрәнеп, бер-берсенә карадылар. Карашларында бер генә шомлы уй-сорау бар иде аларның: "Әллә шуларны?"

Җәелеп китеп сөйләшмичә генә чәй эчтеләр. Яшьләрнең күңеленнән теге сихерчеләр чыкмады. Сания дә уйчан, басынкы тотты үзен. Ул да нидер сизенә, улы белән килененең нидер сизенгәнен сизенә иде. Аның пошаманга калып йөрүе дә шуннан ахры.

Бераздан Сания ачылып киткәндәй булды. Бигрәк тә Майя тирәсендә күп бөтерелде. Әле бер төрле, әле икенче төрле ризык алып бирде, үзе туктаусыз кыстады:

—Һи, бер дә ашамыйсың икән син, кызым. Сиңа ашарга кирәк. Балаңа көчле сөт төшсен дисәң, көчле ризык кабарга кирәк диләр бит. Менә—бавырсагыннан житеш, бәрәңге тормәсен дә тәмле пешерәм мин... Әнис сибеп...

Майя һаман ачылып китә алмады. Аның уяна башлаган күңелен сихерчеләр хакындагы хәбәр шыплап ябып-томалап куйган, ахры. Аннары, бу дөнья аңа шулкадәр ят иде ки, ни генә эшләсә дә, ни генә әйтсә дә, бер-бер хәл булыр да бу сихри тормыш, челпәрәмә килеп, җимерелеп төшәр кебек. Ул әле дә түзем. Гомерендә беренче мәртәбә урманнан чыгып, кешеләр арасында калуы ласа аның... Әнә бит—стенадагы тишекләр урынында якты тәрәзәләр, сәкеләре дә йомшак, утырсаң чумып китәсең, бүкәннәре дә, бәрән кебек, дүрт аяклы, менә-менә сикергәләп йөгереп китәр төсле... Стенада эленеп торган сәгать аеруча нык аптыратты Майяны. Бертуктаусыз текелдәп торган сәгатьне, аның арлы-бирле йөренгән телен озак күзәтте ул. Сәгать эленгән стена ягына барырга да курыкты, хәтта. Менә аның игътибарын каршы якта эленеп торган олы рам җәлеп итте. Дөресрәге, андагы сурәтләр. Дәшмичә-сорашмыйча, хәтсез карап торды ул андагы фотоларга. Хәлимнең хәрби киемдә төшкән сурәтен озаклап карады; күз карашлары Сания белән төшкән ир затына күчкәч, сискәнеп киткәндәй булды, күптәнге танышын очраткан кебек, карашлары белән сурәтнең эченә кереп чумды... Кайдадыр күргәне бар кебек бу кешене. Аның бит беренче мәртәбә кешеләр арасына чыгуы. Урманда күрде дисәң инде... Ә?! Шул бит бу! Чәнтисез әпә! Хәлимнең атасы! Менә тагын бер фото. Шул ук ир-егет. Шат, бәхетле. Ә болары кемнәр? Майя күз-керфекләрен рам пыяласына терәп үк куйды. Нинди шәүләләр соң болар? Теге ир-егет артыннан мут елмаеп карап торучы кара адәмнәр дә таныш тоелды аңа. Тукта! Әбиләр бит болар! Урмандагы әби-карчыклар! Нишләп монда йөриләр соң алар?..

Кинәт Майяның күзаллары караңгыланып, башы әйләнеп киткәндәй булды, буыннары йомшады. Өстәл артында һаман чәй чөмереп утырган Хәлим булмаса, гөрселдәп идәнгә килеп төшәр иде, мөгаен. Хәлим аны сак кына түшәккә яткырды.

—Нәрсә булды икән? И Аллам! Хараплар гына иттек бит үзен...—дип сөйләнә-сөйләнә, Сания дару үләннәреннән төрле дәвалар әзерләргә тотынды.

—Майя, ни булды? Йә, ач инде күзеңне... Майя!

Иң элек Майяның хәлсез керфекләре ачылып китте. Аның ачы моң, шомлы гамь кунган күз алмалары Хәлим күңеленә авыр таш булып төштеләр.

Майя хәлсез куллары белән стенадагы рамга төртеп күрсәтте.

—Әнә анда—әбиләр... Алар мине үтермәкче булалар... Алып ат син аларны...

Хәлим шундук стенадагы рамга барып ябышты. Пыяласын салдырып, теге фотоны алды, каплап, матчага кыстырып куйды.

Бераздан Майяга хәл керде. Гөләш тә уянды. Тагын берәр чынаяк чәй эчтеләр. Баланың йокысы тәмам ачылган иде. Ул елмаеп ук җибәрде. Хәлим кызы белән уйный башлады. Сания белән Майя табынны җыештырырга керештеләр. Бераздан Сания, сөйләнә-сөйләнә, Майяны хуҗалык белән таныштырырга алып чыгып китте. Хәлим дә, бөтен борчуларын онытып, бармак очы белән кызының алсу бит мендәрләренә баса-баса, такмакларга кереште:

Карга килер—казан асыр,
Торна килер—тоз салыр,
Саескан килер—салма салыр,
Песнәк килер—пешерер,
Чыпчык килер—төшерер,
Моңа бирмәс, аңа бирер,
Кечкенә тутый тумый калыр,
Кетер, кетер, кетер итеп
Казан төбен кимерер...

## XV

Мәхәббәттән нәфрәткә бер адым, диләр. Дөрес икән. Бөтен җанытәне белән Хәлимне яратып яшәгән Нәфисә танымаслык булып үзгәрде. Каяндыр хатыны, гаиләсе белән кайтып төшүен ишеткәч, бөтен авылны Хәлимгә каршы котырта башлады. Очраган бер кешегә әллә нинди кирәкмәгән сүзләр сөйләп, үзе кеше көлкесенә калып бетте. Өен, гаиләсен, ирен онытты, алга бүлтәеп чыккан олы корсагын көмәнен өстерәп, өй борынча гайбәт таратып йөрде... Нәрсә генә сөйләсә дә, сүзе бер нәрсәгә килеп төенләнә иде—сихергә. Имеш, Хәлимне кайдадыр сихерләп тотканнар, аннары, нинди дер жен баласы белән пәри кызын ияртеп җибәргәннәр. Бу пәри кызы авылга зәхмәт, кара каргыш китерәчәк, тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр...

Әлбәттә, Нәфисә Хәлимне яратмаудан йөрми. Хәлим аныкы, юк ла, үзе Хәлимнеке булмаганга үртәлеп шулай кылана ул. Нәфисә үзе дә моны анлый. Анлый, әмма берни дә эшли алмый. Бөтен бәла дә шунда: Хәлимнең каяндыр хатын алып кайтуын алар арасындагы олы мәхәббәткә хыянәт кебек кабул итте ул. Өзгәләнде, көйде, үз-үзен эчтән кимерде. Менә-менә якты дөньяга аваз салам дип торган баласы ничек түзгәндер бу изалануларга—Ходай гына белсен! Сүз дә юк, моның бер ахыры булырга тиеш инде. Әмма ул көнгә ерак, бик ерак иде әле.

Ә бер көнне Нәфисә кинәт үзгәрде, берәр сәгать урамда "чәйнәшеп" йөргәннән соң, туган йортына кереп, әнкәсенең күкрәгенә капланып, сулкылдап-сулкылдап еларга кереште. Тәскирә орылмады-бәрелмәде, кызының башыннан сыйпый-сыйпый, авыр сулап, әмма тыныч кына әйтеп куйды:

—И, кызым, мин бит сине анлыйм. Шуна күрә тиргәмим дә. Түзәргә кирәк. Күрәчәгебез шулдыр...

• Яшенә тыгылып елаган Нәфисә, башын калкыта төшеп, җан тавышы белән сөйли, юк, ачыргаланып-үрсәләнеп ыңгыраша иде.

—Мин бит аны шундый яраттым, шундый көттем!.. Без бит бергә булырга тиеш идек!.. Нигә болай булды соң, әнкәй?! Нигә мин шулкадәр бәхетсез?.. Ходай тәгалә кайда соң? Юктыр ул! Булса, минем яратуымны күрер иде! И, әнкәй... Хәлим ялгыз йөргәндә тынычрак идем әле... Бәлки мине үзенә алыр, хатыны итәр, дип яши идем... Ә хәзер... Хәзер минем ул өметем дә сүнде... Нишләргә инде, ә, әнкәй?.. Кая барыйм, ниләр эшлим?.. Әллә үләргә микән?..

—Ни сөйлисен син, кызым, тәүбә диген! Авызыңнан җил алсын, кайгы чыгарып утырма. Токымың туарга тора, ә син үлем турында сөйлисең...

—Яшәвем дә шул балам өчен генә минем, авырлы булмасам, күптән үзем белән бер-бер хәл кылган булыр идем, билләһи!.. Яшәве бигрәкләр дә авыр бит мина, әнкәй, беләсенме шуны?!.

Озак юандылар алар. Бер-берсенең күңелен күрергә, җаннарын тынычландырырга тырышып, матур, якты сүзләр эзләделәр, тапсалар, сөенә-сөенә, шундый ук матур, якты хискә төреп дөньяга чыгарырга ашыктылар... Ана белән бала арасында гына була торган хисләр дөньясында яшәделәр алар бу минутта. Күп сөйләшмәделәр дә. Күзгә күз карау да, бармак очы белән кагылу, яисә уч төбе белән сыйпап-назлап кую да аларның кешелек асылына төшә, иң тирәндә яткан серләрен кузгата, басылыбрак калган хисләрен уята, әллә нинди тирән мәгънәләрне, дөньяви уй-ниятләрне калкытып куя, күңелләрен яшәешкә дәртләндерә иде.

Башын әнкәсенең күкрәгенә салган килеш, монаеп утырган Нәфисә йоклап китте. Тәскирә, акрын гына кузгалып, сак кына тотып, кызының башын тау кебек өелеп торган мендәрләр өстенә күчереп куйды, өстенә шәлъяулыгын япты. Аннары бер адым артка чикте дә, бик күп еллар буе бөтен тормыш гамен, яшәү ачысын, югалтулар сагышын үзенә җыеп барган күзләрен мөлдерәтеп, мәче баласы кебек бөгәрләнеп йоклап яткан кызына озак кына карап торды. Бераздан айнып-сискәнеп киткәндәй булды, ярым пышылдап: "Ходай үзе ташламасын!"—диде дә ашыгып чыгып китте. Ул бу минутта шулкадәр ышанычлы, ныклы адымнар белән атлады ки, тау-кыяларны ишеп каршысына килгән гарасат-давыл да аны туктата алмас кебек иде. Ул җил-җил атлап урамга чыкты, капкасын ябарга да онытып, кызу адымнар белән югары очка табан китте. Сизгер укучы аңлап алгандыр, Тәскирәнең бүгенге юлы туп-туры Санияләр капкасына барып төртеләчәк иде.

Сания Тәскирәне сагаебрак каршылады. Ул инде Нәфисәнең галәмәтләре хакында ишеткән иде. Тәскирәнең бу килүе аның кызы белән бәйле булуын бик тиз сизенеп алды. Шуңа күрә бик ачылып китмәде ул. Коры гына: "Әйдә, уз",—диде дә урындык куйды. Үзе, юеш кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә мич янына барып, тәбәнәк кенә эскәмиягә чүкте. Бер тын тик утырдылар. Тәскирә өй эчен күзәтте. Өй уртасында түшәмгә беркетелгән сиртмәдә асылынып торган бишеккә аеруча озак карап торды ул. Ниһаять "теле ачылды":

—Хәлим кайда соң?

Сания аның Хәлим янына килүен чамалаган иде инде. Димәк, Нәфисә җибәргән? Тагын янарыр микәни бу күңел газаплары? Инде тынычлана башлагач кына...

—Юк шул, өйдә юк шул әле...

Саниянең сүзе шунда өзелеп калды. Сүзен генә түгел, бөтен күңел кылларын өзгәләп, ишек шыгырдап ачылып китте дә аннан олы-олы атлап Хәлим килеп керде.

Тәскирәне күрүгә, ул да, басылып, сагаеп калды. Хәтта исәнләшергә дә онытты. Сания, урыныннан торып, кунакка ымлады:

—Тәскирә апаң белән исәнләш...

—Исәнме-саумы, Тәскирә апа...

—Исән, бик исән, Хәлим...

Шунда Тәскирәгә әллә нәрсә булды. Ул, учлары белән йөзен каплап, елап җибәрде.

—И-и, улым... Хәлләребез бер дә әйбәт түгел шул... Нәфисәне җен алыштырды.... Якты дөньядан гайрәте чикте... Сез кайтканнан бирле телендә гел бер сүз: "Хәлим" дә "Хәлим"... Акылга җиңеләймәсен дип тә курка башладым инде. Җиңеләймәсә, өй саен кереп, чи гайбәт сөйләп йөрмәс иде... Килүем дә шуңа, Хәлимкәем. Сөйләшеп карыйсыңмы әллә үзе белән? Аңлатсаң, төшендерсәң, бәлки, бераз басылыр иде.

Аптыраганнан әйтәм инде. Ачуланма, яме... Теләмәсәң, йөрмә...

—Ярар, сөйләшеп карармын, Тәскирә апа. Борчылмагыз, барысы да әйбәт булыр...

Шунда сүзгә Сания кушылды:

—Кирәк микән, балам? Күңелен генә үртәрсең бит?..

—Кирәк, әнкәй, кирәк. Башта ук сөйләшергә, аңлашырга кирәк иде безгә.—Хәлим бу сүзләрне нык итеп, бәхәскә, шик-шөбһәгә урын калдырмаслык итеп әйтте.

—Рәхмәт, балам.—Тәскирә китәргә кузгалды. Сания аны чәйгә калырга димләсә дә, Тәскирә ниятеннән кайтмады, ишеккә юнәлде. Әмма ишек тоткасына кагыла алмый калды, аның каршына кипкән керләр күтәреп кереп килүче Майя очрады.

Шунда Тәскирәгә әллә нәрсә булды. Ул, Майяны күрүгә, күзләрен шар ачып катып калды, аннары акрын гына артка чүгә башлады. Ул шулай чүгә-чүгә егылып та киткән булыр иде, мөгаен, аны ике ягыннан Сания белән Хәлим генә тотып калды.

—Си-и-н?

Тәскирә тәмам йомшап төште. Әмма аның басып торырлык кына, Майяга таба ике-өч адым атларлык кына хәле булган икән. Менә ул, Сания белән Хәлимнән аерылып ишеккә омтылды, керләрен күкрәгенә кыскан килеш ишек төбендә аптырап калган Майяны кочаклап алды:

—Кызым минем!..

Нәрсә? "Кызым" диме? Сания белән Хәлим берни дә аңламадылар. Майяны әйтәсе дә юк. Ул да чак-чак кына басып тора иде булса кирәк, артка чигеп, аркасы белән ишек яңагына сөялде. Үзе мөлдерәмә күзләре белән: "Коткарыгыз мине бу хәлдән",—дип ялваргандай, әле Саниягә, әле Хәлимгә карады.

—Ни сөйлисең син, Тәскирә, нинди кызың булсын ул синең? Бу бит Мәйя, минем киленем, Хәлимнең хатыны... Ә синең Нәфисәң авылда, үзең белән...

Шунда Сания тотлыгып калды, хәтта, бермәлгә аңын югалта язды. Бу төш кенә түгелме, дигән кебек, ул күзләрен йомып алды да тагын Майяга тутырып карады: Сания каршында башка беркем дә түгел, Тәскирә белән Фәнил кызы—Нәфисә үзе басып тора иде! Ничек килеп чыккан соң монда Нәфисә? Әнә бит—чәчләре дә аныкы—озын, кара, дулкынланып-уйнап тора, күзләре, йөз чалымнары да, хәтта караш-ымнары да шуныкы!

Хәлим дә шундыйрак тойгылар кичерә иде булса кирәк. Баскан җирендә кадакланган кебек, бик озак һәм бик текәлеп, хәтта аны танымаган кебек, Майяга карап торды. Нишләп элек шәйләмәгән соң ул моны? Аның Майясы бик тә, бик тә Нәфисәгә охшаган лабаса! Әллә тагын берәр сихер галәмәтеме бу? Юк, шул ук Майя! Аның сөйгәне, бердәнбере. Тик... ничек күрмәгән соң ул бу охшашлыкны?

Майяны кочаклап торган Тәскирә, ниһаять, исенә-аңына килде. Артка тайпылып, аска караган килеш: "Ходаем, барлык гөнаһларым өчен кичер мине",—дип үрсәләнде дә ашыгып чыгып китте.

Өй эчендә, һәрберсе үз уй-хисләренә күмелеп, өч җан калды. Дүртенчесенең—Нәфисәнең шәүләсе дә кайдадыр шушында гына йөри кебек, әмма аны беркем дә күрми. Шулай да, Майяның үткәненә Нәфисәнең нindидер катнашы булуын Хәлим дә, Сания дә чамалап алганнар иде инде. Бу олы сернең ачкычы Тәскирә кулында булуы да шик уятмый. Киләчәктә тормышларының тагын да катлауланачагын, көтелмәгән борылмаларга кереп китәчәген, шактый изалап интектерәчәген сизенеп, сагаеп-шомланып торган ана белән балага, бигрәк тә гөнаһсыз урман кызына карап, иң каты бәгырьле адәмнең дә үзәге өзелер, җаны сыкрар иде бу минутта.

## XVI

Тәскирә ничек өенә кайтып житкәнен дә хәтерләми. Өенә килеп кергәндә түшәктә йоклап калган Нәфисә юк иде инде. Ишек-капкалар шар ачык, ишегалды тулып йөргән чебешләр бөтен урамга таралган...

Уйланырлык, күнел кузгатырлык гамьнәр, уйлар төште шул анын башына. Күпме еллар буе күнел төпкелендә яткан хәтер ташы белән бастырылып торган һәм һәр ягыннан кан саркыган олы сергә кагылды ул бүген.

Ул көннәрдән соң күп сулар акты, әмма Тәскирә бүгенгедәй ачык хәтерли: Фәниле белән яратышып өйләнештеләр. Бик тиз балага узды. Күрше әби-апалар башта ук юрап куйдылар: корсагы аска төртеп тора— игезәк булачак. Ул елны сыерлары да игезәк бозау китерде, Бөдрә дигән олы сарыклары да игезәк бәрән бүләк итте. Маймунә карчыкны чакырып китап ачтырганда да берничә мәртәбә "пар әлиф" кә чыкты.

Игезәкләр туасына Тәскирә үзе дә тәмам ышанып бетте, ирен дә ышандырды. Котылыр вакытка да күп калмаган иде инде, көзге янгырлар чоры башланды. Ул вакытта таш юллар юк иде. Янгырлар чорында Кампәрлегә кереп тә, аннан чыгып та булмый. Хәтта, урамдагы ут күршеләр дә бер-берсе белән сирәк аралашалар. Атна буе коеп торган шундый бер кара янгыр вакытында, төн генә кунып чыгырга дип, аларга ике юлчы карчык килеп керде. Сонгы жепләренә кадәр чыланган карчыкларны Тәскирә кызганды, төнгә үзләрендә калдырды. Фәнил дә каршы килмәде, бала тавышы янгыраячак нигезгә дога кылып, Алла сүзе индереп чыгарлар, дип сөенеп тә куйды әле.

Төнлә Тәскирәне тулгак тота башлады. Юк, башта алар чөкердәшеп сөйләшә-сөйләшә урын-жир түшәделәр, аннары, тәмле төшләр теләшеп, йокларга яттылар. Әбиләргә идәнгә жәйделәр.

Төн урталарында Тәскирә басылып уянып китте. Үзе бертуктаусыз укшый, эчендәге жан бөртекләре, тизрәк якты дөньяга чыгаруны сорап, тибенә башладылар.

Фәнил:

—Хәзер күршеләргә кереп чыгам, Рәхимә абыстайны алып киләм, аз гына көт...—дип чыгарга гына жыенган иде, Тәскирә тирәсендә бөтерелгән карчыкларның берсе аны туктатып калды:

—Хатынынны ташлама, ярамый, ә тулгагында үзебез булышырбыз, безнең бала алганыбыз бар, тизрәк кайнар су әзерлә, ак жәймәләренне китер,—диде дә, жиннәрен сызганып, Тәскирә үрсәләнеп яткан түр караватка табан китте.

Калганы төш кебек кенә. Тәскирә куе томан үтәли чагылып киткән жыерчыклы йөзләрне ачык хәтерли. Аннары бик хәтәр авырту... жаны өзелдемени! Бала тавышы... Бераздан тагын жан тамыры тартылгандай булды, тагын бала тавышы... Әйе-әйе, Тәскирә ап-ачык хәтерли: ике мәртәбә бушанды ул. "Игезәкләр дип дөрес әйткәннәр икән", дип уйлап та куйды әле. Әмма, зиһенен туплап, исенә-аңына килгәндә, менә бит нинди хикмәтле хәлләр, янында иреннәрен чәпелдәтеп бер бала гына ята иде. Ире янында утыра. Теге карчыклар күренмиләр... Күрше Рәхимә карчыкны чакырып кerткәннәр—мич артыннан анын таныш тавышы ишетелә. Фәнилнең авыл башында торган Зәйтүнә исемле апасы да шунда гына бөтерелә.

Тәскирәнең күнеленә шундук шом йөгерде. Исән-сау котылуына, баласы янында булуына сөенеп кенә ятасы да соң, юк, төнге гыйбрәтләр һич кенә дә анын хәтереннән китми жәфаладылар... Бу эчке бәгырь сызланулары бик озакка барды, дәресрәге, гомерлеккә калды. Әмма Тәскирә үзенең шик-шөбһәләре хакында иренә дә, туганнарына да әйтмәде, бөтен мәхәббәтен, күнел жылысын Нәфисәсенә биреп, эченнән генә сызып гомер кичерде. Фәниленең кинәт кенә авырып китүе, жир

куенына керүе дә шушы сер белән бәйләнмәгән микән, дип бер уйлана башлаган иде дә, бераздан бу уйлар тибеп чыккан күнел чишмәсен томалап куя алды, аннары хәтер савытының капкачын бөтенләй каплап куйды.

Тәскирә ул кадәр җүләр түгел лә, бик аңлый: Хәлим иярләп кайткан хатын-кыз ничек Нәфисәсенең игезәк туганы булсын ди?! Бу мөмкин түгел хәл. Бәй... Нигә соң, алайса, аны күрү белән, Тәскирәнең күңеле җилкенеп, җаны тетрәп китте, күз алдында Нәфисәсенең сурәте пәйда булды? Юк, бу ниндидер тышкы охшашлык кына түгел иде, Тәскирә үзенең бөтен эчке җан һәм кан тамырлары белән тойды: ишектән килеп кергән кыз-хатын— аның хәләле, газизе...

Тәскирәнең күңеленә ургылып ике хис килеп керде. Берсе—сөенеч хисе, хәтта, өмет тойгысы. Күп еллар элек югалткан кызын табар кебек иде ул. Икенчедән, аның күңелендә шомлы уйлар гарасаты купты. Йөрәгендәге иң авыр җәрәхәтләр ачылды, әрнүле хатирәләр янарды. Юк, игезәкләрнең берсе югалу белән, ике серле карчык белән, иренең үлеме белән бәйле хатирәләр генә түгел, тагын да элгәрерәк булган вакыйгалар хәтеренә төшеп, ул әллә нинди караңгы, ямьсез уйлар дәрьясына кереп чумды...

...Биатай булган кеше—Казык Мәмәт карт— үләр алдыннан улы Фәнил белән килене Тәскирәне чакырып китерде дә, тәрәз каршындагы тупыл агачына ымлап:

—Кисеп атыгыз моны. Ул бу нигезгә афәт китерәчәк,—дигән иде.

Картның сүзенә игътибар итмәделәр. Саташа, ахры, агачның ни гаебе бар инде?—диделәр. Чынлап та, үләр алдыннан Казык Мәмәт бик мәзәк тотты үзен. Ниндидер җен-шайтаннар белән тарткалашып, албастылар белән алышып ятты. "Бу минем җир... Үзегез китегез..." - дип, ниндидер җир, нигез өчен көрәшеп, үзен дә, башкаларны да йокыдан мәхрүм итте.

"Казык" дигәннән, Фәнил сөйли иде: бу кушамат шушы авылга килеп утырган иң борынгы бабасыннан калган. Шушы тупыл төбендәге алачыкта яшәп яткан бер дивана карттан күчкән аңа бу нигез. Дивана булса да, аның янына оныклары килеп йөргән. Көннәрдән бер көнне әлеге дивана җан тәслим кылган, аны күмәргә әллә кайлардан бөтен туган-тумачасы җыелган. Барысы да кара җиләннән, өскә очлаеп киткән башлыктан икән. Үзләре сәер догалар пышылдыйлар, ниндидер агач курчаклар, таш тылсымнар тотып сөйләшәләр, сихри-зәхмәти йолалар башкаралар, имеш.

Фәнилнең нәсел бабасы түзеп торган-торган да, бер көнне теге алачыкка ут төрткән. Шулай итеп кара сихердән, яман зәхмәттән котылмакчы булган ул. Дивана картны күмеп кайтып, үзләренең зәхмәти догаларын башкаручы сихерчеләрнең җидесе шунда янып үлгән, калганнары бу урынны ташлап киткән. Сихер кагылмасын өчен, Фәнилнең ерак бабасы исә шушы янган алачык урынына усак казык кага да анын башына әлеге алачык урыныннан табылган баш сөяген элеп куя... Бер күкрәүле-яшенле яңгыр вакытында ул баш сөяге юкка чыга, әмма Фәнилләр нәселе кешеләренә "Казык" кушаматы мәңгелеккә тагылып кала. Шундый сүзләр дә йөри: бу нигездә яшәгән ир-атларның берсе дә үз үлеме белән үлми, имеш.

Һәркемгә мәгълүм: Тәскирәләр урыны—авылның тап үзәге. Төбәккә нигез салучы урман кешеләренең беренче алачыгы да шушында салынган, диләр, дөрес булса. Шул вакыттагы кара урманнарга шомлы ишарә булып, көне-төне шыбырдап утыручы ялгыз тупыл агачы гына калган. Картлар аның хакында "җанлы", "рухлы" дип тә сөйләнәләр. Шул тупыл агачын кисәргә кушкан да инде Мәмәт карт.

Менә шундый шомлы хатирәләр янарды Тәскирәнең изаланып беткән күңелендә. Ул бу дөньяда япа-ялгыз калганын тойды. Моңарчы кызы белән аңлашып яши иде әле. Бүген анысы да башка борчулар

белән йөри, Хәлимгә булган мәхәббәте ан-зиһенен томалаган, аның яшәү гамен алган, хәтта, туачак сабыен да онытырлык хәлгә житкергән.

Хәзер ничек яшәргә инде? Бер Ходайга сыенырга да бертуктаусыз авыртып торган жан-бәгырьгә таянырга кала.

"Әмәнтә билләһи вә мәләпкәтиһи вә көтөбиһи вә рәсилиһи вәлйәүмиләхири вәлкадәри хайриһи вә бәгъдәл-мәүти... Инандым Аллаһы тәгаләгә, аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә дәхи ахирәт көненә һәм тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһы тәгаләдән булуына һәм үлгәннән соң янә терелүгә..."

## XVII

Саниягә тормыш көннән-көн кыенлашты. Күзе тәмам күрмәс булып, жир йөзендә яшәү аның өчен олы газапка әверелде. Бәрелеп-сугылып йөри торгач, йорт-кура тирәсен өйрәнсә дә, ул инде урамга, авыл арасына чыгып йөрми, күп вакытын өйдә, тәрәз каршында утырып үткәрә.

Хәлим белән Майяны иң гажәпләндергәне шул: әнкәләре әллә ни борчылган, кайгырган кебек тә түгел. Тыныч, сабыр гына бер урында утыра да утыра, кайчакта белгән догаларын пышылдый, кайчакта, бигрәк тә кеше юклыгын сизсә, ниндидер моңлы көйләр көйли...

Елга буйларында сары чәчәк,
Сары чәчәк саен күбәләк...
Әллә күзләремнән яшьләр ага
Әллә болытлары тәбәнәк?..

Анысы дөрес: Саниянең фажигасен күреп, Хәлим белән Майядан да ныграк өзгәләнгән кеше булмагандыр. Әмма авыл кешеләре дә авыр кичерделәр бу хәлне, Санияне жәлләп-кызганып сөйләшмәгән кеше калмагандыр. Шулай да, кереп хәл белүче, жылы сүз әйтүче күп булмады. Бу нигездәге сихер аларга да йогар, Сания янына керсәләр, авыруы күчәр, иярер, дип шикләнделәр ахры. Хәлимнең ниндидер хатын-кыз һәм сабый бала ияртеп кайтуы тынгылык бирмәде авыл кешеләренә. Нәфисәнең коткы таратып йөрүе дә үзенекен эшләми калмагандыр. Ничек кенә булмасын, авыл Санияләрдән читләште... Әмма бер вакыйга халыкны уятып жибәрде һәм Хәлимнәргә мөнәсәбәтне үзгәртергә мәжбүр итте.

Бу вакыйга да Саниянең авыруы белән бәйләнгән иде. Баштарак Хәлим, әнисен дәвалау өчен, район үзәгеннән табиблар чакыртып карады. Килгән белгечләр исә: "Күзләре үлеп бара, берни дә эшләп булмый",— дип сөйләнделәр дә ашык-пошык жыенып китеп бардылар. Мәймүнә карчык та өшкереп карады. Ул төтәсләгән йорт атна буе сасы ис аңкытып утырды, әмма Саниянең күз алдында эленеп торган кара пәрдә гаиб булмады.

Көннәрдән бер көнне Майя Хәлимгә әйтеп куйды: "Сания әнкәнең күзләрен үзем камлап карыйм әле. Мин моның серен беләм. Әбиләрнең күз имен искә төшерәм дә..."

Хәлим шаклар катып торды. Ничек башта ук бу хакта уйламаган ул? Майя күп имнәр, тылсымнар, әфсеннәр белә бит. Сихер кайтарулар, өшкерү-төчкерүләр аның өчен гадәти хәл... Чынлап та, бәлки ул әнкәсенең күзен каплаган кара пәрдәне юып ташлый алыр, яман сихерне кайтарыр?

Саниягә иплэп, жайлап кына ачылдылар. Әнкәләре шунда ук кырт кисте:

—Бала имезгән хатын сихердән, әфсен-төфсеннән ерак йөрергә тиеш. Явыз көчләрнең ана сөте белән балага кереп кала торган гадәте бар, юк-юк, өшкертәмме соң!.. Нишлисең, тәкъдиремә шулай язылгандыр. Менә бит—янымда сез бар, сез булганда берниндә кыенлык та тоймыйм мин, балалар, бер дә борчылмагыз...

Ахырдан килеште тагы. "Бу бер дә кара им-том түгел, иң гадәти дәва гына",—дип ышандырдылар аны. "Ярый, алайса, тик Гөләш өйдә булмасын",—дигән шарт белән яшьләр ихтыярына буйсынды Сания. Төрле табиблардан, имче карчыклардан ялыккан әнкәләрен озак тилмертмәделәр, якын көннәрнең берсендә тәвәккәлләделәр. Берничә көн әзерләнеп үтте. Икәүләп урманга барып килделәр. Иртәнге сәгать биштән торып, Гөләшне ашатып йокыга салгач чыгып киткәннәр иде, бер кочак үлән, куак ботагы, агач гөмбәсе, кыргый җимеш күтәреп, арып-алҗып кайтып егылдылар. Шул көнне үк Майя төрле үлән, кайры, гөмбә, җимеш оннары ясарга кереште. Һәр таңда торып, ялан үләненнән таң суы җыеп алдылар. Дәва өчен тартылган оннарны Тәнре юынган чакта җиргә чәчрәп калган шушы чык тамчыларына изәргә кирәк, имеш...

Ниһаять, изге сәгать сукты. Гөләшне Васимә карчыкка кертеп куйдылар. Ак бабай Саниягә дә, Майяга да Коръән телендә фатихасын биреп чыкты. Менә өй эчендә өчесе генә торып калдылар. Хәлим алар ягында булырга теләсә дә, Майя аңа чыгып китәргә кушты, аны әнкәсе белән ялгыз кадыруны сорады. Хәлимнең күңелендә хатынына карата үпкә хисе кузгалды. Ничек инде, малае була торып, әнкәсе янында торырга ярамасын ди?! Шулай да, каршы килмәде, өйдә газизләрен калдырып, тышка чыгып китте, чынлыкта, үз эченә кереп бикләнде. Ә уйлыйсы уйлар уй янчыгында шактый җыелып өлгергән икән...

Чынлап та, Майя белән Гөләшне авылга алып кайтканнан бирле Хәлимнең ныклап уйланганы, хәтта ялгыз калганы да булмаган икән. Ә бит уйланыр уйлар, борчылыр борчулар җитәрлек. Иң элек теге урман карчыклары тынгы бирми Хәлим йөрәгенә. Алар хәзер ни хәлдә икән? Исән-саулармы? Исән-сау булсалар, ник Майяны эзләп килмиләр? Нигә эзәрлекләмиләр? Карчыклар, мөгаен, аларның кайда икәнлеген дә беләләрдер... Бу бик сәер...

Икенче борчыган нәрсә—Нәфисәнең кыланмышлары. Ул үзенең гайбәте белән бөтен авылны Хәлимгә каршы куйды. Аларның өен урап узалар, аралашмаска тырышалар, төрле коткы сүзләр тараталар...

Инде менә әнкәсенең авырып китүе. Кычкырып әйтмәсәләр дә, кешеләр Саниянең сукыраюын Хәлимгә ияреп кайткан зәхмәттән күрәләр. Майяга да, Гөләшкә дә шикләнеп карыйлар. Хәлим белә: болай озак яшәп булмаячак. Майяга да кыен, Хәлимнең үзенә дә. Хәлим үзе белән булган хәлләрне батырларча кичерсә дә, инде әнкәсенең дөм сукыр булып калуына ничек чыдар? Көн яктысы күрмичә яшәү—иң зур газапларның берседер ул... Их, Майясы гына, Аллаһы тәгаләнең язганы белән, үзе белгән урман рухлары ярдәме белән, әнкәсенең күзен кайтара алсын иде!.. Нинди зур шатлык булыр иде! Кешеләрнең шик-шөбһәләре шундук юкка чыгар иде, иң мөһиме, әнкәсенә якты дөнья кайтыр иде...

Майя Сания янында ике сәгать торып чыкты. Чыкты да томаланган тәрәз капкачларын ачып җибәрде, тир бөрчекләре бәреп чыккан, бераз алсуланыбрак киткән йөзен үлән исләре аңкытып торган куллары белән сыпырып алды, аннары Хәлим янәшәсенә утырды, башын аның кулбашына куеп, күзләрен йомды, бераздан йомшак кына итеп: "Әнкәйнең күзләре күрәчәк,"—диде. Хәлим бер сүз дә әйтмәде, олы авыр куллары белән хатынын кочаклап алды, күкрәгенә кысып, баш түбәсеннән үпте...

Сания янына кичкә табан гына керделәр. Керер алдыннан Майя Хәлимгә Ак бабайны, Васимә карчыкны чакырырга кушты. Бер төркем кеше өй эченә килеп кергәндә Сания йоклый иде әле. Түр түшәктә яткан әнкәсен Хәлим баштарак танымый торды. Аяк өстенә кадәр ап-ак күлмәк киеп яткан Сания бу минутта изгеләрнең изгесе булып күренде аның күзенә. Йөзе дә ап-ак, күзләренә капланган тасма да ак төстә иде. Һәркем әнә шул ак тасмага төбәлеп, тукталып калды. Гүя Саниянең язмышы, юк, бу өй эчендәге һәркемнең язмышы шушы тасмадан торгандай тоелды. Бу тасмада сер бар кебек: аның астында йә бәхет, йә бәхетсезлек; йә яктылык, йә дөм караңгылык...

Бу минутта дөньяга Майя хуҗа иде. Ул имләде, ул барысын җыеп алып керде, ул беренче булып әнкәсенә эндәште:

—Әнкәй, торасынмы инде, вакыт җитте, күзләренне ач...

Саниягә шул да җитте. Ул уянды. Бераз сискәнебрәк куйды. Әмма сер бирмәде, сикереп торып та утырды, тыныч кына:

—Әү, кызым... Булды дамыни?—дип сорады.

—Булды, әнкәй... Хәзер күзләренне ачарсын, яме...—Майя Саниянен күзләрен каплап торган ак тасманы читкә алып куйды.—Әйдә, ач инде... Әнкәй, күзенне ач...

—И кызым, ачарга куркам бит...

—Барысы да әйбәт булыр, ач күзләренне, әнкәй, курыкма.

—Ачыйм микән?..—Ул, күзләрен йомган килеш, ун кулын алга сузды.—Улым, бир әле кулынны. Синен кулынны, кан тибешенне тоясым килә...

Хәлим, үрелеп, сак кына әнкәсенен кулын үз учына алды. Алды да:

—Ач, әнкәй, күзләренне, күнелем сизә—барысы да әйбәт булыр. Майя да шулай ди...

—Хәзер, хәзер, балам... Хәзер ачам...

Шулвакыт Саниянен йомык күзләре дертләп-калтыранып киттеләр. Тагы бер мизгелдән чем кара матур, нурлы-балкышлы, дөньяга тутырып, йотылып карап тора торган күз алмалары якты дөньга томырылып чыктылар...

Бөтенесе дә "ах" итте. Чөнки өй эчендәгеләр Саниянен күргәнен күрделәр. Моны күрми, сизми мөмкин түгел иде. Сания үзе исә күзләре ачылуга әзер үк түгел иде булса кирәк, берара ярымһушсыз хәлендә ятты әле.

Ниһаять, ул тагын торып утырды, кискен борылып тәрәзәгә карады, аннары янында басып торган кешеләрнен һәрберсен аерым-аерым карый башлады. Менә анын сонгы көрчегенә җитеп ачылган күзләре Майяга килеп җиттеләр. Җиттеләр дә озакка туктап калдылар. Бераздан ул исенә-анына килде, әмма карашын читкә алмады, шулай төбәлеп торган килеш Майяга омтылды. Үзе елый-елый тәкърарларга кереште:

—И-и, кызым минем, җаным-бәгърем минем, мен рәхмәтләр сина, изге бәндә икәнсен, Алла кешесе икәнсен, ничек кенә кайтарырмын икән бу изгелегенне...

Саниянен кинәт кенә күрә башлавы башкаларга да нык тәэсир иткән: Ак бабай бармак очларында дисбесен йөгертә-йөгертә, догаларын пышылдый, Васимә карчык үзалдына мен төрле теләк тели, ә Хәлим, әнкәсе янына тезләнеп, анын кулларын үбә... Ниндидер серле-илаһи мизгел иде бу. Җир тормышы түгел, башка төрле дөнья, төш дөньясы кебек... Һәрхәлдә, читтән берәрсе күреп калса, йә болар кумәкләшеп акылдан шашканнар, йә җыелышып сәер бер йола башкаралар, дип уйлар иде, мөгаен.

...Санияләр өендә булган галәмәт хәлләр хакында хәбәр авылга бик тиз таралды. Башта ышанмадылар. Сания урамга, кибеткә, авыл арасына чыгып йөри башлагач кына кешеләр тау башындагы алтынсу-сары йортка берәмләп тә, төркем-төркем дә агыла башладылар. Бу тылсымлы галәмәткә үз күзләре белән күреп ышану өчен килгәннәрнен исәбе-хисабы булмас кебек иде. Кемдер Сания янына, икенчеләр Майяны күрергә, ана гомер буе җәфалап интектергән хәтәр авырулары хакында сөйләргә, шифа-дәва сорарга керде. Сания дә, Майя да килгәннәрне ачык йөз, такта чәй белән каршы алдылар, озаклап сөйләшеп утырудан да тайчанмадылар. Майя кайбер авыруларга шундук ярдәм күрсәтте, кинәшләр бирде, кайберәүләренен өйләренә үк барырга, чирләрен шунда дәваларга риза булды...

Чынлап та, бер атна үтмәгәндер, Майянын шифалы кулы авылдагы тагын берничә авыруны аякка бастырды, хәтта, үлем авыруы тигән

Мөсәллим карт та, таягына таянып булса да, капка төбендәге әскәмиягә чыгып утыра башлады.

Хәл үзгәрде. Моңа кадәр сагаеп, читләшеп яшәгән авыл халкы өчен Саниялар йорты берничә көн эчендә Дөньяның үзәгенә, Галәм киңлеге урнашкан изге урынга әверелде. Бу хәл бер шатландырды, бер сагайтты Хәлимне. Шатлануы аңлашыла, ә менә сагаюы Майя хакындагы хәбәрләрнең тирә-якка бик тиз таралу белән бәйләнгән иде. Шомланырга, сагаерга сәбәп тә бар: Майяның тылсымлы шифасын эзләп күрше-тирә авыллардан ук килә башлаганнар иде шул.

Авылда Майяга мөкиббән китмәгән бер генә кеше калгандыр. Нәфисә генә. Ул Майяның тылсымлы шифасын да каршы юнәлешкә борып җибәрергә тырышты. Өй борынча кереп: "Ул сезне шулай үзенә карата да соныннан хәтәр афәткә юлыктыра, сак булыгыз!.."—дип кисәтеп тә йөргән, диләр.

Хәлим урынлы шомланган икән. Майяның халык арасындагы даны буйлап, таныш урман карчыклары Кампәрлегә бик тиз килеп җиттеләр. Җиттеләр дә, бөтен авылны афәт шаукымы белән өркетеп, ничек килгән булсалар шулай китеп тә бардылар.

## XVIII

Алар авылга көтмәгәндә, бөтен кеше басуда, урманда чакта, кызу эш өстендә килеп керделәр. Шул ук кара киемдә, башларына очлаеп торган кара башлык кигәннәр, аркаларында юл капчыгы, кулларында кара таяк. Урман авызыннан килеп чыккан бу сәер затлар туп-туры Саниялар йортына юнәлделәр, әмма эчкә кермәделәр, йорт каршындагы яшел чирәмгә җәелеп утырдылар.

Баштарак аларны беркем дә шәйләмәде. Югыйсә барысы да өйдә иде: Сания мендәр тышлыгы алыштырып йөри, Хәлим балта үткерли, ә Майя бала имезеп утыра... Беренче булып Майя сизенде. Аңа кинәт әллә нәрсә булды: ул баласын көчләп диярлек күкрәгеннән аерып, читкә алып куйды, тораташ булып каткан килеш, урыныннан торды, туп-туры түр тәрәзәгә карап китте. Ак-бүз пәрдәнең читен күтәреп карады. Бу юлы да сәер тотты ул үзен. Пәрдәне күтәрә башлавы булды, шундук ябып та куйды. Ул бик хисләнгән, дулкынланган иде. Шул иләс-миләс хәлендә ул өй эченә карап басты да, юка матур иреннәре арасыннан: "Килделәр..."—дигән бердәнбер сүзне кысып чыгарды. Барысы да аңлады: ниһаять, көткән кунаклар килде. Алда нәрсә буласын, белсә дә, Аллаһы тәгалә үзе генә беләдер...

Сания, йөгереп барып, ишекнең келәсен төшерде, тәрәзәләрне томалап куйды. Аннары гына үз алдына сөйләнгәндәй: "Беркая да чыкмыйбыз, торырлар-торырлар да китеп барырлар",—диде. Аның сүзләре белән килешкәндәй, Хәлим дә, Майя да, бер сүз эндәшмичә, күкрәк балаларын күтәреп, мич янындагы тар сәкегә барып утырдылар.

Сания ялгышты. Карчыклар китмәделәр. Бер сәгать узды, ике, өч сәгать... Майя борчыла башлады. Хәлим дә бертуктаусыз ишекле-түрле йөренде. Баланы үз кулына алган Сания дә күнеленнән белгән догаларын ярдәмгә чакырды. Нидер сизенгән кебек, кинәт Гөләш елый башлады. Шул бала тавышы барысын да хәл итте ахры. Майя, җәһәт кенә торып, чыгарга җыена башлады. Хәлим берничә мәртәбә җан тавышы белән:

—Майя! Майя!..—дип караса да, хатын үзенекен итте, беренче төнне Сания биргән бөтиләрен күкрәкчәсе эченә урнаштырып, яулыгына җиде төен төйнәп (шайтан шуны чишеп интеккәнче, зәхмәт кагылмый, янәсе), ишек катына юнәлде. Хәлим дә аның артыннан омтылган иде, Майя шып туктатты:

—Юк, сиңа ярамый. Әбиләр минем белән сөйләшергә телиләр.

Борчылма, берни булмас, алар элеккеге түгел инде, теге янгыр шаукымы көчләрен нык бетергән. Мин моны сизәм...

Шулай жилләнеп чыгып китте ул. Артыннан ишек кенә ухылдап калды. Сания дә, Хәлим дә дәррәү тәрәзәгә ябырылдылар.

Юкка борчылганнар икән. Урамда куркырлык берни дә булмады. Карчыклар Майяны үтә дә тыныч каршы алдылар. Читкәрәк китеп торган танышларын кабат очраткандай, әллә ни исләре китмичә генә, сабыр гына сүз башладылар. Башта берсе сөйләде, аннары икенчесе. Урман ягына төртеп күрсәтә-күрсәтә, нидер анлатырга керешге.

Майя баштарак берни дәшмәде, сөйләшмәде... Икенче карчык түбән оч ягына күрсәтә башлагач кына, кулларын кискен жилпи-жилпи сөйләп китте.

Хәлим аның сүзләрен ишетмәде. Әмма төгәл анлады: сүз урман хакында бара... Кабат алып китмәкче булалармы әллә? Тагын нинди бәлаләр юрап йөриләр икән бу албастылар... Хәлим кызу-кызу киенә башлады. Сания аның юлын бүлде:

—Ярамый диде бит... Түз, балам... Хәзер китәрләр алар. Күнелем сизә, китәрләр. Чыгып, бөтенесен дә бозып куюын бар...

Чынлап та, теге урман затлары, тагын бераз таптанып торганнан соң, Майя белән тиз-тиз генә хушлашып, киту ягына кузгалдылар. Майя исә, урман авызына кереп югалганчы, аларның артыннан карап торды, аннары ашыга-ашыга капкага юнәлде...

Кергәч Майя барысын да жентекләп сөйләр дип уйлаганнар иде, нык ялгыштылар. Хатын борчулы йөзен яшереп булашмады.

—Әбиләр минем белән хушлаштылар, калганын сөйләмим, вакыт житкәч сөйләрмен әле...—диде дә өзде, кабатлап сорарлыкны калдырмады.

Хәлим дә, Сания дә башка төпченмәделәр. Ин мөһиме, барысы да исән-сау, бергә. Тагын ни кирәк адәм баласына... Афәт ияләре бер зыян салмыйча китеп барганнар икән, димәк, Аллаһы тәгалә бүген үз бәндәләрен саклап кала алды, шул гына...

Ә, юк... Алай тиз генә котыла алмадылар алар бу зәхмәти карчыклардан. Майяның күнеленә ниндидер шом салып киттеләр алар... Шул көннән соң хатынының нык үзгәргәнен тойды Хәлим. Әллә ничек кенә, үз эченә кереп бикләнде Майя... Авыл тормышына күнегеп, дәртләнеп яши генә башлаган иде, тагын нидер булды—сирәк көлә, озак уйланып утыра, берничә мәртәбә, онытылып китеп, баласын да кулыннан төшереп жибәрә язды...

Хәлим тәмам аптырады, нишләргә белмәде, жаны үрсәләнүенә түзә алмыйча, ялгыз башын алып, урманга чыгып китә торган булды. Берничә мәртәбә эчеп-исереп кайтты...

Ә беркөнне... Ә беркөнне ул Нәфисә янына барды. Кыюлык өчен бераз "төшерде" дә авылның тап уртасындагы үзәнлектә урнашкан таныш йортка китте. Яшь чагында бу йорт юлын ул күп таптады. Сигезенче сыйныфтан башлап һәр кич Нәфисәсен озата төшә иде. Башта авыл читенә чыгалар, берәр нарат яисә каен төбендә сыенышып, серләшеп утыралар да акрын гына авыл уртасына төшәләр. Унынчыда укый башлагач, көзге жылы көннәрнен берсендә беренче мәртәбә үбештеләр... Мәхәббәтеннән, сөю хисе шаукымыннан тәмам исереп кайтты Хәлим. Танга кадәр йокламыйча, уйланып, әсәрләнеп ятты. Киләчәген күз алдына китереп елмаеп-көлеп ятканын әле дә хәтерли ул...

Нәрсә булды соң ул чактагы Нәфисә белән? Нигә болай булды бу? Нәрсә өчен төште соң аңа бу газаплар? Бу урман афәте?.. Нәфисәнен кияүгә чыгуы?.. Майяны очратуы? Гөләш?.. Нәрсә, ни өчен?..

Хәлимнен аракы томаныннан әйләнебрәк торган башында барысы да буталды. Караңгы төн пәрдәсен ертып, Нәфисәләр капкасына килеп төртелгәч кенә айнып киткәндәй булды ул.

"Керергәме, юкмы? Кабул итәрме? Теләсә нәрсә әйтеп куып чыгарса?" Инде, бикне күтәреп, капка рәшәткәсен эчкә төртәм дигәндә

генә зиһененнән бер уй сызып үтте: "Ә бит Нәфисә монда яшәми!.. Ул бит—ир хатыны, аның йорты бүтән!"

Үттан өреккәндәй, кулларын капка тактасыннан тартып алуын сизми дә калды Хәлим.

Шунда ниндидер эчке бер тойгы Хәлимгә: "Нәфисә монда, монда! Кире китмә, бар, кер! Ул монда!"—дип әйткән кебек булды. Һәм Хәлим бу тойгыга ышанды. "Хәзер керәм, бераз гына, бер мизгелгә генә тукталып хәл җыеп торам да..."—дип, күңеленнән генә җавап та бирде әле.

Менә ул ишегалдына үтте. Ян тәрәзәгә якын килеп, үрелеп эчкә карады. Пәрдә читеннән өй эче күренеп тора. Әнә Тәскирә апасы йөреп ята—урын-җир түши. Нәфисә күренми... Ә! Әнә ул... Карават өстенә асып куелган чаршауга чорналып тын калган. Буш өстәл өстенә караган да тораташ кебек катып тора. Нәрсә хакында уйлый икән ул бу минутта? Ә бәлки... Хәлимгә мәхәббәте хакындадыр?.. Әллә туасы баласы хакындамы?

Шулвакыт чаршау селкенеп китте, аннары, сүтелеп, өй эченә Нәфисәне чыгарып җибәрде. Кызык булды шулкадәр—артында торган Хәлимне сизгән кебек, Нәфисә кинәт сикереп торды да тәрәзәгә якыная башлады. Хәлим чак кына читкә тайпылып өлгерде.

Нәфисә тышка бик озак карап торды. Хәлим, хәтта, аның йөрәк тибешен дә ишеткән кебек булды. Үзе исә бераз вакытка сулышын буып торды. Нәфисә бик сәер иде бу мәлдә.

Ул бертуктаусыз: "Хәлим, Хәлим..."—дип пышылдап тора иде. Менә ул тәрәзәдән кубарылып китте дә ишеккә юнәлде, аннары, ашыгып-кабаланып, веранда аша ишегалдына чыгып китте...

Хәлим исенә килгәндә Нәфисә тышкы ишекнең келәсен күтәреп булаша иде инде. Караңгыда тиз генә таба алмадымы—шактый озак булашты ул. Хәлим шушы берничә мизгел эчендә урынын алыштырып өлгерде—тәрәзә янынан тайпылып китте дә, ике-өч сикерүдә, якындагы утын өеме артына посты. Ул килеп кенә чүгәләде, ишек келәсе янгырап ачылып китте дә аннан атылып Нәфисә килеп чыкты:

—Хәлим!..

Хәлим тәмам айнып житте. Тукта, Нәфисә аны эзли түгелме соң? Тик каян белеп алды соң әле ул Хәлимнең монда булуын? Каян сизенде? Чынлап та, күңел сизенә микән әллә? Әнә бит ничек өзгәләнеп эзләп йөри Нәфисә Хәлимне:

—Хәлим!.. Хәлим...

Нәфисә артыннан әнкәсе килеп чыкты:

—И кызым, тиленәнәсең бугай инде шул Хәлим дип... Бөтен авыл көлә бит үзеннән!.. Әйдә, кер, йә берәрсе ишетеп калыр...

—Әнкәй! Монда ул... Якында гына... Белеп торам, сизеп торам аны... Хәлим!.. Хәлим!.. Хәлим, кайда син? Хәлим...

—Каян килеп монда булсын ул. Хатыны, баласы, әнкәсе янындадыр...—Монысы Тәскирә тавышы.

—Юк-юк-юк!.. Ул монда бүген, минем янда!.. Мин аны тойдым, йөрәгем, җаным белән тойдым...—Бераз тын торгач өстәп куйды:

—Ә теге сихерче хатыны баласы-ние белән дөмегәчәк әле бер... Дөмекмәсә, үзем дөмектерәчәкмен!

—Нәрсә сөйлисең син, кызым!.. Авызыннан жил алсын. Алай димә... Язмыш, тәкъдир дип тик тор, шулай дисәң, жинелрәк була ул...

—Их, әнкәй, берни анламыйсың син!.. Берни тоймыйсың! Мин бит Хәлимсез яши алмыйм, беләсеңме шуны! Мин барыбер үземнеке итәм аны, кеше җаны кыеп булса да үземнеке итәм!

—Тәүбә диген, кызым, әстәгъфирулла, диген... Бар, юньсез бала, афәт чакырып торма, өйгә кер, карыныңдагы баланнан оялыр идең, ичмаса...

...Хәлим ничек кайтып житкәнен дә белми. Аның зиһен тубалында бердәнбер аек уй чәбәләнде: "Майясын, баласын, мең газаплар белән

яуланган мәхәббәтен мәңге ташламаячак ул, шул мәхәббәтен яклап утка, суга керәчәк, жанын да, гомерен дә кызганмаячак...”

## XIX

Газаплы тормышта тагын бер атна узды. Майя һаман ачылып китә алмады, карчыклар киткәндә ничек уйчан булып калган булса, шул ямансулыктан айнымады, киресенчә, үз күңеленә ныграк кереп бикләнде, елмаю-көлү, рәхәтләнеп гәпләшү-сөйләшү дигән нәрсәне онытты, башка дөнья кешесе булып яши бирде.

Хәлим хатынының бу халәтен карчыклар сихеренә юрады. Әмма ул шуны да ачык чамалый: бу—сихер генә дә түгел иде. Урман албастылары Майя күңеленә ниндидер шомлы хәбәр салып киттеләр, ахры. Әлегә Хәлим сорарга кыймый. Болай да үз жанын йөдәтеп, үрсәләнеп яшәгән Майяны борчырга теләми. Әллә нык кына бер сөйләшеп, аңлашып караргамы? Юк ла, бераз көтәргә кирәк. Майяның ачылганын, дөньяга йөз белән борылган чагын көтәргә кирәк...

Шулай борчылып, эчтән сызып яшәгән бер вакытта Санияләргә Ак бабай килеп керде. Ул бик мөһим хәбәр китергән. Дөресрәге, ике хәбәр.

—Сания балам, авылга хәтәр сүз таралган, керми булдыра алмадым,—дип сөйләп китте карт керә-керешкә.

—И-и, Ак бабай, нәрсә сөйлисең син? Нинди хәбәр ул?

—Нинди дип, бик начар хәбәр шул.—Үзе өй эчен күзләпме күзли.—Яшьләр өйдә юкмы?

—Юк иде шул, бакча тирәсендә булашалар...

—Сания кызым, халык телендә шундый сүз йөри. Имеш, Тәскирә Нәфисәсе Майяны үтерергә тели. Хәтта Хөрәсән Чулагын яллап та карамакчы булган. Тегесе бу хакта салмыш баштан ычкындырган. Кеше ышанмаслык хәл бит. “Үтерәм, дөмектерәм, Хәлимне үземә кайтарам”,—дип әйтеп әйтә, ди...

—Тәүбә диген, Ак бабай... Нинди кәфер сүзләр сөйлисең син? Нәфисә булып Нәфисә ничек итеп кеше үтерсен ди... Дошман сүзе, шайтан шаяруыдыр бу...—Сания ах-ух килеп ишекле-түрле йөренә башлады. Үзе туктаусыз сөйләнүендә булды.—Әгәр бу сүз дөрес икән—үз башына жилкенә ул хатын... Бала табыр вакыты житкән, ә тәкъдиргә каршы сүз сөйләп йөри... Болай булса, барыбер баласы аркылы килер...

—Менә шул шул... Икенче хәбәрем нәкъ шул хакта. Нәфисәне тулгак тота башлаган, ә баласы туарга теләми, ди... Аркылы килгән имеш... Нәкъ өстенә бастың, кызым... Ходай каргышы төшкән аңа, башка бер нәрсә дә түгел...

Күрше карты чыгып киткәч тә Сания шактый вакыт исен-аңын жуеп утырды. Аның башына сыймый иде: ничек инде алай? Кеше үтерү хакында бара бит сүз! Юктыр, шайтан коткысы гынадыр... Алай дисәң... Нык үзгәрде соңгы вакытта Нәфисә. Тәскирәнең килүе дә юкка түгелдер. Аптыраганнан кергән инде ул, мескен...

Ак бабай китергән шомлы хәбәр хакында Хәлимгә әйтмәскә булды Сания. Барыбер дә ышанып бетә алмады ул аңа. Гайбәткә, дошман сүзенә кайтарып калдырырга тырышты. Шулай да, бер жаен китереп, Хәлим белән икесе генә калган сәгатьтә, әлеге шом пәрдәсенең бер читен күтәреп куйды:

—Улым, Майя кая китте ул, иртәннән бирле күренгәне юк, бер-бер хәл булмагандыр бит?

—Юк, әнкәй, юк. Иртән үк астурамнан Мәдинә апа килеп алды. Малайлары төне буе кызышып, саташып чыккан—шуны имләргә китте... Нишләптер озак торды бүген. Бик каты авыру булды, ахры...

—Хәлимкәем, моннан соң үзен генә жибәрмә. Ул бит әле ныклап

күнегеп тә бетмәгән авылга. Аннары... төрле кеше бар. Юри дә бер-бер хәл кылып куярлар...

—Әнкәй, нигә әле син бүген сәер сөйләшәсең? Кем тисен аңа? Майя—дөньяның бәгыреннән өзелеп төшкән бер Хода бәндәсе. Күреп торасың бит—кешеләр хәзер үз итә аны, чакырып кына торалар...

—Шуннан куркам да инде, балам, гел ялгызы йөри бит. Урман тамагына кереп торган авыл урамында кем очрамас!

—Җитте инде, әнкәй! Юк нәрсә сөйләп башны катырма әле. Бала чакырып, вакыт уздырып утырмыйк, эшләр болай да баштан ашкан...

Хәлим сүзен тәмамлый алмады, ишектән Майя килеп керде. Бик сәер иде ул. Чырае мич йөзе кебек ап-ак. Күзләрендә шом, хәтта, курку. Ул, артыннан ишекне дә ябып тормыйча, йөгереп килеп Хәлимнең киң күкрәгенә капланды:

—Үтерәбез диде бит... Көннәрең санаулы калды... Урманына олак, диде...

—Кем әйтте? Кем үтерә? Нәрсә сөйлисең син, Майя?

—Мәдинә апалардан кайтканда бер исерек юлыма аркылы төште... Шул әйтте...

—Кем соң ул?

—Белмим... Беренче күрәм...

Хәлим аңлый башлады. Әнкәсенең шомлы хәбәрен Майя белән булган хәлгә янәшә куеп карады. Әйе, алар өстендә ниндидер кара болыт куера башлаган, ахры. Ниндидер афәт якынлаша иде нигезләренә...

Моңа кадәр дә мең газаплар кичергән, инде бөтенесе дә артта калды, дип куанып яши башлаган өч җан тагын бер сорау каршында аптырап калды: “Индениләр генә язгандыр алар башына?”

## XX

Кояш офык артына төшеп китмәгән иде әле, капкадан ашыгып Тәскирә килеп керде. Өйгә кереп-нитеп тормады, тәрәзә алдына барып, ярсып-ярсып кычкырырга тотынды.

—Майя!.. Майя кызым! Сания дим, Сания... Сез кайда? Ник чыкмыйсыз берегез дә? Майя!..

Түшәктә изрәп йоклап яткан баласы янында мендәргә тыйнак кына башын төртеп черемгә талган Майя, ниһаять, торып утырды. Кем бу? Нәрсә бу? Ул аңына килгән арада ишегалдындагы тавыш тагын кабатланды:

—Майя! Кызым! Нәфисәм үлә бит... Сине чакыра... Кайда соң сез? Дөмектегезме әллә?..

Майя тәрәзәгә капланды. Энгер-меңгер төшә башлаган ишегалдында җан әсәре күренмәде. Ә, бар икән. Әнә бит кемдер кыштырдый. Чаштыр-чоштыр килеп, тәрәзәдән тәрәзәгә йөренә... Кинәт Майя карап торган тәрәзә артында да борчулы чырай пәйда булды. Тәрәзәдән төшкән ут яктысында бу чырайның иң сай, иң нәзек җыерчыклары да аерымачык күренеп, күнелне өркетеп тора иде... Майяның җаны-коты табанына төшсә дә, түзде, шул баскан урынында тора бирде.

—Майя кызым!.. Нәфисәнең хәле начар. Баласын китерә алмый бит бәгырькәем. Икенче тәүлек китте. Фельдшер да, имче карчыклар да берни эшли алмыйлар... Алсаң да син генә алырсың ул баланы... Кулыңны шифалы диләр бит синең...

Ниһаять Майя аңлады. Кеше телендә күп чайкалып йөргән Нәфисә бүген авыр хәлдә ята. Ничек бармасын, барыр, үзе нинди генә ачы, усал телле булмасын, аның якты дөньяга чыгарга омтылган баласы—бәгырь ите хакына барыр...

Майя, түшәктә чалкан төшеп йоклап яткан баласын уятмаска теләп, аяк очларына гына басып ишеккә таба китте. Ишегалдына чыгып кына

китте, бакчаның ян як капкасында Сания күренде.

—Нинди тавыш монда?.. Баядан бирле кем чәр-чәр килә дисәм, син икәнсең әлә, ахирәт. Нәрсә булды? Нәфисә ни хәлдә?

—Шуның өчен дөнья бетереп йөрим дә инде, Саниякәем... Китерә алмый бит баласын. Әйттем мин ана, артыгын кыланасың, артыгын сөйләнәсең, дидем... Бер әйләнеп кайта шул ул, үз башыңа кайта...

—Үз балаң турында алай димәле, ахирәт. Барысы да әйбәт булыр, теләп тор, бөтен нәрсә Хода кулында, нишлисең бит...

—Бер сөйләнмәс, бер чәпчемәс идем. Үзәкләремә үтте шул соңгы вакытта. Хәзер менә шуның әҗерен күрәбез... Киттекме, кызым?

—Әнкәй, Гөләш берүзе калды, тизрәк кер инде, бигрәк яраттырып йоклый, җеннәр килмәсен тагын...

—Бар, кызым, бар, бар... Хәзер керәм, бер дә борчылма. —Керә башлаган җиреннән капыл туктап, сорап куйды:—Ә Хәлим кайда соң?

—Хәлим?.. Хәлимме? Белмим шул. Төшке аштан соң, чыгып йөреп кайта торган гадәте бар бит. Келәт бурасына агач белешәсе бар, дип тә сөйләнгән иде...

Сания өйгә кереп китте. Тәскирә белән Майя кызу адымнар белән урамга чыктылар да авыл уртасына алып төшә торган тар урамга кереп югалдылар.

Хәлим бу вакытта, чынлап та, келәт бурасы хакында кайгыртып йөри иде. Ул инде эшен бетергән, Торна Хәниф белән сөйләшеп, бер атнадан бураны үзләренең ындырларына күчереп куярга килешкән. Кул сугышып, кайтырга кузгалган гына иде, кинәт йөрәге чәнчеп куйды. Ул хәтта сискәнеп китте. Нәрсә булыр бу? Бер дә йөрәгенә зарланмый иде бит... Әнә хәзер ничек сулкылдап тибә, ничек ярсый...

Хәлим шундук аңлап алды. Моңа кадәр дә күңел тоемына ышана иде ул—алдамый иде аны күңеле. Чәнчеп сулкылдый икән—димәк, нидер булачак... Урманда чакта әтисенең афәтен тоеп та шундый халәт кичергән иде ул.

Кайтып кергәндә Сания Гөләшне ашатып утыра иде. Хәлим көчкә-көчкә сулышын җыеп:

—Майя кайда?—дип сорый алды.

—И, балам, Нәфисә һаман бала табалмый икән бит. Тәскирә ахирәт, имләп-камлап, хәлен җиңеләйтмәсме дип, киленне үзләренә алып китте.

—Ә син җибәрдеңме?

—Ничек тотыйм инде мин аны? Үзе барырга чыккан иде, тотып калырга кыенсындым. Хәле авыр ди бит...

—Әллә ничек шунда, күңелем тынычсызлана, Майя өчен куркам, гомердә булмаганны, йөрәгем җилкенә... Нидер сизәм мин, әнкәй, тоям...

—Йәле, улым, күңелгә шом кертмә. Болай да утлы күмер өстендә яшибез. Баскан саен җанга шеш-яра чыга...

Хәлим, торып, стенага эленгән олы рам янына килде, андагы сурәтләрне җентекләп карый башлады. Әткәсен шундук танып алды. Әнә пинҗәген җилкә аша гына тотып, кунак озатырга чыккан ул. Ә менә бу фотода әнкәсе белән бергә утыра. Бәхетле йөзләр... Шунда Хәлим капыл гына бик авыр уйга юлыкты. Әнкәсе белми бит әле теге әпә язмышын!.. Ничек кенә әйтергә икән соң? Ничек җай табасы?

Үзе дә сизми калды, Хәлим тыныч кына:

—Әнкәй, мин әткәйне күрдем бит,—дип әйтеп куйды.

Баштарак бу сүзләргә Сания игътибар итмәде, аннары гына, мәгънәсенә төшенә башлагач кына, йөрәге чәбәләнеп:

—Ә? Нәрсә сөйлисең син, улым? Ул әллә кайчан җир куенында инде, мәрхүм... Нишләп алай сөйләшәсең әле син? Бер-бер хәл булмагандыр бит?—Сания, тамагын туйдырып, ике мендәр арасында мыгырданып яткан Гөләш яныннан торып, Хәлим каршына килде.—Кая, карыйм әле күзләреңне... Күз агың чиста түгел, балам, нинди борчу кергән сиңа, хәерлегә генә булсын инде...

—Әнкәй дим! Мин әткәйне күрдем...

—Ни дигән сүз бу, улым? Һаман бер нәрсәне тукыйсың...

Хәлим нишләргә дә белмәде. Әйтә башлагач, әйтеп бетерергәме әллә? Юк ла, әлегә әйтергә ярамый, тынычлана башлаган ана күнеле тагын борчу-гамьгә чорналсынмы? Тагын җан сызу, өзгәләнү, бәргәләнү, күз яше түгү башлансынмы?

—Күрдем шул, төшемдә күрдем мин әткәйне,—дип әйткәнен сизми дә калды Хәлим.

Сания балкып елмаеп җибәрде; шул елмаю аның йөзенә куна башлаган шом пәрдәсен юып та төшерде.

Өстәлгә кайнар аш килде. Ана белән ул, чөкердәшә-чөкердәшә, кичке ашны ашадылар, алдагы эшләр хакында гәпләшеп алдылар, олыларча, авыр сулап йоклап яткан Гөләшне уятмас өчен, ярым пышылдап кына сөйләштеләр. Ә Гөләш барыбер уянды. Бер дә булмаганча тынгысыз, борчулы иде ул бу минутта. Бала йөрәге—иң сизгер йөрәк, диләр бит. Ул, мөгаен, нииндидер бәла, афәт якынлашуын тоеп борчылгандыр. Әлбәттә, Сания дә, Хәлим дә хафага калдылар. Әмма бу хакта бер-берсенә сиздермәскә тырыштылар. Сания дәшми-нитми генә өстәлен җыештырып куйды да маллар арасына чыгып китте. Хәлим, Гөләшне көрәк куллары белән күкрәгенә кысып, ярсып көйли башлады:

—Ы-ы-ы!.. Ы-ы-ы!..

Бала һаман тынычланмады, киресенчә, тагын да ныграк ярсыды.

Хәлимнең түземлеге чигеннән чыкты. Аның бу балага ачуы килә башлады. Нигә елый ул? Ни җитми аңа? Өсте коры, тамагы тук, ятканы йомшак... Әнкәсе юкка елыймы? Кала иде бит әле башка вакытта... Менә—әткәсе аның янында ич... Ник болый ярсый ул?..

Хәлим теге хәтәр уйны ничек тә якын җибәрмәскә тырышты. Юк, Майяга берни дә булмагандыр, нәрсә булсын ди, ул бит Нәфисәләрдә... Ә? Нәфисәләрдә?

Шунда гына Хәлимнең "башына сукты". Нәфисәләрдә бит ул! Ә Нәфисә Майяны куралмый, куралмый гына түгел, ул аны талап, буып, йолкып үтерергә дә әзер... Бу хакта теге исерек төндә Нәфисә үзе әйтеп торды бит. Их, нигә бу хакта башта ук уйламады соң ул?!. Нигә артыннан китмәде?!.

Хәлим тәмам каушап төште, нишләргә дә белмәде. Ичмасам, әнкәсе дә әллә кая чыгып киткән... Шундый вакытта!.. Һәр минут,һәр мизгел кадерле бит...

Хәлим башкача түзеп тора алмады, зәңгәрләнеп елаган Гөләшне күтәреп, тышка чыгып китте. Аңа әнкәсен эзләп торасы калмады, Сания үзе кереп килә иде. Хәлим, буыла-буыла елаган баланы аның кулына атып бәргәндәй бирде дә урамга чыгып йөгерде. Тышкы яктан, эңгер-меңгердә күзләре томаланып, капка төбенә укмашкан казларның каңгылдашуы гына шактый вакыт ишетелеп торды.

Хәлимнең үз кайгысы кайгы иде. Бу минутта аның күзенә капка төбендәге казлар да, койма буенда җыелып торган сарыклар да күренерлек түгел иде.

Күпме йөгергәндер, ничә мәртәбә сөрлегеп егыла язгандыр, хәтерләмиме, әмма ул һәр адымын: "Майя!"—дип атлады, аның йөрәге дә һәр типкәндә: "Майя!"—дип типте, хәтта, күктәге йолдызларның ара-тирә ухылдап куюы да "Май-й-а-а..." булып ишетелә иде...

Шунда йолдызлар ухылдавына бер ыңгырашу авазы килеп кушылды. Астурам тыкрыгына борылган вакытта, карт каен яныннан узганда ишетте ул бу ыңгырашу тавышын. Тукта! Нинди тавыш булды соң әле бу? Таныш тавыш... Майя? Майя! Май-а-а-а!

## XXI

Тәскирә белән Майя ашыгып килеп кергәндә Нәфисә тирәсендә өч карчык кайнаша иде: кем анын маңгаен сөртә, кем түшәген рәтли, кем шифалы үлән сулары әзерләп тора... Шунда ук яшь кенә табибә өстәл артында нидер язып утыра. Күрәсең, ул инде Нәфисәдән өметен өзгән, карчыклар да әллә ни борчылмыйлар кебек. Майя аңлап алды: өйдәгеләр дә, табибә хатын да, имче карчыклар да аны көткәннәр. Әнә бит ничек яктырып, ачылып китте йөзләре! Ләкин өйдәгеләрнең шатлыгы озакка бармады, Майя аларның барысына да чыгып китәргә, өйдә Нәфисә белән икесен генә калдырырга кушты. Менә ул хәлсез, ярым һушсыз яткан Нәфисәгә күзен генә төшереп алды да кулындагы төенчеген чишеп җибәрде. Кашемир яулык эченнән төрледән-төрле им-том әйберләре, камчы-сихерче әсбаплары коелды. Ул үз янында бер генә кешене—Тәскирәне генә калдырды; әмма анысы да, мичкә ут үрләтеп җибәргәч, казанга су тутыргач, чыгып китәргә тиеш булды. Майя үзенең бөтен сихере, тылсым-кодрәте, кыскасы, җаны-тәне белән Нәфисәгә ябырылды. Галиҗанәп Табигать каршында, Хода, Тәңре, Алла, Раббы (укучы күнеленә ничек якын, шулай кабул итсен) каршында Майя кулының тылсымлы көче хакында язып тормыйм, анысы яшерен эш, илаһи кодрәт эше, шулай да, ике сәгатьтән соң Тәскирәләр өенең, бала елавына түзә алмыйча, чүгеп-сагаеп, басылып калганлыгы хакында дәшми калу мөмкин түгел.

Бала тавышына сискәнеп, Нәфисә үзе дә исенә-аңына килде, тәмам уянды. Әмма ул әле бик хәлсез иде. Тыштан Тәскирә, аңа ияреп имче карчыклар килеп керделәр. Килеп керделәр дә Майяга булышырга тотындылар.

Калган бөтен эшне карчыкларга калдырып, Майя ихатага һава суларга чыкмакчы булды. Юк, тиз генә чыгып китә алмады әле ул. Нәфисәнең йөрәккә үтәрлек итеп, җан авазы белән ыңгырашуы Майяның юлына аркылы киртә булып ятты.

—Ы-ы-һ!.. М-м-а-й-а-а!..

—Майя кирәкмени, кызым? Хәзер чакырам, хәзер... Мең рәхмәтләр аңа, үз телләрең белән рәхмәтеңне әйт, яме...

Майя Нәфисәнең баш очына килеп басты.

—Май—йа... Кайт-ма... Си-ңа кай-тыр-га... яра-мый...

Тәскирә бу сүзләрне начарга юрады:

—И бала, тагын саташа башлады бугай инде.

Майя тынычрак иде.

—Кайтыйм инде мин... Минем дә өйдә балам бар бит. Син борчылма, монда сине карап бетерерләр, әнә бит, туп шикелле балаң туды, сөенеп кенә ят...

—Кит-мә... Май-й-а...

—Ни сөйлисең син, Нәфисә? Миңа кайтмыйча ярамый...

—Я-ра-мый... Я-ра-мый....—Нәфисә тагын хәлсезләнде. Бер үк сүзне кабатлый-кабатлый башын читкә алды, йөзен чытып, башын чайкый башлады.

—Йә, тынычлан инде, кызым. Менә, тәгәрәп торган малай таптың, әнә бит ул ничек имеп ята...

Нәфисәне тынычландырып калдылар, Майя, әйберләрен төйнәп, ашыгып чыгып китте. Өйалды тәрәзәсе ягыннан үткәндә дә әле Нәфисәнең: "Кит-мә, Май-й-а, я-ра-мый, ха-рап бу-ла-сың..."—дигән сүзләре ишетелә иде.

Майяга кайтмыйча ярамый. Өйдә аны гаиләсе, Гөләше көтә. Инде югалтып та бетергәннәрдер. Ашыгырга кирәк. Әллә ничек, төне дә шомлы, караңгы... Йолдызлар да сирәк... Әнә бит, бүген алар бөтенләй күк йөзендәге кара болытлар хөкемендә калганнар...

Майяның уйлары кабат Нәфисәгә әйләнеп кайтты. "Китмә", диме?

Һаман үз туксаны туксан бу хатынның. Шушы авыр хәлендә дә Хәлимнән көнләп ята. Әнә, кайтма, дип күз дә ачырмый бит... Тагын нәрсә диде соң әле ул?.. Майяның хәтерендә ишегалдында чагында тәрәзә аша ишетелгән тавыш яңгырады: "Харап буласың!.." Нигә алай дип әйтте икән Нәфисә? Нигә харап булырга тиеш әле ул? Кинәт Майяның күңелендә вакыт тузаны куна башлаган хатирәләр янарып-ачылып китте. Әле күптән түгел генә йорт каршындагы чирәмлектә әбиләр белән булган сөйләшү яңарды. "Авыл уртасындагы йорттан чыккан хатын сине харап итәчәк. Тик аңынчы бу хатынның гомере синең кулда булачак, кара аны..." Әлеге хатынның Нәфисә булуын шунда ук аңлап алды Майя. Тик бу минутта нинди зыян сала алсын ул? Әнә—хәлсез, буынсыз килеш ятып калды, бичара җан... Исән-сау гына булсын инде, бәлки, бала тапкач, акылга утырыр, теләсә нәрсә дә сөйләп йөрмәс...

Майя уйлый башлаган уйларын тәмамлап, төйнәп бетерә алмады, якындагы тыкрык караңгылыгыннан бер олы таш очып чыкты да нәкъ чигә турысына килеп тиде. Аның: "Ах!"—итеп, гөрселдәп җиргә ауганын беркем ишетмәде дә, күрмәде дә. Тыкрык авызыннан тагын авыр-авыр ташлар очып чыга башлады; алары да җирдә боргаланып-сыргаланып яткан гәүдәнең әле кул-аякларына, әлә сөткә тулышкан күкрәгенә тиеп, үзләренең кара эшләрен башкардылар.

Баштарак Майя йөз-битен капларга тырышып карады, эчен, күкрәкләрен яшерергә маташты. Әмма ниндидер зәхмәти көч ярдәме белән тыкрык артыннан очып килеп торучы ташлар артык зур иде шул. Майя бик тиз аңын югалта башлады, хәлсезләнеп, кулларын йөзеннән шудырып төшерде, чалкан ятып, тынсыз-хәрәкәтсез калды. Әмма җаны чыгып җитмәгән иде әле аның. Ул кай төше beләндер теге карангы тыкрык авызыннан пәйда булган ике исерек бәндәнең янына килүен, аны әйләндереп-әйләндереп каравын, хәтта аларның сөйләшүен дә аерымачык тойды һәм ишетте:

—Дөмеккән бу... Хәзер Нәфисә безне бер ай буе сыйлаячак инде...

## XXII

Гөләш елаудан туктамады. Сания ниләр генә эшләмәде: сөт җылытып китерде, манный боткасын марляга салып, имезлек итеп биреп карады, уенчыклар шалтыратып, өйдә пәри туе кузгатты... Әмма Гөләш боларның берсенә дә әллә ни игътибар итмәде, бер кызарып-бүртенеп, бер күгәреп-зәңгәрләнеп тамак яруында булды.

Бала тавышына күршедән Васимә карчык керде.

—Әллә баланың үзен генә калдырганнармы дип торам. Бигрәк каты елый, күтәне чыкмасын, тотып карале—эче катмаганмы?

—Юк-юк, бер дә авырганга охшамаган. Анасын юксынып елый ул. Майя Нәфисәнең тулгагын алырга киткән иде. Тәскирә үзе килеп алды...

—Мескенкәем. Тәскирәнең ул кызы авылга бер бәла булды инде. Бөтен тирә-юньне сасытты, хәзер үзе шуның җәфасын күрә...

—Баласы җәл, ире җәл, бигрәк тә Тәскирә җәл. Аларның бер гаебе дә юк бит.

—Анысы шулай инде. Җинел генә котыла алсын иде дә бит. Бала китергән хатын яхшы якка үзгәрүчән була. Нәфисә дә үзгәрер әле, гел болай чыгымчылап йөрмәс... Майяны әйтәм, бер дә үч сакламаган, киткән тагы...

—Тәскирә бик ялынып сорады шул, нык үтенде...

—И-й, балам, иртәме-соңмы, адәм баласы үз насыйбына тиенә ул. Васимә абыстай әйтте диярсең. Майя да үз изгелекләре өчен игелек күрәчәк әле...

Шулвакыт урам капкасы шыгырдап ачылды. Кем булыр? - Гөләш бер мәлгә елаудан туктады, хәтта, сулый торган сулышын буып куйды.

Икенче мизгелдә ул тагын ачыргаланып еларга тотынды. Сания, Гөләшне Васимә карчыкка тоттырып, ишеккә юнәлде, әмма ул, ишекне ачып чыгып, ике адым да атлый алмады, "аһ-ваһ" итеп, кире килеп керде. Анын артыннан ике беләгенә жансыз, тынсыз Майяны салган Хәлим күренде. Гөләш кайгысы бетте, Васимә карчык та, Сания дә Хәлимгә, анын кулында канга батып яткан Майяга ябырылдылар. Китте елаш, китте аһ-зар... Хәлим Майяны иплəп кенә түшәккә салды. Анын күзләреннән хатынынын жансыз гәүдәсенә, ап-ак булып катып калган йөзенә бертуктаусыз яшь ага...

Шунда Майя ыңгырашып куйды. Кергәннән бирле бер сүз дәшмәгән Хәлим, ниһаять, исенә-аңына килеп, дивана кеше шикелле, башын түшәккә бәрә-бәрә, сөйләнергә кереште:

—Майя! Майя!.. Нәрсә эшләттеләр сине? Кем тиде, йә әйт! Кемгә ярамадын, кемнен юлына аркылы төштен син, ә?

—Ы-һ-һ!..

—Кай жирләрен авырта сон, бәгырем? Ни генә эшлик соң? Әнкәй, бар инде, йөгер фельдшер артыннан!..

—И балакаем, Васимәттәй чыгып китте инде... Әйдә, врач килгәнче, өсләрен салдырып, яраларын юа торыйк. Әнә бит күпме кан аккан. Хәлсезлеге дә әнә шул кан күп югалтудан анын. Мескенкәемне нишләткәннәр бит...

—Ы-һ-һ!..

—Әнкәй дим, йомшаграк мендәрләр бир әле. Жайсыз ятмасын... Ну монын кем икәнен белсәм!..

—Ы-һ-һ!.. Хә-лим-м!..

—Әү, Майя. Ничек хәлен? Нәрсә булды сиңа бүген? Хәзер врач килеп житә, чак кына түз, яме...

—Хә-лим-м!.. Мин... үләм инде...

—Үлмисен әле син, Майя... Озак яшибез әле без синен белән, Гөләшне үстерәбез, аны кеше итәбез...

—Үләм... мин... Гөләшне... ташлама...

—Ни сөйлисен син, Майя?!. Нинди үлем ул? Ни дигән сүз бу?..

—Теге вакытта... әбиләр... дөрес әйткәннәр... Хәлим... алар миңа... үлем юрап киттеләр... Рас килде...

—Ә? Кемнәр? Теге албастылармы? Шуларга ышанып, үләргә жыендынмы? Юк, үтермим әле мин сине! Әнә, Гөләш елый, әнкәй үлмәсен дип елый ул, белденме?

Хәлим үзе сөйләнә, үзе Майяның кулларыннан, йөзеннән сыйпый, күзләреннән бертуктаусыз яшь ага...

—Хәлим... Хәлимем минем... Үләргә... кайтканмын икән авылга... Күпме тырышсам да... кешеләрдән яраттыра алмадым... Битәрләмә... мине... Бәхил бул... Гөләшне сакла... үстер... әбиләргә... бел... дер...

Майя шул сүзләрдән соң ияген сикертеп куйды да жаныннан бушап, тәслим кылды. Йөзе тынычлангандай булды, керфекләре дә йомшак кына йомылып, фотосурәттәге кебек, хәрәкәтсез калдылар... Хәлим инде тавыш-тынсыз гына сулкылдый. Сания, Гөләшне күкрәгенә кысып, аһ-ваһ килеп, ишек төбендәге сандык өстендә утыра. Ә Гөләш... Гөләш һаман елый да елый... Гомерлек күз яшен берьюлы елап бетерергә теләгәндәй, ачы яшьләрен агызып, бөтен жаны-тәне белән ярсып елый...

Әллә каян гына Ак бабай кереп баскан. Ул бер сүз эндәшми. Жыйнак сакалын учлап тоткан да, тынсыз яткан Майяга төбәлеп, катып калган. Фельдшерны ияртеп кайтып кергән Васимә карчык та шундук аңлап алды. Бер сүз дәшми-нитми, авызын яулык чите белән каплап, Сания янәшәсенә барып утырды. Кулларын алга сузып, догага керешге: "Бисмиллаһир... Вәл-Көрьәни... Хәким... Тәнзиллəл—газизиррахман..."

Ә Гөләш елады да елады, анасынын үлемен сизенеп, ятимлектәге ачы язмышын тоеп елады ул, бу тавыш—бала тавышы гына булмыйча, бәла, кайгы тавышы да иде...

## XXIII

Нәфисә малай тапты. Әмма ул баласын кабул итмәде. Юк әле, башта ул аны имиенә авызлыкландырды, тик, менә хикмәт, Майяның үлгәнен ишеткәч, баласын якын җибәрмәде, тәмам акылдан язган кыяфәттә, мендәр-түшәген кыйный-кыйный, хәлдән тайганчы чәбәләнде. Аны хәтта бәйләп куярга мәҗбүр булдылар.

Майяны бөтен авыл күмде. Нәфисә генә үз түшәгендә саташып, бәргәләнеп ятты. Тәскирә аның янында калды. Ә! Тагын ике җан көеге бармаган икән каберстанга. Бу ике бәндә авылның каршы як ягына урнашкан дуңгыз абзары артында, сасы тирес базында менә икенче көн инде аракы чөмерәләр. Айнып бетә алмыйлар, шушы чебен оясында бераз туңкаеп яткач, айный башлагач, тагын шешәләренә ябышалар...

Каберстандагы кешеләр үзләрен бик сәер тоттылар—бер-берсенең күзләренә туры карый алмый изаландылар. Һәркем үзендә ниндидер гаеп, кичереп булмый торган гөнаһ тойды. Кешеләрнең җаны таш булып катты, күңелләре, гүя, асыл хакыйкать каршында мәңгелеккә ябылган кебек булды. Күпләргә Кампәрле авылы якты дөньяның калган өлешеннән аерылып кителеп төшкәндәй, әйе-әйе, заман кыясыннан кителеп, вакыт упкынына очкандай тоелды.

Гомердә булмаганны, зиратка хатын-кызларны да керттеләр. Хәлим каберне үзе казыды, ләхетне үзе куйды. Еламады. Мышкылдаша башлаган хатыннар ягына бер генә карап алды, тегеләр шундук шым булды. Ак бабай, дин кушканның барысын да башкаргач, хатынының җансыз гәүдәсе каршында басып торган Хәлим янына килде. Тыныч кына:

—Йә, хушлаш инде,—диде.

Хәлим кызыл балчык өеме алдына тезләнеп, маңгаен шул салкынча таучыкка терәде, аннары, кинәт кенә башын калкытты да кабер өстенә бармагы белән тырнап албастылар тамгасын төшереп куйды: башта аркылы чалыштырып ике сызык сызды, аннары бу аркылы-торкылы сызыкларны божра белән әйләндереп алды. Шул тамгага бераз карап торды да, үзалдына, теш арасыннан гына:

—Соңгы тамга...—дип, авыр сулыш белән әйтеп куйды.

Гөләшне күтәргән Сания белән Хәлим зираттан иң соңгы булып чыктылар. Сания ара-тирә күзләрен сөрткәләп ала. Гөләш тыныч. Саниядән күрмәк, ул да Дәү әнисенең күзләренә үрелмәкче... Юлда баланы Хәлим үзенә алды. Ул инде тәмам тынычланган, хәтта, артык тыныч. Бөтенләй эченә кереп бикләнгән. Әйтерсең, дөнья белән тоташтырган ишекне ябып, бикләп куйганнар, ә ачкычын Майя үзе белән алып киткән...

Өйгә килеп керү белән Хәлим сөт сорады.

Әнкәсе:

—Әнә шунда, мич куенындагы чүлмәктә бар. Шуннан алып эч,—дисә дә, Хәлим һаман үз сүзен тукыды:

—Әнкәй, яңа сауган сөт эчерик әле Гөләшкә. Аңа хәзер сыер сөтенә күнегергә туры киләчәк...

Сания шундук, кабаланып-каударланып, көтүдән калдырылган, көне буе абзарда мөгрәп басып торган сыеры янына чыгып китте. Хәлимгә шул гына кирәк иде. Ул тиз-тиз генә җыенды да, кулына беренче эләккән киемне төенчеккә төйнәп, бераз ризык алып, аларның барысын да тузып, ямалып беткән юл капчыгына тутырып, аркасына киде, аннары Гөләшне кулына алып, урамга чыгып китте. Капкадан килеп чыгуга, угры-карак кебек, як-ягына каранып алды, тирә-юньдә кеше юклыгына ышангач, эре адымнар белән урман ягына китте. Сания зур чүлмәктә күбекләнеп торган яңа сөт алып кергәндә Хәлим урман тамагына төшеп бара иде инде. Ул әнкәсенең: "Ул-ы-ы-м!"—дип ачыргаланып, көяләнеп кычкыруын да, шушы инрәүле тавыш белән бергә күзләреннән якты дөнья сурәтенен юыла баруын да белерлек түгел иде...

## XXIV

Урман юлыннан берәү бара. Дөресрәге, икәү баралар. Берсе—әзмәвердәй ир-ат, икенчесе—сабый бала. Ул әле сөйләшә белми, шатлана, кайгыра да белми. Ул елый гына белә. Тагын... елмая-көлә белә. Менә әле дә ул йокы аралаш елмаеп бара. Әткәсенә елмая, урманга, бөтен дөньяга елмая. Елмаеп калсын, алда анын елыйсылары күп әле.

Әнә—әткәсе, киресенчә, көлә. Юк ла, шулай елый икән ул. Үзе көлгән кебек, ә үзе елый. Күзләреннән тамган яшь бөртекләре, баланың битенә тамып, татлы йокысыннан уяталар. Бала мыгырдана-мыгырдана боргаланып ала да тагын йокыга тала. Бераздан тагын елмая башлый.

Урман юлы озын, хәвефле. Урман дөньясы үзе тагын да куркынычрак. Анда кара көчләр, убырлар, албастылар, шүрәлеләр яши, кара рухлар гомер сөрә. Ә кешеләр дөньясы? Кешеләр дөньясы хәвефле түгелмени?! Кешеләр дөньясы тагы да хәвефлерәк әле. Шулай булмаса, сабый бала күтәреп барган бу ир авылдан кара урманга качмас иде. Кешеләр дөньясында албастылар юк, алар үзләре албасты, убыр, шүрәле, угры... Тик алар бу хакта белмиләр генә. Белсәләр... үзләреннән-үзләре гайрәтләре чигеп, йөрәкләре ярылып үләр иде. Шулай да, күк йөзендә Кояш бар. Урман куенында чишмә бар. Чишмә буендагы таллыкта кошлар сайрый. Талгын җилдә аланлыктагы кыңгырау чәчәкләре дулкынлана-дулкынлана үз биюләрен бии. Күбәләкләр оча...

Димәк, бу дөнья бөтенләй үк өметсез түгел әле.

Кешене олы афәттән шушы Кояш, чишмә, кошлар, чәчәкләр, күбәләкләр саклап калачак. Аллаһы тәгалә кешелек дөньясын урманнан гына мәхрүм итмәсен! Ярабби!

Урман юлы буйлап берәү бара. Дөресрәге, икәү баралар—әзмәвердәй ир-ат һәм сабый бала. Әнә инде алар күздән дә югалалар. Бераздан талгын юл тасмасыннан аргы якка шуып төшеп китәчәкләр. Туктале-туктале... Бу юлда тагын кемдер бар: безгә үтә дә таныш карт. Хәтерлисезме, теге вакытта Хәлимгә берничә мәртәбә ярдәм иткән иде ул. Безнең заманның Хозыр-Ильясы ахры ул. Әнә ул тагын теге ике жан иясе артыннан бара. Белеп торам: ярдәм итәргә тели ул аларга. Урман юлы озын, барыбер бер куып җитәр аларны, яктылыкка, өметкә, тормышка чыгарга булышыр.

Амин, шулай булсын!

*1998-1999*



# Равил Фәйзуллин

## ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

Үз вакыты житкәч—имән ава,
йолдыз арып сүнә, рух какшый...
Ни хәл итмәк кирәк: кемдер чынлап
Яшәештә мәңге калмакчы!
...Була кайчак, Дөньяны баскан
Явызлыкны жиңә бер Яхшы.

«Син—яшь! Мин—яшь!» дигәннәргә
ышанып йөргәнмен дә...
Сандугач йокысы кадәр
Яшьлекнең гомере дә!

Тай айгырга әйләнгәндәй
житкәнмен картлыгыма.
Картлыкка ук булмаса да,
моңсу олпатлыгыма.

Уем белән олы икәнне
яшьтән дә белә идем,
тик аны тышка чыгармый,
сиздерми генә идем.

---

*Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943)—Татарстанның халык шагыйре (1998), Г. Тукай исемдәге Дәүләт премиясе лауреаты (1978). Казанда яши.*

...Менә хәзер гармония!
Тән дә, жан да—бер чама.
Яшеренмичә яшәреп,
иҗат итәргә кала!

Урман авызындагы хәйран киң юл,
эчкә кергән саен,
гел тарая барып, югалды...
Төртенсәң дә—дүрт як кыйбла!

Җыр яздырткан Олы Мәхәббәт,
ваклык-сатлыкларга түзә алмый,
еллар рәшәсендә эреде.
Калды—Нәфрәт
кара моржа кебек.

Яшәүгә дәрт, хыял-өмет арта һәр ел саен.
Беркөн баксам—гомер шәмем
ике яктан янып килә!..

Алда маяк дигәннәре—
Билгесезлек—пәри туе дигән өермә...

## Зиратта

Озак күмәләр кешене!..
Зират туйдыра.
Тизрәк чумасы килә
Яшәү куенына!

Монда бергә яшәлгән
күпме жаннар иңгән!..
Бәлки, өмет итәләрдер
берәр дога синнән.

Синдә тизрәк чыгу уе
Мәңгелек Йорттан.
Үзеңне дә җибәрмәскә
Еллар буып тоткан.

Синдә әле, ләззәт тоеп,
бала теләү уе.
Туу-үлемнәрдән тора
Кешелекнең туе.

...Озак күмәләр кешене.
Тиз оныталар.
Уйласаң, алар—без бит,
ә без тиздән—алар...

Әрәм үткән кичләр,
мыскылланган таңнар...
Очлы субай актың
җәрәхәтле җанга!
Көйгән мәхәббәтнең
нәфрәте яман!

Тиледән алданган
ир-ат үзе юләр.
Бер Ходайга мәгълүм:
кем әле алдан үләр?
Кемне гөлләр күмәр,
кемне көлләр күмәр...

## Бар да үтә...

«Кызыл ыштан»* кигән
чаклар онытылган.
Беренче кырынган
көзгеләр ватылган.

Беренче сөйгән яр
бүтәндә капланган.
«Зөфаф»ның кан-тапсыз
җәймәсе акланган...

Туган йорт нигезен
әремнәр каплаган.
Хәтердә—яшьлектән
бер дога сакланган.

## Бизү

Бизелсә бизелә икән
бөтен бизләр белән!
Үткән—микъдарлап үлчәнә,
акыл-бизмән белән.

Вертолетлар әверелгән
энә карагына!
Салават күпердән калган
ак та кара гына.

## Авырганда

Моң-гамь белән мөлдерәмә
Гомеремнең савыты.
Йоклый алмый саташыпмы,
тартышыпмы, алмашыпмы...
бәргәләнә җан уты.

Гөнаһлыга да, савап өчен,
бәлзәм бирер вакыттыр.
Бурычым күп, үтәп китим,
И, Ходаем, савыктыр.

Картлык—йогышлы чир.
Йога—Вакыттан.
Булмый аны туктатып
атып та туптан!

Картлыкны тоймассың—
булмасаң гына.
Вакытта «куырылмассың»—
тумасаң гына.

* Сөннәткә утырту.

Үткәнне сорама.
Сиңа да—киләчәк...
Җавап урынына
бирием бер чәчәк.

Күпме су сипсәң дә,
ул да бер корыр.
...Кемнеңдер бер җыры
гомерләргә тора!

## Басып тору

*Тәртип бозган өчен Әни мәрхүмәнең үз тәрбия ысуллары бар иде: без—малайларны ярты яки бер сәгатькә урындыкта бастырып тота иде.*

Ичмасам, бәргәләп
алса гына икән!
Басып торам шәмдәй,
тере малай-һәйкәл...

Шундый гаделсезлек!—
риза түгел күңел.
Бәбкә югалганга
мин гаепле түгел.
Җәймәгә караны
ялгыш кына түктем,
беленмәсен диеп,
ерттым әле читен...
Күрше бакчасына
өч көн кергән юкка!
Әни биргән җәза
булды бер дә юкка...

Сәгать йөрми кебек.
Минутлар озак үтә!
Уйнарга урамда
дус малайлар көтә!

Әни күрмәгәндә
чүгәләп тә алам.
Бу вакытны тизрәк
үткәр сана, Аллам!
Эх, беразга гына
мәрткә китсәң иде!
Әни үрсәләнеп
янда йөрсә иде!
Әй, үкенсә иде!
Уйнар чак җиткәндә
янә терелсәң иде!..

—

Әй, газиз сабый чак!
Әй, үткән гомерләр!
Ул чакларны сирәк
төшләрдә күрү дә!
Үтте күпме көннәр!
Үтте күпме еллар!
Яшәлә-яшәлә
төз басып торулар
күп булды. Булган күк
Үзгәртеп корулар.
Тордык төрле чатта
үсмер егет чакта,
тордык төрле постта
гади солдат чакта.
Кешеләр күмгәндә
церемонлы сакта...

...Басасы иде хәзер
урындыкка менеп!
Бөтен җаным белән
торыр идем көлеп!
Торыр идем сәгать,
торыр идем тәүлек...
Язмыш тарафыннан
бәхетле үртәлеп!

Әлегә әнием
кабере янында
тып-тын басып торам...

## Уйланды ир иртән уянгач...

*Чыны ир-атның—*
*көн дә кичә сиратны.*

**«Ир егетнең йөрәгендә**
**иярләнгән ат ятыр!»**

**Төшендә чапты-чапты да шул атта,**
**уянгач иртән, уйланды шул хакта:**
**Су—батырып, кочмакчы булды;**
**Ут—көйдереп, куырмак булды;**
**Җир—«әйләнеп», башыннан төйде;**
**Хатын-кыз—кадады аркага...**

**Ә Күк менә нишләр?**
**Фәрештәләр канатында күтәрерме?**
**Җәһәннәмгә себерерме җилләре?..**

## Кичеп чыкмады...

**Төнге бураннарда, чаңгы тагып,**
**бозлар аша тартып карадым.**
**Урау юллар аша,**
**төрле-төрле машинада кичтермәкче булдым.**
**Сөйрәдем буксирдай, йөзә-йөзә колач салып...**

**Һич булмагач,**
**турылатып күпер салдырдым.**
**Кызыктырмак булып,**
**каршы якта сарайлар кордым...**

**Иске нигезеннән яңа йортка**
**күченмәгән Ия шикелле,**
**калды Сөю Иске Шәһәрдә—**
**Казансуны кичеп чыкмады!..**

**...Әллә Үзе көчсез булды?**
**Әллә без юньсез булдык...**

## Эх!

*(фольклорга ияреп)*

*И иш булды, иш булды...*
*Иш булмады, биш булды!*
*Комнан аркан ишә дигәч,*
*Кызыккан гына эш булды...*

**Кама суы зур дәрья,**
**диңгез чалымнары бар.**
**Төннәр буе йокламыйсың,**
**йөрәк яраларың бар?**
**Әй, егетем баш сау булсын!—**
**ярның яңалары бар!**

Кем тапкан, кем югалткан:
кем качкан да, кем капкан!..
Эх, милай!
Сайлаганым булып чыкты
урам авыз, җил капка...
Урам авыз, җил капка!

Безнең тауларның башында
бөркет түгел, әрләндер.
Тишек эшләпә кигәнмен,
шуңа башым әйләнде.
Көтүче чыбыркысына
абынганга гарьләндем!

Кем тапкан, кем югалткан!
Кем качкан да, кем капкан!..
Эх, милай!
Сайлаганым булып чыкты
урам авыз, җил капка...
Урам авыз, җил капка!

*Н. гә*

Затлы.
Татлы.
Атлы.
Хаклы.

Усаллыгы?
Минеке чаклы.
Тырышлыгы-үҗәтлеге
кырык сигез катлы!

...Өреп терелтә ала
арыган учакны.

Әңгер-меңгер язмышыма
Ходай биргән Якты!
Югалтсаң, тагын йөрерсең—
«улмы-минме хаклы?»

Орлыктан кибәкне аермый
күпме гомер акты...

## Дүртьюллыклардан

Иркен идек—тар калдык.
Күмәк идек—таркалдык.
...Бер көн килде—таң калдык!—
парлы-парлы такъ калдык.

## Күз уңу

Яшәмәдек дисәк, алар әйтсен—
еллар, ярлар, диңгез-атаулар...

Дөнья камиллеге кимегәнме?—
ниндидер бер төс җитми ал таңда...

## Бигайбә!

Аттылар—атылмады.
Саттылар—сатылмады...
Мәгънәсезлек ярышында
тилегә пар булмады.

## Була кайчак...

Суда сусап, су эчелми
Утта өтелеп, пешелми.
Гайрәт чиксә, бернине дә
күңел кичерми.

«Ике икең дүрт» кебек хакыйкатьне
белеп бетермибез—кызганыч!
...Атасына карап, улын ярат,
анасына карап, кызын коч.

## Үзгәреш

Авыл инде чит. Әмма таныш...
Мәчет тә буш, клуб та буш.
Өйборынча экраннарда
ату-үтерү, секс-тавыш.

## Сәясәт

Күмдек Тегене
Тудырдык Моны.
...Тарта тегермән—
юк кына оны.

Яралар, төзәлсә, үзе куба.
Язган бәхет иңгә үзе куна.
...Очарга йә егылырга Кеше
канатларны үзе куя.

Диңгезләрне кичеп, ярга чыккач,
Томаннарда каласы иттең.
Синең-минем язмыш әле бер хәл,—
Дөньяны ямансу иттең...

Кешегә сан булса, көн була.
Көн булса—кояшлы ил була.
...Шәхесең, милләтең тапталса,
яшь тамган туфрагың көл була.

Якуб
Зәнкиев

# ӨТЕЛГӘН МӘХӘББӘТ

РОМАН *

## 11

Авыл өстенә кыш үзенең мамык юрганын җәяргә ниятләде бугай. Көннәрдән бер көнне авыл кешеләре, йокыдан уянгач та, ни күрсеннәр—ишек аллары да, урам буйлары да, күршеләрнең өй түбәләре дә ап-ак карга төренгән, имеш. Эре-эре йомшак кар бөртекләре талгын-сабыр гына төшүләрен әле һаман дәвам иттерәләр иде. Карның болай, хәбәрсез-нисез дигәндәй, кинәт кенә төшүенә өлкәннәр, галәтләренчә, биниһая гаҗәпсенсәләр дә, бала-чага һич тә аптырамады шикелле. Киресенчә, сөенделәр генә балалар. Аннан-моннан гына битләрен югандай булдылар да, тәрәзәдән күзләрен ала алмыйча гына, тамакларына бераз капкалап, тизрәк урамга чыгу ягын карадылар. Ап-ак кар өстенә һәркайсы үзенең сукмагын салып, кулларындагы букчаларын тәмам онытып, чыр-чу килеп, бер-берсенә карлар атышып, рәхәткә тарыдылар. Мәктәпкә алар, дәрес башланыр вакыт житкәч кенә, өерләре белән килеп керделәр.

Салкын Себер кышы якынлашты. Директор булып, бөтен мәшәкатьләре үз җилкәсенә төшкәч кенә, мондагы хәлләрнең бик хөрти икәнен аңлады Зиннур. Ул мәктәпне тәмамлаганга да байтак вакыт узды бит инде, ә монда берәр тапкыр ремонт булуы шикле иде. Мичләр төти, чи утын ягудан стеналар корымга баткан. Агартырга известь кирәк. Идәннәрне әйтеп торасы да юк, алар бина салынганнан бирле буяу-мазар күрмәгән. Мескен җыештыручылар, көн саен салкын идәнгә тезләнеп, үтмәс пычак белән кырып идән юалар, үзләренчә чисталык сакларга тырышалар. Читтән килгән балаларга рәтле торак бүлмәләр дә юк. Стеналары тузып, челтәргә әверелгән бүлмәләрдә җил уйный, почмакларын бәс сарган. Иртән торуларына, балаларның юыныр сулары боз булып ката, ках-кох ютәллиләр нарасыйлар...

Көне буе мәктәп эшендә йөгереп, төннәр буе уйланып ята Зиннур. Эшләрне ничегрәк итеп рәткә салырга? Өстенә урман аварга торганда, суыктан күшегеп утыр инде туң мәктәптә. Укытучыларга печән чабарга рөхсәт ителмәгән кебек, утын әзерләргә дә ярамый колхоз җирләрендә.

---

* Дәвамы. Башы 1 санда.

РайОНО бүлеп биргән диләнкәләр авылдан ерак, аны ташытырга һаман шул Шыр Шәкүр, Кәрбек Хәйрүшкә ялынырга кала. Быел исән-сау чыксалар, киләсе уку елына ныклап әзерләнәсе булыр. Ә хәзергә шуны аңлады яшь директор: иң әүвәл язмышлары аңа тапшырылган кешеләргә эш, яшәү шартлары тудырырга тиеш ул. Шулай булмый торып алардан сыйфатлы хезмәт, югары нәтиҗәләр сорарга хакы юк.

Беркөн иртән үк мәктәпнең хуҗалык мөдире Әхмәдүш аларга килеп керде, йөзеннән үк ашыгыч эше булуы күренеп тора. Авылга чегәннәр килгән икән, бер бик әйбәт бурлы айгырларын сатарга уйлыйлар, ди. Акчалата булмаса, алыштырып алырга да ризалык бирәләр икән.

—Әллә мәктәп үгезенә алыштырып алыйк микән, Зиннур абый? Атлаган саен ат кирәк дип колхозга ялынып йөрмәс идек. Кичә атланып та йөреп карадым, бик йөрәкле, елгыр күренә хайван.

Зиннур да ат турында уйлап йөри иде, «чыннан да ат булса, эшләр бермә-бер җиңеләер иде» дип уйлап куйды ул һәм, киенеп, Әхмәдүш артыннан атлады.

Дер-дер килеп калтырап торган бахбайның як-ягына чыгып карадылар, хайван бик ябык күренсә дә, тәвәккәлләргә булдылар. Әйбәтләп тәрбияләсәләр, карап кына йөртсәләр, рәтләнер әле.

Атна-ун көн эчендә беренче чана юлы төште. Иртә китеп, кич кайтырга исәп тотып, Зиннур торага барырга җыенды. Үгезнең абзарын сипләп-карап алганчы айгырны Әхмәдүшләрдә сакларга булдылар. Кирәкле кәгазьләрен папкасына салып, иртән үк аларга сугылды директор. Ул килеп житкәндә, хуҗалык мөдире йөрәксегән атны көчкә дилбегәсеннән тотып тора иде.

—Әйдә, Зиннур абый, тизрәк кошовкага утыр, астыңа печән дә җәйдем,—дип ачык чырай белән каршы алды аны Әхмәдүш.

Директор утырып, җилкапканың ачылуы булды, бурлы айгыр ишек алдыннан урамга атылды. Зиннур аз гына чанасыннан чөелеп, төшеп калмады.

«Менә шәп атны каптырганбыз икән, рәхмәт төшкере!—дип уйлады Зиннур, куанычыннан нишләргә белмичә.—Болай булса, торага да күз ачып йомганчы барып житәргә була». Айгыр очыртып кына авыл Астанасын[1] да үтеп китте. Колакларда җил генә сызгыра. Шулай бер чакрыммы, икенеме барды да «йөрәкле айгыр» сабырланды, акрынлап атлый башлады. Башта Зиннур, ярый, аз-маз ял итсен дип, риза булып барды. Аннары бүген үк әйләнеп кайтырга тиешлеген исенә төшереп, атны куаларга тотынды. Ләкин юртырга уйлау түгел, тагын да акрынлады айгыр. Чанадан төшеп, юл буенда гына үсеп утырган тал чыбыгын сындырып, әйдәп карады, бу да файда бирмәде. Ничек тә Көмешлесудан өч чакрым ераклыгындагы Усаклы авылына життеләр. Авылга керүләре булды, әлеге мәхлук, чегәннәрнең гадәте буенча, капка саен борылып, туктый башлады. Әнисенең кәгазьгә төреп кесәсенә салган икмәк, кыстыбый кисәкләре белән алдаштыра торгач, авыл артта калды. «Мәктәп атлы булган икән, котлы булсын,—дип калды таныш агайлар, тик яшь директорның, йөрәкләнеп, аты белән тарткалашуын гына аңламадылар:—Баш бирәсе килми бугай айгырның».

Юл газапка әверелде, шатлыклы уйлар онытылды. Сөйрәлеп барды-барды да бурлы айгыр, бөтенләйгә туктады. Монсу күзләрен мөлдерәтеп хуҗасына карады. Әллә нишләде Зиннур, аю сөйрәтеп кайтып, яңып үлгән аты исенә төшеп, тәне эсселе-суыклы булып китте. Айгырны сыйпап, тынычландырырга тырышты, ләкин ат аның учы тигән саен дерелдәп, тарткалашып куйды. Әнисе биргән ризыклар да беткәч, култыгына печән кыстырып, алга атлады, айгыры да аңа иярде. Алар шул рәвешле торага барып кергәндә, урамнарда караңгы төшеп, фонарьлар яна иде инде. Очраган бер кеше, әллә нинди хикмәт күргәндәй, аның артыннан карап

[1] Астана—изгеләр күмелгән урын.

кала башлады. «Юкка килдем, Усаклыдан ук борылырга булган икән,— дип уйлады Зиннур.—Ләкин хәзер борылудан мәгънә юк, азрак ял иттереп алырга кирәк». Бурлы айгырга нәрсә булганын уйлап бара торгач, үзе тукталасы йортка да якынлашты. Соңгы борылышны үткәндә генә бер агай, янында барган юантык хатынына борылып, юри Зиннурга да ишетелерлек итеп:

—Кара әле, Минсылу, Хужа Насретдин үтеп бара, күрмәсәң күр әнә,—дип көлеп калды.

Кеше көлдереп йөреп булмый, килгән эшләренә дә кул селтәп, иртәнге карангыда кире ук кайтырга юлга чыкты. Кайтышлый да шул ук хәл кабатланды: алдан култыгына печән кыстырып мәктәп директоры атлый, артыннан аңа ияреп бурлы айгыр бара. Ул ял итәргә туктаган йорт хуҗасы тормышны күп күргән тәҗрибәле карт иде. Зиннур хәлне сөйләп биргәч, айгыр тирәли бер әйләнде дә, авыз тирәсен капшап, тешләрен карады.

—Атың үз тиярен ашәгән, балам, исән-сау кайтып житсәң, мондый ерак юлга жәяүләп чыксаң тынычрак булыр, хайванны да жәфаламассың,— диде карт аңа кинәш биргәндәй.

Кайтыр юлында Зиннур атны суккалап интектермәде, үз адымына атлатып кайта бирде. Ләкин айгырның кичә юлга чыкканда җан фәрманга чабуын гына нигә дә юрарга белмәде ул.

Кышкы көн кыска, авылга кайтып кергәндә, караңгы төшеп килә иде инде. Зиннур үзе дә ашыкмады, авылның усал телләре күрсә, такмак чыгарырга да күп сорамаслар. Ояты ни тора бит, директор башың белән ат танымыйча йөре инде! Уйлагач, берәр олырак кеше белән кинәшләшергә дә башына килмәгән, чегәннең мактавына ышанып, алып калды шул. Әхмәдүшләрнең өе юл өстендә генә, хуҗалык мөдиренә тезгенне тоттырды да үзе хәл алырга утырды. Ике көн юлда булуының сәбәбен тиз генә аңлатып бирде, мәктәптәге хәлләрне сорашты.

—Ничек болай булды икән соң?—дип исе китте Әхмәдүшнең дә, директор сүзләрен тыңлагач.—Мина Хәйрүш белән Локман килеп әйттеләр бит, көн аша колхоздан сорап йөргәнче, үз атыгыз булыр, диделәр. Ә мин соң, ачыгавыз, шуңа ышанып та куйдым. Аларның кайчан кешегә яхшылык эшләгәне бар соң?—дип үз-үзен битәрләде.

Соңыннан билгеле булды, айгырны сатар алдыннан сигездән үрелгән камчы белән яргән икән чегән, шуңа күрә дә тегесе, янына кеше килүгә үк, котырынып чаба башлаган. Ат вакыйгасы да Хәйрүшнең этлегеннән башка үтмәде...

Яңадан ат алырга мөмкинчелеге булмаган директор шул ук үтенеч белән РайОНО мөдиренә мөрәҗәгать итеп карады. Мәктәпнең хәлен болай да белгән Марфа Ивановна бу юлы өметләндерерлек җавап бирде. Якындагы балалар йорты директоры Новопашин дигән кеше үзенең карамагында булган алты атның берсен аңа бирергә риза булган. Биш яшенә кадәр ияр, ыңгырчак күрмәгән Кола исә үзен алырга килүчеләргә баш бирергә теләмәде. Бу ирек сөюче хайванны җигәргә өйрәтүләренә ышанмаган директор да үзенең шиген белдерде.

—Өйрәтербез,—диделәр бертавыштан Зиннур белән бергә килгән Әхмәдүш.—Авылга кадәр ара ерак, сабырланыр,—дип тә өстәделәр.

Шулай итеп, мәктәп атлы булды. Чыннан да, сокланырлык елгыр бия иде Кола, авыз ачып торганнарны санга да сукмый, үзе кебек яшь, көчлеләрне генә хуҗасы итеп таныды ул. Авылга кайтып, беренче тапкыр урам әйләнгәндә үк, тамаша карарга чыккан Хәйрүшне тәртә башы белән төрттереп, аяктан екты. Әле ярый, чанада Зиннур үзе түгел, хуҗалык мөдире генә иде, эш зурга китмәде. Колакчынын табып, башына каплады да Кәрбек, юлда тәгәрәп ятуын кеше күрмәгәндә, югалу ягын карады.

## 12

Мәктәп бинасын, гомуми торакны җайга салу өчен дә аз-маз материаллар арттырды РайОНО мөдире, ял көннәрендә өмә ясарга карар иттеләр. Үтәдән-үтә җил йөргән урыннарны сылап, фанера кактылар, авылдагы иң яхшы мич чыгаручыны күндереп, бүлмәләрне җылыту хәстәрен дә күрделәр. Мич, стеналар агартылгач, укытучы-укучыларның да йөзләре яктырып китте. Әкренләп мәктәпкә җан иңде. Ләкин почмактагы тугызынчы сыйныфлар укый торган «көфер почмагына» барыбер кирпеч җитмәде. Алар гына нәүмизләнеп калды, тун якаларын күтәреп, бияләйләр киеп дәрес тыңлауларын дәвам иттерделәр.

—Әх, тимер мич юнәтеп булса икән!—диде Зиннур Әхмәдүшкә.—Ләкин аны хәзер көндез чыра яндырып эзләсәң дә, табармын димә.

Утыра торгач, киңәшләшеп, мондый фикергә килделәр: Әхмәдүш тимерче эзләп торага бара, мөмкинлек булса, тимер мич ясату чарасын күрә. Иртәгә кеше Әхмәдүш, бер атнадан тимер мичен, моржаларын берүзе өстенә йөкләп алып та кайтты. Җылысыз калган теге «көфер почмагына» да рәхәт җылылык иңде, укучыларның башлары күккә тиде. Шул ук өмәләр белән утын да әзерләнде. Берәү дә эштән читләшеп, карышып тормады, бергәләп башкарылган эшнең авырлыгы да сизелмәде. Эшләренең нәтиҗәсен күрү яшь директорга көч өстәде, үзен ышанычлырак тотарга ярдәм итте. Инде ул укучыларның күзләренә дә туры карый, укытучылардан да эшләрен җиренә җиткереп үтәүләрен таләп итә алачак иде.

Иң авыры хуҗалык эшләрен җайга салу, дип уйлаган Зиннур нык кына ялгышкан булып чыкты. Укытучыларның эшен тикшерүдән башланды директорның күрәчәкләре.

Яшь директорның мәктәпкә төрле яңалыклар кертеп, җан атып эшләве күпләргә ошый иде. Торгынлык сазлыгына баткан мәктәпкә Абдуллин үзе белән бергә шифалы һава, ачык мөнәсәбәтләр алып керде. Бигрәк тә яшьләр канатланып эшли башладылар. Физика, химия дәресләре өчен приборлар булдырды яшь директор, сирәк кенә булса да лаборатор эшләрне башкару өчен шәһәрдәге шеф мәктәпләргә бару мөмкинчелеге туды. Җылы бүлмәләрдә гөлләр үстерелә башлады. Ботаника укытучысы бакчага утырту өчен төрле орлыкларны хәзердән үк әзерли башлады. Спорт уеннары, ярышларда яшьрәк укытучылар белән берлектә директор абыйлары үзе дә рәхәтләнеп катнаша килде. Бөтен җаны белән укуга, мәктәп эшләренә бирелгән Нурия дә мәктәпкә кайтуына куанып бетә алмый, хәленнән килгәнчә Зиннур абыйсына ярдәм итәргә тырыша иде.

Дәресләрне тикшерүдән соң үткәрелгән педсоветтан башланды хәлләр. Директор укытучыларның дәресләренә бәя биреп, кайбер киңәшләрен, үз фикерен әйтте. Күп кенә укытучылар мактау, ышаныч сүзләре ишеттеләр. Чират бишенче-тугызынчы классларда тарих укытучы Туйбикәгә җиткәч, Зиннур дәреснең күп кенә җитешсезлекләрен күрсәтте, укытучының дәрескә әзерлеге тиешенчә булмавын әйтте. Даут абыйларыннан тәнкыйть сүзе ишетмәгән тарих укытучысы, әлбәттә, үзенең тәҗрибәле белгеч булуын да, Зиннурның әле мәктәп бусагасыннан атлап кына керүен дә калдырмады. Пыр тузып, укытучылар бүлмәсеннән чыгып ук китте.

Китапханә эше дә директорны канәгатьләндермәде. «Булган китаплар да рәтләп куелмаган, бернинди күргәзмәләр, әдәби почмаклар оештырылмый», дип санап чыкты ул, һәр сүзенең Өннәшкә ничек тәэсир итәсен алдан ук белеп. Коллектив аның фикере белән килешсә дә, авыз ачып сүз дәшәргә җөрьәт итмәделәр. Зиннур хаклы иде, китапханәченең тавышы Туйбикәнекеннән дә яманрак булды.

Кисәтү алган укытучылар эшләрен яхшырту өчен аркылыны буйга да алып салмадылар. Киресенчә, яшь директорның үзен күзәтергә, тырнак астыннан кер эзләргә керештеләр. Әдәбият укытучысы Фәүзия Тукай иҗаты буенча конференция үткәрергә теләп, китапханәгә материаллар сорап керсә дә, ана игътибар итүче булмады. Өннәш белән Туйбикә

серләшеп утыралар иде, аның ягына әйләнеп тә карамадылар. Зиннурга алар арасына керергә, кисәтергә туры килде.

—Тукай томнарын мин үзем җилкәмә күтәреп кайттым, Өннәш апа,—дип башлады ул сүзен тыныч кына.—Ә портретын, тузан эченнән алып, элеп куегыз дип, кулыгызга тоттырдым. Кичәгә кирәкле материалларны табып, әдәбият укытучысына тапшырмасагыз, үзегезне эштән азат дип саный аласыз.—Чигәсен тотып, үз бүлмәсенә юнәлде директор.

Бу хәлләргә Даут абыйсы да бик борчылды, хатынының һаман да ипкә килмәгәнен күргәч, аерылырга ниятләде бугай.

—Зиннур энем, Өннәш белән Туйбикә ханымның серләре бик килешә, соңгы вакыт гел бергә йөриләр. Сак бул, берәр мөгез чыгара күрмәсеннәр,—диде ул, чын күңелдән борчылып.

Зиннур белән Нуриянең аралары бик якынайды. Кешегә күрсәтергә тырышмасалар да, күзләре белән аңлаша, бер-берсенә ышанычлы терәк була башлаган иде алар. Эш буенча кирәккәндә, Нурия тартынмыйча директор абыйсының өенә дә керә, ә Ниязбикә карчык бу хәлгә куанып бетә алмый. Тотнаклы, саф иде аларның мөнәсәбәтләре. Мәхәббәтне яшереп торып буламыни, алар сүзсез дә аңлашты. Бу икәүнең мөнәсәбәтләре мәктәптә дә мәгълүм булды, күпләр:

—Пар килгәннәр дә соң, күз тимәсен,—диюдән узмады. Ләкин тәнкыйтьләнгән укытучыларга бу бик зур җим булды:

—Директорга үзенең укучысы белән чуалырга ярыймы соң!

—Җитмәсә кыз аның өенә дә кереп йөри икән бит әле, ахирәт кенәм!..—дип пышылдашты алар икәүдән-икәү генә калгач. Юкка гына түгел, бер-бер хәлләре бардыр, дигән нәтиҗәгә килде бозык хатын. Җаен туры китереп, бу хакта Хәйрүш белән дә серләште. Кәрбеккә шул җитә калды, Зиннурның мәктәптәге эшләрен күреп-ишетеп тора бит. Ул директор булып алгач, караңгы карга күмелеп утырган авыл өчен бердәнбер яктылык учагы, үзенә тартып торган мәдәният үзәгенә әверелде мәктәп. Бу исә көндәшенең зур җиңүе, Хәйрүшнең берсүзсез җиңелүе иде. Тагын бер кабат Зиннурга этлек эшләргә җай чыгуына куанып, як-ягына каранды да бик акыллы киңәш бирде:

—Югарыда мондый эшләр зур әхлаксызлык дип бәяләнә,—диде ул Өннәшнең эченә керердәй булып,—аның ояты бөтен педколлективка төшәчәк. Монардан тыш мулла баласы, ишан оныгы икәнен дә онытмыйча, РОНОга гына түгел, Мәскәүгә үк язарга кирәк. Җитәкчеләр аның белән ничек сөйләшергә кирәген белерләр.

Уйлап эш йөртте Хәйрүш, өстәге иптәшләр казынып, тикшеренеп тормаслар. Печән хәйләсеннән чак котылды Зиннур, ә бу эш печән кебек кенә булмас...

—Чыннан да, безне тикшереп утырганчы, үзен тикшерсеннәр әле, бер-бер гөнаһы булмыйча калмас яшь директорның.

Яза торгач, хат зурга китте. Директорның балаларга тискәре үрнәк күрсәтүе дә, үз укучысы белән гыйшык-мыйшык тотуы да, атасы мулла булгач, мәктәптә атеистик эш алып бармавы да, төрле хорафатлар белән көрәшмәве дә әйтелде. Алай гынамы әле, коммунистлар партиясенә, иптәш Сталинның үзенә тел тидерә башлавы кат-кат язылды. Көмешлесу авылы урта мәктәбе директоры Зиннур Абдуллин совет властена аяк чалучы, иң зур дошман, азгын, әхлаксыз бәндә булып гәүдәләнергә тиеш иде. Хатны әлеге дә баягы Хәйрүшкә тапшырдылар. Бригадир исә бөтен шартын туры китереп, хатны Тубылдан, заказной итеп салды. Шикаять, кеше ышанмаслык хәбәрләр тулы пычрак хат озын юлга чыкты. Хатны язучылар исә мыек асларыннан гына елмаеп, үз эшләренең нәтиҗәләрен көтә башладылар. Җавап озак көттермәс, районнан килгән һәрбер вәкил нотыкларын халык дошманнары, партия дошманнары белән көрәшергә чакырып бетерәләр. Аларга тел тидерергә җөрьәт иткән Фәтхулла картның улы да бик озак йөри алмас борын чөеп, тиз сындырырлар...

## 13

Идарә утырышы озакка сузылды. Шыр Шәкүр гадәтенчә колхозның планнары, колхозчыларның ялкаулыгы хакында бик тәмләп, каткат сөйләде. Кайтырга чыккач, Локман җан дусты Хәйрүш белән бергәрәк атлады. Әллә кайчаннан бирле киңәшләшәсе сүзе бар иде аның. Икәүдән-икәү генә калгач, пышылдап кына сүз башлады:

—Мин, малай, бер тузга язмаган хәлгә тап булдым бит әле. Сиңа гына ышанып сөйли алам, бәлки берәр киңәш бирерсең...

Кәрбекнең колаклары тагын да тырпая, күзе тагын да кысыла, болай да җәенке борын яфраклары тагын да киңәя төште. Иллә дә ярата ул кеше серен тыңларга.

—Йә, йә, сөйләп кара, ни хәсрәтләрең бар икән?—дигән булды ул шаярган сыман итеп.

—Эш көлкедән узган, малай,—диде Локман чыннан да ачуланып.—Йә үләм, йә калам, болай булса...

Дустының чынлап торып пошаманга калуы тагын ныграк кызыксыну уятты. Һәм ул, барудан туктап, Локманга текәлде.

Шаклар катты Хәйрүш, котлары алынды. Алынмаслык та түгел шул: венерик авыру эләктергән икән ләбаса аның ахирие! Ашаганы аш, эчкәне су түгел икән егеткәйнең. Авыру артканнан-арта барып, хәзер тоташ сызлавыкка әйләнгән икән. Күрше авылга барганда классташы Гөлсылуны очраткан егет. Аның шул көннәрдә генә әнисе үлеп, кыз ятим калган. Озактан бирле күрешкәннәре булмагач, сөйләшер сүзләре дә күп булган. Классташын өенә чакырган кыз, тегесе юл унаенда авыл кибетенә тиеп, ярты алырга да онытмаган. Гөлсылу кунагына колбаса белән бәрәңге кыздырган, Локман биргән акчага балыкчы Әхмәт картларга кереп, сап-сары табаннар да алып чыккан. Төн озын мәктәп елларын искә алып утырган классташлар, табан да пешеп чыккан. Әкренләп кенә шешәне дә түнтәреп куйганнар. Локман кунарга калган...

Кызның колхоздан китәргә теләп тә, документлары булмагач, беркая да бара алмавы хәтерендә калган егетнең. Һәр колхозда шулай бит, үзебезгә дә эшләрдәй кешеләр җитешми, дип, идарә җитәкчеләре берәүгә дә кәгазь бирми икән.

Сүзен тәгәлләп дустыннан киңәш сорады Локман, кайда, ничек дәвалыйлар икән бу яман чирдән? Ә бит кызга өйләнмәкче иде, сылулыгы, килеш-килбәте бер дигән. Үзенә кадәр кемнәр кулында булган, ни рәвешле кәеф-сафа кылганын каян белсен ди ул?

Уйларга, ярдәм итәргә вәгъдә биреп, Хәйрүш өенә юл алды. Икенче көнне үк үзенең планы белән дустын таныштырырга ашыкты. Төне буе йокламаса-йокламады, ә планның шәбен корды Кәрбек.

—Беләсеңме, дускай, менә нишлибез. Син яңадан барып, Гөлсылуны монда алып кайт. Минем Фәтхулла улы Зиннурга бурычлы икәнемне беләсең, әгәр кызый, бер хәйләсен табып, аңа да шул «бүләген» калдырып китә алса, аңа белешмәләр дә, сиңа дәва да табылыр. Шуңа кадәр бераз сабыр итәргә, түзәргә туры килер, дускай. Барыбер миннән башка бер эшең дә чыкмас. «Эче авырта» дигән сылтау белән торага дәваланырга озатырмын, паспорт алу өчен кирәкле кәгазьләр алырга да булышырмын. Җаен туры китереп керсәң, Шыр Шәкүр ярты-йортыга ярты колхозын сатып җибәрергә риза. Җаен гына таба белергә кирәк.

Гөлсылуга документлары өчен фотолар кирәк булачак бит, ә фотога төшерүче тирә-якка да бер Зиннур гына. Шуны сәбәп итеп, аларны очраштырырга булдылар, калганнарын кыз үзе дә төшенер. «Төшенер, колхоздан, авыруыннан исән-имин котыласы килсә, бик тиз төшенер кызыкай».

Локман килгәндә, Гөлсылу үз-үзенә кул салырлык дәрәҗәдә әрнеп, елап утыра иде. Күзләре шешенеп беткән, йөзләре сулып калган. Сабакташын күргәч, куркып, куырылып калды, ни диярге дә белмәде.

Кан-яшьләрен түгеп Локманнан гафу сорады, аңа кадәр үзенең авыру икәнен белмәвен аңлатырга тырышты. Алар авылына, янәсе, шәһәрдән килгән вәкил тиз арада кызны күреп, ышанычлы кешеләрдән аның ялгыз яшәвен белеп алган. «Мин сине үзем белән алып китәм, син миңа бик ошадың» дигәч, каршы килмәгән кыз, вәкилне үзләренә чакырган. Янадан кайтып алырга вәгъдә иткән шома егетнең эзләре суынган, Гөлсылу гына ике ут арасында ятып калган...

Чарасызлыктан интеккән, киңәшләшергә бер якын кешесе булмаган кыз, азрак уйлап торгач, Локманның сүзләренә колак салды. Тиз арада юмалап, авыруы турында берәүгә дә белдермәскә, алар әйткәнне булдыра алса, торага алып барып дәваларга вәгъдә итеп, Көмешлесуга алып кайтты егет Гөлсылуны. Бер вакыттарак укыган булганлыктан, кыз Зиннурны да белә, аның институт бетереп кайтып, директор булып эшләвеннән дә хәбәрдар иде. Локман белән Хәйрүшнең сүзләрен тыңлагач, бермәлгә югалып, икеләнеп калды ул. Укып кайтып кеше булган авылдашларыннан көнләшә булыр егетләр, берәр этлек уйлыйлар булыр, тик нигә соң моны Гөлсылу эшләргә тиеш, аның нинди катнашы бар монда? Ләкин егетләр шаяртмыйлар, әнә бит ялпак танаулы Хәйрүш дигәннәренең сызык кына калган кысык күзләре очкынланып тора, аларныкыча итмәсән, гайбәтең бөтен авылга таралачак. Көт тә тор, яшәрлегенне калдырмаячаклар болар. Тәвәккәлләде кыз, егетләрнең биргән вәгъдәләре дә бик зурдан иде. «Исән-сау бу авырудан котыла алсам, паспорт юнәтеп торага да китсәм, ир-егетләр ягына борылып та карамас идем, бер Ходаем»,—дип антлар эчте ул үз-үзенә.

Дәресләр бетеп, Зиннурның өенә кайтуын тәгаенләгәч, егетләр Гөлсылуны директорның урам башына кадәр озатып куйдылар. Бу вакытта ул кайтып, түбән өйдә ашап-эчеп, икенче катка күтәрелгән иде. Дәрес өстәле артына утырырга да өлгермәде, берәү ишек шакыды. Укытучы, укучылары булса: «Керергә рөхсәтме, абый?»—дип кенә сорарлар иде. Кем булыр икән бу? Ишекне ачса, ять-яшь кыз басып тора. Таныган да кебек Зиннур, исемен дә төгәл әйтә алмый.

—Керергә мөмкинме сезгә, Зиннур абый?—ди кунак, үз итеп елмаеп. Кызның әнә шул елмаюлары, бит очының чокырланып китүе дә таныш аңа. «Кем соң әле бу?» Үзенең кызны танымавы өчен гафу үтенде һәм кул ишарәсе белән түргә уздырды.

—Баш ватмагыз, Зиннур абый, сез мине хәтерләми дә булырсыз,—дип елмайды кыз.—Күрше авылдан мин, кайчандыр сезнең авылда укып, тулай торакта торган идем.

—Гөлсылу?—диде Зиннур һаман да үз-үзенә ышанмыйча.—Без мәктәпне бетергәндә сез бала-чага гына идегез ләбаса, ә хәзер нинди кыз булгансың.—Егет тагын бер кат баштанаяк аны күздән кичерде. Гөлсылу чыннан да буйга-сынга чибәр, бите алсуланып тора, елмайгандагы чокыры тагын да мөлаемлык өсти үзенә. Гөлсылу чыннан да танымаслык булып үзгәргән, олыгайган иде.

—Урамда очратсаң, танымаслык булгансың,—дип сөйләнеп, өстәл янындагы урындыкны тәкъдим итте. Авыл аралары ерак түгел, еш барып йөрергә туры килмәсә дә, туйлар, үлем-китем хәбәрләре ишетелеп тора. Үзләренең мәктәпләрендә укыган Гөлсылуның әнисе үлеп, бөтенләй ялгыз калуын белә иде Зиннур, ләкин чибәркәйнең нинди йомыш белән килүен аңлый алмады. Аның сораулы карашы кунагына да тәэсир итте, күрәсең. Гөлсылу үзенең гозерен әйтте:

—Кыз балага авылда ялгыз яшәүләре ай-һай авыр,—диде, күтәрелеп карамыйча гына.—Торага барып, эшкә урнашасым килә. Документлар, кәгазьләр юллап йөрим. Сезне фотога төшерә дип ишеткән идем, мөмкин булса, миңа да ясап бирмәссезме икән, Зиннур абый?—Кыз сораулы карашын күтәрде.

Менә эш нәрсәдә икән, кызның уйламаганда үзенә килеп керүенә нык кына гаҗәпләнгән Зиннур җиңел сулап куйгандай булды.

—Андый гына эшне булдырабыз аны, тик сиңа аны алып кайтып китәргә кирәк булыр бит.

—Әйе шул, бер килгәндә алып китсәм, әйбәт булыр иде. Вакытыгыз булса инде...

—Ярый, Гөлсылу, хәзер мин сине төшерим, аннан соң эшкә барасым бар. Кич белән кайткач, ясармын, берочтан кайчаннан бирле җыелып килгән башка фотоларны да эшләрмен.

Яктылыкны тикшереп, аны җайлабрак утыртты да, төшереп, мәктәпкә китәргә җыена башлады. Кызга туры карамыйча гына:

—Мин эшкә юл тотам хәзер, син кемнәрдә тукталдың, юл унае түгелме?—дип сорап куйды.

Кыз сорауны үткәреп кенә җибәрде дә, тагын да серлерәк итеп:

—Зиннур абый, минем тагын бер үтенечем бар иде,—дип егеткә карады. Өстәл өстенә иелеп, кирәкле китапларын эзләгән Зиннур, кызыксынып кызга текәлде, аның күзләрендә сүзсез сорау иде.

—Мөмкин булса минем фотоларны кәгазьгә төшерүегезне карап торасым килә. Минем өчен бу баш житмәслек серле бер эш. Фотога төшереп, ясый белүчеләр тылсым ияләре булып тоела миңа.

Моны көтмәгән егет рәхәтләнеп көлеп куйды, Гөлсылуга карап:

—Аны ясауның бер тылсымы да юк, бары тик кирәкле реактивларың гына булсын. Сиңа унайлы булырмы икән соң, мин аларны карангылаткач, аерым ут яктысында гына ясыйм бит,—диде ул ризалык та, каршы килү дә белдермәгән бер тавыш белән.

—Мине эзләп йөрүче булмас, ә сезгә комачауламаска тырышырмын.

Кыз белән икәүдән-икәү генә калуны килештермәсә дә, аның соравын кире кагарга да яхшысынмады Зиннур. Фото эше белән күпләр кызыксына бит, әнә унынчыларның барлык кызлары да түгәрәккә йөри, беренче килүләрендә аларның кызыксынуы да Гөлсылудан ким түгел иде.

—Ярый алайса, килерсең, ләкин мин тугызларсыз да бушамам. Өске өйдә ут кабынгач, рәхим ит.—Зиннур, кунагының килешле буйсынына тагын бер кат күз төшереп, озатып калды.

Мәктәптә укыган кайгысыз елларын исенә алып кайтты Гөлсылу. Мондый бәхетсезлеккә дучар булмаса, бер мәктәптә укыган, аңа берсүзсез ярдәм итәргә атлыгып торган, кайгысын чын күңеленнән уртаклашкан кешегә яманлык итәр идеме соң ул? Аякларын сөйрәп, Локманнарга ерак кына туган тиешле карчыкның өйалдына атлады. Озак көттермичә, Локман да килеп житте, сөяркәсенең хәлен сорашты. Икеләнүе йөзенә чыккан иде ахры кызның, егет тагын аны юата, үгетли башлады:

—Мин бит сиңа чыннан да өйләнергә уйлаган идем, бер кичкә түз акыллым, аннан соң икебез дә дәваланып, бергә булырбыз. Хәйрүшнең белмәгән кешесе юк аның, документларын да җайлар, врачларын да табар. Риза булмасак, икебез дә бу авырудан котыла алмабыз,—дип юмалады.

Гөлсылу риза булмас, баш тартыр бу эштән, дип коты алынды егеткәйнең. Алай булса, Хәйрүштән рәхим-шәфкать көтмә. Үзенә кирәк булганда гына дус ул, берәр нәрсәне аныңча кылмасаң, гомерлек дошманы булып калырсың. Тубылга барып врач эзләп йөрерлек ышанычлы кешесе дә юк, бөтен өмет Хәйрүштә. Хәзер ничек булса да кызны күндерергә кирәк.

—Мин бит мәктәптә укыганда ук сине өзелеп сөя идем, син генә миңа карамадың,—дип дәвам итте ул сүзен,—ә хәзер без бергә була алабыз, авыруны берәү дә белмәс.

—Ул чагында дөнья миңа ал да гөл булып кына күренә иде шул,—дип куйды кыз, авыр сулап.—Ә тормыш без уйлаганча гына түгел икән...

Теге якта хуҗа карчык кыштыр-кыштыр килеп, нәрсәдер эшләп йөри, Локман әледән-әле ул якка каранып, тынычсызлана иде.

Ниһаять, көткән сәгатьләре житте, озакламыйча югары очтагы алар көткән өйдә ут яктысы күренде. Атласа да атлады Гөлсылу, атламаса да

атлады. Зиннур белән үзен ничек тотасын күз алдына да китерә алмады. Локман әйтүенчә, егет ана үзе үк бәйләнә башлаячак, ана тик карышмаска гына кирәк булачак иде. Зиннур да ир-егет ләбаса, аулактан файдаланмыйча калмас...

Сөйләшкәнчә, кызны ачык йөз белән каршы алды Зиннур, өс киемен чишенгәч, утырырга тәкъдим итте. Кирәк-яракларын әзерләп бетергәч, тылсымлы кызыл утын кабызды. Гөлсылу чын-чынлап исе китеп эшне күзәтте, кәгазьдә үзен күргәч, тәэсирләнүдән кулларын чәбәкләп, Зиннурны битеннән үбеп алды. Егет көйдергеч итеп карап куйды, Гөлсылу хәтта бер-ике адым артка да чигенде, авыз эченнән мыгырданып, гафу үтенде. Унайсыз тынлык урнашты. Хәленнән килсә, жир ярыгына төшәрдәй булды кыз, ләкин ул моннан чыгып китә алмый шул: тегеләр икәүләп капка төбенә каләр китереп куйдылар, тиз генә кайтып та китмәсләр.

Байтактан бирле жыелган негативлардан кәгазьгә төшереләсе фотолар шактый жыелган иде, Зиннур башын күтәрмичә эшләде дә эшләде, бермәлгә кунакны онытып та жибәргәндәй булды. Фотоларны киптерергә дип тезә башлагач кына, аны яна күргән кебек, гажәпсенеп карады да, сәгатенә күз салды. Гөлсылунын сораулы карашы ана төбәлде.

—Син кемдә тукталдым диден әле?—егет унайсызланып ана карады.

Моны көтмәгән кыз тотлыгып калды, шулай да югары очтагы үзе туктаган карчыкнын исемен әйтә алды. Бераздан, аска карап кына:

—Ул мине көтмидер инде, ишекләрен бикләп яткандыр, мин моннан авылга кайтып китәм, дип әйттем,—диде.

Зиннур чигәләрен уып, чәчләрен кулы белән артка сыпырды. «Тегеләр әйткәнчә, директор абый ялгызлыктан файдаланырга уйламый ахры»,—дип уйлап куйды сылукай эчтән генә.

—Төннен берендә юлга чыкмассын бит инде, ят әнә сәкегә, үземә урынны идәндә жайлармын.

Тиздән ут сүнде, Локман белән Хәйрүш, кулларын угалап, кайтыр юлга кузгалды.

Төне буе угаланып чыкты кыз, күзенә йокы әсәре кермәде. «Ничек булды сон әле бу, тегеләргә нәрсә дияргә сон, болай булгач?» Бер көенде, бер сөенде кыз. Гомерендә нибары ике егет белән ялгыз калып, икесендә дә тегеләрнен азгын дәртенә дәрман булган сылукай Зиннурга олы хөрмәт белән карады. Сизеп торды бит Гөлсылу, ана да ошады ул, әнә ничек сөзеп, баштанаяк күздән кичерде Зиннур аны беренче күрүендә. Кызыл ут яктысында да карап-карап алгалады. Әрнүләре үзәгенә үткән, бу тормышта кинәшләшер кешесе дә булмаган Гөлсылу күнеленнән Зиннурга рәхмәтле иде. Шулай да эшнен болай булып чыгуына коты алынды. Тегеләр бит уйный торган кешеләр түгел. Локманга хәлне анлатып бирерсен дә, Хәйрүш дигәненнә бит мәрхәмәтнен эзе дә юк. Локман үзе дә анын алдында дер калтырап тора бит. Кеше алдында оятлы итеп кенә туктап калмас ул, үз дигәненчә булмаса, үтереп бәрүдән дә тартынып тормас. Яман чирдән дә яманрак булдылар лабаса бу явызлар. Иланым, үзен сакла шул рәхим-шәфкатьсез бәндәләрдән!

Ут сүнгәч, кайтыр юлга чыккан егетләр иртәге көнгә план кордылар. Болай булса, эш барып чыкты. Ләкин ин-ин кирәклесе әле эшләнмәгән. Ничек булса да бу пар йоклап торгалаганчы Нурияне аларга кертергә һәм хәлне үз күзләре белән күрерлек итәргә кирәк. Төрлечә уйлап карадылар. Хәйрүш үзе турыдан-туры Нурияләргә барып керә алмый. Кыз акыллы, хәйләне бик тиз анлап алачак. Хәйрүштән шикләнерлек булмасын иде. Уйлана-кинәшләшә торгач, бу якны Локман карарга тиеш, дигән нәтижәгә килделәр.

Кышкы төн бик озын, ләкин Зиннурнын иртән мәктәпкә барасын һәркем белә. Эшне ул уянгалаганчы «пешерергә» булдылар. Хәйрүшнен кара айгырын жигеп, Локман Нуриянен ахирәте Камиләләр капкасы төбенә килеп туктады. Мичтән куе төтен чыга, өйдәгеләр аякка баскан

булырга тиеш. Тәрәзәне шакып кына Камиләне чакырды егет. Иртәнге кунакны нигә юрарга белмәгән кызга турыдан-туры:

—Камилә, күрше авылның Гөлсылу сездә кунмадымы?—дигән сорау бирде.—Ул кичә Зиннур абыйга фотога төшергә дип килгән иде, авылына илтеп куюымны сорады. Эшкә кадәр озатып куярмын дигән идем...

—Юк шул, безгә кермәде, күренмәде ул. Бәлки, Нурияләрдә кунгандыр?

Локман эшнең болайга китүенә бик шат иде, кызның үзен үк Нурияләргә кертеп җибәрде. Гөлсылу, әлбәттә, аларда да юк иде. Локман гаҗәпкә калган кыяфәт ясады. Кызлар да йомгакны ничек сүтәргә белмәделәр. Бераз торгач, егет, ашыкканлык галәмәте чыгарып, сүз башлады:

—Бәлки, ул кайтып ук киткәндер, минем дә вакытым бик тар. Кызлар, Зиннур абыйга кереп кенә сорап чыкмассызмы икән, тынычланып, эшкә китәр идем.

Камилә белән Нурия таныш баскычлардан җәһәт кенә өскә дә менеп киттеләр. Үз күзләренә үзләре ышанмады алар: ишек ачык, Зиннур абыйлары йокыдан тормаган, идәндә хатын-кыз киемнәре сибелеп ята, ә сәкедә—кап-кара толым сүтелеп төшкән. Бер секундка гына катып калган Нурия, битен каплап, кире чыгып йөгерде, Камилә аның артыннан ташланды.

## 14

Гөлсылу керүчеләрне сизеп ятты, алар чыгып киткәч үк, киемнәрен җыеп киенде, үз фотоларын алып, чыгып та йөгерде. Иртәнге чәйне эчкәч, Зиннур кондәгечә мәктәпкә ашыкты. Кичә бик соң яткач, түшәктән дә соңрак күтәрелде. Ашыкканда җил каршы дигәндәй, юлын Хәйрүш бүлде. Мыскыллы елмаеп, уртларын чәйни-чәйни карап торды да, һаваланган борынын кинәйтеп, сүз башлады:

—Ну, хәлләр ничек, директор?—дигән булды ул, авызын җыя алмыйча.

Зиннур шундук аның тагын бер этлек эшләп йөрүен сизде.

—Ничек булса да, синең белән бүлешергә исәп юк,—дип кырт өзде.

—Әйе, андый серне бүлешмиләр инде. Бәлки, дуслыгыбыз хакына бусы белән бүлешерсең, күрше авыл кызын әйтәм?

Зиннур, өстенә шакшы су сипкәндәй, сискәнеп китте, ялт итеп Хәйрүшкә карады. Ә тегесе шуны гына көткәндәй тезеп китте:

—Син хәзер зур кеше булгач, фотога төшәргә дә өенә генә чакырасың, ясауны да төне буе бергәләп кенә ясыйсың, диләр. Түләве дә бик кыйммәт түгел, бер кич кенә, диләр.

Ачуыннан нишләргә белмәде Зиннур, йодрыкларын йомарлап, өстенә ташланудан үзен чак тыеп калды. Ә тегесе мырлапмы-мырлый, ата мәче диярсең:

—Ятим дигәч тә кызны шулай мыскылларга ярыймы соң?—дигән булды Кәрбек.—Мескен елый-елый шешенеп беткән. Нәрсә булганын сорагач та, күпме тынычлана алмыйча барды. Авылына кадәр озатып куйдым. «Зиннур абый мине харап итте» дип, юл буе яшь түкте Гөлсылукай...

Мәктәп директоры ана:

—Кеше ышанмастайны дөрес булса да сөйләмә,—диде дә зур-зур атлап китеп барды. Ә үзенең йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып типте. Аның авызына кергән хәбәр—үзең урамга чыгып сөйләгән белән бер: иртәгә үк авыл буйлап таралыр.

—Кеше ышанмаса да, Нурия ышанырга тиеш,—дип кычкырып калды Хәйрүш, хахылдап көлүдән тыела алмыйча.

Дөрес уйламады Зиннур. Хәбәр иртәгене дә көтмичә, кеше теленә эләкте, директорның ялгыш адымын көтеп кенә йөргән Өннәш, Туйбикә-

ләргә сөйләр сүз табылды. Аларның Зиннурга теш кайрап йөргәнен бик яхшы белгән Хәйрүш бу юлы да шулар аша эш йөртергә уйлады. Даут абыйсының эшкә китүен көтеп кенә торды да, сердәше янына юл тотты. Хуҗалыктагы байтак кирәк-яракларны, печән, утын кебек нәрсәләрне гел Хәйрүш аша гына булдырды Өннәш. Ә тегенә нәрсә, «үзем тапкан мал түгел, колхозныкы җәл түгел» дип, хатынның бар теләген дә үтәп килә. Бушка түгел, билгеле...

—Соңгы хәбәрләрне ишеттеңме соң әле, Өннәш әбәкәем?—дигән булды ул, исәнләшкәч үк, хатынның юантык беленә кагылгандай итеп.

—Мин йоклаганда дөньясы җимерелмәгәндер әле,—дигән булды тегесе дә, сырпаланып. Хатынның торып килүе генә иде ахры, чәчләре тузган, күз төпләре шешенгән, йокы күлмәге өстеннән кигән халаты да төймәләнмәгән, изүләре ачык...

—Капты бит яраткан директорыгыз капкынга,—диде Хәйрүш, сүзне озакка сузмыйча.

Шуны гына көткәндәй, Өннәш тә ялт итеп аңа борылды:

—Әллә Мәскәүдән тикшерү килгәнме, тизрәк мәктәпкә йөгерим алайса, иң кызыгын күрми калам бит,—дип, җыена ук башлады.

—Анысы да озакламас, монда икенче нәрсә әле. Зиннур Тегермәнле авылыннан бер кыз белән кунаган, ди, кызны, фотога төшерәм дип, алдалап өенә чакырган икән. Төне буе фотолар ясаганнар, аннан кыз куна ук калган, ди... Бик яхшы белгән кешеләр сөйләде, утларын сүндереп ятуларын үз күзләре белән күргәннәр. Үз укучылары белән генә шаяруы житмәгән, инде күрше авыл кызларын иярләштерә башлаган. Директор дигәч тә, бөтен нәрсә рөхсәт ителә дип белгән, күрәсең.

Бу хәбәрдән Өннәшнең дөньясы түгәрәкләнде, куртыныкыдай[1] җәенке авызы тагын да ныграк җәелде. Ул ашыга-ашыга мәктәпкә җыена, бу хәбәрне суынганчы башкаларга житкерергә тели иде. Хәйрүш тынычланып кайтып китте. Хәбәр ышанычлы авызларда, үзе кайтканчы бөтен авылга мәгълүм булыр. Берәр айдан Зиннурның йогышлы авыру әләктерүе дә беленер, чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, теге хатка җавап та килми калмас. Фәтхулла картның әдәпле баласы да муеннан пычракка чумды болай булгач!

Планнарының төгәл үтәлүенә шик тотмаган Хәйрүш, Шәкүр янына кереп, «бик нык эче авырта икән» дип, Локманны торага шифаханәгә илтергә китәчәген белдерде. Ата-аналары улларының авыруына кайгырып, Хәйрүшкә рәхмәтләр әйтеп калдылар. Авылны чыгып бераз баргач, уңга каерып, Тегермәнлегә юл алдылар...

Усал хәбәр тешле була. Бер колактан икенче колакка пышылдап кына сөйләнгән хәбәр дә күпләргә билгеле булды. Сүз икенче берәү хакында барса, бик исләре дә китмәс иде. Монда бит мәктәп директоры катнашкан, сүз зурга китмәгәе. Зиннур абыйларын якыннан белгән, Нурия белән араларын күреп-сизеп йөргән яшьләр ышанмады моңа. «Ясаса соң, бик күпләргә ясый ул фотоларын, күрше авылдан килгәч, кунар урыны булмагандыр ул кызның», дип кенә җибәрделәр.

Бу хәлгә иң гарьләнгәне Нурия булды. Бусы печән гаугасы гына түгел бит. Күрше авыл кызы Гөлсылуны ул да яхшы белә, Нуриялардан бер генә сыйныф алда укыды ул. Сабыр холыклы, ягымлы гына кыз иде. Нурия укымаган бер ел эчендә дә әллә ни үзгәрмәгәндер. Кыз чыннан да йомыш белән килгән икән инде, Зиннур абыйсы аны кунарга аларга да кертә ала иде бит. Аңламады кыз, бөтен башы чуалчык уйлар белән тулды. Мәктәптә Өннәш апасы белән Туйбикә, ана бармак белән төртеп, үзара сөйләшеп үттеләр, узып киткәч, бертавыштан шаркылдашып көлделәр. Күршедә генә дә бит, кереп сорап булмый. Зиннурның җылы күз карашы, ягымлы сүзләре белән генә яшәгән иде. Кичә генә аның күзләренә тутырып-тутырып караган, шул карашыннан кызның үзенә

[1]Курты—шамбы, налим.

никадәр якын, кадерле булуын аңлаткан кеше ничекләр итеп икенче бер кызга карый, аны назлый алсын ди? Бу Нуриянең башы җитмәслек зур мәсьәлә иде. Әйе, ул олырак, бәлки аны баласытып, сеңлесе итеп кенә күрә торгандыр? Ачыктан-ачык сөйләшкәннәре дә юк бит. Ләкин аларның мөнәсәбәтләренә сүзләр кирәкми, барысы да аңлашыла кебек тоела иде бит кызга. Ялгышты микәнни соң? Укыган сабаклары башына кермәде кызның, күптәннән кадалып утырса да, бер юлын да күнеленә сеңдерә алмады. Китапларын кире өстәлгә салып, «Камиләләргә генә барып киләм» дип, чыгып китте. Әнисе башын селкеп озатып калды. Инде ничә көннән бирле кызының үз-үзенә урын таба алмавын сизеп торды ана. Сизми димени соң, әнә нинди ямьсез сүзләр таралды бит Зиннур турында, кызына кагылмаган дисеңме син ул гайбәтнең?

Кызларның үз хәсрәтләре башларыннан ашкан. Җыелышып бер-берсенә серләрен чишкәч, зарларын сөйләгәч, җиңеләеп калгандай тоела. Көзнең соңгы айларында Камиләнең Мифтахын Армиягә алдылар; аның өчен дә бергәләп кайгырды кызлар; хәзер егеттән атна саен хат килеп тора, Камилә тынычланып калды. Үткән атнада Туктабикәнең сөйгән егете икенче кызга өйләнде. Ә бит кызлар, тиздән туй итәрбез, дип ышанып йөргән иделәр. Ләкин Мансурдан яучылар килгәч, кызның әниләре кырт кисеп каршы төшәләр: без сартлар белән тугандашлык итмибез, диләр. Ата-аналарыннан мондый җавап көтмәгән кыз аптырап кала, каршы әйтә алмый. Кич белән Мансур үзе килеп, Туктабикәне күз яшьләре белән ябышып чыгарга үгетли. Әти-әнисенең сүзеннән чыкмаган кыз ризалашмый. Шуңа үч итеп, икенче көнне үк егете күрше авылга яучылар җибәрә. Үзенең кыюсызлыгына үкенеп бетә алмый Туктабикә, менә хәзер көн саен яшь килен Миңлинең чишмәгә су алырга төшкәнен карап, йөрәк әрнетергә генә калды. Соңгы көннәрендә Нуриянең кайгысы өстәлде. Зиннурның башка кызларга күз төшерүен, ул гына да түгел, кунып йөрүләрен һич кенә дә башларына сыйдыра алмады алар...

Ялгышты кызлар, менә ничәнче көн инде Зиннур Нурияне ялгызын очратырга җай эзләп йөри. Кичләрен кыз өйләрендә бикләнеп ята, кеше күзенә күренми. Мәктәптә йөзләгән пар күз карап торганда очрашу түгел, дәрескә керү дә кыенлашты. Кыздагы үзгәрешне дә сизде ул: дәрес буе күтәрелеп тә карамый Нуриясе. Чынлап та шул гайбәткә ышанды микәнни? Үзен төрмәдән йолып калган Нуриясен танымады Зиннур.

Бүген унынчыларда контроль эш. Класс аны гадәттәгечә аягүрә торып каршы алды.

—Утырыгыз,—диде ул үзенә дә ят тавыш белән.

Чебен очкан тавыш та ишетелми, класс сагаеп калган кебек. Әллә аңа гына шулай тоеламы? Күз кырые белән генә күреп калды: Нурия үз урынында иде. Җиңел сулап, тактага биремнәрне яза башлады. Классның бик тырышып эшкә керешкәнен күргәч, күңеле азрак тынычлана төште. Дәрес барышында берәүнең дә янына килмәде, урындыгына ябышып каткан сыңдай, сабыр гына утырды. Укучыларны күздән кичерде. Партага иелгән кара, коңгырт чәчләр арасында дулкын-дулкын булып күпереп торган сары чәч аның күңеленә тиңсез якын иде.

Класс эшне яхшы үтәгән дияргә була, Зиннур канәгать калды. Нуриянең дәфтәрен иң ахырга салып куйды ул, арифметика дәфтәре түгел, мәхәббәт хаты укыгандай, дулкынланып ачты. Әйе, Нуриянең хәтере калган, алай гына түгел, кызны тирән борчуларга салган бугай укытучы. Гел бишле билгеләренә генә укыган кыз бу юлы бөтен материалны бутап бетергән, эшенең ахырында үзе үк зур итеп сорау билгесе куйган иде. Уйга калды Зиннур, кызга йөрәген ачып салырдай булды. Ләкин кыз аны тыңларга теләмәсә? Әнә бит инде ничә көннән бирле күтәрелеп тә карамый Нурия, әллә бар ул дөньяда, әллә юк. Хат язып карарга булды ул, бәлки очрашып аңлашырлар, икесенә дә җиңел булыр. Үз гаебен дә аңлый егет, янында сып-сылу кыз кунып чыккач, үзеннән

гаепсез икәненне аңлатып кара инде син кешегә. Болай буласын башына да китермәгән иде бит ул. Гөлсылуның да Хәйрүшкә очравын әйт әле син, чыннан да шулай ялган сөйләде микәнни кыз? Кунуын әйтсә дә житкән ич, калганнарын өстәргә зур акыл кирәкми. Әнә бит ничек авызын ерып, очраган саен берәр пычрак сүз атып үтә Кәрбек, аларның Зиннурга, аннан да битәр Нуриягә ничек тәэсир итәсен белә ул эт җан. Теге юлы да никадәр кешеләрне кайгыга салып, җәзасыз котылды, шуна котырына.

Хат кисәге язарга утырды Зиннур. Теге хәлләрдән котылгач, пионер бүлмәсендә утырганда юри генә саннар белән языла торган шифр өйрәткән иде ул кызга. Янәшә ике сан бер хәрефне аңлата. «Бәлки кирәге чыгар» дип, саннарның аңлатмасын Нурия үзенә салып куйды. Ул чакта көлешкәннәр генә иде, ә менә кирәге дә килеп чыкты. «Нурия акыллым,—дип язды ул,—бүген сезгә кереп, сөйләшәсем килә. Риза булсаң, ян тәрәзә янына лампа кабызырсың. Зинһар өчен, кире какма. Зиннур». Кәгазь кисәген Нуриянең дәфтәренә кыстырып куйды. Дежур укучы икенче көнне дәфтәрләрне таратырга тиеш иде. Ләкин хат Нуриягә эләкмәде. Дәфтәрләрне таратканда, гадәттәгечә бер-берсенең билгесен ачып караганда, ул кәгазь идәнгә төште. Тоташ саннардан торган кәгазь кисәген, чүп булып ятмасын дип, дежур укучы кесәсенә алып тыкты. Кыз моны күреп торса да, кәгазьне кире сорап алмады. Цифрлар укытучы кулы белән язылган иде...

Зиннур исә төне буе арлы-бирле йөреп, нурлы ут балкышын көтте, ә өмет уты кабынмады да кабынмады. Өметләре өзелде егетнең, үзен кирәксез бер кеше итеп тоя башлады. Үзе гаепле шул, инде яшүсмер чаклары түгел, көтеп алган бердәнбер мәхәббәтен үзе үк саклый алмады. Нурия бүлмәсендә берәр егет кунып чыкканын ишетсә, нишләр иде икән? Шушы уй аны тетрәндереп җибәрде. Нуриягә ачуланган булып йөри тагын, үзен аның урынына куеп карамаган икән бит! Сөйләшәсе килмәсә дә, гаепле түгел: аның карашынча, Зиннур—хыянәтче. Күршедәге өйдә генә Нуриясенең дә өзгәләнеп, күзләре йокы күрмичә җәфаланып ятуын белми иде ул.

Быелгы җәйгә кадәр Нуриянең тормышы да Иртеш кебек талгын да тын акты. Зиннур кайтып, кыз күңелендә давыл, өермә куптарды. Тормышны гап-гади, беркатлы итеп кенә күрергә өйрәнгән кызның җанын айкады соңгы вакыйгалар. Дөньяга күзен ачкан, әлегә кадәр татымаган татлы хыялларга, өметләргә салган кешесе аны очраклы гына килеп чыккан чит авыл кызына алыштырды. Ичмасам, гафу да үтенмәде, аңлатуны да кирәксенмәде. Ышан син кешегә. Шуларны уйлап, кызның Зиннурны күңел түреннән алып ыргытасы килә—җүләр йөрәк моны эшләргә ирек бирми. Күз алдыннан ялварулы карашы китми. Зиннурның күкрәгенә башын салып, иннәрендә аның көчле кулларын тоярга теләмиме әллә ул? Төрмәдән котылып чыккач, шулкадәр назлап яшьләрен сөрткән иде бит, чәчләреннән сыйпаган иде. Шулар күз алдына килеп, кабат-кабат газиз кешесен юксынды, моңайды кыз, тамагына утырган төерне йота алмыйча җәфаланды.

Иртән иртүк мәктәпкә ашыкты Нурия, тизрәк кичә дежур торган Калканы очратып, теге кәгазь кисәген сорыйсы килде.

—Нинди кәгазь соң ул, теге чалбар кесәсендә калган, кирәкле идемени?—дип сорады классташы үз чиратында.

—Кызлар белән отыш уйнаган идек, бүген тикшерәсе идек, бәлки мин отканмын,—дигән булды ул аерым әһәмият бирмәгәндәй кыланып.

—Кирәксә, өйгә кайтып алып киләм, әле вакыт бар,—дип, эчкерсез үсмер өйләренә йөгерде.

Калка килүгә, дәрес башланды, ул кәгазьне кызның учына салып, үз урынына үтте. Кәгазь аның учын көйдергәндәй булды. Бераздан, бар да эшкә керешкәч, Нурия язуны туздырып карады. Ул ялгышмаган, саннар Зиннур абыйсы күрсәткәнчә, парлап-парлап төзелгәннәр иде. Хатның ачкычын өендә, кирәк-яраклар шкатулкасында саклый ул. Көне

буе парта урындыгында түземсезләнеп утырды. «Нәрсә язды икән соң, нәрсә генә язды икән?» Ә дәресләрнең бетәсе дә юк, шулкадәр сузылса да сузылыр икән вакыт! Соңгы дәрес алдыннан киемнәрен, мамык шәлен үзе янына алып утырды, кыңгырау чылтырауга ук, бер-бер эш чыгып тоткарламасыннар тагы дигәндәй, киенеп, чыгу ягын карады. Урам буйлап тыныч кына кайтырга тырышса да, йөрәге озак йөгергәндәге кебек еш-еш тибә, чыгып төшәрдәй булып дөпелди иде.

Гадәттә дәресләреннән соң эше буенча тоткарланып кала торган кызы болай иртә кайткач, әнисе тагын борчылып куйды. Кызы да ачыктан-ачык сөйләшүдән кача, иренең дә бу көннәрдә гел кәефе китеп тора. Ни эшләргә, кайсысын ничек юатырга белми Хәлимә. Әнә әле дә кызы, аскы өйгә тукталмыйча, йөгерә-атлый каршы як баскычтан үз бүлмәсенә ашыкты. «Ходаем, тагын кем нәрсә житкерде икән инде?»

Әллә кайчаннан бирле ачып карамаган шкатулкасының ачкычын таба алмый аптырады кыз. Шунда гына куйган иде ләбаса. Кайда соң? Кабаланудан киштәдәге китаплары шапылдап ишелеп төште. Аларны да җыеп тормады. Кайда соң? Инде ничә елдан бирле почмактагы киштәдә утырган уенчыгына да чират житте: ул да ачуланган кебек егылып төшеп, йөзтүбән капланды. Тирләп чыкты Нурия, «уф» диеп урындыкка утырды. «Нигә дип болай кабалана соң әле? Нәрсә язса да барыбер түгелмени? Кичә генә төне буе сөйләшмәскә, аның исемен дә телгә алмаска антлар эчте бит». Шулай да учтагы кәгазь кисәге тере нәрсәдәй тыпырчына, тизрәк ачып укуларын тели иде. Тагын әкрен генә өстәл янына атлады, шкатулкасын кулына алды. Шунда гына күрде: ачкыч шкатулкасының астында гына булган икән ләбаса. Ачкычны кулына алгач, кабалана-кабалана ачты. Шифр алдында ятканда, саннар тезмәсеннән сүзләр ясап укуы читен булмады. Хат кичә язылган иде, димәк ул төне буе мендәрен чылатып ятканда, Зиннур абыйсы аның тәрәзә төбен саклап чыккан. Кичәге буранда аның арлы-бирле алар ишек төбендә йөрүен күз алдына китергәч, күнелен каршылыклы уйлар биләп алды. Димәк, ул аны уйлый, аңлашуны өмет итә. Менә хәзер ялынып йөрсен инде! Борылып карыйсы да юк! Алай дисәң... Директор башы белән бала-чага кебек ишек төбе саклап йөрсен инде кеше, әле тагын нинди буранда! Нишләргә? Башы буталып бетте: әле якын итү, күрешеп сөйләшү, аңлашу хисе өскә калыкты; әле горурлык, тәкәбберлек җиңде. Байтак утырды ул шулай. Бераздан үз-үзен җиңеп, сикереп торды да, кулына каләм алып, саннар тезә башлады. Тиз генә киенеп, Камиләләргә кереп китте.

—Ахирәтем, менә шушы кәгазь кисәген Зиннур абыйга кертеп чык әле,—диде ул, дусты белән исәнләшеп алгач ук.

—Нәрсә булды тагын, артыннан бер өер этләр кудымы әллә?

—Хәзергә берни булмады, була калса, соңрак сөйләрмен. Зинһар, үз кулына гына бирә күрә, яме.

Кич житүен көчкә көтеп алды кыз. Зиннурны бик күрәсе килсә дә, ни әйтәсен белмәде ул. Эх, шул вакыйгалар булмаса, рәхәтләнеп укыр, эшләп йөрер иде. Соңгы вакытларда Зиннур абыйсы үтә якын була барып, кыз инде киләчәген хыялларында гел аның белән бергә итеп күрә башлаган иде. Һәрбер карашында бер мәгънә, беркемгә дә сөйләп булмый, якын дуслардан да яшерә торган серләр бар иде. Шуларның барысы да беттемени? Әгәр аны гафу итсә, теге кызның күләгәсе араларында тормасмы соң, очрашкан саен исләренә төшеп, хисләрне суытмасмы? Белеп тора, Зиннур абыйсы аңа гафу үтенергә, аннан кичерү сорарга керә. Нишләргә, үзен ничек тотарга тиеш соң кыз бала?

Ян тәрәзәдә лампа яна...

Ишек шыгырдап ачылды да, икеләнеп кенә берәү бусаганы атлады. Стена буена куелган караватына утырган кыз башын борып та карамады, бер ноктага текәлгән хәлдә утыра бирде. Сәламне алучы булмады. Бүлмәгә күз йөртеп чыккач, өстәл артыннан урындык алып, Нуриянең каршысына барып утырды. Кызның керфеге дә селкенмәде, гүя дөньядан бөтенләйгә

киткән иде. Бәгырькәен шулкадәр газапларга салырмын дип башына да китермәгән Зиннурның йөрәге сулкылдап типте. Үзе керсә, әллә нәрсәләр әйтергә әзерләнеп торган кыз әллә нишләде, тораташтай катты да калды. Бөтен дөньясы мәгънәсез, караңгы булып тоелды ана. Менә бит ул, инде ничә айлардан бирле төшенә кереп, дөньяда яшәвен мәгънәле иткән кеше. Сузыласы да, башларыннан сыйпыйсы, күзләреннән үбәсе иде. Ләкин юк шул, араларында күренмәс стена аларның. Ышанычны югалту, хыянәт диләр аны...

Нидән башларга белмәде Зиннур сүзен, сак кына кызның кулларына кагылды, әллә нинди жансыз, суык иде кызның куллары. Учына алып җылытырга, җан өрергә тырышты. Кымшанмады да Нуриясе, бары тик зур итеп ачылган күкчәчәктәй күзләреннән генә эре-эре яшьләр тәгәрәде. Урындыгыннан төшеп, кызның алдына тезләнде егет, кулларын иреннәренә тидереп, тыны белән җылытырга тырыша башлады. Шунда әллә нәрсә булды кызга, эченнән бер дулкын ургылып менде дә, нишләгәнен дә белештермичә егетнең җилкәсенә сыгылып төште, үксеп елап җибәрде. Инде күпмедән бирле күкрәгендә таш булып төенләнгән үпкә-ачулары күз яшьләренә әверелеп, тышка бәреп чыкты.

—Нишләдең син, Зиннур?—диде кыз калтыранып, беренче тапкыр егеткә исеме белән генә эндәшеп.—Бөтен нәрсәне үз кулларың белән боздың бит син, шуны аңлыйсыңмы? Башланмый торып ук, бөтенесе бетте, бетте...—Төнге тынлыкта кызның сулкылдап-сулкылдап елавы Зиннурга тетрәндергеч тәэсир итте.

—Тынычлан, газизем. Белсәң иде күз яшьләреңне юкка коюларыңны. Мин сине рәнҗетергә, түбәнсетергә теләмәдем. Ант итеп әйтә алам, синең алдыңда ышаныч югалтырлык бер генә гаебем дә юк минем. Яман хәлләргә төшкәч, беләсеңме, нәрсә көч, ышаныч бирде миңа? Синең кеше сүзенә карамавың, минем гаепсез булуыма ышануың. Ятимә кыз ярдәм сорап килгән икән, бу бит әле минем ышанычсыз булуымны расламый. Кыз чыннан да кунарга калды, ләкин төннең берендә ул кая барырга тиеш иде соң?

Инде тынычлана башлаган кыз «дерт» итеп китте, яна гына йокыдан уянгандай, күзләрен тутырып Зиннурга карады. Әллә нинди, егеткә таныш булмаган өшеткеч-мыскыллы елмаеп:

—Сүзне нәкъ менә шуннан башлыйсы иде, Зиннур Абдуллин. Инде үзегезне миннән азат дип саный аласыз. Исемегезне дә ишетәсем килми, чыгып китегез,—диде ул теш арасыннан һәм янадан мендәренә капланды.

Акрынлап аягына басты Зиннур, урындыгын урынына илтеп куйды, сабыр гына тун төймәләрен каптырды. Әледән-әле тартышып куйган яңаклары гына егетнең эчендә уйнаган өермәне, каршылыклы хисләр бәрелешен сиздерә иде.

—Сине шулкадәр кичерешләргә салганым өчен тагын бер кат гафу сорыйм, Нурия,—диде ул тавышын тыныч, ышанычлы тотарга тырышып.—Ләкин кабатлап әйтәм, синең алдыңда тырнак хәтле генә дә гаебем юк минем. Син миңа ышанасың дип, нык ялгышкан икәнмен. Хуш, сау бул!..

Ишек кабат шыгырдады. Менә бетте дә. Күңелдә бушлык, баш шаулый. Кыз яңадан торып, тезләрен кочып утырды, әле генә булып үткән сөйләшүдән бернинди дә йомгак ясый алмады ул. Кулларында аның иреннәренең кытыршылыгы, көйдереп алырдай сулышы, колагында әйткән соңгы сүзләре генә яңгырап калды: Ялгышкан икәнмен... Хуш, сау бул!.. Ялгышкан... Әллә төш иде бу, әллә өнендә моңлы җыр көе кызны икенче дөньяга, үсмерлектән яшьлеккә таба алып китте:

Тылсымлы әкият иленә
Алып киткән иде ул.
Күңелемә яз, җаныма наз
Бүләк иткән иде ул.

Хыянәт җилләре кисте
Язым, назым чәчәген.
Җилгә очты хыялланган
Бәхетле киләчәгем.

## 15

Себер якларының очкан кош жиргә егылып төшәрлек, төкергән төкерек шул мизгелдә үк бозга әверелеп, аяк астына тәгәрәрлек зәмһәрир суыклары үтеп китте. Хәзер инде кыш, үзенең көченкодрәтен соңгы тапкырлар күрсәтеп калырга тырышкандай, буран туздыра, чана юлларын каплап, көрт өя.

Шундый көннәрнең берендә, авыл халкын гаҗәпкә калдырып, артлы кошовкаларга икешәр ат җигеп, бер төркем чит-ят абзыйлар килеп төште. Арада белгән кешеләр дә булган күрәсең, кәрван туп-туры идарә йортына килеп туктады. Толыпларга төренгән юлчылар акрын гына урыннарыннан кузгалып куйдылар, бер-берсенә ярдәм итешеп, чанадан төштеләр. Кунаклар акрынлап идарә йортына үттеләр. Шыксыз, тәмәке төпчекләренә баткан бүлмәгә кергәч, абзыйлар, утырыр урын эзләп, як-якларына карандылар.

Бәхетенә күрәдер, колхоз рәисе урынында юк, идарәдә Хәйрүш белән юантык гәүдәле хисапчы хатын гына утыра иде. Керүчеләрнең югарыдан килгән түрәләр икәнен бер карауда чамалап алган бригадир, урыныннан сикереп торып, баш иеп исәнләште. Араларыннан берсе, ерактан килгән булырга тиеш, алдында ясалма елмаеп басып каткан Хәйрүштән:

—Сез буласызмы «Урак-чүкеч» колхозы рәисе?—дип сорады.

—Юк. Кызганычка каршы, Шәкүр иптәш салкын тидереп авырып ята. Мин бригадир Хәйретдин Хәйбуллов булам. Хәзергә колхоз рәисе вазифасын үтим.

—Бик яхшы, без—бик мөһим мәсьәләне тикшерергә килгән комиссия әгъзалары. Иртәгә якыннанрак танышырбыз, иң әүвәл сез иптәшләрне берәр йортка җайлап урнаштырыгыз. Карыйсы эш бик катлаулы, озак торырга туры килмәгәе.—Кунаклар бик кырыс сөйләште.

—Хәзер була ул. Чәмилә әбә, тиз генә Өннәш әбәне чакырып кил әле.—Баядан бирле бу серле кунакларга курку катыш сәерсенү белән карап торган хатын, житез генә кыланып, пальтосын киеп тә бетермәгән килеш, чыгып йөгерде. Хәйрүш беренче каравында ук аңлап алды: бу—алар зарыгып көткән комиссия, Фәтхулланың күз өстендә каш булып торган улының башына житәсе кешеләр иде. Комиссия әгъзалары толыпларын чишеп, бураннан, юлларның юклыгыннан зарланган арада, сулышы кабып, Өннәш тә килеп керде.

—Менә килеп тә житте,—диде Хәйрүш, ачык чырай күрсәтергә тырышып.—Өннәш әбә, сезгә колхоз идарәсе бик хөрмәтле кешеләрне ышанып тапшыра. Кунакларны алып кайтып, әйбәтләп ял иттерегез.

—Ханым, без күбәү бит, сезне бимазаламабызмы?

—Юк, юк, хуш килдегез. Өебез зур, картым белән икәү генә яшибез. Күпме кирәк, шул кадәр торырсыз,—дип, Өннәш тә кунакчыллык, ачык йөз күрсәтергә тырышты.

Икенче көнне серле кунаклар мәктәпкә юл тоттылар. Алдан, юл күрсәтеп, Хәйрүш бара. Комиссия житәкчесе, мәктәп директоры белән танышкач, бөтен укытучылар коллективын бер бүлмәгә җыюларын үтенде. Аптырап калган укытучылар, бер-берсенә карашып, нәрсә уйларга да белмичә, укытучылар бүлмәсенә җыелды. Барысы да утырышып, тынычлангач, Тубыл райкомының пропаганда бүлеге мөдире, аны күбесе таный иделәр, Мөхәммәтжанов Наил иптәш сүз алды.

—Иптәшләр,—диде ул, тамак кырып,—без монда бик зур мәсьәлә буенча тикшерү алып барырга килдек. Сезнең коллектив укытучылары соравы буенча, директорыгыз Зиннур Абдуллинның эше тикшереләчәк.

Укытучылар барысы да аңа борылып карады. Нәрсәдер сизенсә дә, Зиннур комиссиянең мәктәп эшен түгел, ә үзен тикшерергә килгәндер дип, башына да китермәде. Мәскәүгә җибәргән хатка коллективларыннан тарих укытучысы Туйбикә белән китапханәче Өннәш кул куйганлыгына

укытучыларның бик исе китмәде, алардан башкаларның мондый түбәнлеккә, кешегә күрә торып яла ягарга исенә дә килмәс иде. Ә менә хат язучыларның өченчесе колхоз бригадиры Хәйрүш Хәйбуллов булуы күпләрне гаҗәпләндерде: бригадирның мәктәп эшләренә ни катнашы бар?

—Мин бөтен колхоз халкы исеменнән,—диде Хәйрүш, күзен дә йоммыйча.

Абруйлы комиссиянең башында өлкән бер абзыйны Мәскәүнең үзеннән үк дип таныштырдылар. Шпитальник фамилияле, мәгариф министрының урынбасары иде ул. Кунакларның икәве—Төмәннән: өлкә мәгариф бүлеге рәисе Белозерцев, аны Зиннур күреп белә иде, һәм өлкә профсоюз житәкчесе Гайнуллина ханым. Тубылдан райкомның пропаганда бүлеге мөдире һәм РайОНО мөдире Марфа Ивановна.

Хатның авторлары белән килгән көнне үк танышып өлгергән тикшерүчеләр директор һәм укытучылар коллективы белән дә күрешкәч, эшкә керештеләр. Иң әүвәл иптәш Сталинның үзенә атап язылган хатны укыдылар.

—Йә, нәрсә әйтә аласыз? Бу жалобага караганда, сезнең гөнаһыгыз ифрат зур. Сез череп таркалган милләтче, динне яклаучы, партиягә каршы элемент, халык дошманы булып чыгасыз. Әгәр әйтелгәннәр расланса, белеп торыгыз, безнең кулда өлкә прокурорының сезне кулга алырга хокук биргән кәгазе дә бар,—диде Мәскәү кешесе Шпитальник ага, хат укылып бетеп, шомлы тынлык урнашканнан соң.

Зиннурның күз аллары карангыланып китте. Маңгаеннан суык тир бәреп чыкты. Ходаем, тагын шул ук нәрсә кабатлана: өстәлнең бу ягында ул һаман берүзе. Куркыныч төштәге кебек, ләкин бу юлы вакыйгалар шулкадәр чуалган, шулкадәр буталчык итеп күз алдына китерелде ки, бер минутка Зиннур үзе дә аларны ерып чыга алмастыр кебек тоелды. Ә бит әле ана вакыйгаларны үзе өчен генә түгел, комиссия әгъзаларын, туп-туры аның күзләренә карап утырган чит кешеләргә дә аңлаешлы булырлык итеп тәртипкә китерәсе бар. Аның өстенә төшкән сынаулар берсеннән-берсе катлаулана гына бара, биек таудан тәгәрәтеп жибәргән кар йомарламы диярсең. Барган саен үсә, кыенлаша гына бара чишәсе мәсьәләләр. Теге юлы аның ягында дуслары, авылдашлары, Нуриясе бар иде. Бу юлы аңа үзенә генә көрәшергә туры киләчәктер. Шулай икән, ул барысына да әзер, сорасыннар!

Язылганнарга телдән өстәгәннәр күрәсең, тагын Нурия исеме яңгырап, Зиннурны телдән калдырды сорау алучылар. Имеш, бер ай элек ул Тегермәнле авылы кызы белән кунып чыккан да анардан куркыныч авыру ияртկән икән. Кем белә, бәлкем хәзер Нуриягә дә күчкәндер ул зәхмәтле чир? Бу кадәресен көтмәгән иде Зиннур. Гөлсылу вакыйгасы шундый да пычракка төрелеп яңадан янгырар дип уйга да китергәне юк иде. Иң әшәкесе—чишмә суыннан да саф кызның исемен пычратулары булды. Ярый әле, бу сүзләрнең барысын да директорның үзенә аерым гына әйттеләр. Бер кеше генә дә ышанмаса да, кызга никадәр оят китерер, кеше күзенә күренмәслек итәр иде ул. Ә ышанучылар, авыл өстендә намуслы кыз баланың исеме белән авыз чайкаучылар да табылыр бит.

—Мин бу кешеләрнең ни өчен хат язуларын аңлыйм, ләкин кешедә шулкадәр мәкер һәм ялган булыр дип күз алдыма да китерә алмый идем. Булса да булыр икән кешедә этлек. Мин гаепләрнең барысын да инкяр итәм. Ялган алар...—Ачуыннанмы, әллә бик каты гарьләнүдәнме сүзен дә бетермичә бугазына төер, күзләренә ачы яшь тыгылды.

—Гафу итегез, иптәш Абдуллин, Мәскәү күз яшьләренә ышанмый. Безгә фактлар кирәк. Тикшерү тәмамланганчы без сезне сак астына алырга мәжбүрбез.

—Укытучылар коллективыннан, авылдашларымнан да сорагыз, зинһар, тик... кыз баланың исемен генә пычракка бутамагыз, аның бер катнашы да юк.

—Без эшнең асылын тикшерергә дип килдек тә инде. Иптәш Гостева

сезгә бик яхшы характеристика бирә, өлкә мәгариф бүлеге дә аның сүзенә кушыла. Алай булмаганда, сезнең урыныгыз күптән рәшәткә артында булыр иде. Мондый эшләр өчен стенага терәп ата торган закон яшәвен ишеткәнсездер дип беләм.

Тикшерү атна буена сузылды. Барлык укытучылардан аерым-аерым шикаятькә карата фикерләрен сорап чыктылар. Сөйләшенгән кебек, бер үк фикердә иде укытучылар. Яшь директорның җан атып эшләп йөрүләрен, мәктәпне төзекләндерүен, җилкәсенә асып китапларга кадәр алып кайтуын, югары белеме булмаган укытучыларга төпле ярдәм күрсәтүен тезеп киттеләр. Мәктәпнең авыл халкы арасында абруе зур булуын, укучыларның мәктәпкә бик теләп йөрүләрен, монда директорның төп рольне уйнавын әйтеп үттеләр. Берәүдән дә Зиннур Абдуллин хакында начар сүз чыкмады. Бик күпләр эшнең асылы тарих укытучысы белән китапханәчегә педсоветта әйтелгән тәнкыйть сүзләреннән башлануын искәртте:

—Китапханәгә, дәресләргә кереп карагыз, сез бәлки аннан да катырагын әйтерсез. Бөтен эшләре ялган сөйләү дә гайбәт тарату бит аларның,—диде яшьрәк укытучылар.—Зиннур абый кебек директор булсын иде әле бөтен мәктәпләрдә дә.

Нурия белән Зиннурның ялгыз калып сөйләшкәненә дә бер айлап вакыт узды. Аларның юлы башка кисешмәде дияргә дә була. Икесе дә күзгә-күз очрашмас өчен барысын да эшли иде бугай. Очрашканда да үз эшләре белән мәшгуль булып кыланалар. Тик менә унынчыларда дәрес биргәндә директорның күз карашы гел укучылар өстеннән генә йөри, йә бер ноктага текәлеп, сәер халәттә катып кала иде. Нурия исә унынчыны тизрәк тәмамлап, бу мәхшәрдән котылырга теләгәндәй тоела иде.

Бу көннәрдә авыл мәктәптәге хәлләр белән генә яшәде. Укучылар мәктәпкә бер төркем тикшерүчеләр килүен ата-аналарына түкми-чәчми житкерделәр. Төрлечә юраулар, башланган эшнең сәбәбе, нәтиҗәсе турында уйланулар китте. Мәскәү кадәр Мәскәүдән, Сталин иптәшнең үзеннән җибәрелгән тикшерүнең юкка гына булмавын һәркем аңлый иде. Ләкин яшь директорларына нинди гаеп тагылганын тәгаенләп кенә беркем дә әйтә алмады. Телдә-тештә Өннәшнең гайбәтләре дә Туйбикәнең төкрекләрен чәчә-чәчә сөйләгән сүзләре. Алар гәбенең уннан бере дә дөрес булмый да бит, бу юлы сүзләр чынга охшаган шул. Атна буе тикшерү үткәрерлек нинди чатаклыклары булды икән соң япь-яшь кешенең? Әнә бит, балаларны мәктәптән аерып булмый башлады, ярыш та җыелыш, кичә дә түгәрәк телләрендә. Шулай да астыртын эш алып барды микәнни соң яшь директорлары, зурга китте бит болай булса хәлләр?! Халык дошманы, партиягә, иптәш Сталинның үзенә каршы икән мактаулы директорлары, Алла сакласын! Бу хәбәрне сөйләгәндә авыл кешеләре чыннан да чит-ят кешеләр ишетмәсен тагын дигәндәй, як-якларына каранып, төкеренеп куялар, хатын-кызлар алъяпкыч итәкләре белән авызларын каплый. Хөкемнән соң Зиннур абыйларын мылтык терәп атасылары икән, Ходай сакласын, ни көннәргә калдык бит!..

Бу хәбәрләр Нуриянең йөрәгенә без белән кадаган кебек булды. Сораулар тикшерелеп беткәнчегә кадәр дип, Зиннур абыйсын сак астына алдылар бит җитмәсә, чын җинаятьче кебек. Теге көнге катылыгы өчен үкенеп бетә алмады кыз. Ышанмады шул Нурия Зиннурга, ә бит аның күзләре алдашмый иделәр. Үзе кебек, Зиннуры да горур кеше шул: ялынып, үзен түбәнсетеп йөрмәде, янадан очратып, аңлатып та тормады. Үзенә ышанмаган кешегә нәрсә сөйләсен ул, ышанычсыз ничек аңлашып булсын ди? Гомерендәге иң зур ялгышы өчен көне-төне битәрләде кыз үзен. Менә хәзер барын да тынлар, аңлашырлар иде, ләкин барысы да үкенечкә генә калыр микәнни? Әгәр аны чынлап та алып китсәләр, атып үтерсәләр?! Аллам сакласын!

Дәрестән кайтып кергәнендә дә әниләре шуны сөйли иде ахрысы, кызлары кергәч, гапләре өзелеп калды. Нурия гадәттәгечә үз бүлмәсенә менеп, озакламыйча әйләнеп кире төште.

—Мәктәптә эшләрегез ничек?—диде әткәсе, күпмегәдер сузылган тынлыкны бозып.—Тикшерүләренең очы-кырые күренәме?

—Укытучыларның барысыннан да Зиннур абыйның ничек эшләвен сорап чыкканнар, тагын укучылар белән дә сөйләшәселәр, ди.—Нурия атасына карамыйча, өстәл җәймәсенең чукларын куллары белән бөтергәләп утыра иде.

Хәмитенең кызы белән ачыктан-ачык сөйләшергә теләгәнен аңлаган хатын, утырган жиреннән кубып, аш-су тирәсенә чыгып китте.

—Кызым, халык теләндә Зиннурны халык дошманы, партиягә каршы кеше икән, дигән сүзләр таралды. Кайбер озын телләре аның белән синең исемеңне дә телгә алалар. Сиңа ышанам, кызым. Әгәр син дә Зиннур абыеңның гаепсез икәненә үзенә ышанган кебек ышансаң,—әткәсе кызның күзләренә туп-туры карап, тукталып торды,—әллә шул тикшерүчеләргә барып, үзең белгәннәрне сөйлисеңме, дип әйтүем. Фәтхулла кордашның улы белән бер чанада шуып үстегез бит сез. Әүлиядәй кешеләрнең улы бит ул, нахак бәлаләр өчен башы бетмәгәе...

Әллә ничә тапкыр талпынып караган иде бит Нурия, ләкин шул-кадәр зур кешеләр алдына кереп, сүз башларга көче житмәде аның. Рәхмәт әткәсенә, чыннан да барачак ул, абыйсының инде икенче тапкыр шул бер тиенгә тормаслык кешеләр сүзе аркасында күпме җәфа чигүен, бер гаепсезгә инде ничәнче көн бикләнеп утыруын әйтеп бирер! Әзрәк уйланып утырды да, бер карарга килеп, янадан үз бүлмәсенә йөгереп менеп китте.

Мәктәпкә кадәр йөгерә-атлый барды ул, ишек төбенә житкәч, азрак тукталып торды да, тәвәккәлләп ишекне ачты. Өстәл артында чәчләре агарган өлкән кешене күреп, тукталып калды. Юл буе уйлап килгән сүзләре дә онытылды, бер мизгелгә артка чигенергә дә уйлады. Ләкин моны сизгәндәй, теге агай, башын күтәреп:

—Кер, кызым, кер. Миңа берәр сүзең бар идеме?—дип йомшак кына сорагач, янадан үз хәленә кайтып, алгарак атлады.—Йә, кем дип белик инде сезне, туташ?

Мәскәү кешесенең шулай гади генә сораулар бирүе, ничектер якын күргән кебек дәшүе кызны кыюландырып жибәрде. Нидән башларга белмичә бераз урынында таптанып торганнан соң сүзен башлады:

—Сезне эшегездән аерып, борчыганым өчен гафу итегез,—диде ул, кулындагы шәленең почмагын тарткалап,—ләкин бу минем өчен бик мөһим мәсьәлә.

—Йә, йә, тыңлыйм,—диде үз чиратында абзый кеше дә, чын кызыксыну белдереп.

—Сезгә язылган хатта минем исемем дә телгә алынмыйча калмагандыр, ул кешеләр күп гайбәт тараттылар инде...—Кыз беразга тукталып торды, аннан соң агайның күзләренә туры карап, дәвам иттерде:—Нурия Сәлимова мин, абый.

Тикшерүче бермәлгә тукталып, дөрес ишетәмме дигәндәй, кызга сораулы караш ташлап куйды, аннан соң кәгазьләрен актарып, нәрсәнедер карап алды.

—Сезнең ул кәгазьләрегездә нәрсә язылгандыр, белмим,—диде кыз, жебеп төшмәскә тырышып,—ләкин Зиннур абый әйбәт укытучы, яхшы кеше. Бер урамда үстек без, аны үз абыем кебек беләм...

—Бик яхшы, сеңелем, үзеңнең килүең бик әйбәт булган. Синең белән икәүдән-икәү генә сөйләшергә теләгән идем мин дә. Безнең бу сөйләшү башкаларга мәгълүм булмас, наныем, курыкмыйча сорауларыма дөрес җавап бирергә тырыш, яме. Абдуллин абыеңның язмышы синнән тора!—үтәли күргәндәй, күзләренә карады тикшерүче.

Авыл жирендә бер хәбәрнең дә бишкә әверелүен белә министр урынбасары, шуңа күрә үзе теләп аның каршына килеп баскан кызга да каты кагылмаска тырышты. Шунысы да бар бит әле: үзе килгән икән, димәк куркырлык эше юк. Мондый кызны яратса да, гаепле түгел егет.

Аңа утырырга урын тәкъдим итте өлкән абый, әкренләп сораштыра башлады. Сораулар гади иде, кыз да тиз арада үзен кулга алды, тынычланып сөйләргә тотынды. Хәзер унынчыда укып, берочтан пионер эшләрен оештыручы булуын әйтте кыз, ни сәбәпле бер ел укый алмавын өстәде. Киләчәктә, Зиннур абыйсы кебек, югары белем алырга да теләге бар икән, моны ул шундый ышаныч, зур горурлык белән әйтте ки, кызның балаларча беркатлы, самими һәм бер үк вакытта үз-үзенә нык ышанып сөйләвенә сокланып утырды тыңлаучы. Зиннур абыйсының дәресләре, дәрестән соң оештырылган эшләр хакында да ялкынланып сөйләде кыз. Министр урынбасарының иманы камил: ялганларга, үзеннән көлгән, мыскыл иткән кеше турында болай сөйләргә мөмкин түгел! Әмма ул туры сораугa туры җавап алырга тиеш, башкача ярамый. Ахырдан икеләнүләр калмаслык булсын. Сүзне акрын гына үзен кызыксындырган якка борды комиссия җитәкчесе.

—Нурия сенелем,—диде ул, кызга туры карап,—мин сүзләреңнең барына да ышанам, башка укытучыларыгыз да шулайрак сөйләделәр.—Нурия шатланып та, сагаеп та карады.—Ләкин сиңа тагын бер соравым бар иде. Хәтта Зиннур Абдуллинның мораль яктан тотнаксыз булуы хакында сөйләнә, мәсәлән Тегермәнле авылы кызы...—Абзый кеше кәгазьләренә күз төшереп алды.—Әйе, Тегермәнле кызы Гөлсылу туташны алдавы хакында да сүз алып барыла. Сезнең хакта да бик үк матур булмаган сүзләр бар. Моңа ни диярсез икән?

Әйе, сизенгән иде кыз эшнең Зиннур абыйсының хезмәте, мәктәптәге мөнәсәбәтләр белән генә калмасын. Һаман бер балык башы икән. Әле генә сабыйларча канатланып сөйләгән Нуриянең йөзендәге үзгәрешне тикшерүче абый да сизенде. Паузадан соң калтыраган, ләкин ышанычлы тавыш белән җавап бирде:

—Мин ул гайбәтләргә ышанмыйм. Ә минем белән Зиннур абый... Зиннур Абдуллин арасында кеше хөкем итәрлек мөнәсәбәтләр булганы юк. Кеше сүзе—кеше үтерә, диләр. Чыннан да, абзый, шул гайбәткә ышанып, аны атып үтерерләрмени соң?—Кыз битен каплап, өзгәләнеп елый башлады.

Мәскәү кешесе уйга калды, кызның тынычлануын көтеп, сүзен дәвам иттерде:

—Сүз әлегә үлем карары турында бармый, сенелем, эшнең нәтиҗәләре уңай булуга охшаган, ләкин сезгә бер комиссия үтәргә туры килер.—Кызның кызарган күзләре кабат аңа текәлде.—Әйе, менә нәрсәдә эш: Зиннур Абдуллинның эшенә нокта кую өчен сез районга барып, хатын-кызлар врачыннан белешмә алып кайтыгыз. Башкача мөмкин түгел!

Әйе, бу мәсьәләгә нокта куярга вакыт килеп җитте. Ана бу хакта әйтәләр икән, димәк, Зиннур абыйсын да тикшерәчәкләр. Болай булса, иң соңгы сораулар да ачыкланачак!

—Мин риза, абый, шул кәгазь кисәге бөтен нәрсәне чишә икән, ярар, алып кайтырмын андый кәгазьне,—диде ул, кызарынган битен күтәрергә дә оялып.—Кайчан?

Нурияне торага Гайнуллина ханым озатып барасы булды, ата-анасына мәктәптәге эше буенча бара, дияргә булдылар. Аннан алып кайткан кәгазь Нуриянең гыйффәтле туташ икәнлеген раслады.

Тикшеренүләр ахырына таба якынлашты, бөтен сораулар диярлек ачыкланды. Директорның унынчы класс укучысы Калканы кыйнавы да шул ике укытучының уйдырмасы гына булып чыкты, «сорасалар—сукты» дип әйтергә кушып куйган булсалар да, беркатлы үсмер егет алдаштырып тормыйча, дөресен сөйләп бирде: «Абый миңа сукмады»,—диде.

Эш тәмамлангач, партбюро секретаре Әхмәт әкә җитәкчелегендә, педсовет һәм тикшерү комиссиясенең тулы катнашында кинәйтелгән җыелыш үткәрелде. Комиссия җитәкчесе Шпитальник иптәш шикаятьтә язылган фактларның берсе дә расланмавын рәсми төстә хәбәр итте. Тикшерү нәтиҗәләрен, җыелган документларны күрсәтте. «Әгәр өстәмә

фактлар, сораулар булса, әйтегез, без энәсеннән-җебенә кадәр тикшерергә дип килдек!»

—Ә әтисенен муллалык итүе сон?—дип сорады Хәйрүш, урыныннан тормыйча гына.

Янадан сүзне Шпитальник агай үзе алды.

—Менә мина тиздән алтмыш яшь тула, әтиемә сиксән яшь инде. Өебездәге почмакта икона эленгән, атам шуна табына, ышана. Мин коммунист кеше, ләкин гомеренең соңгы көннәрендә атамны иконасы белән өйдән куып чыгара алмыйм бит инде. Бу мораль яктан да, кешелеклелек ягыннан да килешә торган эш түгел. Абдуллин иптәшнең әтисе Фәтхулла карт белән дә күрешеп, сөйләшеп утырдык. Бик ипле, акыллы карт, улын да укытып, кеше итәргә тырышкан. Кеше әйберен урламаган, гомерендә авызына аракы алмаган, совет властена каршы бернинди агитация алып бармый. Халыкны тәртипкә, дуслыкка чакыра. Баласының гаепле эш эшләмәвенә иманы камил. Аның берәүгә дә зыяны тимәс, дип уйлыйм. Тагын сораулар юкмы?

Тикшерү нәтиҗәләрен һәм тәкъдимнәрне уку өчен сүз бу эшне башлап җибәргән Мәмәтҗанов иптәшкә бирелде. Ул шикаятьнен, хатта язылган фактларның тулысы белән уйдырма булуын әйтте. Тынлаучылар бер-берсенә карашып, җинел сулап куйдылар, яшьрәк укытучылар, шатлыкларыннан кулларын кысыштылар, директорларын барып котлаудан көчкә тыелып калдылар. Бу тикшеренүләр Зиннур абыйларын гына түгел, аларны да күп борчуга салды. Наил иптәш сүзен дәвам иттерде:

—Халыклар атасы иптәш Сталинның вакытын алып, кеше өстеннән уйдырма шикаять язулары өчен тарих укытучысы Туйбикә ханымга каты шелтә, соңгы кисәтү ясарга, ә китапханәче Өннәш ханымны эштән азат итәргә—җыелыштагылар инде аларга күз төшерде. Аларча булмаганда пыр тузып тавыш-гауга чыгарырга күнеккән ханымнар бу юлы ачуларыннан шартларга җитсәләр дә, түзеп утырдылар. Җыелышны үткәрүчеләрнен ерактан килгән олы түрәләр булуы аларны да шүрләткән, күрәсең. Ә бит комиссия килеп төшкән көннәрдә үзләрен инде җинүчеләргә санап, күкрәкне киереп, астыртын гына көлеп йөргән иделәр. Эшнең үз файдаларына булмавы ачыклана башлагач, күзгә-башка бик күренмәскә тырыштылар. Нәтиҗәдә хатны үз-үзләренә каршы язгандай булып чыкты бит, ачуыннан буылыплар үләрсең!

Тикшерү нәтиҗәсендә Хәйрүш Хәйбулловка кагылышлы бүлек тә булды. Анда: «Зиннур Абдуллинга яла якканы өчен, Х. Хәйбулловның персональ эшен райком бюросында карарга» диелгән иде. Моннан тыш мәктәп директорының хат язучыларны закон буенча җавапка тарту хокукы булуы да әйтелде.

Зиннурның өстеннән авыр йөк төшкәндәй тоелды. Комиссия әгъзалары кулын кысканда, тамагы кибеп, бернәрсә дә әйтә алмады. Шпитальник агай директорның аркасыннан кагып, эшендә уңышлар теләде. Бу язылганнарның дөрес булмавы аны да сөендергән иде. Зиннур да, дулкынлануын яшермичә, министр урынбасарының кулын кысты, рәхмәт әйтте.

—Рәхмәтне мина түгел, үзегезгә, сезгә ышанган коллективыгызга һәм...—Житәкче бер кырыйдарак басып торган пионер эшләрен оештыручыга күз төшереп, елмаеп куйды,—әйе, әнә теге чибәркәйгә, асыл затка әйтергә кирәктер.

Инде Зиннур да, шушы тәмуг газапларыннан котылып, беренче кабат күргәндәй, Нуриягә карады. Кыз инде баядан бирле аны күзәтә, бөтен укытучылар, җитәкчеләр, партия әгъзалары Зиннур абыйсы тирәсендә кайнаганда, килеп котларга батырчылык итмәде. Җыелышның нәтиҗәсен ишетүгә, куанычы эченә сыймады. Нигәдер кычкырып көләсе дә, башын бәгырькәенең иненә салып, үксеп-үксеп елыйсы да килде аның. Шау-гөр килеп директорны тәбрикләүләр, кул кысышулар башлангач та, байтак вакыт урынында гына калды. Икесенә дә тынычланырга, атна буена сузылган тәмуг газапларыннан арынырга кирәк иде....

Өй кыекларыннан карга чумып утырган тыныч татар авылы өчен бик зур булып тоелган бу гаугалы вакыйгалар шулай тәгәлләнде. Мәктәптәге соңгы вакытларда кешене изеп торган тончыктыргыч һава сафланып, чистарып киткәндәй тоелды. Март ае туган чак. Өй түбәләреннән тамган тамчылар, җыелыш беткәндә сөңгеләр ясап, җиргә таба очлаеп сузылганнар иде. Көнбатыштан искән салкынча җил, җыелышта төн уртасына кадәр тирләп-пешеп утырган кешеләрне чиркандырып, куеннарына үрмәләде...

## 16

Көмешлесу тирәсендәге авылларда бер гадәт бар: әгәр яшь гаиләнең башлап туган балалары тормаса, вафат була барса, янадан туган балаларына Туктар, Туктамыш, Туктабикә дигән кебегрәк исем кушалар. Ягъни, инде үлем-китем булмасын, бу хәл тукталсын, дигән өмет белән кушыла мондый исем. Нуриянең дусты Туктабикә дә гаиләдә өченче булып туган, ләкин ни сәбәптәндер алдагы нарасыйлары бу фани дөньяны күрер-күрмәс үк, китеп тә барганнар. Туктабикә көтеп алган, кадерле бала була. Күз карасыдай кызларын укытып, кеше арасында сүзе үтәрлек итеп тәрбияләргә тырыша ата-анасы. Инде теләкләре дә тормышка ашты: кызлары техникум бетереп кайтып, авылда бердәнбер шәфкать туташы булып эшли башлады. Сөенеп бетә алмады алар, инде үзенә тиң пар гына насыйп була күрсен!

Әти-әниләре Алимҗан улы Мансурдан килгән яучыларны кабул итмәде. Күз өстендә каш булып торган кызларына пар булыр дисеңме ул жирсез-көнсез сартлар токымыннан чыккан бала? Булыр әле, үз тиңнәре дә кагыр ишекләрен, әнә бит, кызлы ишек тоткасына кырык ат бәйләнер, ди торган иде күршеләре мәрхүм Али әкә.

Ләкин эшләр алар уйлаганча гына барып чыкмады шул. Алимҗанның улы өйләнгән көннәрдә кызлары үз-үзенә урын таба алмас булды. Эштән кайтып, үз бүлмәсендә бикләнә дә төннәр буе үксеп чыга. Әллә соң уйламыйчарак җавап биреп, җаннарыннан да артык күргән балакайларын гомерлеккә бәхетсез иттеләрме?

Ачуыннан, сөйгән кызының үзенә «ә» дип тә, «җә» дип тә җавап кайтармавы гарьлегеннән йортка яшь килен алып кайткан Мансур бу адымының үз тормышындагы иң зур ялгышы икәнен тиз көндә аңлады. Аңлады, ләкин соң иде инде. Берәүгә уч итәм дип, үзен дә, Минлине дә бәхетсез итте егет. Күз алдыннан Туктабикәсе китмәде, ә янында аннан бер кәлимә наз күрмичә, яшь хатын тилмерде. Гаилә тормышы барып чыкмады. Яшь киленнең монсу карашы, күтәрелеп бер сүз дәшмичә, күләгә кебек өй эшләрен башкарып йөрүеннән үк аңлады Мәмдүхә: улы белән килененең аралары якынаерга охшамаган. «Ходаем, яхшы ата-ана баласын хараплар гына иттек ләбаса, улыма сабырлык бир», дип үз-үзенә сөйләнеп, килененә ачык чырай күрсәтергә тырышты каенана. Ә Мансуры гүя хатынын күрми дә иде...

Көннәр язга таба авышты, кар эрегән тау битләрендә яшь-жилкенчәк кич утыра башлады, авыл өстенә гармун моңы җәелде. Мансурның өйләнгәненә дә бер айга якын вакыт үтте. Авыл халкы арасында тормышларының рәте булмавы хакында имеш-мимешләр таралырга өлгерде. Күпләр эшнең сәбәбенә төшенә иделәр. Хәбәрләр тиз көндә исбатланды: яшь килен үз авылына кайтып китте. Берәүләр, Мансур хатынын яратмаган, куып җибәргән, дип сөйләсәләр, икенчеләр исә, кызларын кызганып, атасы аерып алып киткән, дип хәбәр тараттылар. Ни булса булган, мәхәббәтсез кушылган яшьләр артык зур тавыш-гаугасыз гына аерылдылар. Хәбәрне Туктабикәгә Камилә житкерде. Сөендеме, Туктабикә, әллә көендеме—аны үзе генә белә. Дәресләре беткәч, Нурия дә дустының хәлен белешергә дип, эш урынына сугылды. Камилә анардан алдарак килгән—уңганрак булып чыкты. Соңгы көннәрдә генә дә Мансур әлләнича

тапкыр, аларны очратып, Туктабикәсенә сәламнәр әйтте, аны оныта алмавын житкерергә кушты. Инде эшләр әнә кай якка борылды бит. Янадан кабул итәрме егетне? Мансур өйләнгәннән соң да никадәр егетләр сүз кушып карады бит ана...

Кызларның телендә шул хәбәр генә булды. Туктабикәнең эш сәгате беткәнне көтеп, бергә кайтырга булдылар. Шулчак ишекне киң ачып, Мансур килеп керде. Өйләнгәннән бирле аларның очрашканнары юк иде әле. Туктабикәнең ялгызы гына булмавы егет өчен кулайрак та әле: ялгыз гына очратса, әйтәсе сүзен дә әйтә алмас, кыз да аны тыңларга теләмәс иде. Күзгә-күз карашып, катып калган икәүне фани дөньяга кайтарырга теләп, Камилә гадәтенчә шаяртырга тырышты:

—Нәрсә, Мансур, аяк-кулың сызлыймы әллә? Бу йортка сырхауларның гына килгәнен беләсеңдер, шәт?

Дусларының бу сүзсез тынлыктан шулай жиңел генә коткаруына икесе дә рәхмәтле иде. Мансур ялт итеп аңа борылды:

—Эх, кызлар, белсәгез иде, йөрәк авырта, жан әрни минем.

—Туктабикә, карачы, чынлап төсе калмаган бу мескеннең, бир кәрепкә йөрәк даруын. Без күзләребезне йомып торырбыз, бер «пәп итсәң, шифасы тияр, иншалла,—дип көлеп сүзгә кушылды Нурия дә.

Графиннан бер стакан су салып бирде кыз.

—Мә, эчеп жибәр, хәзер үк янган йөрәгеңне басар...

Туп-тулы стакан суны татлы ширбәт эчкәндәй каплап куйды, үзе каш астыннан сөзеп кенә Туктабикәгә каравында булды егет.

—Йә, ничек?—дип сорадылар шаркылдык кызлар, эшнең житди якка борылмавын теләгәндәй.

—Туктабикәнең шифалы кулыннан эчкәч, чыннан да йөрәк януларым басылды. Мондый дәвага көн дә килергә риза мин, Туктабикә генә риза булсын,—диде Мансур, кызның күзләренә караган килеш.

Аның өчен тагын дуслары жавап бирергә булды:

—Сиңа дигән шифаны көн дә бер графин тутырып куяр Туктабикә. Әйе, бит, дустым?—диде Камилә.

Аның фикерен Нурия дәвам иттерде:

—Әйе, бүген аулак өйдән соң чишмәдән кайтара башларбыз зәмзәм суын, берочтан Туктабикәнең үзенә дә эчерербез.

Кызларның тел төбен аңлап алды егет, аулак өйгә жыеласыларын да, Туктабикәнең аның өчен йөрәге януларын да. Болай булса, аңлашырлар, ялгышларын төзәтерләр иде дә бит...

Кичен тагын очрашты алар. Туктабикәнең үпкәсе бик зур иде шул, тиз генә ачылып, егет белән сөйләшеп китә алмады. Аның татлы иреннәре һаман балаларча турсайган иде. Югыйсә кич житүен түземсезлек белән көтте үзе. Мансуры бик әһәмиятле нәрсә әйтер кебек иде аңа. Шулай да сер бирмәскә тырышты кыз, ялынып йөри, аннан башка яши алмый дип уйлап, борынын чөеп йөрмәсен әле!

Уен бара. Уртада калучы жырлый, аңа кушылып түгәрәктә әйләнә яшьләр. Жыр бетүгә, үзенә пар сайлый егет, уен шулай дәвам итә. Менә Мансур уртага чыгып баса, көчле генә тавыш белән жыр башлый:

Яна йөрәк, яна йөрәк,
Яна йөрәк сүрелми.
Күкрәк калын, күлмәк аша
Янган уты күренми.

Ямьле Иртеш буйларында
Карагат мәнчәкләре.
Күнелемнең сине уйлап
Өзгәләнгән чаклары.

Туктабикә каршына килеп, кызны кулларыннан алды Мансур. Көйгә салмак кына икесе әйләнә башлады. Кулдан-кулга кайнар агымнар үтте, тәннәр чымырдап киткәндәй тоелды. Аңлаган кешегә күп нәрсәләр сөйли иде егетнең назлап кына кул кысулары. «Сагындым, бик сагындым,

---
Кәрәп—мескен.
Мәнчәк—тәлгәш.

жаным, сине генә сөям», диләр иде алар. Бер тотышкан куллар кабат аерылмады. Тын авыл буйлап байтак йөрделәр, баштарак ялганып китә алмаган сүз, икәү генә калгач, эзгә төшкәндәй булды. Тымызык салкынча һавада сулышлар иркенәеп киткәндәй тоелды.

Кыз юка гына пальтодан иде. Якасын күтәреп, җиң очларына кулларын яшергәнне күреп торган егет гүя аңына килде: сөйгәненең дерелдп башлаганын абайлап, аны шундук биленнән кочып алды, үзенә табарак тартты. Әнә шунда гына Туктабикәнең җанына җылы керде, күнеленә рәхәт булып китте. Бу ай эчендә булган хәлләрне икесе дә уйламаска тырышты. Авыз ачып икесенең берсе аклану яки сагыну сүзе әйтмәде. Инде кавышабыз, дип өметләнеп кенә торганда, Сак белән Сок хәленә төшүләрен, бер-берсен күрергә зар-интизар булуларын, сагынулары соңгы чиккә житүләрне сүз белән генә аңлатып буламыни соң! Хәер, икесенең дә йөрәге бердәй типкәндә, бере икенчесенә җан атып, күңелләре бер-беренә омтылып, җаннары-тәннәре менә хәзер үк кушылырга, тизрәк кавышырга атлыгып торганда, сүзнең кирәге кала микәнни әле?!

Бермәл тын гына атладылар, бер-беренең халәтен сүзсез дә аңладылар, моның гомер буена шулай дәвам итәсенә, бер-беренә әле менә хәзер кабынган тыелгысыз дәртләренең мәңге сүнмәслегенә ышандылар.

—Туктабикә!—диде Мансур, кызның кулларын учларына алып. Кыз тукталып, ана борылды.—Туктабикә, әйдә бүген үк безгә кайтабыз! Иртәгә, баш иеп, әниләрең каршына басарбыз. Кызларының бәхетен теләсәләр, гафу итеп, хәер-фатихаларын бирерләр. Бездән генә калган йола түгел бит, күпләр ябышып чыга сөйгәннәренә. Ни әйтерсең, акыллым? Синнән башка бер көн генә дә яшисем килми бүтән...

Анын ялварулы карашы шулкадәр якын, кадерле иде Туктабикәгә, әмма кыз мондый зур мәсьәләне шулай җиңел генә, аяк өсли генә хәл итә алмый иде шул. Беравык уйланып торгач, җавап бирде. Ләкин Мансур зарыгып көткән сүз түгел иде ул. Үз туксаны-туксан булды сөйгәненең. Ата-анасын санга сукмау була бит бу, алай ярамый, барыбер бәхетләре түгәрәк, күнелләре тыныч булмас, имеш.

Ничек итсә-итте кыз, ләкин сүзләренең ныклыгына ышандырды Мансурын. Тагын бер кат абруйлырак кешеләрне яучы итеп җибәреп, кызның ата-анасын күндерергә карар кылдылар. Ил агасы булырдай кешеләр барса, сүзләрен аска салып ташламаслар, иншалла. Туктабикә өенә кереп югалгач та, өй алдындагы тупыл агачының кәүсәсенә сөялеп, бик озак басып торды Мансур. Әле уянырга өлгермәгән агачтан башны әйләндерерлек бөре исе, яз исе килә иде. Көндезге кояш нурларында эрегән күлдәвекләр пәрәвез сыман гына булып боз белән капланган. Атлаган саен, кыштырдаган тавыш чыгарып, юеш кар күнелле генә зарланып кала. Яз килә...

Ике-өч көн дә үтмәде, егетнең ата-анасы тагын кызның бусагасын атлады. Алдан, уң балагын итегенең тышына чыгарып, Фәтхулла абзый атлады, аның артыннан, бисмилласын әйтеп, Мансурның әтисе, аларның соныннан чуклы шәлләре белән балкып, карчыклары да соңламады.

—Әссаләмәгаләйкүм. Йортыгызга тынычлык, муллык,—дип сүз башлады вәкаләтле кунаклар.

—Вәгаләйкүм-әссәлам,—дип җавап кайтардылар.—Хуш килдегез.

Килүчеләр, күрсәткән урынга утырып, кулларын догага күтәрделәр. Сүзнең ни хакында барасын хуҗалар төшенде, ләкин сабыр гына утыра бирделәр.

—Илчегә үлем юк,—дип башлады сүзен Фәтхулла муллакә,—без сезгә зур йомыш белән кердек. Иншалла, безне нәүмиз хәлгә куймыйча, сүзебезне тынларсыз, аяк астына салып таптамассыз.—Чуклы шәлләләр дә сүзгә көч-куәт өстәгәндәй, «әйе, әйе» диешеп утырдылар. Сүзне шулай җайлап кына, ерактан башлады, Фәтхулла, йоласы шулай.—Әйе, үтенечебез зур. Кызыгыз Туктабикәне Алимҗан белән Мәмдүхә кордашларның улы Мансурга хәләл җефетлеккә сорап килдек. Ходай Тәгалә кушып, табышканнар

икән, теләкләренә каршы килмик, яшьләрнен бәхетенә каршы төшмик, диюебез. Ризалык-фатихагызны бирсәгез иде, дип килдек.

—Эһем...—дип куйды кызнын атасы. Хужабикә исә яшьле күзләрен кулъяулыгына сөртеп утыра иде.

Тимерне кызуында сугарга кирәк дигәндәй, Фәтхулла сүзен дәвам иттерде:

—Егетебез Мансур, үзегез күреп торасыз, эшмәгәр, сау-таза, рәтсезләнеп йөрми. Кушылсалар, кызыгызны бәхетле итәрлек кеше. Кызыгыз Туктабикәнен дә яше житкән, үз оясында үз учагын ягар вакыт, диюебез.

Хужалар һаман жавап кайтарырга ашыкмады, ләкин риза буласылары ачык иде инде. Карт хужабикәгә ым какты, тегесе торып, мич артына узды. Озак та үтмәде савыт-саба тавышы ишетелде. Дөресен әйткәндә, Туктабикәнен әнкәсе сонгы көннәрдә бик еш бу хакта сүз башлый, егетне кире борып, бердәнбер кызларын бәхетсез иткәннәренә икесе дә бик пошына иде. Ходайга тапшырып, бирерләр ахры ризалыкларын. Ә яучылар сүзне дәртләнебрәк дәвам иттерде:

—Алимжан кордаш белән Мәмдүхәнен тормышы да күз алдыгызда, чөкердәшеп гомер кичерәләр. Нәселләрендә адәм рисвае булып йөргән кеше юк. Алла боерса, болары да яхшы яшәр, сезгә тупырдашкан оныклар китерерләр. Сарт булсалар да эшмәгәр, яхшы күнелле алар. Шәехләр, әүлияләр токымыннан.

Шәжәрә тамырлары чыннан да Бохара ягыннан дин, ислам кануннарын таратырга килеп, Себер якларында тамыр жәеп калган шәехләргә барып тоташа аларнын. Шунысы да хак, аларга жир бирелмәгән. Өлкәнрәкләр мона бәйле зур вакыйгаларны да хәтерли әле. Француз сугышыннан алда гына, 1811 елда булган бу хәл. Көмешлесу авылы сартлары жир булмаудан нужа чигеп яшәгәннәр-яшәгәннәр дә, бер көн үз зарлары белән патша хәзрәтләренә баш иеп барырга булганнар. Уйлана торгач, бу эшне булдырса, Әхмәтша Шәехов кына булдыра инде, дигән нәтижәгә килгәннәр. Акыллы кеше, аз-маз гына русчаны да сукалый икән. Юлына уртак акча жыйганнар. Иртеш буйларыннан башлап, Төньяк котыпка кадәр хужасыз жирләрнен очы-кырые юк бит, шуннан аларга да өлеш бирүләрен үтенеп, прошение язганнар. Өстенә зур үтенечне йөкләп, юлга кузгала Әхмәтша. Зур кыенлыклар белән Петербургка ирешә. Анын кебек падишаһка мон-зарларын түгәргә килүчеләрнен очы-кырые булмаган. Ләкин күбесе айлар-еллар буена көтеп тә, теләкләренә ирешә алмыйча, кайтып китәргә мәжбүр булганнар. Аларнын өмет тулы кәгазьләре патша сарае ишегенә беркетелгән махсус «озын» тартмада саргая биргән. Олуг падишаһ аларны алып укыр дип, юкка гына өметләнгән кара халык, андый вак мәсьәләләр белән башын чуалтмаган ул. Йөри торгач, Әхмәтша абзыйнын да акчасы тәмам беткән. Шул арада рус-француз сугышы да башланган. Озак уйлап тормастан, Әхмәтша да үзе теләп, сугышка киткән. Ходай саклаган күрәсен, авыр бәрелешләрдә катнашса да, башы исән калган. Батырлыклар күрсәткәне өчен, мактау кәгазьләре дә биргәннәр. Патша әмере буенча, туган якларына кайтыр юлын түләүсез генә үткән. Анын исән-имин кайтырына өметен өзгән авылдашлары «ах» иткән, ике башлы бөркет төшерелгән кәгазьне әйләндереп-әйләндереп караганнар. Ләкин жир мәсьәләсе тәки хәл ителмәгән. Әлегә кадәр исеме халык телендә сакланган Әхмәтша солдат Мансурнын ерак бабасы була инде.

Юллары унышлы булды яучыларнын, сүз жырлап торган самавыр артында дәвам итте. Кунакларга гына саклап тотылган кытай чәе белән тирләп-пешеп гәп сатты булачак кодалар. Туктабикәнен куанычы эченә сыймады: сабыр иткән—морадына ирешкән, ди бит. Бу юлы кызларынын бәхетенә киртә салмады картлар. Шат күнел белән, туй көнен дә булчап[1], сон гына кайтыр юлга кузгалды яучылар.

Бер айдан гөрләтеп туй ясадылар. Дусларынын бәхетле йөзенә

[1]Булчап—билгеләп.

карап, көнләшеп тә куйды кызлар: алар соң кайчан жан сөйгәннәре белән кавышыр?

Көннәр жылытып, язгы чәчү вакытлары якынлашты. Елдагыча авылга районнан вәкил килеп төште. Теге юлы Тегерманлегә килеп, Гөлсылуны алдап киткән «кияү егете» Кызылбаев иде бу. Хәйрүш кинәшеннән башка булмагандыр, вәкилне колхоз идарәсе фатирга Хәмит абзыйлар йортына билгеләде. Нурияне күреп, хәйран калды ыспай егет. Бригадир да юкка гына авыз суларын корытмый икән, дигән уй күнеленнән узды. «Чылбырсыз сәгать» иясенен буй-сыны, кием-салымы да авылдагылардан күпкә өстен, кыз белән анлашырга да вакыты житәрлек. Көчләп түгел, жайлап кына, бөтен тел осталыгын эшкә жигеп, бу баш бирмәс кызны үзенеке итәчәк! Бер акыллы кешенен: «хатын-кызны үзегезгә каратырга теләсәгез—мактагыз!» дигән сүзләрен һич исеннән чыгармады.

Кыз дәресләрдән кайткач, укуы турында сораштырган булды, шаян сүзләр кыстыргалады. Тегерманледәге чибәркәйгә биргән вәгъдәсе, аңа калдырган теге «бүләге» ике ятып бер төшенә кермәде: анын ише вактәякне уйлап башын катырмады.

Ә чибәркәй... Бер атуда ике куянга тидерде Гөлсылу: мәктәп директорынын исемен пычратуны егетләр кыйммәт бәяләде. Ай буе дәваланып, яман чиреннән дә арынды ул, берочтан паспортны да, авылдан китәргә рөхсәт кәгазен дә кулга төшерде. Шифаханәдән чыккач, авылына кайтты. Алар авылыннан балалар әле дә Көмешлесуга йөреп укый иделәр, мәктәптәге хәлләр аңа да мәгълүм булды. Тикшерүләр бетеп, азрак тынычлангач, янадан Зиннурга барырга ниятләде. Теге очрашудан сон нәрсәдер күнелен тырнап торды. Барып, бөтен булган хәлне сөйләсә, жиненәеп калыр төсле тоелды. Тәвәккәлләде кыз. Гөлсылу килеп житкәндә, көн кичкә кунган, мәктәп тирәсе тынлыкка чумган иде. Үзенә таныш баскычлардан өскә күтәрелде, ишетелер-ишетелмәс кенә директор кабинетынын ишеген шакыды.

Зиннур укып утыра иде. Башын күтәреп, керүчегә текәлде. Теләсә кемне күрергә әзер иде, тик инде янадан Гөлсылу килеп керер дип һич көтмәгән иде директор.

—Син?—диде ул, үзе дә сизмәстән, һәм, шаккатып, кызга карап калды. «Шушы эшләрдән сон син кабат мондамы?»—дип сорый иде анын күзләре.

—Зиннур абый, зинһар, гафу итегез,—диде дә үксеп жибәрде сылукай.—Мине бит мәжбүр иттеләр.

—Мин барысын да беләм, Гөлсылу, күз яшьләрен дә, гафу үтенүен дә кирәк түгел. Бу юлы да берәр этлек уйлап кергәнсендер әле.

—Юк, Зиннур абый, ышансагыз-ышанмасагыз да, рәхмәтләр әйтергә кердем. Теге юлы сүземне тынладыгыз, кире борып чыгармадыгыз, минә инде паспортым да бар. Авылдан киткәнче, сезгә анлатасым килде.—Кыз, тынычланып, яулыгы белән күзләрен сөртеп алды.

—Ярый, морадына ирешкәнсен икән, молодец,—диде Зиннур да үз чиратында.

—Минә сез дә ышанмыйсыз инде мина, ә бит мин моннан ярты ел элек кенә теләсә нинди сүзгә ышана торган саф күнелле кыз идем. Алдандым мин, Зиннур абый... Алдап кына да калмады, яман чир йоктырды... Ә бит ышанган идем шул жирбиткә. Башым әйләндергәч, ышанган идем. Ялгызлыктан, колхозда бер тиенсезгә ике битем белән жир сөрүдән котылырмын, дигән идем. Тубылга барып, эшкә урнашсам, барыбер табып, битенә төкерәм әле шул Кызылбайнын! Локман белән Хәйрүш минем авыру булуымнан гына файдаландылар. Шул чир булмаса, гомеремдә андый ялганга бармас идем. Мин...

Бу исемне ишетүгә, Зиннур «дерт» итеп куйды. Кызга текәлеп карады, дөрес ишетәмме дигәндәй, кабатлап сорап куйды:

—Тукта әле, нәрсә диден, Гөлсылу? Нинди Кызылбай, нинди чир?

Зиннурнын йөзе үзгәреп китте, эченә керердәй булып, кызга текәлде.

—Минем авыруымны ишеткәнсездер инде... Тегеләр дә бит шуны йоктырсын дип, өегезгә хәтле озатып куйдылар.

—Син чыннан да авырумыни?—диде Зиннур, гаҗәпләнүен яшермичә. Тагын ни әйтергә белми, тукталып калды.

—Авылыбызга торадан вәкил булып шул Кызылбаев җирбит килгәч булды барысы да. Аның юмалавына ышанып кына харап булдым ла... Әнием дә үлеп, бөтенләй ялгызым торып калган чаклар иде. Гомеремдә бер кешедән дә ишетмәгән сүзләр сөйләде бит ул, эшләремне барып җайлыйм да, кайтып алам, дип антлар эчте...—Күзләрендәге яшьләрен сөртеп, тынып калды кыз.

Гөлсылуның соңгы сүзләрен Зиннур гүя ишетмәде дә. Урыныннан сикереп торды да, кызны гаҗәпкә калдырып, ашык-пошык киенә башлады. Коридорга атылып чыккач кына, кыз ягына борылып карады:

—Гөлсылу, минем ашыгыч эшем бар икән әле, рәхмәт килгәнеңә.

«Димәк, Локман белән Хәйрүш Гөлсылуның Кызылбайдан алданып, яман чир эләктерүен алдан белгәннәр. Кызны әллә нәрсәләр вәгъдә итеп күндергәннәр, эшнең ни белән төгәлләнәсен алдан планлаштырып эшләгәннәр.—Зиннурның баш мие җилгә каршы куелган канатлы уенчык тизлегендә эшли иде.—Кызның кунып калуы да алдан ук сөйләшенгән. Менә сәбәп нәрсәдә икән. Теге тикшеренүләр вакытында үзен шифаханәгә алып барып, әлләничә төрле анализлар бирергә мәҗбүр итүләренең сәбәбенә хәзер генә төшенгәндәй булды директор. Кыз янында кунып чыккач, Зиннурның да шул пычрак авыруны эләктерүенә иманнары камил булган күрәсең аларның». Юк, Зиннур үзен бу кадәр дә җүләр хәлдә тойганы юк иде әле. Рәхмәт Гөлсылуга, килеп, күңелен бушатмаса, эшнең төбенә гомере төшәсе юк икән. Аны мәсхәрә иткән, алдаган, авыру йоктырган «тәти егет» хәзер Нурияләрнең өендә берни булмагандай рәхәтләнеп яшәп ята! Бу уй аның җен ачуларын чыгарды. Ә бит монда да Хәйрүшсез үтмәгәндер. Вәкил китүгә, янә берәр гайбәт таратыр иде ул мәкерле җан.

Кызып китеп, Хәмит абзыйлары капкасы төбенә килеп җиткәнен сизми дә калды мәктәп директоры. Кереп, вәкилне бугазыннан алырга, Гөлсылу каршына тезләндерергә теләде. Ярсып, капка келәсенә кулын салды. Ләкин соңгы мизгелдә мондый эшнең башсызлык буласын уйлап, туктап калды. Районнан чәчү эшләрен уңышлы итеп оештырырга дип җибәрелгән вәкилгә кул күтәргәне өчен ни буласын чамалый иде әле генә ут-суларны үткән яшь директор. Ятимә бер авыл кызына кем ышаныр дисең? Ләкин ни эшләргә соң? Бу эшне шулай калдырып булмый бит инде. Бүген үк Нурия белән сөйләшергә кирәк!

Бераз уйланып торгач, җил-җил атлап Мансурларга таба юл тотты. Эшне тиз-тиз аңлатып бирде. Гөлсылуның кабат килеп чыгуын ишеткәч, телен шартлатып, серле генә күз кысып куйган дусты, эшнең вәкил Кызылбаевка барып бәйләнгәнен абайлагач, җитдиләнеп калды. Уйлашып, киңәшләшеп алды егетләр. Кече якта үз эшләре белән мәш килеп йөргән Туктабикә дә ире белән Зиннурның бик катлаулы мәсьәлә чишкәндәй бәхәсләшүләрен, нәрсәдер планлаштыруларын ишетеп, бу якка чыкты.

—Берәр ярдәмем тимәсме дип чыктым әле, шулкадәр уйланырлык нинди хәсрәт төште башыгызга?

Ир-егетләр бер-берсенә карашып алды. Мансур «Туктабикәгә ышана аласың», дигәндәй, баш селкеп куйды. Шуннан соң гына Зиннур аңа да бүгенге хәлләрне сөйләргә булды, бәлки ул берәр нәрсә уйлап чыгарыр, Нуриянең ахирәте ләбаса.

—Туктабикә, син теге миндә куныл калган Гөлсылуны хәтерлисең булыр,—дип башлады ул сүзен.

Хәтерли, дусларын утка салган ул сылукайны бик яхшы хәтерли Туктабикә. Үз колагына үзе ышанмыйча, торган саен күзләре зуррак ачыла барды. Әле Мансурына, әле Зиннурга карады.

—Өйрәтергә, мәңге хәтерендә калырлык сабак укытырга кирәк ул

мөгезсез үгезгә!—диде Туктабикә, сүз бетәр-бетмәс.—Икенче безнең як кызларына нәфесен сузмаслык итәргә кирәк!

Байтак утыргач, бер фикергә килеп, кузгалдылар. Туктабикәне Нурияләргә юлладылар, ә Мансур кайбер дусларына кагылырга булды. Зиннур үзе мәктәпкә таба юл тотты. Авылда клуб юк. Сирәк-мирәк кенә килгән киноны мәктәпнең коридорында күрсәтәләр. Олысы-кечесе мәктәпкә агыла ул көнне. Нурия белән алар да бүген шунда очрашырга сүз куешкан иделәр. Мәктәптә шау-шулар тынган теге бәхетле көнне күзгә-күз карап аңлаштылар алар. Башка беркайчан да кеше сүзенә ышанып, эчтән янып-көеп йөрмәскә, ачыктан-ачык сөйләшергә вәгъдә бирештеләр. Нурия бер дә тартынмыйча, газизенең яңакларыннан сыйпады, бармак очлары белән генә иреннәренә кагылып үтте. Әллә нинди, әлегә икесенә дә билгесез бер дулкын аларны бер-берсенә этәрде. Иелә төшеп, әкрен генә кызның назлы иреннәреннән үпте егет. Нурия дә гадәттәгечә аннан качмый, әллә нинди бер ләззәтле йокыга талгандай, сөеклесе кочагында эри, югала барды. Моннан соң алар гомергә бергә булачаклар. Саф мәхәббәтне юкка чыгарырлык көч табылмас. Ә иреннәр коры көннәрдә суга сусаган гөлләр кебек, бер-берсеннән яшәү көче алды. Иске мәктәп стеналары өр-яңа сүзләр ишетте: «Сине генә яратам. Сине генә сөям»,—дип пышылдады иреннәр...

Туйлары узгач, Туктабикәне сирәгрәк очрата башлады Нурия. Кичке уен, аулак өйләргә йөрми яшь парлар. Кайбер көннәрдә генә мәктәптән кайтканда дустының эш урынына кагылып, туйганчы серләшәләр. Менә хәзер дә яшь киленне кочаклап каршы алды. Бәхетле елмайган күзләреннән ахирәтенең дөньясы түгәрәк булуы аңлашыла иде. Аның алсуланып торган йөзенә карап:

—Кияүгә чыгу килеште үзеңә, айның үндүртенче кичәсе кебек балкыйсың. Күз тимәсен тагы,—дип, як-ягына төкеренгәндәй итте Нурия.

—Без Мансур белән киногa барырга булдык әле,—диде Туктабикә, исәнләшеп, сердәшенең хәлләрен сорашып алгач.—Сине дә ыспай кавалерың белән чакырырга кердем. Өйдәдер бит?

—Әй, куйсана шуны. Күзен майландырып хәзер үзе дә кереп җитәр әле. Комплиментлары белән үзәгемә үтеп бетте инде. Кайчан чәчүләре бетеп, котылырмын шуннан,—диде Нурия, чыраен чытып.—Бүген без дә Зиннур белән кинода очрашырга сүз куешкан идек бит.

—Сүз куешкан булсагыз, очрашырсыз, Алла боерса. Тик бүген ул тәти егетне дә үзебездән калдырмаска тиешбез. Егетләрнең аңа сүзе бар,—диде, серле елмаеп, Туктабикә.—Сораулар биреп, вакытны сузма, бик шә-әп булачак бүген кино. Чакыр кавалерыңны.

Бернәрсә дә аңламаган Нурия авызын гына ачкан иде, ишек шакып, вәкил егет үзе кызлар ягына чыкты. Туктабикәне күреп, елмаеп исәнләште. Шуны гына көткәндәй, кыз сүз дә башлады:

—Мин Нуриянең дус кызы. Әле менә аны киногa чакырырга кергән идем. Сез дә барырга теләмисезме? Бик кызык картина күрсәтәләр икән.

Кызылбаевка шул гына кирәк тә инде! Атнага якын шуларда фатир торып, кыз белән бер минутка да ялгыз кала алганы юк бит әле. Менә ичмасам, бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, диләрме әле? Бик зур рәхмәтләр әйтеп, ризалашты егет, итагатьле генә баш иеп, үз ягына киенергә чыгып китте. Җан дустына ачуланырга, эшнең асылы нәрсәдә икәнен сорарга да өлгермәде Нурия, «ыспай кавалер» киенеп тә чыкты.

Алар мәктәпкә барып җиткәндә, анда инде байтак яшьләр җыелган, ә ишектә йозак эленеп тора иде. Кычкырыша торгач, ишекне ачарга тиешле кеше—завхоз Әхмәшүдне эзләп таптылар. Ләкин болай да эш барып чыкмады, ул мәктәптә кино булмасын гына белдерде. Имеш, яңгыннан саклану начальнигы мәктәптә кино күрсәтүне тыйган икән.

—Кино күрсәтеп, башымны төрмәдә черетер хәлем юк, җәмәгать, гаепләмәгез,—диде Әхмәдүш җыелучыларга.

Нуриянең исе китте бу хәлгә, Зиннур бернәрсә дә әйтмәгән иде

бит. Шуны гына көткән Туктабикә вәкил егетнең салпы ягына салам кыстыра башлады:

—Гомердә бер кино карарга чыккан идек, шунда да булмады. Сез торадан килгән зур кеше бит, сөйләшеп карагыз әле, бәлки күрсәтерләр. Сез рөхсәт итсәгез, күрсәтәләр инде алар.

Кавалерның күкрәкләре кинәя төште, «сезнең хакка барысы да булыр» дигән кыяфәт белән, кызларны калдырып, әле һаман таралышырга уйламаган яшьләр арасыннан Әхмәдүшкә таба атлады.

—Туктабикә, бу нәрсә тагын?—дип сорады Нурия дустын читкәрәк тартып.—Кайда Мансурың, кайда Зиннур?

—Хәзер, барысын да аңладым, әйдә бу тирәдән югалыйк әле,—дип, як-ягына карангалап, Нурияне үз урамнарына алып китте сердәше.

Кызылбаевның үзенә таба килүен күреп, Әхмәдүш тиз генә егетләр арасына кереп югалды. «Торадан килгән зур кеше», күпме эзләсә дә, мәктәпне ачып, кино күрсәтер кешене тапмады. Хәлне аңлатырга дип, кызлар калган урынга килсә, алардан да җилләр искән. Башка чара юк, кайтырга чыкты вәкил. Шулчак күзе кибет ягына төште. Кино карарга килгән яшь-җилкенчәк ачтырган күрәсең, кибет ишегендә аркылы тимер юк иде. Хатын-кызлар белән шаярырга яраткан кебек, туры килгәндә тәмле тамагын әче су белән чылатырга да хирыс тәти егетнең аягы шул якка тартты.

Таңсылу белән дә таныш иде, шаулатып сәлам бирде.

—Бу сылукайның кибете һәрвакыт ачык, күңеле дә шулай булсачы, дигән булды кичке кунак. «Культурно» ял итәргә уйлап та, киноның булмавын сөйләп, зарланып алды. Икенче төрлерәк ял итүгә ишарә итеп, кибетчегә шыгырдап торган акчалар сузды. Таңсылу да хәленнән килгәнчә ачык йөз күрсәтеп, пакетка кызылбашларны төреп салды. Ләкин кибетне ябарга кирәклеген әйтеп, вәкил егет теләсә—үзләренә кунакка чакырды. Өйләре дә ерак түгел икән. Татлы ризык белән чибәр кызларны әллә кайдан сизенә Кызылбай, Таңсылуның да үзен кире какмасын беренче күрүендә үк чамалады. Кызга сугылып чыгарга гына вакыты юк иде әлегә кадәр. Үзе торган йортның кызын каравыллады егет. Ә ул һаман берни аңламаган булып кылана, үз бәясен күтәрә. «Ярар, бүгенгә Таңсылу дигән сылу да ярап торыр, иртәгесен тагы күз күрер».

Кызның әти-әниләре өйдә юк, иләмсез зур йорт караңгы тынлыкка чумган. Моны күргәч, Кызылбай батыраеп китте, хуҗаларча кыю түргә узып, өстәл янына киерелеп утырды. Хуҗабикәнең өстәлгә аны-моны куйганын көткән арада, бер рюмканы бушатып өлгерде. Әзрәк кызып алгач, аның теле дә ачыла төште, куллары да иркенрәк йөри башлады. Таңсылу да тартынып тормады, егеткә каршы утырды, савытлары бушаган саен, кыстап-кыстап эчерә торды. Теге кыстатмады, хатын-кызны авызына карата алуына горурланып, үз-үзенә сокланып, төрле мәзәк хәлләр сөйләде, кызның күңелен күрергә тырышты.

Гайрәтләнеп алгач, урынында гына озаклап утыра алмады, урындыгы-ние белән сылукайга якынлашты, биленә кул салды. Таңсылу моны сизмәмешкә салышты, рюмканы тутырып, кунагының кулына тоттырды. Башын артка ташлап, бер генә йотты кунак, савыт бушап калды. Эчкән саен телләре бәйләнә, сүзләре мәгънәсезләнә барды. Шулай да ул сылуның тагын да татлырагына, тагын да таңсыгырагына нәфесен сузды. Кочагыннан шома балыктай шуып кына чыккан хуҗабикә:

—Ашыкма—ашка пешәрсең, сабыр итсәң—морадыңа җитәрсең,—дип сөйләнә-сөйләнә, ишек ягына китеп югалгач, тәкать тотар хәле калмаган Кызылбай да торырга талпынды. Ләкин нәрсәгәдер абынып, сөрлегеп китте. Бер-ике адым ясауга, мәтәлеп төште. Башын күтәреп, аягына басарга азапланды. Шуннан калганын торадан килгән вәкил аңлап бетермәде. Ишек ягында күзенә әллә ничә күләгә күренгәндәй булды. «Артыграк эчелде ахры»,—дип уйларга өлгермәде, әлеге күләгәләр моның янына килеп, башына киндер капчык кидереп тә куйдылар. «Кияү егетен»

ике яктан боргычлап тоткан ныклы куллар боргаланырга да ирек бирмәделәр. Мингерәүләнгән баш ни уйларга да белмәде, берәүләр күтәреп, аны тезләндереп, тункайтып та куйдылар. Шуннан аргысына кеше сөйләсә— ышанмас иде. Бермәл артына каеш, тал чыбыклары чажлап төшмәсенме! Аны, районнан килгән вәкилне каешлыйлар! Бер секундта айныды кунак, ләкин соң иде инде. Арт ягы үтереп әчеттерүгә түзә алмыйча, аюдай үкерә башлады. Нәзек чыбыклар тагын-тагын сыздырып үтте.

—Бик шәпләп тамызыгыз, егетләр, онтылмаслык булсын. Адым саен бер кызга кул салып, чир йоктырып йөрмәсен моннан ары.

—Туктагыз, егетләр, кызларыгызга түгел, авылыгызга да якын килмәм!

Адәм мәсхәрәсе аю булып үкерде, чучка булып чинады. Яшьләр шау-шу килеп өйдән чыгып киткәннән соң да әле вәкил, әрнүенә чыдый алмыйча, шактый вакыт акырып та бакырып ятты. Кызлар үзләре генә калгач, аяк астында ухылдап яткан «кияү егетне» күз алдына китереп, рәхәтләнеп көлделәр. Авыл егетләре кинонын бик кызыклысын күрсәтте бүген. Булды ирмәкләр Көмешлесу авылында.

Үз гомерендә беренче тапкыр, иясез эт кебек, иднәдә йоклап чыкты Кызылбай. Йокы түгел, тәмуг газаплары булды бу. Мингерәүләнгән башын тотып, чигәләрен уа-уа, урындыкка торып утырган иде, артына инә кадалгандай, сикереп торды. Тавышка түр якта йоклаган Таңсылу да уянып чыкты:

—Чәйме, әллә аракымы кирәк баш язырга, чибәр егет?

—Берсе дә кирәкми. Рәхмәт, болай да сый житәрлек булды. Су бир, салкын су.

Көмешле чишмәнең салкын суын аягүрә баскан килеш кенә голт-голт йотты да, кеше-кара күрмәгәндә атын жиктереп, таң беленгәндә Кызылбай, чанасына кырын ятып, авылдан чыгып сызды.

Авыл яшьләре генә: «Инде нәрсә белән бетәр бу хәл, берәр этлек кылмагае»,—дип, атна-ун көн буе сагаеп-шүрләп көттеләр. Бәхетләренә каршы, һичбер ләм-мим диюче, вакыйганы кабартып, чокчынып йөрүче күренмәде: эш шуның белән вәссәлам...

Кызылбай эчтән тынды. Кеше алдындагы кеше бит. «Көмешлесу егетләре исерек чагымда башыма капчык киертеп, чи итне чыгарганчы артны каезладылар»,—дисенме? Телефоннан гына чылтыратып, авырып кайтуын райкомга хәбәр итте. Атнадан артык мамык мендәр салып та утыра алмады вәкил, өендә бикләнеп, караватында аунады. Гөлсылу, Таңсылу кебек сылуларга байтак вакытлар күтәрелеп тә карамаслык булды.

## 17

Тикшерүләр вакытында, кырмыска оясына таяк тыккан кебек, мәш килеп гүләп алган мәктәп, язгы ташкыннан соң сабырланып калган Иртешкә охшап, тынычланып калды. Яшь директорның эшләре дә әкренләп үз юлына, элеккеге эзенә төште. Өннәш мәктәптәге эшеннән азат ителгәч, Туйбикәнең дә теле кыскарды.

Төгәл фәннәрне бала вакытыннан ук аеруча якын итсә дә, тарих фәненә Зиннур битараф түгел иде. Югары сыйныфларда тарихны укытучы Гөлсинә туташның дәресләрен чын кызыксыну белән тынлый. Әле күптән түгел генә читтән торып югары уку йортын тәмамлаган укытучы үз фәненә чынлап торып гашыйктыр, мөгаен. Дәресләрен үткәннәргә сәяхәт рәвешендә корып жибәрә дә балаларны үз авызына карата, әллә күпме гыйбрәтле хәлләр тезеп, тарих фәненә мәхәббәт һәм кызыксыну уята. Әнә бит кыш көне үткәрелгән тарихи викторинага да югары сыйныф укучылары мәш килеп әзерләнгән иделәр. Тарихтан башка фән юк диярсең. Барысы да Тубылга, музейга барудан башланды. «Туган ягым тарихы» дигән темага үткәрелгән викторинага урта сыйныф укучылары гына түгел,

Ирмәк—көлкеле хәл, мәзәк хәл.

укытучылар, ата-аналар да чакырылды. Кичәдә катнашучы укучылар да үз белемнәренә үзләре горурланып сөйләгән иделәр. Ата-аналары шаккатып тыңлады. Әнә бит ниләр сөйли алар, исләрен китмәле! Көмешлесудан ары дөнья юк дип йөр син тагы...

Дәресенә директор кереп утыргангамы, бүген укытучының бите алсуланып чыккан. Балаларның һәрберсенә белемне ярып салырдай булып сөйли Гөлсинә. Ә бит Зиннур үз төбәкләренә кагылган, балаларны кызыксындырырлык теманы сайлап керде. Шуңа классның тын калып укытучыны тыңлавы бер дә гаҗәп түгел.

—Алтынчы-җиденче гасырларда ук Казакъстан далаларында яшәгән төрки хатан кабиләләре, әкренләп күчеп килә-килә, безнең Иртеш-Тубыл елгалары буена якынлаша. Төпләнеп, яши башлыйлар. Унберенче гасырда кабиләләр берләшеп, зур гына төрки дәүләте дә төзиләр. Тура, Ишим елгаларына кадәр җирләрне алып тора бу ханлык. Әмма унөченче гасырда зур фаҗигаләр була. Монгол яулары күп дәүләтләрне бер-бер артлы буйсындырып, Иртеш ярларына яу чаба. Безнең ата-бабаларыбызның җире дә Алтын Урда империясенә кертелә. Монгол татарларыннан безнең халыкларга татар кушаматы кала. Тора-бара ул бөтенләй милләт исеме булып китә. Димәк, без—борыңгы төрки халыкларның дәвамы икәнбез, әйеме, балалар?

Укытучы беразга тукталып, үз сөйләгәннәренең балаларга аңлашылуына тәмам инанырга теләгәндәй, класска күзен йөртеп чыкты. Бер дәрестә дә үз фикерен белдермичә, йә сорау бирмичә калмаган Әпсәләм ягына күз салды. Белеп тора укытучы, ниндидер соравы бар баланың. Әллә директордан читенсенә, әллә башка берәр сәбәп бар, кулын күтәрергә кыймый утыра. Ләкин теленә килгәнне әйтмичә дә булдыра алмый, боргалана, энәгә утыргандай кылана. Гөлсинә апасы үзе, мөлаем елмаеп, укучыга ярдәмгә килде:

—Әпсәләм, берәр соравың бармы әллә, нәрсә аңлашылмады?

Аның сипкелле бите кызарып китте, ләкин урыныннан кубып, үзен борчыган сорауны бирде:

—Апа, алай булса нигә дип урыс малайлары безне «татаро-монгольское нашествие» дип үчекләләр, аларга ниме, тарихны өйрәтмиләрме әллә?

Класс янадан укытучыга борылды.

—Кызганычка каршы, балалар,—дип сүзен дәвам иттерде укытучы,—тарихны дөрес аңламаган галимнәр дә бар шул. Бөтен бәла дә «татар» атамасының кулланышында. Монголиянең Буир-Нур дигән күле буенда яшәгән гаять кырыс холыклы, сугышчан кабиләнең исеме ул. Монгол гаскәрендә татарлар хәтсез була. Иртеш, Җаек, Идел буйларын яулап алгач, монда яшәгән төрки кабиләләр дә әкренләп «татар» исеме белән йөртелә башлый. Тарихта мондый аңлашылмаучылык-буталчыклар күп. Сез шуны аңларга, исегездә калдырырга тиешсез: безнең борыңгы бабаларыбыз—төркиләр, Казан ягында яшәүче хәзерге татарлар—безнең кан кардәшләребез. Ә монголлар—бөтенләй башка халык.

Чыннан да, бик катлаулы мәсьәләне күтәрде бит әле бу тиктормас бала. Зиннурның үзенә дә күпме ишетергә туры килде бит андый сүзләрне. Кайчан ачыклык кертелер бу мәсьәләгә, кайчан төп-төгәл тарихлары булыр да, мондый сүзләргә чик куелыр?

Директор боларга җавап таба алмады. Күп сораулар ачык килеш калды.

## 18

Соңгы вакытларда Даут үзенең көнкүреше, Өннәш белән яшәүләре хакында бик еш уйланды. Олыгайган көннәрендә юаныч булырга, ичмасам, балалары да юк бит. Хатыны, өрми дә, җибәрми дә дигәндәй, Даут аннан аерыла да алмый, тыныч гомер дә күрми. Ирен хатын-кыз җенесеннән булган һәрбер үткән-барган кешедән көнләгән

хатын үзенең кыланышларын кеше күрми дип белде, ахрысы. Ләкин аңа әллә кайчаннан бирле битараф булган Даут, Өннәшне үз җаена калдырды. Утын-печәннең дә нинди юл белән китерелгәнен белде ир. Хәйрүшнең үз йортында бик еш «кунак» булуын да сизде, ләкин бу хакта ләм-мим дәшмәде. Аның битарафлыгына, үзенә игътибар итмәвенә хатыны озак түзеп тормас, аерылу ягын карар, дип тә өметләнде. Ләкин хәлләр аныңча барып чыкмады— Өннәш һаман иренең колак итен кимерүдән туктамады.

Өннәш мәктәптән куылгач, Туйбикә дә әллә ничек сабырланып калгандай булды. Тел озайтыр сердәше калмагач, дәресләрдән соң өенә ашыга, укытучылар белән артык очрашмаска тырыша кебек иде. Ире фин сугышында ятып калды аның.

Даут белән Туйбикәнең мөнәсәбәтләре икесе дә уйламаганда, һич көтмәгәндә башланды. Көннәрдән бер көнне Туйбикәнең классы яныннан үтеп барганда, тарих укытучысының уйланып утыруын күрде Даут. Дәресләр беткәнгә дә байтак вакыт узган, укытучылар инде күптән өйләренә таралышкан. Бер урамда, юл аша гына яшиләр бит, дәшмичә узарга кыймады. Бергәләп кайтырга чыктылар. Башта икесе дә, сүз булмаганнан сүз дигәндәй, укучылар, дәресләр хакында сөйләделәр. Аннан, ничектер, гаилә, көндәлек тормыш мәсьәләләренә күчтеләр. Туйбикә ялгыз яшәүнең авырлыкларыннан, йорт-кура тирәсендә ир-ат кулы җитешмәүдән зарланды. Кайтып җиткәннәрен сизми дә калдылар. Капканы япканда, күршесен онытып бетермәскә, кереп йөргәләргә чакырды хатын. Даут ни әйтергә дә белмәде, кабызган папиросын тирән итеп суырды да үз ягына атлады.

Туйбикәнең соңгы сүзләрен ни дип аңларга да аптырады. Әллә гадәттәге саубуллашу сүзе генә булдымы ул, әллә?.. Шайтан котырта диярсең, тынычлыгы югалды бит Даутның. Телгә зәһәр булса да, сөйкемле генә иде хатын. Өс-башы пөхтә, озын чәчен югары күтәреп, шарф белән бәйләп куйган. Ниндидер мәхәббәтле сөяге бар бит ул шайтан хатынның. Кәс-кәс атлап йөрүләре генә дә ни тора...

Өенә кайтып, ашап-эчте ир-ат, көндәлек эшләрен карап алды. Өннәш тә юкны-барны такылдап йөрде-йөрде дә, урын җәеп, йокларга җыенды. Хатынының йоклап китүен озак көтәргә туры килмәде аңа, тиздән Өннәшнең тигез мышнавы ишетелде. Күзенә йокы кермәде Даутның. Өйалдына чыгып, тәмәкесен кабызды. Байтак уйланып утырды, янадан кереп ятты. Стенадагы күкеле сәгать вакытның ярты төнгә таба авышуын күрсәтә иде. Тагын урынында озак ята алмады шайтан коткысына бирелгән ир, торып, папиросына сузылды. Шуннан соңгысын акыллы баштан гомерендә дә эшләмәс кебек иде. Ләкин күңелгә коткы салынгач, аннан котылам димә икән. «Кунак ашы—кара каршы»,—дип уйлады ир-ат, мышнап яткан хатынына күз төшереп. Юкка көнләшеп баш авырттырганчы, барга көнләшсен! Өйалды баскычыннан тиз-тиз карангылыкка чумды. Әллә Туйбикә дә йоклый алмыйча борсаланып яткан, тәрәзәгә бармак очы белән генә чиртте—идәннәр шыгырдап, хуҗабикәнең өйалдына чыгуы ишетелде.

Калганы төштә күргәндәгедәй булды. Даутның курку-икеләнүләре бер минутта юкка чыкты. Йокы күлмәгеннән генә калган күрше хатын, бер сорау да бирмичә, төнге кунакны өйгә уздырды... Ызгыш-талаштан, гайбәт сөйләүдән башы чыкмаган хатында бу кадәр наз, йомшак сүзләр булыр дип башына да китермәгән иде Даут. Хатын аны эссе сулышы белән сихерләде, озын толымы белән чорнап, башын әйләндерде. Таң алдыннан гына үзенең суык түшәгенә кайтып ауды ир заты.

Инде ни заманнардан бирле хатыннар назы күрмәгән ирнең дөньялары түгәрәкләнде, кәефе киткән саен күңел юаткычына кереп чыга башлады. Соңлап уянган мәхәббәт көчле елганы буып торган киртәне ерып киткән, котырып аккан суга тиң бит ул. Гомерен сабыр үткәргән Даут көчле мәхәббәт вәсвәсәсенә бирелеп китүен тоймыйча да калды. Ул мәхәббәт дингезенә чумган яшүсмердәй башын җуяр дәрәҗәдә иде. Көн дә, төн дә шул елтыр күзле Туйбикә аның исеннән чыкмады. Әй аның төнге назлаулары, суырып үбүләре, кайнар сулышы исертте дә куйды салмак абзыйны. Бозаудай үшән

бәндә дип уйлап, Өннәш бик саташкан икән. Авыл бит бу, бер башында төчкергәнне икенче очта ишетеп торалар. Көтмәгәндә күрше-күлән ап-ак киемле өрәкнең төннәрендә Туйбикәнең янкапкасыннан кереп югалуын күрә башлаган, ди. Өннәшнең күңеленә шик салды бу хәбәр, саклык чараларын күрә башлады. Кичтән ул иренең тышкы киемнәрен яшерә торган булып китте. Бер күнеккәч, Даут абый төрле хәйләләр белән үз «сәяхәтен» эчке киемнән генә дәвам итү чарасын тапты.

Ә бер көнне... Ишекнең шыгырдап ачылуына хатыны уянып китсә, ни күзе белән күрсен... аның «бозавы» кереп килә, имеш... Хатын:

—Кайда булдың, карт шайтан?—дип үкереп җибәргәнен сизми дә калды.

Җавап кыска булды:

—Гомерең буе юктан көнләшеп тәмам җанга тидең. Менә инде чынлап көнләш, алайса.

Монарчы гел юаш бозау кыяфәтендә йөргән ире бүген арысланга әверелгән иде. Өннәш тәмам телсез калды. Аңына килгәч кенә:

—Даутым, җаныем, көнләшмим инде. Ташла шул карабатыңны[1]!—дип, ире тирәсендә сырпалана башлады.—Йөрмә, җаныем, ятлар янында, үзем сиңа җаның теләгәнчә иркәләрмен, яме?! Әйт кенә, шуның нәрсәсенә кызыгасың? Йөрмә, зинһар, шуның янында!..

Шул көннән соң Өннәш, таң тишегеннән торып, иренә пәрәмәчләр, бавырсаклар пешерә торган булды, кытай чәен каймаклап та шикәрләп хәстәрләргә өйрәнде, аркаларына массаж ясады, битләреннән яратып сыйпады. Күпмедер вакытка өйдә тынычлык урнашты. Мәгәр, Өннәше никадәр генә тырышмасын, Даут абыйның күңелен инде Туйбикә билэп алган, нәрсәсе беләндер гел үзенә тартып тора иде. Бераз вакыт үткәч, абзый янәдән күршесенең йортына аяк басты. Рәхәтләнеп сөешә генә башлаганнар иде, әлеге албасты Өннәш бастырып та керде. Керешли үк:

—Ах, җирбитләр! Ах, карт шәрмәндәләр[2]!—дип акырып, көндәшенә ташланды һәм чәчен эләктереп алды.

Анысы да авыз ачып калмады, уң кулы белән Өннәшнең тузган чәченә чытырдатып ябышты. Ике хатын арасында тартыш китте. Даут, акылларын җуйган ике хатынны аера алмыйча, хәлдән тайды. Ыргакка әверелгән кулларына эләккән чәч толымнарын урыннарыннан умырып алмыйча торып, һич туктамадылар. Үзләре усал этләрдәй кабышалар. Тилергән хатынын Даут көчкә сөйрәп алып чыгып китте. Шуннан соң Өннәш белән Туйбикәнең дуслыгы өзелде, бер-берсен күрәлмас булдылар. Ләкин Өннәш иренә биргән сүзендә озак тора алмады. Март ахырларында янына Хәйрүш кергәч, инде аны куалап чыгарыр, дип уйлап ире хаталанган икән. Юк, кайда ул. Сагынышып, озаклап сөештеләр. Дәресләрен тәмамлап кайткан Даут бикле ишекне шакыгач кына, аптырашып, кузгалдылар. Ире кереп килгәндә, түшәктә күп аунаган Өннәшнең чәчләренә ястыкның ертык урыныннан тузып чыккан каз мамыгы сарылган иде. Даут абый борын эченнән:

—Чучка тизәк ашавын куямыни ул?!—дип, эчке бүлмәгә үткән арада, Кәрбек үз теләгенә ирешеп, чыгып сызды...

Икенче көнне Туйбикә, мәктәпкә кергәч, Даутының кулына бер язу тоттырып китте. Кешеләр күрмәгәндә абзый, әлеге язуның эчтәлеген бик беләсе килеп, конвертны ачты: «Даут, мин буйга уздым. Рәхмәт сиңа. Картлыгымда терәгем, юанычым булыр»,—диелгән иде анда. Даут нәселен дәвам иттерүче булмауга пошынып йөри иде, ул да куанды. Бу аларның сонарып килгән мәхәббәт җимешләре иде.

... Колхозда чәчү эшләре барса, мәктәптә «урак өсте» якынлашып килә. Һәркемнең телендә сынаулар гына. Аеруча унынчылар чын-чынлап әзерлек алып баралар, укучыларның эше дә артканнан-арта гына бара. Зиннур Нуриясенең мәктәпне уңышлы тәмамлавына чын күңеленнән ышана, кызның белемнәре нык, бу сынауларны да югары билгеләргә тапшырып

[1]Карабат—уйнашчы.
[2]Шәрмәндә—бозык, оятсыз.

чыгар, иншалла. Хәзер имтиханнарны тәгәлләп, бергә булу хакында хыяллана алар. Дәресләрдән ял иткән арада очрашып, киләчәк тормышлары хакында уйлана торган булып киттеләр. Нуриягә тиздән унтугыз тулачак. Очрашу турында сөйләшеп куйсалар, икесе дә кичне житкерә алмыйча йөдәп бетәләр.

Нурия иңнәрендә пар канат бар төсле очып кына йөрде. Аннан да бәхетле кеше юктыр дөньяда. Аллага шөкер, әтисе савыгып китте, үз жаена йорт тирәләрен карап-сипләп йөри. Мәктәптә дә эшләр жайлы гына бара. Тиздән бәхеткәйләре бөтенләй түгәрәкләнер аларның. Ялгызы калган вакытларда сөйгәне белән кушылу көннәрен уйлап, үз бәхетенә үзе ышанмый башлый. Бер ел эчендә дә әллә никадәр вакыйгалар булып үтте бит. Аларның мәхәббәтен, хисләренең ныклыгын сынаган кебек булды язмыш. Ялгышсалар да, бер-берсен гафу итә, вакытында үз хаталарын аңлый алдылар. Хәзер күңелләре тыныч: аларны инде кеше сүзе генә аера алмас. Уйланып утырса, нинди генә эш башкарса да, күңеленнән бер жырны көйли кыз, кичерешләрен жырга сала:

Иң якынга, «жаным», диләр,
Жаннан якын бар микән?
Жанымнан да якын күргән
Син гүзәлем бар икән.

Мәхәббәт чокыры бизи
Нурлы йөзен иркәмнең.
Ышанам уртак бәхетле
Киләсенә иртәнең...

## 19

Колхоз рәисе Шәкүр соңгы вакытларда эчүгә бирелеп китте. Кайбер көннәрдә идарәгә кереп йөрсә дә, чынында эшләр белән бригадир Хәйрүш идарә итә иде. Рәис калтыраган куллары белән язу-сызуларны караштырган атлы булып утыра да, тизрәк өенә кайту ягын карый. Колхоз мөһере әллә кайчан Хәйрүш кулында. Хәйрүш аны берәүгә дә кире кайтарып бирмәс. Тиздән ул бөтен колхозның башы булып алыр.

Ул көн үзен озак көттермәде...

Шәкүр эчәргә әкренләп күнекте. Колхоз малыннан өлеш чыгарса, «юмарт» авылдашлары үзләре үк рәисне өйләренә чакырып сыйлый, аның салпы ягына салам кыстыра башладылар. Соңрак инде ул үзе дә барлык кылган «изгелек, яхшылыклары» өчен рәхмәтне ярты белән генә саный иде. Шыр Шәкүр шулай агым уңаена йөзде дә йөзде. Колхоз да, авыл халкы да аннан бер мыскал файда күрмәде. Хатыны Мөжамал гына ирен акылга китерергә, шулкадәр эчүдән туктатырга теләп, үгетләп тә, орышынып та карады. Берсе дә файда итмәде.

—Мөжамал, нәнәвем, сиңа нәрсә житми?—дип кенә жавап кайтарды гадәтенчә тамак төбенә салып алган рәис.—Ялган дөньяның рәхәтен күреп калыйк әле, янекәм. Колхозда эш бетмәс.

Көннен-көнендә өстәп торырга «кызыл башы» булса, берни дә кирәкми башлады. Андый чакларда орышмады, хатынына кул күтәрмәде рәис, аның күңеле йомшарып, нечкәреп китә иде. Менә бүген дә иртә таңнан теләндә бер генә нәрсә булды: «Бажайларга кунакка барыйк». Бер башлаган сүзне өзмәде дә куймады. Мөжамалы ничекләр генә үгетләп карамасын, нәтижәсе булмады. «Чәчү өсте бит, кеше ни әйтер?»—дип уйлады хатыны. Авызыннан сасы самогон исе аңкып торган ире янына килеп, юмалап та карады:

—Шәкүр, йөрәккенәем, язгы чәчү вакыты бит. Кәнсәләренә кереп, эшләренне караштыргалап чыксаң иде, дим. Кунакка бару качып китмәс. Чәчү бетүгә, гөрләтеп барып килербез сеңелләремә. Тыңла сүземне. Бажаена да колхоз эшләренә барасы булыр...

Ләкин Шәкүрне үз сүзеннән кайтарыр көч юк иде. Иртәгә үк кара айгырны жиктереп, жилдереп кенә бажаларына барырга карар кылды рәис. Кичә генә аягын сындырып суелган колхоз сыерының да ите-маена ис кергәнче урнаштырасы бар. Бажаена менә дигән күчтәнәч булыр. Дөньясы түгәрәк колхоз башының.

—Әйдә, бичә, үзең дә утыр. Типтереп калыйк үзебез баш чакта.

Ире баш булып алганнан бирле кыр эшләренә чыкмаган хатын тутырган тавыктай түгәрәкләнеп калган иде. Сеңлесен күреп килү теләге анда да юк түгел. Тик менә бу эшләрнең хәерлегә булмасын күңеле сизде. «Мәтәлдереп төшерә күрмәсеннәр колхоз башын, дус бар, дошман бар, дигәндәй...» Шулай дип уйлады ул кысыла-кысыла мич арасыннан чикүшкә белән самогон алып чыкканда.

Иртәгесен иртән үк торып, баш язды Шәкүр. Идарәгә барып, тиешле күрсәтмәләрне биреп чыкты, чәңгелчәк арбага[1] мимылдап торган бичәсен утыртып, күрше авылга, бажаларына юл тотты.

Алар барып кергәндә, Мөҗәмалнең сеңлесе терлек-туар арасында кайнашып йөри иде, иртәнге кунакларны сәерсенеп каршы алды. Бүкән башыдай Мөҗәмал белән кипкән чабактай Хәбипчамал кочаклашып күрештеләр. Өйалды ишегеннән Бәшир бажалары да күренде. Колгадай биек буен бөкрәйтә төшеп, күрешергә атлады. Каушап калган хуҗабикә өстәленә ни куярга белмәде. Бәшире эшне тиз генә чамалап, күрше урыс авылындагы танышларыннан самогон алып кайтырга юлланды. Хатын-кыз өстәл җайларга, яна иттән пилмән бөгәргә кереште.

Күрше авыл кул сузымы урында гына утырса да, җәяүле кеше барып әйләнгәнче байтак вакыт узды. Дүрт күз белән бажаен көтеп яткан Шәкүрнең тәмам түземлеге төкәнде. «Атны тугарганчы, үзем генә барып килгән булсамчы»,—дип уйлады ул, ишекле-түрле йөренеп. Хатыннарның пилмәннәренә дә күңеле тартмады, алар бер-берсенә ябышып бетте. Үзенең йортында әчкелтем суы бер дә өзелеп тормаган рәис бажасының булдыксызлыгына җаны түзмичә, орышынып-сүгенеп тә алды. Берзаман тирләп-пешеп Бәшир дә кайтып керде. Бажасының балкыган йөзен күргәч, сулышлары кинәеп киткәндәй булды.

—Булды гына, бажай,—дип шешәне «дыңк» иттереп өстәлгә утырткан иде, тегесе катырак кыланды ахрысы, «лык» итеп төбе төште. Бер үк вакытта кызганыч та, курыкынган да күзләре белән Шәкүргә текәлде Бәшир. Тегесе хатын-кыз алды дип тормыйча, әче итеп бер сүгенде дә, өстәл кырыеннан агып торган көмешкәгә учын куйды. Моны күреп, бажасы да, калган зиһенен җыеп, тиз генә чынаяк чокыры алды, икенче яккарак ага башлаган «чишмәгә» тотты. Өстәлгә җәелгән күлдәвекне тамчысын да калдырмыйча җыеп эчте бажайлар. Хатыннары исә, апалы-сеңелле, маймыл кыяфәтенә төшкән ирләрен, башларын селкеп, хәйран калып күзәтеп тордылар. Тиздән күңелләр түгәрәкләнеп, җаннар тынычланып калды, икесе ике көйгә «Тәфтиләү»не суза башладылар.

Күрше авылда башлаган «күңел ачу» өйгә кайткач та тукталмады. Төне буе, аяктан егылганчы эчте колхоз җитәкчесе, башын күтәреп, сүзен әйтә алмас хәлгә килде. Утырган урынында кыйшаеп йокыга киткәнче, ярты төн җитте.

Иртәгесен торып, аш-су ягына чыккан Мөҗәмалнең коты алынды: ире өстәл артында кыйшаеп йоклаган хәлендә күм-күк күгәреп каткан иде. «Бәйрәм» шулай тәгәлләнде, колхоз башы фани дөньядан, яшәвенең мәгънәсен дә белмичә, китеп барды...

Колхоз язмышы инде бөтенләе белән Хәйрүш кулына күчте. «Эштә тәҗрибәсе бар» дип, райком аны рәис итеп билгеләде. Кәрбекнең дөньялары түгәрәкләнде. Шәкүрнең йомшаклыгыннан файдаланып, колхоз эшләренең үз җаена куелуын күреп торган Хәйрүш, дилбегә законлы рәвештә үз кулына килеп кергәч, гайкаларны ныграк бора башлады. «Урак-чүкеч»тә тимердәй нык тәртип урнаштыруны төп бурычы итеп куйды. Колхозчылар сагая калды. «Бу егет эш чыгара, болай булгач»,—дип тел шартлатучылар да булды. Язгы чәчүне бик вакытлы тәгәлләделәр. Иртә таңнан кич караңгыгача эштә булды халык. Соңлап килүче, алдан китүчеләрне яшь башлык үзе карап, күзәтеп, андыйларга хезмәт көне язылмавын атлаган саен кисәтеп, кабатлап торды.

[1]Чәңгелчәк арба—ике тәгәрмәчле, сиртмәле арба.

Ашлык тирәсендә эшләүчеләрне кесәләре, эчке киемнәренә кадәр капшап-тикшереп кайтара торган булды: «Бербөртек колхоз милкенә кул сузучыларны төрмәдә черетәм»,—дип янады. Яшь рәиснең ныклы тәртип урнаштырып, зур уңышларга ирешүе хәбәре райком тирәсенә дә барып җитте. Алар мактаган саен, Хәйрүш дуганы бөгә барды. Дуга ясаучыларның бер сере бар: хәттән тыш бөксәң, ул сынып китә. Хәйрүшнең кыланышларына авылдашларының да түземлеге сынган чаклар булды. Ләкин андый вакытларда каршы төшкән кешенең үзәкләренә үтте рәис. Ник туганнарына үкенерлек ясады. Икенче авыз ачып каршы сүз әйтмәслек итте.

Ачлык елларында көчеп килгән, яки колхозлашу вакытларында туган якларыннан сөрелгән, татар-башкорт якларыннан килеп монда урнашкан гаиләләргә аеруча кыен тормышлар башланды. «Халык дошманнары», «кулак калдыклары», «килмешәкләр» дип кенә кычкырды ул аларга. Олысы-кечесенә рәхим-шәфкать күрсәтмәде. Ялгызы бер өйдә яшәп, олыгаеп килгән ирегет бөтен кешегә әллә нинди үче бар кебек кыланды.

Казан якларыннан килеп, Көмешлесуда төпләнеп калган Салих останың вафаты күпләрне тетрәндерде. Бик булдыклы, алтын куллы зат колхозда да бар көчен куеп эшләде, сүз әйтерлек итмәде. Чәчү ахырына якынлашкан көннәр. Салих абзыйны сука сөреп йөргән җиреннән чакырып кайталар: хатыны бәбигә авырып ята, кендек әбиләренең дә ярдәме тими, хатын үлем газаплары кичерә икән. Аны-моны уйлап тормастан, абзый атын җигә дә торага чаптыра. Газапланган хатынын, туасы нарасыен кайгыртa инде үзенчә. Бу баласына да бирәр нәрсә булса, хатынының йөрәге түзә алмас. Беренче балаларының ярасы да җөйләнеп бетмәгән бит әле. Аларны Себер якларына сөргенгә озаттылар. Әле имчәктән аерылырга да өлгермәгән нарасыйлары, Төмәннән ат белән килгәндә суык тиеп, вафат булды. Озатучы конвой туктап, балаларын күмәргә дә рөхсәт итмәде. «Бу суыкта кәрванны туктатып, күмгәнегезне көтеп торырга бик важный персона түгел әле, кар эчендә дә бик шәп ятыр ул көчегегез»,—дигән иде озатучыларның башлыгы. Нарасыеның үлек гәүдәсен мамык шәленә төреп, ике көн күкрәгенә кысып барды хатыны. Өченче көнне, олаулар бер татар авылында туктагач кына, акылдан язардай хатыныннан баланы алып, бер татар картына калдырды Салих. Үзебезчә кадерләп, җеназасын укып, күмүен сорады. Олаулар кузгалып, авыл кечке энгердә югалганчы Нәүбәһәре күз нурларын шул тарафтан алмады.

Салихның торадан кайтуын Хәйрүш көтеп алды. Тегенең арбадан төшкәнен дә көтмичә, акырына башлады:

—Кылны икегә ярыр вакытта нишләп син, кулак калдыгы, суканны ташлап, торага чаптың? Ананны...

—Сабыр ит әле, Хәйрүш энем, мин бит уен уйнап йөрмәдем. Хатыным бәбәйли алмыйча бик интеккәч, аны шифаханәгә илтергә мәҗбүр булдым. Калган эш нормамны төнлә булса да эшләп тутырырмын,—диде дөнья авырлыгыннан гаҗиз булган Салих юаш кына.

Аның тыныч булырга тырышып сөйләве Хәйрүшнең җен ачуларын чыгарды. Кызарынып-бүртенеп торды да, үтемле сүз тапканына куангандай, бармак янап дәвам иттерде:

—Бүтән бичәләр өйләрендә генә бәбәйлиләр бит, синең Нәүбәһәреннең арты алтынлымы әллә? Юк, бу син—кулак калдыгының колхозга юри зыян китерүең. Беләбез без синең замашкаларыңны!—Хәйрүш борын яфракларын киңәйтеп, тагын да ачырак итеп сүгенде.

Мондый рәнҗету-кимсетүләрне күп күргән йөрәк, авырттырып, тагын бер чәнчеп куйды. Башын түбән иеп, бугазына килеп тыгылган төерне йотарга тырышып, эшенә таба атлады Салих. Сукасына тотынып, бөтен ачу-рәнҗүләрен онытырга тырышып, эшкә кереште. Ләкин йөрәк сикерүе басылмады, күкрәк турысы чәнчешә-чәнчешә, тоташ утка әйләнде. Иртәгесен авылдашлары кыр читендә башын иеп торган, тугарылмаган атны күреп, янына бардылар. «Казанлы» Салих оста яңа гына сөрелгән бураздада кулын йөрәгенә куеп, үлеп ята иде. Туктабикәнең уколлары да файда итмәде. Хатынының хәлен, туасы баласын да күрә алмыйча бу шәфкатьсез-

миһербансыз дөньядан рәнжеп китеп барды. Кайчан булса да туган жиренә кайтып, газиз башын ата-баба туфрагына салу өмете дә үзе белән бергә үлде. Хатыны, яна туган баласы чит жирләрдә тәрәксез торып калды...

Азынганнан-азына барды Хәйрүш. Электән корган планнарын тормышка ашырыр вакыт житте бит. Бүген анын урамында бәйрәм: олысы-кечесе ана баш иеп килә, гозерен сөйли, үтенә дә ялвара. Кешене түбәнсетү-рәнжетүдән әллә ничек бер ләззәтләнү таба иде. Бер эшне дә бушка башкармады, сорап килүченең желекләренә үтеп, бәгырьләренә төшмичә торып, бер кәгазь кисәгенә дә кул куймады. Ә рәискә баш иеп килүчеләрнең исәбе бетә торган түгел иде. Азмыни сон авыл кешесенен ачлы-туклы гомерендә кирәк булган нәрсәләр?! Чәчәргә игене, ашарга оны гына да юк бит! Чәчүне уңышлы төгәлләгәне өчен сурәтен районнын мактау тактасына элделәр. Ин кадерле урында, ялпак колакларын тырпайтып, ул хәзер үткән-барганнардан бер карыш өстәрәк кәпрәеп утыра. План үтәү күрсәткечләренең югары булуына нинди юллар белән ирешелүе берәүне дә кызыксындырмый. Бөтен колхозчыларны тез чүктерер әле ул, бөгеп кенә калмас, карышу-чыларнын умырткаларын да сындырыр.

Эштән кайткач, гомергә жыелмаган урынына авып, әнә шуларны уйлап ятарга ярата, жанын шулар белән тынычландыра, киләчәккә берсеннән-берсе кәттәрәк планнар кора. Әлегә кадәр анын бөтен уйлары да тормышка аша барды, озакламас, мәктәп директорын авызлыклар көн дә килеп житәр. Кышкыга утын, печән юнәтер вакыт килеп житәр, борынын югары чөеп озак йөри алмас Зиннур, барыбер ана төшәр ялынычы. Менә шул вакытта карарбыз кемнен кем икәнен. Үзенең тузанлы итекләрен яларлык итәр әле рәис, алдында шуышып йөрер егетен! Хәйрүш Хәйбуллов диләр аны...

Авылдашлары Хәйрүшнен күптән түгел генә яман чир белән авырып китеп, вафат булган атасын да яхшы хәтерлиләр. Әнкәсе бер сәүдәгәргә ияреп Кавказ ягына китеп югалды. Халыкка артык җәбер-золымнары тигәне юк иде аларның. Игезәк сыңары Сәйбүш тә тракторчылар курсын тәмамлап, Ишим якларындагы бер МТСта рәтле генә эшли, дип сөйлиләр. Күзле-башлы булып, балалар үстерә икән. Хәйрүш исә һаман ялгызы көн күрә, үзенә тин булырдай асыл затны каптырмыйча, тынычланачак түгел. Шул исәпкәрлеге Хәйрүшнен канына сенгән. Берәр яхшылык кылса, көт тә тор: костырып булса да ала. Бригадир итеп үз урынына Локманны куюы да башка түгел. Егет анын алдында бурычлы, шуна күрә, кулга ияләштерелгән аттай, ни кушсан, шуны эшләр. Ике арада азрак бәргәләнеп йөрде дә Локман, Гөлсылуны авылга хатын итеп алып кайтты. Монда да үз өметләре бар рәиснең. Бәлки, бәлки... сылу хатыннын куен жылысын да татып булыр. Локманны ерак юлга озатырга жае чыкмый тормас...

## 20

Язгы кояш көннән-көн мулрак яктырта, назлы жылысы белән барча жан иясен иркәли башлады. Төшлек яктан искән талгын жил нәфис, йомшак куллардай битне кытыклый, күнелләрне жилкендерә. Югарыга карасан, күзләр камаша. 1941 елнын май ае шулай матур килде. Иртеш буйларындагы шомыртлар ак эшләпә киеп алганнар да күршедәге нәзек билле миләшләр белән, башларын чайкый-чайкый серләшәләр, яна килгән язга куанып бетә алмыйлар. Табигатькә акрын-акрын гына жан инә, бөтен тереклек дөньясы карлы-бозлы салкын тормыштан арынып, кышкы озын төннәрдән уянып килә. Берәүләр ап-ак чәчәк атарга да өлгергән, икенчеләр әле яна гына бөреләрен күпертә. Язнын исләрен, төсен, тавышларын чагылдырып бетерерлек хушбуйлар да, музыка да, картина да тудырылмаган. Бүген генә өй кыекларыннан тамган тамчыларда чыпчыклар коенса, күр дә тор: ике-өч көннән гөрләвекләр китәчәк, алардан сон авыр сулап Иртеш үзе дә кузгалачак. Көмешлесунын Иртеш белән кушылган урынында да кар әллә кайчан китеп, аланлык, гүя туй дәстәрханы, аллы-гөлле, күнелле төсләргә күмелгән. Учма-учма утырган күкчәчәкләр янындагы сап-сары

гөлбәдраннарның төсе тагын да ачыграк, көләчрәк булып күренә. Кошлар тавышы тоташ бер гүләүгә әйләнә, күңелгә якын, күркәм бер көй, гармония барлыкка килә. Яр карлыгачлары уйнаклап күк гөмбәзенә, югарыга күтәреләләр дә, уктай атылып төшеп, бәреләләр инде дип котың очып торганда гына, ярның битен шадралаткан түгәрәк-тирән ояларына кереп югалалар. Иртеш суы өстендә акчарлаклар өерелә. Көтмәгәндә кинәт башларын суга тыгып чабак-мазар эләктереп алалар да, кеше күзеннән читтәрәк камышлыкта ояда утырган парларын сөендерергә ашыгалар. Бөтен тереклек иясе җәйгә олуг өметләр баглый, яшәешен дәвам иттерергә, үзеннән соң буын калдырырга ашкына. Табигатьтәге бу бәйрәм, бу тантана кешеләргә көч, күңелләргә ышаныч, өмет, мәхәббәт килә...

Унынчыны бетерүчеләр дә мәктәпнең кысан коридорларына сыешып тора алмадылар, өлгергәнлек кәгазьләре алып, укытучыларының котлау сүзләрен, олы юл алдыннан соңгы киңәшләрен тыңладылар да, табигать кочагына сибелделәр. Ун ел буе үзләренең икенче туган йортларына, гомерләренең аерылгысыз бер өлешенә әверелгән мәктәп бусагасын атлап чыкканда, кызларның күзләренә яшь тәелде. Моңарчы этешеп-төртешеп, шаярып йөргән егетләргә дә әллә нәрсә булды. Күңелләренең әллә кайсы бер жире чеметтереп алды, әлегә кадәр тоймаган бер халәттә иде унынчылар. Кызыклы китапны укып, соңгы битләрен япкандагыдай бер хис кичерделәр. Яна китап, бәлки әле моннан да мажаралырак, мавыктыргычрак та булыр, тик ул китап әлегә ачылмаган. Билгесезлек тулы ашкын өмет күңелләрне бер үк вакытта нечкәрткән дә, иләс-миләсрәк тә иткән иде.

Мәктәп бакчасын үтеп, Кызлар Убасына таба юл алуга, янадан уенкөлке, шаян сүзләр башланды. Бүгенге көн аларныкы. Унынчылар белән авыл яшьләре, яшьрәк укытучылар да бәйрәм итә. Гармун тавышы авыл урамнары буйлап Убага юнәлде. Китте уеннар, жырлар, биюләр... Унынчылар үсмерлектән яшьлеккә атлады...

Уеннар озакка сузылды. Берәү дә тиз генә кайтып китәргә ашыкмады. Иртәгә янадан мәктәпкә барасы юк, ничектер бар кешегә ямансу да, куанычлы да иде. Йомшак үләнгә тезелешеп утырып, байтак сөйләштеләр. Ел саен Кызлар Убасында очрашырга, бер-берләрен онытмаска вәгъдәләр бирделәр. Уку елларындагы мәзәкләрне гәпләп, туйганчы көлделәр. Соңында төркемнәре белән Иртеш буена, су керергә юнәлделәр. Зиннур белән Нурия дә көне буе бергә булды. Иртәгә Нурия Төмәнгә китәргә тиеш иде...

Сөйләшенгәнчә, ун көннән соң алар кабат шул ук урында очраштылар. Кызның шатлыгы эченә сыймый, ул бүген генә Төмән пединститутының тел-әдәбият бүлегенә керү имтиханнарын тапшырып кайтты. Тиздән өйләнешергә уйлаганга, ул читтән торып укыячак иде. Берәр елдан, бәлки, мәктәптә дә эшли башлар. Ана теле укытучысы олы яшьтә, үзенә алмаш булса, бүген үк эштән китәргә риза. Кулга-кул тотынышып, югарыга атладылар. Билен бөгеп, аларга махсус утырыр урын әзерләгәндәй бөкрәеп үскән каен янына житкәч, туктап, утырырга булдылар.

Иртеш ягыннан жиләс жил исә. Аска карасаң, офыклар киңәйгән кебек була. Бермәл икесе дә югарыдан күренгән манзарага хозурланып телсез калдылар. Агачлар күзгә күренеп яшелләнгән, әле юл тузаны кунарга өлгермәгән ачык яшел төсе күңелләрне тынычландыра. Аста Иртеш жәйрәп ята. Камышлар арасыннан бәпкәләрен ияртеп килеп чыккан бер оя үрдәк тә күзге өстеннән шудырган йомшак уенчыкларны хәтерләтә иде. Сапсары йомгактай бәпкәләр «пип-пип» дип әнкәләре тирәсендә бөтереләләр, тал яфрагы кадәр генә канатчыклары белән кагынып, шаяралар, чумалар, йөзәләр. Әнкә үрдәк бик булдыклы кыяфәт белән нарасыйларын маймыч ауларга, бөжәк тотарга өйрәтә. Ялтырап торган яшелле-каралы әткә үрдәк әледән-әле башын суза төшеп, тирә-ягын күзәтә, ул-бу булмагае дигәндәй, бакылдап-бакылдап ала иде.

Зиннурның күзе күл белән тау арасыннан торага таба сузылган юлга төште. Аларның дөнья матурлыгына хозурланып утыруында беркемнең дә эше юк, һәркем үз шөгыле белән мәшгуль. Юл буйлап атлы-арбалылар,

җәяүлеләр үз эшләре белән ары-бире уза торалар. Кемдер шатлык-куанычларын арбага төяп, кайсыдыр авыр хәсрәтен аркасына атландырып үтә. Нуриясе һаман күзләрен үрдәк бәпкәләреннән ала алмый, үзе дә сизмәстән елмаеп утыра бирә. Ел җиләкле булырга охшаган, аяк астында җир җиләкләре ап-ак чәчәк атып утыра. Бу мизгелдә кыз үзен оҗмах түрендә итеп сизде. Сөйгәненә сыена төшеп, әкрен генә күңелендә туган шигырь юлларын кабатлады:

Назлый җаннарны Кызлар Убасы—
Табигатьнең җылы кочагы.
Күңелләрнең язы, җаннар назы,
Себер дөньясының оҗмахы.

Нуриянең институтка кереп кайтуына кызлар аулак өйдә уртак аш оештырырга булдылар. Көннәр озая бара хәзер, йорт-җир тирәсендәге эшләрне караштыргалап, кичне житкерделәр. Кызлар Бәдерниса корткаякны алдан ук күндереп куйган иделәр. Аның карты колхоз мал-туарын каравыллый. Үзе дә, кызлар җыелгач, ахирәтләренә кереп китте.

Уртак ашка һәркем үз сые белән килә. Һәрбер сыйның да үз хикмәте булырга тиеш. Пилмән эченнән чыккан кишер—бу кешенең бәхетле булуын күрсәтә; быел кияүгә чыгучы яки өйләнүчегә дип, парлы йөзем дә салына; пәрәмәчтән ипи катысы яки борчак чыкса—быел парын таба, дип фараз ителә. Бавырсак, пәрәмәч пешереп керүчеләр дә бар, коймак коючы да табылган. Кәнфит, шикәр алып керүчеләр дә булган. Хәлле хәленчә тырышкан. Кызлар үзләренең сыйларының серен әйтүгә, шау-гөр килеп, табын янына тезелештеләр. Әле суынырга да өлгермәгән пилмән, пәрәмәчләрдән авыз иттеләр. Пешерүчеләрне мактап куярга да онытмадылар. берсен-берсе кысташу, мактошу китте.

Зиннуры янына кунаклаган Нурия дә, бәхетле елмаеп:

—Хуш килдегез, безнең аштан да авыз итегез,—дип куйды. Бүген яшьләрнең телендә аның исеме генә булды. Тырышты бит кыз, унынчыны да бетерде, инде институт кадәр институтка да барып имтиханнар тапшырып кайтты. Күпләрнең әле Тубылга да бара алганнары юк, ә Нурия әнә Төмәнгә үк тәвәккәлләгән. Менә ичмасам, батырлык үзендә. Дуслары аны чын күңелдән котладылар:

—Зиннурдан калышмыйсың үзе...—дип, күз кысып та куйдылар.

Аштан берәр нәрсә чыкса, алып күрсәтелергә тиешле иде. Бераздан Әхмәдүш белән Тансылуга парлы йөзем чыкты. Аларның икесе парлы булуга юрадылар. Зиннурның пилмәненнән кишер, Нуриянекеннән түгәрәк кәнфит чыккач, көлешеп, кул чабып куйдылар. Пәрәмәчтән Фәридәгә тупырдап торган борчак чыкты, ана да бәхетләр теләделәр. Фәридәгә карап күз кысып куючылар да табылды: «Бәлки, мине дә бәхетле итәрсен?»—ди шаян егетләрнең күз карашы. Камилә өйнең хуҗасы булып исәпләнгәнгә, ул барысын да кыстый. Аның Мифтахы армиядә, шунлыктан оялып торыр кешесе юк. Хәзергә ул егетнең хатлары белән генә канатланып яши. Аулак өйдә Хәйрүш юк иде. Кемдер аны искә төшерде.

—Зур түрә булгач, безнең кебек ыбыр-чыбыр белән буталып йөрмәс инде ул,—дип чеметтереп куйды Әхмәдүш.

—Аның булуыннан булмавы хәерле, бөтен бәйрәмнең ямен җибәрер иде,—диде Камилә, ахирәте Нурия ягына күз төшереп,—алдыннан арты матур.

Кичәгә яшь парлардан Мансур белән Туктабикә, Локман белән Гөлсылу да килгән иделәр. Хәйрүш турында сүз чыккач, кайберәүләр шикләнә төшеп Локман ягына күз салдылар. Тик ул моңа әлләни игътибар итмәде, хатынын сыйлавында булды. Локман Гөлсылуны авылга алып кайткач, башта яшьләр ничектер аларны чит иттеләр, ләкин Гөлсылу тиз арада аларга да үз булып китте. Яшь киленнең ачык йөзе, Локманына гына карап торуы аның белән Зиннур арасындагы аңлашылмаучылыкны да оныттырды.

Табын тирәләре гөрләп торды. Барысына да диярлек берәр төрле хикмәтле ризык чыкты. Һәркемнең дә бәхетле, ризыклы, парлы буласы

килә, ырымлы ризыкларга барысы да шат иде. Иң соңгы булып Зиннурга пәрәмәч эченнән тозлы ипи кисәге чыкты. Бу—кеше читкә китсә дә, икмәк-тоздан ризыгы өзелмәвен аңлата иде.

Рәхәтләнеп сыйлангач, уеннар башланды. Уеннарны да Камилә башлап җибәрде. Яшьләрнең җыелышканда яратып уйный торган уеннары «Чыбыгым, чык»тан башладылар. Парлашу ыгы-зыгысы басылгач, Камилә уйнаучыларга шырпыдан калынрак чыбык күрсәтте. Барысы да уенга әзерләнеп, кулларын кушырып, тезләренә куйдылар. Китте уен. Камилә житез генә түгәрәкне әйләнеп, һәркемгә дә иелә-иелә, учларына чыбык салгандай хәрәкәт ясап чыкты. Кырыйга басып:

—Чыбыгым, чык, парыңны калдырып чык,—дип, учын чапты.

Чыбыкны Камилә Нуриягә салган икән, ул җәһәт кенә торып, атылып чыкты. Бу уенга бик үк күнегеп бетмәгән Зиннур аны тотып өлгерә алмады. Бар да көлешеп, гөрләшеп куйдылар. Уенның шарты буенча, егеттән фант алырга тиеш иделәр. Ул күлмәк изүеннән чишеп, «Ворошиловский стрелок» значогын салып бирде. Камилә уенны дәвам иттерде. Бу юлы «Чыбыгым, чык» дигәндә, Әхмәдүш атылып чыкты. Таңсылудан фант итеп чиккән кульяулык алдылар. Өченче фантны Мансур бирергә мәҗбүр булды. Дүртенчесен Нуриядән каптырдылар. Фантлар саны күбәйгәч, аларны «сату» башланды. Алып баручы бүрек эченә салынган фантларны берәм-берәм алып, аларның ияләренә нинди җәза бирергә кирәклеген сорый башлады. Таңсылуның кульяулыгы чыккач, бар да бертавыштан аның биюен сорадылар. Күптәннән бирле бармаклары кычытып утырган гармунчы, аның ризалыгын да көтеп тормастан, «Әпипә» көен кетердәтергә керeште. Таңсылу тыпырдатып басканда, кызлар кул чабып, егетләр кайсы сызгырып, кайсы такмак әйтеп, кызга көч биреп тордылар. Аның бит алмалары кызарып киткән, бу минутта ул күпләрне сокландыргыч матур иде.

Камилә дәвам иттерде:

—Бу товар кемнеке?

—Минеке.

Инде уртага Зиннур чыкты. Бу юлы егетләр бертавыштан:

—Күгәрчен ашатсын!—дип көлештеләр.

Аларның сүзе закон. Уен тәртибе шундый. Зиннурга да үзенә пар табып, «күгәрчен ашатырга» туры килде. Аның кемне чакырасын барысы да чамалый иделәр. Шулай да, Зиннур Нурияне уртага чакыргач, тамак кырып куючылар, күз кысучылар табылды. Шырпыны авызына кабып, Зиннур кызга табарак иелде. Нурия, зәп-зәңгәр күзләрен куе керфекләренә яшереп, аяк очларына басты һәм алсуланып торган иреннәре белән шырпыны эләктереп тә алды. Тидеме яшьләрнең иреннәре бер-берсенә, юкмы—берәү дә күреп өлгермәде. Шулай да канәгатьлек белдереп кул чаптылар.

Уен кызганнан-кыза гына барды. Һәркем хәрәмләшмичә үзенә тиешле «җәза»ны ала торды. Зиннурдан соң чыгучыга:

—Көлтә бәйләп күрсәтсен!—дип кычкырды яшьләр.

«Көлтә бәйләргә» тиешле егет тә озак ялындырып тормады: күңеленә хуш килгән чибәркәйне уртага чакырып, биленнән көлтә бавыдай кочып, биеп китте.

—Монысы кемнеке?

—Мансурныкы. Әйдә, ул җырласын.

«Көмешле» көен барысы да белә иде, Мансур да җыр эзләп, аптырап тормады, күкрәгенә тутырып сулыш алып, таныш җырны сузды.

Фантлар таралып беткәч, уен да тәмамланды. Аннан соң «Йөзек салышмак», «Булавка яшерү» уеннары китте. «Арканда кем бар»ны уйнаганда барысы бергә такмаклап тордылар:

—Арканда ниләр-ниләр бар?

—Бакчар-бакчар[1] күзләр бар.

—Берсен мина бирсәнә?

---

[1]Б а к ч а р —сыерчык.

—Көчен житсә, алсана.

—Алырмын-алырмын, корткаяк.

—Цебер такыян[1] утка як.

—Ялгыз балан калганда, ялынырсын, корткаяк. Әнә бер кызынны тилгәнтас[2] эләктереп тә китте...

Шул төнне Таңсылу Әхмәдушкә ябышып чыкты. Табигатьнең җәй урталарына таба борылган чагы, адәм балаларына бирелгән төннәрнең ин кыска вакыты иде бу. Таңсылу белән Әхмәдушкә бигрәк тә кыска тоелды ул. Егет Таңсылуның тормышында үзенең беренче ир-егет булмавын сизенсә дә, кызга каты бәрелмәде. Үзе сайлаган язмыш лабаса, егет кызны кичерде. Таңсылуы да үзенең бәхетенә чын күңелдән сөенеп, Әхмәдушенең күкрәгенә капланды:

—Зинһар өчен, кичер минем гөнаһымны...—диюдән артык берни дә әйтә алмады. Алар, үз язмышларына үзләре риза булып, яна тормыш башладылар.

## 21

22 июнь таны гадәттәгечә башланды. Көтү кудылар, көндәлек эшләренә керештеләр. «Аулак өйдәге» килешенү буенча, иртәнге чәйдән соң Кызлар Убасына чыгарга тиеш иделәр. Әмма көтмәгәндә әллә кай тарафтан өер-өер кара болытлар чыкты. Урамнардан өермәләр тузан куптарып үтте. Иртә таңнан елга буена төшеп киткән каз бәпкәләрен дә ышыграк җиргә җыеп өлгерә алмадылар, күк йөзен чатнатып, яшен уклары атыла башлады. Карт-коры хәвефләнеп, күк йөзенә карады. Егерме-утыз минут эчендә авыл өстеннән мәхшәр үткәндәй булды. Ләкин көтелгән яңгыр урынына ташборчактай боз кисәкләре сикереште. Әле генә ныгый, чәчәккә бөреләнә башлаган яшелчәләрне, болынлыктагы хуш исле чәчкәләрне кырды да салды боз болыты. Иртеш котырына, акбаш дулкыннар ярны ашыйлар. Җил-давылны алдан сизенгән акчарлаклар каядыр китеп югалган, яр карлыгачлары да ояларына кереп поскан иделәр. Кичәге сүз куешулар, ял итүләр онытылды. Күңелләрдә табигатьнең кодрәте-көче алдында курку туды, күңелләргә хәвеф-шом төште...

Җил-давыл ничек килгән булса, шулай ук китеп тә барды. Ярты сәгать вакыт эчендә әллә никадәр үсемлекләрне кырып, агачларны сындырып, яр башыннан әлләничә каен агачын дулкын кочагына ташлап өлгергән иде инде. Бераздан, кешеләр янадан тынычланып, үз эшләренә керешкәнне генә көткән шикелле, радиоалгычларның кара тәлинкәләре шаулый башлады. Озак та көттермичә, Левитанның бер үк вакытта тыныч та, шомлы да тавышы ишетелде:

—Мәскәү вакыты белән унике сәгатьтә хөкүмәтебезнең мөһим тапшыруы булачак...

Кешеләр, сагаеп, радиоалгычлар тирәсенә җыелды, әлеге хәбәрне көтә башладылар. Нәкъ уникедә тәлинкәләргә янадан җан кереп, шыгырдап куйды. Бу юлы хөкүмәт исеменнән Молотов сөйли иде. Аның хәбәре маңгайларга төшкән тукмак кебек тәэсир итте. Сүзләрнең мәгънәсе тиз генә миләргә барып җитмәде, халык мингерәеп калгандай булды. «Сугыш? Тагынмы? Озаккамы? Кемнәрне ут эченә озатырлар бу юлы?» Телләрдән шул хәбәр төшмәде, тик менә беркем дә бернәрсәне дә төгәл генә аңлатып бирә алмады. Олыраклар: «Гаскәрләр азрак сөзешеп алырлар да туктарлар әле»,—диеп үз-үзләрен тынычландырырга тырышты. Афәтнең никадәр зур икәнен бераү дә күз алдына китерә алмый иде әле.

Икенче көн иртән үк торадан хәбәр килде: Армия сафында хезмәт итеп кайтканнарның кайберләрен ике-өч көнлек азыклары белән хәрби комиссариатка чакыра иделәр. Шушы хәбәр үзенә кагылганнар, кинәт

[1] Цебер такыя—таушалган, иске бүрек.

[2] Тилгәнтас—тилгән.

кенә йокыдан уянгандай, эшнең уен булмавына төшенделәр. Ирләрен озаткач тынычлана алмаган хатыннар икенче көнне үк, имчәк балаларын муеннарына шәлләр белән асып, торага агылдылар. Аларга күрше авыллардан кушылдылар. Хәрби комиссариат алдында халык кара болыт кебек җыела барды, шау-шу купты, аларга бала-чаганың, хатын-кызларның сыгыт[1] тавышы кушылды. Озатучыларны хәрби йортның коймасы артына куып чыгардылар. Көн саен яна кешеләрне озатты авыл, сугыш дигәнен, туя белмәгән аждаһадай, аларны йота барды.

Алтынчы көн дигәндә Зиннурга да чакыру кәгазе килде. Ул хәбәрнең бүген булмаса, иртәгә киләчәгенә ышанып, әзерләнеп көтте. Институтта укыганда ук студент егетләргә запастагы офицер исеме биргәннәр иде.

Юл кирәк-яракларын биштәренә салгалагач, Зиннур Нурияләргә юл алды. Оялып-тартынып тормады бу юлы, туп-туры өйләренә барып керде. Хәмит әкәсе белән кул биреп күреште, гадәт буенча хәлләрен сорашты. Нуриянең чыкканын да озак көтәргә туры килмәде. Өске яктан үзе килеп төште кыз. Парлап урамга атладылар. Байтак вакыт дәшмичә утырдылар. Зиннур сүзне нәрсәдән башларга, кызны ничек юатырга белмәде. Нәрсә әйтсә дә, урынсыз, мәгънәсез булыр кебек иде. Әнә бит сугыш турында бер генә өметле сүз әйтүче юк. Андагы мәхшәрне радиодан ишетә торалар. Шулай да тирән сулап утырудан файда чыкмаячак. Һәр минут аларны аерылу сәгатенә якынайта бара. Бергә булган сәгатьләрнең кадерен белергә кирәк. Кызны алдына утыртты Зиннур, чәчләреннән сыйпап, күкрәгенә кысты. Менә шулай утыр да утыр иден ул. Иртән аерылу, сугыш дигән дәһшәтле ут эченә керүләр булмасын иде...

Авыр сулап, Зиннур кызны да, үзен дә ышандырырга тырышып, сүз башлады:

—Нуриям, акыллым, сугыш озакка бармас, Аллам боерса, тиз арада дошманны тукмап, әйләнеп тә кайтырбыз. Син бит мине көтеп торырсың, башка берәүләргә күз салмассың бит, Нуриям? Син бит минем бердәнберем. Сугыш булмаса, өйләнешеп, бергә-бергә яшәп китәр идек. Шунысы бик җәл, кушылып яши алмадык...

—Зиннур, мин сине күпме кирәк булса, шулкадәр көтәргә риза,—диде кыз, аның муеныннан кочаклап, беренче тапкыр үзе үбәргә җөрьәт итте.—Мина башка беркем дә кирәк түгел. Бу сугыш дигәнен безнең күрмешебезгә генә чыккандыр инде. Ходаем, болай да бит сынаулар житәрлек булды.

Танга кадәр утырды алар. Бер-берсен онытмаска вәгъдә бирештеләр. Зиннур үзенең картларына күз-колак булып торуын сорады, хатлардан өзмәвен үтенде.

Ниязбикә карчык белән Фәтхулла картның да күзенә йокы кермәде. Әллә ничә мәртәбә урамга чыгып, тынлашып керде алар. Авылның теге очында ялгыз гармун өзгәләнә. Яшьләрнең шау-шуын шомлы тынлык алыштырган. Уллары таң алдыннан гына кайтып керде. Беренче тапкыр баласының күзләрендә тирән кайгы, үзәк өзгеч аерылу сагышын күрде әнкәсе: «Әй, балакайлар, күрәсең бәхеткәйләрегез булмагандыр шул. Бәхетлеләр туй алдыннан аерылышмый».

Һәр таңда берәүләр өзгәләнде, аларның күз яшьләре кибәргә дә өлгермәде, икенчеләрнең кайгысы өстәлде. Авыл әкренләп Зиннурларсыз, Ваһап, Басыйрларсыз яшәргә күнегә башлады. Алар белән бергә кызларның елмаюы китте, тол хатыннарның өметен күз яшьләре юып төшерде. Сугышка алынучыларны Омск каласына Иртеш буйлап алып китәселәр икәнлеге билгеле булды. Ул көнне иртә таңнан Нуриянең күзе тора ягында иде. Минут саен Иртешнең Тубыл ягына таба борылышына күзен салды, Зиннурын сугыш эченә алып киткән пароходны булса да күреп каласы килде аның. Ә бәлки үзен дә күрә алыр әле, Көмешлесу янында Иртеш әлләни киң түгел. Зиннуры үзе дә авыллары яныннан үткәндә сөйгәне чигеп биргән кулъяулыгын болгамый калмас. Егетне озатканга әле ике-өч

[1]Сыгыт—сагышлы, моңсу.

көн генә үтсә дә, Нуриягә ул мәңгелек булып тоелды. Күзләреннән яше кипмәде, теленнән аның исеме төшмәде. Ничек болай булды соң әле бу? Моннан бер ай, бер-ике атна элек кенә бу хәл буласын берәү дә башына китерми иде бит. Истә-хәтердә юкта нинди сугыш булды соң бу? Күзгә, яна уку елына кадәр туктар микән? Ә бит Зиннуры җәй айларына әллә никадәр эш планлаштырып куйган иде. Мәктәп болай да иске, инде тагын шундый ук мәшәкатьләрне кыш көне үтәргә туры килерме? Кышка мәктәп өчен утынны кем әзерләр? Әгәр дә кышка кадәр дә туктамаса? Нуриянең йөрәге «жу» итеп китте. Күнеленә мондый уй килгәч, картлар кебек, як-ягына төкергәләнеп куйды: «Аллам күрсәтмәсен! Әйттем исә кайттым!..»

Менә елганың борылышыннан аккоштай ап-ак муенын сузып, пассажир пароходы күренде. Ул Көмешлесу турысына якынайган саен, ярда кешеләр күбәя, арта барды. Һәркем сугышка китүчеләрне күреп калырга, якыннарының газиз йөзләренә соңгы кабат багарга тырышты. Яр буена сибелеп киткән халык кул болгарга, кычкырышырга тотынды. Нурия дә, ачыграк күренсен өчен, Зиннуры яраткан зәңгәрсу бизәкле күлмәген киеп төшкән, ике күзен бирердәй булып, пароход ягына төбәлгән иде. Палубада бик күп кеше булуына карамастан, сугышка китеп баручылар Көмешлесу кешеләренә үз авылларын, туганнарын соңгы тапкыр күреп калырга мөмкинлек бирделәр. Ярда басып торучыларга аларның йөзләре дә аерымачык танылырлык булды. Башкалары кемнәр булгандыр, Нурия бары Зиннурны гына күрде. Ул, йотардай булып, авылы ягына караган, сөеклесенә кулын болгап, нәрсәдер кычкыра иде. Аның тавышы юньләп ишетелмәде, өстәвенә әле хуҗасын танып өрә башлаган актүшнең шыңшуы комачаулады. Нурия дә башыннан яулыгын салып, болгады:

—Сау бул, Зиннур! Җиңеп кайтыгыз!—дип кычкырды.

Ниязбикә әбинең күзен яшь пәрдәсе каплаган, кулъяулыгы белән сөртеп, балакаен барлык сугыш мәхшәреннән аралап-йолып калырдай булып, карап калды.

Карты гына:

—Илаһым, тиз көндә күрешүләр насыйп ит, балаларыбызны бәхетсез кылма!..—дип теләкләр теле, үзен дә, карчыгын да юатырга тырыша иде.

Пароход авыллары турысыннан үтеп тә, хуҗасы төшеп калырга уйламагач, Актүш башта эшне аңламыйча, тирә-ягына каранды. Аннан башын алгы тәпиләренә салып шыңшый, күзләрен мөлдерәтеп елый ук башлады.

Ир-егетләрне озаткач, авыл мәет чыккан йортка охшап калды. Ирләр дә, атлар да сагындырды, атлаган саен, телдә алар гына булды. Гөлсинә Нурулловны мәктәп директоры итеп билгеләделәр. Гомерләр күзгә авышты. Игеннәр котырып унган иде, исән-имин җыеп, кышка керергә өметләнде авыл халкы. Яшь-җилкенчәкләр дә әле авылда байтак, олырак яшьтәге ир-атлар да бар. Сугышның беренче күзе кыен булса да, үзәкләргә үтәрлек түгел иде әле. Кешеләрнең күңелендә өмет яши, хәлле-хәленчә кышка әзерләнә башлады. Колхоз рәисенә бронь бирелде. Ул бөтен көче белән дәүләткә ашлык тапшыру планын үтәргә тырышты. Идарә ишегә башына «Барысы да фронт өчен, барысы да дошманны җиңү өчен!» дигән өндәүне олы хәрефләр белән кызыл ситсага яздырып элде, эшнең барышын үзе тикшереп торды. Ашлыкны кырып-себереп дәүләткә озатты. Игеннең никадәресе үз амбарында калуын үзе генә белде, колхозчыларга өлеш чыгармады. Беренче күздә үк үзен күрсәтте Хәйрүш, аны авызлыкта тотучы ир-егетләр китүдән бик оста файдаланды. Балаларына кесә төбенә бер уч бодай, ике-өч башак салып кайтучыларның җелегенә төште, милициягә хәбәр итү белән янады. Кая барып, кемнән ярдәм алырга белмәгән солдаткаларга аеруча каныкты—иреннәрен тешләп еларлык, аягына ятып ялынырлык хәлгә төшерде.

Зиннур китүгә, Хәйрүшкә тагын юл ачылды. Хәзер инде Нурия, һичшиксез, аныкы булачак. Туры айгырыннан төшмичә генә уракчыларны күзәтеп йөргәндә аның башына берсеннән-берсе шәбрәк планнар да килә торды. Ничек булса да кызны ялгызын гына очратырга тырышты ул, башта

яхшылык белән сөйләшеп карарга булды. Нурия дә җүләр түгел, дөньяның кем файдасына барганын чамаларга тиеш. Озакламый, җае да чыкты. Караңгы төшеп, колхозчылар өйләренә кайтыр вакыт житте. Элекке заманалар түгел бит, һәркем өенә ашыга, тавыш-тын, көлке сүзләр ишетелми. Нурия дә ялгызы гына кайтып бара иде. Әллә каян гына килеп чыкты Хәйрүш. Кызып алганлыгы төсенә чыккан. Телләре бәйләнә. Атын туктатып, кызның юлына аркылы төште бу.

—Нуриякәй, син икәнсең әле, әйдә, кил, утыртып кына алып кайтыйм әле үзеңне!—дип сүз кушты.

Үз уйларына батып, онытылып кайтып килгән кыз хәвефләнә калды. Кәрбекне ялгыз очратудан юньле нәрсә көтмичә, атлыны әйләнеп үтәргә теләде, як-ягына карангалап, адымнарын кызулатты. Нуриянең үзенә җавап та бирмәвенә гарьләнгән Кәрбек тарантасыннан сикереп төште дә, ике-өч сикерүдә куып житеп, кызны беләгеннән эләктереп алды, куаклык ягына өстери дә башлады. Берәүнең дә үзенә ярдәмгә килмәвенә гажиз калган кыз бала, Актүшне исенә төшереп, ачыргаланып, бар куәтенә кычкырып жибәрде.

Үз исемен ишеткән эт яшен угыдай атылып килде дә, урман аланында аюга ташланган дуамал тәвәккәллек белән, ажгырып, колхоз рәисенең арт санын умырып алды. Хәйрүш аны тибеп очырмакчы булып маташты, әмма зәһәрләнгән жанвар аның саен ярсый гына барды, өс-башының карарлыгын калдырмады. Нурия исә, Хәйрүштән ычкынып, бар көченә авыл ягына элдерде. Яныннан дулап рәиснең аты узды. Эттән таланган Кәрбекнең ни хәлдә авылга кайтып керүен берәү дә күрми калды бугай...

## 22

Зиннур артиллерия лейтенанты итеп фронтка озатылды. Ләкин туплар житмәгәнлектән, аларга вакытлыча дип ПТР, ягъни танкларга каршы ата торган мылтыклар бирделәр. Зиннур мылтыкның беренче номеры, ә икенчесе—чуаш егете Константинов иде. Алар полкының төп максаты—броняле машиналарга утырган дошман дивизиясенең алга баруын туктату. ПТРчыларга үзләренә ут позицияләре әзерләргә приказ бирелде. Зиннур белән Константинов та төне буе тирләп-пешеп окоп казыдылар. Аларга икешәр граната, байтак кына патрон бирделәр. Төн болай тыныч үтте дияргә була. Дошманның коралы күп. Алгы сызыкта утырганнарга бу төн дә «эссе» булгандыр: автоматлар, пулеметлар тынып тормады. Әледән-әле күктә ракеталар кабынып-сүнә торды. Константинов таза, нык бәдәнле, әзрәк бөкрәебрәк йөри торган ир-егет иде. Хәрби хезмәткә кадәр тимер юлда машинист булып эшләгән. Канаш станцасында хатыны, ике баласы калган. Матренасын бик сагына, көн дә хат көтә, җае чыккан саен үзе дә, кәгазьне мылтык янагына салып, сәлам сызгалый. Тыныч вакытларда гомергә дә очрашмас кешеләр атна-ун көн эчендә якын дусларга әверелделәр.

Таң аткач ук, немецлар һөҗүмгә күчте. Алдан аждаһалардай ыжгырып, авызларыннан ут-ялкын бөркеп, танклар килә, алар артыннан калышмыйча автоматчылар якынлаша иде. Дошманның көчләре безнекеләргә караганда биш-ун тапкыр артык булуын күрү өчен сугыш кырына бер күз салу да житә иде. Ләкин уйланып, икеләнеп торыр чак түгел. Алгы сызык буйлап командир Ереминның «Чигенмәскә!» дигән боерыгы чылбыр буйлап Зиннурларга да хәбәр ителде. Аның артыннан ук: «Пушкалардан, ПТРлардан дошман танкларына ут ачарга!» дигән көчле тавыш ишетелде. Кара-каршы атышу, гранаталар, снарядлар шартлау тавышыннан колаклар тонды. Тирә-юньдә мәхшәр. Җирдән кубарылып чыккан балчык кантарлары очып китә дә, туфракка әйләнеп өскә коела, тигез урында тирән чокырлар хасил була. Кемнәрдер яраларыннан әрнеп кычкыра, ярдәм сорый, кемдер гайрәтле тавыш белән команда бирә. Дөньяның асты-өскә килгәндәй булды. Менә танклар Зиннурлар позициясенә дә якынлашты. Балчык катнаш тирен

йөзеннән сөртеп, ярдәмчесеннән патроннар сорады Зиннур. Якындагы танкның үзләренә яңы беләнрәк борылганын абайлап, тиз генә ПТРын төзәде. Аждаһа ыжгыруыннан туктады, өстеннән ялкын күтәрелде. Боларны күреп алган икенче танк, ут бөркеп, өсләренә килә башлады. Аларның янында гына снаряд шартлады. Зиннурның күз аллары тонып калды, бер секундка гына зиһене таралган сугышчы тагын ПТРына ябышты. Дошман танкыннан күзен алмыйча гына, Константинов ягына борылып карады. Әле генә сугыштан соңгы тыныч көннәр житүен өметләнеп хыялланган сугышчан дусты урынында канлы гәүдә иде. Шуннан соңгысын хәтерләми: янында гына шартлаган мина дулкыны аны күтәреп бәрде. Ул үзен караңгы чокырга төшеп киткәндәй тойды...

Күпме ятканын Зиннур белми. Исенә килеп, күзен ачса, беренче күргән кешесе—кара шәл бөркәнеп утырган карчык булды. Ыңгырашу авазын ишетеп, карчык лейтенантның авызына кашык белән су салды. Хәле азрак яхшыргач, егет үзенең кайда ятуын, монда ничек килеп эләгүен сорады. Куцеваловка дигән авыл икән. Авыл янындагы бәрелешләр тынгач, авыл малайлары «трофей» жыярга чыкканнар. Кесәләренә патрон гильзалары тутырганнар. Бер чокырда Зиннурның гәүдәсенә тап булганнар. Офицерның кобурасындагы Кобурадан пистолетны алабыз дип сузылганда гына, теге селкенеп, ыңгырашып куймасынмы! Малай-шалай, котлары алынып, өйләренә йөгереп кайткач, хәлне әнкәләренә сөйләгән. Бәхеткәйләре бар икән әле егетнең, бераздан олылар килеп, лейтенантны алып кайтканнар. Зиннур исенә килгәндә, өченче көн туган була.

Әкренләп ул тернәкләнә башлады. Яралары бер караганда бик тирән булып тоелмаса да, сөяккә тигән күрәсең, бер госпитальдән икенчесенә көчә-көчә 1942 елның көзе дә килеп житте. Ходайның бирмешедер—соңгы госпитале Төмән каласында булды. Бу хәлне үзе кичермәгән кеше Зиннурның ашкынуларын гомергә аңлый алмас иде. Менә бит ул, туган якларыннан кул сузымы жирдә генә. Тәрәзәдән караса—таныш йортлар, таныш урамнар. Эх, бер генә көнгә Тубылга, аннан Көмешлесуга кайта алса икән ул! Уйланып ята-ята да егет, тагын хат язарга керешә. Ләкин әллә кайчан салган хатларга жавап та юк, көткән кешесе дә күренми. Ахыр чиктә Тубыл военкоматына телеграмма бирде. Төмәндә госпитальдә ятуын, тиздән фронтка жибәреләчәген хәбәр итте, Көмешлесуга әти-әнисенә белдерүләрен үтенде.

Зиннур хатлары барысы да Хәйрүшнең кулына эләгә барды. Почтаны торадан ул гына алып кайта иде. Әллә кайчаннан бирле улларының хәбәрләрен алмаган ата-анасы көне-төне улларының исәнлегенә теләк теләде, дога кылды. Нурияның моңсу күз карашын күрсәләр, үзләрен кая куярга белмәделәр. Никләр генә бер-ике кәлимә хат язмый соң уллары? Әллә кошлар очып, хатлар килеп житмәслек жирләрдә йөриме? Билгесезлек аларны изде, яшәүләренең мәгънәсен калдырмады. Торадан, военкоматтан килгән хәбәрне калтыраган куллары ача алмас хәлдә иделәр. Кара кәгазьгә охшамаган үзе, ни хәбәр булыр соң бу? Шул вакыт Ниязбикә карчык, акылына килеп, тиз-тиз генә өйдән чыгып йөгерде. Озак та үтмәде, сулышы кабып, Нурия килеп керде, аның артыннан карчыкның авыр тын алуы ишетелде. Күрше кызының Фәткулла әкәсенә төбәлгән күз карашында курку катыш өмет чагыла иде. Картның күзләрендә шатлык билгеләре күргәч кенә, кыз тынычлана төште, үзенә сузылган кәгазь кисәген алып, укый башлады. Нурия кабат-кабат кычкырып укыса да, карт ана барысын да аңлап бетермәде шикелле. Карчыгының аптыраулы бичара бер кыяфәтен күреп, ата кеше аны үз янына утыртты да аңлаешлырак итеп төшендерергә керешә:

—Ходаем теләкләребезне кире какмаган, карчык, Зиннурыбыз Төмәндә генә ята икән бит. Инде менә яңадан фронтка жибәрәләр икән үзен...

Бер секунд эчендә Нурияның башыннан мең төрле уй үтте. Ни генә булмасын, ул барырга, Зиннурын күреп калырга тиеш! Кискен карарга килеп, картларга күтәрелеп карады:

—Мин юлга чыгам. Бәлки, күреп калырга өлгерермен.

Нурияне инде үзләренең кызлары итеп саный башлаган картлар, шатланышып, аркасыннан сөйделәр. Тиз-тиз генә улларына җибәрергә төенчек төйни башладылар.

Мең газаплар белән госпитальгә килеп җиткәндә, Зиннуры анда юк иде инде.

—Бер сәгать чамасы элек вокзалга китте. Ул ике ай буе сине чакырып хатлар язды. Нишләп алданрак килмәден?—диделәр.

Нуриянең озак сөйләшеп, хәлне аңлатып торырга вакыты юк иде, вокзалга чапты. Ул анда барып җиткәндә:

—Гражданнар, сак булыгыз. Беренче юлдан хәрби эшелон кузгалып китә. Гражданнар, таптала күрмәгез!—дип игълан иттеләр.

Нуриянең бугазына утлы төер тыгылды. Соңгы өметләре дә өзелеп, аяк буыннарының хәле киткәндәй, калтырана башлады. «Шунда хәтле килеп, бер минутка булса да күрмичә кал инде...» Кайнар яшьләре күз алларын томалады. Нәкъ шул вакыт аңа әллә кайдан гына үз исеме ишетелгәндәй тоелды. Борылып караса, әкрен генә барган поездан сикереп төшкән Зиннуры туп-туры аңа таба йөгерә иде.

—Нурия, Нуриям!—диде ул, кызны кочагына кысып.

Уйланып торырга вакыт юк иде. Поезд тизлеген арттыра да башлады. Зиннур тәвәккәлләде:

—Акыллым, әйдә, Затлыторага кадәр генә булса да бергә барырбыз!—дип, кызны кулына ук күтәреп алды. Киң ишеге шар ачык товар вагонына аяк басуына, ике солдат аңа ярдәмгә килде. Кемдер:

—Иптәшләр, лейтенант хатынына булышыгыз әле!—дип кычкырды.

Әлләничә кул Нурияне, аннан соң Зиннурның үзен дә тартып менгезде. Солдатлар аларны ялгызларын гына калдырырга тырышып, бер-берсенә ишарә ясадылар. Нурия күз яшеннән арынып, бер юньле сүз дә әйтә алмады. Ул сөйгәненең күкрәгенә йөзен яшергән дә, бер дә вакытсыз жебеп төшкән борынын тарткалап тора бирде. Шуны бөтен күңеле белән тойды кыз: сөйгәне кочагында аңа чиксез рәхәт иде, торасы да торасы шулай! Алар бер-берсенә карап туймадылар. Иң кирәкле, әллә кайчан әзерләп куелган сүзләр онытылды. Хәер, болай да аңлашыла кебек иде. Очрашу куанычы бик тиздән бетеп, аерылышырга кирәк булуын тою икесен дә аңлатып бирә алмаслык бер халәткә салган иде. Болай озак торырга ярамый, тел очында гына торган сүзләрне әйтеп калырга, аерылышкач үкенечкә калдырмаслык итәргә кирәк. Бераздан Зиннур телгә килде:

—Нурия, мин сине ике ай көттем. Соңгы минутта гына ничек килеп ирештең? Ничек яшисез? Әткәй-әнкәй исәннәрме? Синекеләр ни хәлдә?—дип тезеп китте ул бөтен сорауларын берьюлы. Гүя үзен борчыган сорауларына җавап алырга өлгермәүдән курка иде. Ул йотардай булып кызның күзләренә караган, үзе аның чәчләреннән сыйпый, үз күзләренә үзе ышанмагандай, куллары белән Нуриясенең яшьләрен сөртә, янакларыннан сөя иде. Кыз үзен чиксез бәхетле итеп тойды, язмышына куанып бетә алмас бер халәт кичерә иде бу минутларда.

—Барысы да әлегә исәннәр, Зиннур. Сиңа алардан күп сәлам. Тиздән кайтуыңны көтәләр. Яраларың ничек? Монда кадәр житкәч, бер көнгә генә булса да кайтырга җай чыкмадымыни соң?

—Юк, акыллым, мин әле сине күреп китүемә дә ышанып бетә алмыйм. Көннәр буе сезне уйлап, төннәр буе синең исемең белән саташып чыктым бит. Менә бүген күрешкән кебек, сугышны бетереп тә күрешергә насыйп булса икән!

Сугышның уен эш түгел икәнен егет инде белә иде. Чыннан да, тагын күрешү насыйп булырмы, юкмы? Әнә бит үзе дә беренче бәрелештә үк яраланды, дусты Константинов ятып калды... Бер минутка гына монсуланган егет тагын фани дөньяга кайткандай булды. Ләкин үзенең кичерешләрен кызга сиздермәскә тырышты. Сүзне икенче якка борды:

—Авылда ир-егетләрдән кемнәр калды соң? Сезгә дә бөтен колхоз

эшләрен үз жилкәгездә тарту жинел түгелдер бит?—Зиннур кызның кытыршыланып калган кулларын сыйпады, йомшак кына тотып, йөрәге өстенә куйды.

—Яше тулган бөтен ир-егетләр сугышта хәзер. Авыл мәет чыккан йортка охшап калды. Мәктәптә балаларның көлешкәне дә ишетелми. Күбесе укуларын ташлады, өлкән сыйныфтагылар колхозда эшли. Хәйрүш кенә, сез киткәч, рәхәтләнеп калды. Колхозчыларны эт кебек талап ята. Солдаткаларны, яшь кызларны аяктан екканчы эшләтә. Фронт өчен, жиңү өчен үзебез дә хәлдән килгән кадәр тырышабыз...

Хәйрүш исемен ишеткәч, Зиннурның бөтен тәсе бозылды. Теге чакта судка бирмичә калдырганы өчен үкенеп тә куйды. Алай итсә, бәлки бер сабак булган булыр иде, кулы, теле кыскарыр иде.

—Әллә ул адәм актыгы фронтка китмәдеме? Һаман да авылдашларының канын эчәме?

—Колхоз рәисе булгач, мактау тактасыннан төшми. Авыл хатыннары жаннары чыкканчы эшли, ә ул мактау ишетә. Бронь белән калдырганнар, имеш, аны. Район тулы аның әшнәләре бит.

—Нурия жаным, син, зинһар, аның белән сак бул. Иң борчылганым да син бит. Күз алдында ялгызың йөрмә, аның хәйләләрен, мәкерен беләбез. Юхаланып, йөрәгенә үтеп керә күрмәсен.—Ут эченә китеп баручы егет инде үзен һәр сәгатьтә көтеп торган дошманны уйламый, ә сөйгәненең һәр адымын күзәтеп торучы, үзенә жай чыкканга сөенеп бетә алмаган дошманын гына уйлый ала иде. Эх, канаты булсамы? Кайтып, өзгәләп ташлап, Нуриясенә күтәрелеп тә карамаслык итәр иде.

Поезд Затлыторага якынлашып та килә. Сузып-сузып паровоз кычкыртты. Бермәлгә икесе дә башлаган сүзләрен өзеп, тынып калдылар. Тагын беренче булып Зиннур телгә килде:

—Нурия, вакыт житә. Акыллым, мин сина ышанам. Син көт кенә, мин барыбер кайтырмын. Баргач ук хат язармын. Барысына да миннән сәлам житкер. Үзеңне сакла,—диде, сүзләрен бер-берсенә ялгый-ялгый. Күкрәгенә кысып, сөйгәнен иреннәреннән үпте.

Әле генә очрашу бәхетеннән күз яшьләре түккән кыз аерылу сагышыннан үкси иде. Сөйгәне аны юатырга тырышты:

—Инде күрештек, тынычлан, акыллым. Әгәр килеп тә күрешә алмасак, үкенечле буласы иде. Мин дә, син дә исән-сау. Аллам боерган булса, тагын исән-аман күрешербез.—Үзе сөйләде, үзе сөеклесенең бит алмаларыннан, күзләреннән үпте. Соңгы минутларда гына әллә кайчан әзерләп куйган бүләкләрен исенә төшерде. Юл капчыгыннан бер төргәкне тартып чыгарды. Кечкенә генә сәгатьне алып, кызның беләгенә такты. Зиннурның төргәгендә үзенең һәм Нуриянең әти-әниләренә дип алган чәчәкле яулыклар, кытай чәе бар иде. Зәңгәрсу жирлеккә матур-матур чәчәкләр төшкән ефәк күлмәкне ул туй бүләге итеп әзерләгән иде.

—Сагынганда киярсең, нәкъ синең күзләрең төсле,—диде.

Нурия дә, хәзер генә исенә килгән кеше кебек, кабалана-кабалана эчке кесәләреннән яран рәсеме чигелгән кульяулыгын алып, аңа сузды, әнкәсе бүләк иткән балдагын салып, Зиннурының бармагына киертте. Егет үзен иң бәхетле кеше итеп тойды: «Эх, тыныч чаклар булып, бүген аларның кавышу көне булса икән!» Фронтка китеп баручы солдатларның тавышы бер минутка гына тынып тормаса да, алар бу минутларда үзләреннән башка дөнья булуын тоймадылар, ишетмәделәр.

Поезд озак тукталып тормады. Мышный-мышный әкренәйгән паровоз бик авырсынып пышкылдый-пышкылдый, товар вагоннарын сөйрәп, урыныннан да кузгалды. Зиннур вагон ишегеннән башын сузып, кул болгап, ераклаша барды. Көнбатышка таба жилдергән поездның тәгәрмәчләре такыйтакый килеп, тизлеге арткан-нан-артты. Зәңгәр яулык, күзләрдән яшь китерерлек кадерле яулык, жилферди-жилферди, күздән югалды. Бөтен дөнья шыксыз, ятим булып калды...

## ЯКТЫ МОҢНАР ИЯСЕ

*Минем туган ягымда—Мөслим районының Башкортстан белән чиктәш җирендә гаҗәеп соклангыч, бай табигатькә сыенып утырган Баек авылы бар. Байтак вакытлар әлеге Баек та, безнең авыл да күрше-тирәдәге бүтән авыллар белән бергә бер колхоз тәшкил итеп яшәделәр. Шуңа күрә Баек халкын беркадәр беләм, аның кайбер сыйфатлары миңа таныш. Бераз кайнаррак, ләкин киң күңелле һәм олы җанлы, өлгер-эшчән һәм бер үк вакытта күңелләрендә нечкә моң йөрткән кешеләр яши анда. Менә шушы кайнарлык, тирән моң кайчан да булса бер ни рәвешледер түгелергә тиеш иде, ул гомергә эчкә йомылып, күмелеп кала алмый иде. Һәм ул чыннан да түгелде... Танылган шагыйрәбез Шәмсия Җиһангирова иҗатына килеп орынсам, аның җырларын тыңласам, шул хакта уйланам.*

*Аның иҗатын Шәмсия Гарипова чагыннан—Мөслимдә чыга торган «Авыл утлары» газетасында басылган беренче шигырьләреннән үк беләм, « бу бәллүр храмны ялгыш җимермәм микән» дигән сыман сагаеп-сакланып кына шигърияткә килеп кергән чакларын хәтерлим. Шул кыюсыз беренче адымнарында ук ниндидер бүтәннәргә охшамаган яктылык, җылылык, ихласлык бар иде Шәмсиянең. Республика матбугатында басыла башлагач, аның иҗаты турында өлкән әдипләребезнең җылы-җылы гына сүзләре әйтелде, әдәби җәмәгатьчелек аны шагыйрә буларак таныган, кабул иткән иде инде. Әмма...*

*Нәшриятта эшли башлагач, миңа Рәис абый Даутов белән бер бүлмәдә утырырга туры килде. Шул чорда аңа бер кульязма редакцияләүне тапшырдылар. «Яшел гармун» исемле повесть. Авторы—Шәмсия Җиһангирова. Әлеге повестьны мин редакцияләү барышында ук укып чыктым һәм ул барыбыз өчен дә көтелмәгән ачыш булды. Чәчмә әсәрләр язарга да кулы ята икән ләбаса Шәмсиянең! Проза белән язылган шигырь кебек тоелды миңа ул повесть. Дөрес, Шәмсия бүтән бастырмады прозаны, шулай да «Яшел гармун»—аның бу жанрдагы соңгы әсәредер дип уйламыйм. Күргәннәре-кичергәннәре, тормышындагы борылыш-сикәлтәләр шигырьләргә-җырларга гына сыеп бетмәстер, алар әлегә авторның җанында җылынып-бөреләнеп ята торганнардыр, мөгаен.*

*Еллар узган саен гаҗәпләндерүдән туктамады Шәмсия. Көтмәгәндә ул матур-матур җырлар авторы буларак ачылып китте. Хәзер аның сүзләренә язылган җыр яңгырамаган концерт булмый да торгандыр. Тышкы яктан гади генә тоелган, әмма эчтәлеге белән тирән мәгънәгә ия булган, халыкның күп кырлы күңел тибрәнешләрен сыйдырган бу җырларны тиз арада үз иттеләр, яратып өлгерделәр. Җырчылар да һәм җыр яратучылар да. Безнең бу катлаулы-кырыс, рәхимсез заманда шулай җанга шифа булып ятуларының сере бардыр аларның: тирәннән, күңел түреннән, бәгырьдән сыгылып чыгып тамганнардыр ул җырлар, чәчәк таҗларына тамган энҗе чык бөртекләре шикелле...*

*Эзләнүдән, иҗат дәрте белән янудан туктап тормый Шәмсия Җиһангирова. Әле аның балалар өчен язылган, һәрберсе үзенә күрә бер сер сандыгын хәтерләткән матур-матур шигырьләре барлыгын да укучылар онытмаганнардыр дип беләм. Шуның өстенә ул Татарстан радиосында редактор буларак та тыңлаучы күңеленә үз сукмагын салды, бәйрәм булырдай тапшырулар бүләк итте.*

*Кыскасы, сүземнең башында искә алган Баек авылы кешеләренең, мөслимәләрнең күңел матурлыгын, җан җылысын халкыбызның уртак рухи байлыгына куша алды Шәмсия Җиһангирова. Шуның белән бәхетледер дә ул. Яңадан-яңа иҗат уңышлары, сүрелмәс илһам шулай гомерлек юлдаш булсын аңа.*

**Харрас ӘЮП**



## Шәмсия Җиһангирова

### ИДЕЛЕМӘ ТӨШЕП СУЛАР АЛАМ

**«Син түзәсең»,—димәгез лә,**
**Килми түзәселәрем.**
**Килә шатлык диңгезләрен**
**Иңләп йөзәселәрем.**
**Килә барып сыенасым**
**Иңнәренә ир-атның.**
**Түзә-түзә хатын-кызлык**
**Горефләрен югалттым.**
**Көнләшмәгез: ир-ат кебек**
**Җиңә, дип, авыр эшне.—**
**Хатын-кыз ул көчсез була**
**Алганы өчен көчле.**
**Сөйләп йөрмәгез кешегә:**
**«Ул бит бераз юләр», дип,**
**«Еламас җирдә дә елар,**
**Көлмәс җирдә көләр», дип.**
**Аптырамагыз сүземнең**
**Онытылса азагы,—**
**Сез белгәне агы гына,**
**Җанда барлык газабы...**
**Күргән төшләрем сөйләсәм,**
**Начарга юрамагыз.**
**...Авыр булмасын дисәгез—**
**Хәлемне сорамагыз...**

Моңа кадәр белмәгәнмен генә—
Төннәр о-о-з-з-ы-ы-н икән.
Шатлык белән кайгы арасы да
Бер кул сузым икән.
Белмәгәнмен: мамык юрганның да
Җылысы юк икән.
Ялгызларның сабыр коелары
Тум-тулы ук икән.
Гел елыйсы гына килеп тора
Кич тә иртән икән...
Җаның саклап сине бер чеметем
Өмет йөртә икән.
Кешеләрнең яхшы сүзләре дә
Җанга агу икән.
...Иң читене—гомер уртасында
Ялгыз калу икән...

Иң кайгылы чакларымда
Сыендым барып сиңа.
Беркем аңламаганда да
Аңладың мине. Шуңа:

Кайгылы чакларың булса,
Үземә кил—күтәрмен;
Кайгыларыңның барысын
Үземнеке итәрмен.

Йөз чөермәм—бөтен кеше
Синнән йөз чөерсә дә,
Мәхәббәтеңнән җаныма
Сагышлар бөялсә дә.

Ышан миңа—үз-үзеңә
Ышанмаслык булсаң да.
Яратырмын сине—тоташ
Кайгылардан торсаң да...

Бар исемнәр арасында
Исемең тансык булыр.
Көннең кайсында килсәң дә,
Ишегем ачык булыр.

Сине көткәндә һәрвакыт
Күзләрем дүртәү булыр.
Башкаем ялгыз булса да,
Мендәрем икәү булыр...

Эшең күп шул—
Тын алырга
Вакытың тардыр кебек.
Ә мин сагыш тәлгәшемне
Китердем сиңа өзеп.
Китердем дә—
Күтеп торам
Миңа күз салганыңны,
Тәлгәшемнең бер бөртеген
Үрелеп алганыңны...

Сикереп кенә атланыр да идең...
Атлары шул ап-ак бүз түгел.—
Кем беләндер бергә булу әле
Ялгыз булмау дигән сүз түгел...

Булса булсын атның тик акбүзе—
Башка атлар безгә үз түгел...
Кем беләндер бергә булмау әле
Ялгыз булу дигән сүз түгел...

Чыгыйк та без япан кырларга,
Тергезик икәүләп бер учак.—
Кайгырма, ягарбыз кайгыны—
Миндә бит Шатлыклар бер бөртек,
Кайгылар бер кочак... мең кочак...

Китик тә исемсез илләргә,
Тергезик икәүләп бер шәһәр.—
Миндә бит бер бөртек Шатлык бар—
Нигезгә салырга шул җитәр...

Меник тә иң биек тауларга,
—Кил!—диеп дәшик без Бәхеткә...
Тормышта аерым булсак та,
Салырбыз башны бер ләхеткә...

Аһ!
Ник икән адәми затларга
Акыллар кирә би-и-и-ик соңарып?!—
Юк шул ул безгә тиң юлдашлар,
Исемсез юлларга чыгарлык!..

Иделемә төшеп сулар алам,
Иделләрдән чиста сулар юк.
Җан сөйгәнне көтеп яшим һаман,
Күңелемдә башка уйлар юк.

Иделкәйнең биек ярларында
Карлыгачлар гына оясы.
Язмышлардан узмыш булмаса да,
Җан сөйгәнне килми җуясы.

Иделемә карап хәйран калам,—
Кайгыданмы суы болганган.
Язмышлардан узмыш булса булыр,
Мин барыбер сиңа булалмам.

## Мөслимдә сабантуйда

Томырылып килә чабышкылар,
Тоякта—ут, күзләрендә—ярсу!
Мин дә кайныйм кеше диңгезендә.
Кычкырышам: «Әйдә, әйдә, Мансу-у-ррр!»

Кайсы җайдак исемедер. Белмим.
Тик барыбер дәшәм өзелеп-өзелеп,
Җайдаккамы, әллә хыялгамы:
—Әйдә, Мансур! Әйдә! Әйдә!—диеп.

Аптырашып тора ят агайлар
Алар белән бергә кычкырганга.
...Күпме генә өзелеп сөрән салма,
Мин чакырган кеше юк шул анда.

«Әйдә, Мансур!»—диеп, мин шул аңа
Хыялымда гына дәшә алам...
Сабантуйда кычкырсаң да килешә.—
...Барыбер ишеттерми гөжле мәйдан...

## ЯМЬ ҺӘМ ГАМЬ

*Сәйдә Зыяның беренче шигырьләрендә үк туган як табигатенә, кешеләрнең үзара эчкерсез мөнәсәбәтенә, аларның бәхетенә сөенеп соклануы аермачык сизелә иде. Иҗатының башлангыч әсәрләрендә үк ул укучыларын:*



*— Әйдәгез, бер-беребезгә игелек кылып яшик, тормыш юлыннан җитәкләшеп узыйк, матурлыкны аңлыйк, - дип чакыра иде, әйе, шигырьләренең мәгънәви юнәлеше шушы иде.*

*Сиксәненче елларда Сәйдә Зыя (ул 1941 елда хәзерге Теләче районының эшчән һәм үзә-кырыс холыклы кешеләре белән танылган һәм бай табигатьле Шәтке авылында туган) чәчмә әсәрләр дә яза башлады. Аның «Кайнар сукмаклар», «Кар карасы» исемле повестьларында, шулай ук хикәяләрендә шигырьләренә хас лейтмотив—тормыш яме мәсьәләсе үзәктә тора. Менә «Сыну» дигән хикәясе. Мондагы вакыйга «мәхәббәт өчпочмагы»ннан тора, әмма ул - сирәк очрый торган «өчпочмак». Апалы-сеңелле Халисә һәм Сәвия, алар арасында—Габделнур. Сәвия белән Габделнурның яратышуларын белгәч, бу мәхәббәтнең ныклыгына ышанып, Халисә аларга карышмыйча юл куя. Ләкин сеңлесе Сәвиянең акылы умырткасыз икән, Габделнур авыргач, ул аны ташлап китә. Алай гынамы соң— апасына Габделнур янына кире кайтырга куша. Әйе, тормыш ямен Сәвия кебек аңлаучылар да бар, алар, хәтта хыянәткә барып, тормыштан, кем әйтмешли, барысын да (яхшысын) алып калырга тырышалар. Ә шулай да Халисә кебек олы җанлы кешеләр генә яшәешне ямьгә бизиләр.*

*С. Зыяның «Ике Әнисә, бер Мәхмүт», «Язгы салкыннар», «Ике дөнья арасы», «Юл читендә» исемле хикәяләрендә дә әлеге лейтмотив анык сизелә. «Каеннар да кара бизәкле» дигән хикәядә инде халкыбызның матур итеп яшәвен пычратырга-җимерергә теләү чукындыру сәясәтен кешеләр язмышында сурәтләүдә чагыла. Язучының балалар өчен язылган һәм юмористик хикәяләре дә шактый, алары да шул очтан.*

*... Инеш буендагы чирәмлеккә йөге белән чүп китереп бушатканнар...*

*Журнал укучыбыз игътибарына түбәндә тәкъдим ителгән хикәянең башындарак шундый деталь бар. Язучының бу хәлне алдан искәртеп куюы нигә кирәк булды икән? Хикәяләү барышында чүп өеменә кире кайтылмый ич, автор безне эзлекле рәвештә Булатның балык тотарга әвәслеген тасвирлап кызыктыра кебек. Алай гына түгел икән шул - чирәмлектәге чүп өеме детале безне күл-елга төбендәге чүп-чар тавына алып төшә /!/ икән... Бу кадәресе, тормышны ямьсезләндерүчеләрне һәм ямьләндерүчеләрне укучыга чагыштырып күрсәтү өстенә, язучының әдәби осталыгы үсә баруына да дәлил.*

*Уңышлар телим сиңа, Сәйдә сеңелкәй!*

*Гамьле булуың иҗатыңны ямьләндерә синең!*

Мәгъсум ХУЖИН

## Сәйдә Зыя

# БУЛАТ ҺӘМ КЫЗЫЛ КАНАТ

хикәя

Бабасы, көндәлек гадәти эшне искәрткән кебек кенә:
—Булат, улым, иртәгә күлгә барырбыз,—диде.

Сабыр гына әйтелгән бу сүзләр Булатның иңнәренә канатлар үстергәндәй булды, ул хәзер очып кына йөри шикелле. Әбисенең: «Каз бәбкәләрен ашатыр вакыт житте бугай»,—дип үзалдына сөйләнүен ишетүгә, тураган ипи салынган иске табакны алып инеш буена йөгерде.

Анда ерак барасы түгел: аларның бакча башы ярга терәлеп тора. Яр буенда—яшел чирәмлек. Әбисе иртүк казларны шушында китерә. Казлар кангылдаша, бәбкәләр пип-пип дип аларга кушыла. И, сөенешәләр инде! Су салкын түгел микән, дигәндәй берсен-берсе уздыра-уздыра пипелдәшәләр. Шулай «сөйләшә-сөйләшә» ярдан тәгәрәшәләр. Суга кергәч, бергә жыйналып, тагын бер тапкыр гәпләшеп алалар. Аннары чумып-чумып уйныйлар. Су коенып чыккач, томшыклары белән каурыйларын рәтләргә керешәләр.

Бүген яр буена килеп житәр-житмәс үк Булат туктап калды. Аның исе-акылы китте: чирәмлек өстенә кемдер бер ат йөге чүп түгеп киткән иде. Анда нәрсә генә юк: каз оясының мамыклы саламы, түбән өйдән чыгарылган черек бәрәңгеле балчык, ишегалдыннан себереп алган чүп-чар... Чүпнең беразы яр астына ишелгән, беразы чирәмлеккә таралган. Кылт итеп бабасының сүзләре исенә төште.

—Су буена юньле кеше чүп түкми! Суны пычратырга ярамый,—ди ул.—Үз ишегаллары чиста булса да, андыйлар шапшак, пычрак. Үзе чүп түккән суны ук эчә бит ул! Шунда коена!

Мондагы хәлне кайтып бабасына әйтсә, аның кәефе кырылачак инде. Ярар, әйтми торыр. Әнә, бәбкәләр дә чирәмне чүп-чардан читкәрәк китеп ашый.

Ачуы чыккан ата каз ысылдап килә тагын. Муенын сузган, күзләре кызарган. Әйтерсең, аңа Булат берәр яманлык кылган!

—Килеп кенә кара! Менә сиңа...

Сыгылмалы нечкә тал чыбыгы борыны төбендә үк уйнап торгач, ата каз «көч кулланырга» базмады, муенын сузып Булатка таба килгән жиреннән ана каз ягына борылды. Бүксәсен киереп бара-бара туктаусыз сөйләнә тагын үзе:

—Га-га-га-га...

Чыбыктан шүрләвен ана казга белдерәсе килмәгәне әллә каян аңлашылып тора. «Хужа малае бит. Чыбык күтәрмәсә дә тими идем мин аңа»,—дип аклануы да аермачык сизелә.

Ата казның бу кыланышына исе дә китмәде Булатның. Иртәгә күлгә барасы булгач, өйдәге эшләрне тизрәк бетерергә, бабасына ярдәм итәргә кирәк—бары шул гына. Күлгә уптым-ордым гына чыгып китеп булмый ул. Кирәк-яракны алдан барлап-хәстәрләп куясы.

...Акъяр авылы янында күл бар. Бик борынгы заманнарда ук, урман янәшәсендәге басуны урталай бүлеп, тирән елга барлыкка килгән. Бик тирән ул, аның төбенә төшәргә дә куркыныч булган. Әллә шуңа инде, халык аны «Аю елгасы» дип атаган. Кем белә, бәлки, шул тирәдә аюлар да яшәгәндер... Урман эчендә типкән көмеш чишмәләрнең суы шушы елгага агып төшкән.

Авыл агайлары, шул елганы бөяп, маймычлар җибәргәннәр. Хәзер андагы сазан, кызыл канат, алабуга, кәрәкә балыкларының исәбе-хисабы юк. Балыкчылар да әллә-ә-ә кайлардан килә. Алла кушса, иртәгә бабасы белән Булат та «Аю»га (күл исемен кыскартып, шулай да атыйлар) барачак.

Оныгының куанып өй эшләренә ярдәм итеп йөрүен мыек астыннан гына күзәткән бабасы, әнә, балыкка бару әзерлегенә керешә дә инде. Иң элек кармакларны барлады—калкавычлар көйлеме, җепләре өзелмәгәнме, кармаклар очлымы... Әйе инде, Булат та бабасы янында кайнашты.

—Улым,—диде бабасы,—Нәбиулла абыең янына барып кайт әле.

—Нәрсәгә?

—«Аю»га куна барырга сөйләшкән идек. Әзерләнсен. Аннары ферма артындагы тиреслектән кызыл суалчан казырсың.

—Ур-ра!

Нәбиуллалар Казанда яшиләр. Җәйне Акъярда үткәрәләр. Монда аларның бакчалары бар. Нәбиулла абыйсы да нәкъ инде Булатның бабасы кебек, балыкка, дисән, дөньясын оныта. Менә бәхет! Иртәгә «Аю»га өчәүләп куна барачаклар.

Булатның аяклары җиргә тимәде дә, Нәбиулла абыйларының бакчасына очып диярлек килеп керде.

—Нәбиулла абый!—диде дә сулышы кабып туктап калды ул.

Суган түтәлләре чүбен утаучы Нәбиулла абыйсы балкып күтәрелде.

—О-о, Булат! Кура җиләге белән сыйлыйм әле үзенне. Әйдә әле.

Башына иске салам эшләпә кигән, кыска җинле ак күлмәген җилбәгәй җибәргән Нәбиулла абыйсы куралык ягына бара башлады. Башка вакыт булсамы! Башка вакытта чиләге белән ашар иде лә Булат кура җиләген! Шикәр белән болгатып ашар иде. Бүген булмый. Бүген Булатның вакыты тар, җиләк кайгысы юк бүген! Иртәгә балыкка барасы бит!

—Нәбиулла абый, ни...—дип тирләп чыккан маңгаен кул аркасы белән сөртте ул.—Бабай әйтте, иртәгә «Аю»га барабыз, диде. Куначa барабыз, диде.

—Һай, рәхмәт төшкере! Мондый күңелле хәбәр китергәнең өчен, җиләксез җибәрмим инде сине, үзем җыеп бирәм.

—Ашыгам ич мин, әле эшем күп. Кызыл суалчан казыйсым бар. Син суалчан җыеп торма, Нәбиулла абый, яме.

Икенче көнне төш авышкач, Булатның Кәрим җизнәсе «КамАЗ»ы белән аларны күл буена илтеп куйды. Биш чакрымны җәяүләве бабайларга авыр ич. Әйбәт тә инде аның Кәрим җизнәсе. Нинди гозерең булса да, тынлый. Рәхмәт яугыры.

Машинага төялгән кирәк-яракны тиз бушаттылар. Иң элек кармакларны җиргә алып куйдылар. Бабасының үзенә генә дә алты кармак! Вак балыклар өчен кечкенәләре һәм кыска саплылары, эреләренә—дәп-дәүләре. Балык шулпасы пешерер өчен чиләк, ипи, тоз, бәрәңге, суган салынган кәстрүл, чәйнек... Нәбиулла абыйсының резин көймәсе һәм ишкәкләр... Иң соңыннан утын бушатылды. Төнгә алар учак ягачак.

Һәркайсы эшкә керешә. Нәбиулла абыйсы көймәгә тын тутыра башлады. Шушы резин көймә Булатның күңелен күптән кытыклый инде. Күлнең иң тирән төшенә ярдан кармак салып булмый, зур балык исә тирәндә ятерепеп ята. Сай суда күмелми дә ич ул. Боларны гына Булат белә. Нәбиулла абыйсы рөхсәт итсә, бүген ул да көймәгә утырыр иде.

—Нәбиулла абый, көймә ничә кешене күтәрә?

Нәбиулла абыйсы пешкәккә баса-баса елмайды, шаян күзләре кысылды. Үзенең дә, Булатның да ябык һәм кечкенә гәүдәле булуларына ишарәләп:

—Безне күтәрә! Икебез бергә биш пот та тартмый торганбыз,—дип көлде.

—Мин дә синең белән көймәгә утырыр идем...

—Көймәдән балык каптырасың килә инде алайса.

—Әйе.

—Бабаң рөхсәт итсә, әйдә.

Булатның бабасы яр буена чүгәләгән иде инде. Як-ягына кармакларын тезеп куйган да күзләре белән әле бер калкавычка, әле икенчесенә текәлә. Әнә, теге озын саплы кармакны борчак белән салды. Аның янәшәсендәге ике кармакка суалчан кидергән, тирәнлекләре төрлечә. Уң ягында тагын ике кармак тора. Аның берсендә—чикерткә, икенчесендә—камыр. Калкавычларның әле берсе, әле икенчесе «пелт» итеп батып ала. Бабасының куллары уйнап кына тора. Балык тотканда яшәреп китә ул, маңгай җыерчыклары тарала, йөзенә алсулык йөгерә. Дөньяда шушы калкавычлар да, Булатның бабасы гына калган бугай...

Ул арада суалчанлы кармакның калкавычы сузылып сугаятты. Бабасы кармак сабын ипләп кенә тартып куйды да балыкны ярга таба өстери башлады. Бабасы туры тарта, балык читкә каера. Ниһаять, кармак сабын күтәреп җибәргән иде, канатларын киереп, зур гына алабуга килеп тә чыкты.

—О-о! Ярты кило бар инде бу, әйеме, бабай?

—Шулаймы, улым? Чиләккә су ал да шунда җибәр. Йөзсен.

Кинәт кенә борчаклы кармакның да калкавычы селкенгәләде.

—Вак балыктыр,—диде бабасы.—Эре балык хоп итеп каба да йота кармакны.

—Бабай, мин Нәбиулла абый белән көймәгә утырыйм әле.

—Курыкмыйсыңмы соң?

—Юк, бабай! Нәбиулла абый әйтә, бишәр потлы ике кеше утыра ала, ди.

—Һе. Алайса бар инде. Түлке ярдан ераклашмагыз. Күл тирән. Астан салкын чишмәләр тибә.

Нәбиулла абыйсы көймәгә башта Булатны утыртты. Аннары кармакларны, чиләкне, суалчан савытын куйды. Әкрен генә йөзеп киттеләр. Су өсте тып-тын, тип-тигез. Кояш нурларында җем-җем итеп күзләрне камаштыра.

—Кайсы урынга туктыйбыз?—диде Нәбиулла абыйсы.

—Ә-ә-нә, теге яктагы текә яр буенда,—дип бармагы белән төртеп күрсәтте Булат.

Яры текә һәм биек, көймә белән генә тотарлык анда. Көймәне текә ярга яны белән куйдылар да ике башка ике якорь төшерделәр. Утыргычларына атланып утырдылар. Булатның йөрәге сикерүгә чикчама юк! Су төбендәге исәпсез күп балыклар аның кармак салуын көтеп кенә торалардыр...

Салды Булат кармагын. Каурый калкавычтан су өстенә дулкынчыклар таралды. Бераздан ул «пелт» итеп суга чумып та алды. Тагын тынды. Тагын чумды. Булат түзмәде, кармак сабын кинәт кенә күтәрде һәм текә ярга шап итеп балык бәрелде. Әйбәтләп эләгеп житмәгәндер шул, кармактан ычкынган балык ипле генә итеп суга чумды.

—Их-х, ычкынды...

—Алай кинәт тартма син кармак сабынны,—дип киңәш итте Нәбиулла абыйсы.—Кинәт тартканда балыкның ирене ертыла.

Нәбиулла абыйсы сала да ала, сала да ала. Чүпли генә балыкны. Яна суалчан кидереп, Булат кармагын тагын салды. Калкавычтан күзен дә алмый. Әмма калкавыч тик тора, бөтенләй селкенми. Шактый утыргач, әллә суалчанын алыштырыйм микән, дип савытка үрелгән генә иде, калкавыч—полт!

—Тарт, тарт!—дип пышылдады Нәбиулла абыйсы.

Тарта инде Булат. Ике куллап тарта кармак сабын. Әмма каптырган балыгы бирешми. Тартыша торгач, балык көймәгә якынлашты. Нибары бер метр чамасы ара калгандыр. Булат аның каракучкыл башын, түгәрәк күзләрен күрде. Башы, билләһи, Нәбиулла абыйсының куш йодрыгы

хәтле бар иде... Их, бер унмасаң, гел унмыйсың шул, инде ялтырап килеп чыга, дигәндә... шырт—өзелде кармак җебе! Китте балык! Тагын китте... Балык артыннан үзе чумарлык булды Булат. Нинди зур иде бит! Эләккән иде бит!..

Кечкенәрәк балыкларны әллә ничәне тотты инде Булат. Әмма теге зур балык күнеленнән һаман китмәде, үкенү йөрәген тырнап торды. Тын гына уйланып утыргач:

—Минем кармакны өзеп качкан балык үләр микән инде, Нәбиулла абый?—дип сорады ул.

—Белмим шул.

—Үлсә, җәл инде. Үлмәсен иде...

Егермеләп балык тоткач, Булат көймәнең алгы өлешенә башын куеп, аякларын янга сузды. Резин көймә мендәр кебек, ятар өчен җайлы икән. Нәбиулла абыйсы кармагын ыргыткан саен көймә чайкалып китә дә әкрен генә тирбәлә. Булат шул тирбәлүнең ләззәтен тоеп, изрәп ята.

* * *

Борыннарны кытыклый-кытыклый төн кочагына балык шулпасы исе таралды. Зур ашъяулык өстенә тәлинкәләр-кашыклар тезелде. Ипи уртадан урын алды. Их-х, ул шулпаның тәме! Булатның бу тиклем тәмле шулпа ашаганы юк иде әле.

Булат, тамагы туйгач, учактан читтәрәк җәелгән бишмәте өстенә сузылып ятты. Бабасы:

—Улым, кабинага кереп ят, анда җайлырак та, җылырак та булыр,— дигән иде дә Булат монда каласы итте.

Төнге салмак җил чәчләрне сыйпап иркәли. Җилнең кая юл тотуын күреп калырга теләгәндәй, учак ялкыннары әле сузылып өскә күтәрелә, әле як-якка авыша.

Булат чалкан ятты да күккә карады. Йолдызлар, йолдызлар... Алар бер-берләренә күз кысышалар. Бер йолдыз, әнә, башкалардан аерыла да, каядыр атыла. Булат күзләрен кыса. Алтынсу төстәге ерак йолдыз нуры Булатның күзләрен кытыклый. Аның күзләре әле бер, әле икенче йолдызның нурлары белән тоташа. Шушы нурлар буйлап йөгереп йолдызга менсәң иде...

Тирә-юньь төннең караңгы юрганын ябынган. Бабасы, Нәбиулла абыйсы, Кәрим җизнәсе әкрен генә гәпләшәләр. Булат күзләрен йома. Күз алдында—тирән су, каурый калкавыч. Ул шул калкавычка карап ята. Бераздан калкавыч зәңгәр төскә керә, аннары яшелләнә...

Кармакны өзеп качкан теге балык Булатның йокыга китүен генә көтеп торган икән, килеп тә житкән! Зу-ур кызыл канат икән ул. Өске иренендә кармак кадалган. Авырта икән, ашый алмыйча интегә икән. «Әйдә, миннән калма, йөз,—ди кызыл канат Булатка.—Мин сиңа бер әйбер күрсәтәм». Булат ышанырга да, ышанмаска да белми.

«Нәрсә күрсәтәсең?»—дип төпченеп карый. Шушы караңгыда күл төбеннән балык артыннан бару бераз шүрләтә. Шомлы монда. Озын кыяклы үләннәр куе зәңгәр төстәге дулкыннар чыгарып чайкала. Үләннәр арасыннан чишмәләрнең үксүе ишетелә. Кызыл канат алдан, аның артыннан Булат йөзә. Артта калмадыңмы, дигәндәй, балык борылгалап карап ала...

Алар шактый озак йөзделәр. Ниһаять, балык туктады.

—Күрәсеңме?—дип сорады кызыл канат.

—Нәрсәне?

—Җентекләп кара әле!

Балыкның тавышында үпкәләү катыш боеру да бар иде.

—Кая карасаң да, су гына ич монда.

—Калкулыкны капшап кара!

Түтәл актаргандай итеп, Булат калкулык итәген тырмаштыра башлады. Өзелгән кармаклар икән ич бу! Зурлары, кечкенәләре, өч җәпләләре... Нинди генә кармак юк монда!

—Безнең хастаханә чүплеге бу. Синең эше балыкчылар җәрәхәтләгән балыкларны шушында дәвалыйбыз.

Булатның исе-акылы китте: кармаклардан тыш, монда тагын буш шешәләр, консерв банкалары, төрле чүп-чар өелгән.

—Әйдә, мин сине тауга алып менәм,—диде балык.

—Нинди тау? Елга ич бу,—дип карышты Булат.

—Әйдә, әйдә...

Алар тагын йөзделәр. Кайнап торган янар тау тавышы чыгаручы куе каракучкыл томанлы урынга җиттеләр. Томан киртләч-киртләч булып күтәрелгән дә кыя рәвешенә кергән.

—Монда сасы ис килә,—дип борынын томалады Булат.

—Төтен тавы итәгендә без,—дип аңлатты кызыл канат.—Бу тау агу белән тулы. Кешеләрнең әшәкелеге, шәфкатьсезлеге җыелган урын бу. Һавадагы бар әшәкелек суга сеңә. Кара-пычрак уйларны су үзенә йота. Аннары монда кайный шул әшәкелек. Кайный-кайный да агу булып тарала.

—Сез... Сез... Шушы агуны сулап яшисезме?

—Кешеләр безне үлемгә хөкем иттеләр. Мондый агу эчендә ничек яшисең? Чишмәләрнең ничек үксүен ишеттеңме? Алар сукырайды.

—Алай булмасын, булмасын!—дип кычкырып җибәрде Булат.

—Без балыклар гына,—дип яшьле күзләрен сөртте кызыл канат.— Кешелек үзе һәлакәт алдында. Кешеләр үз агулары белән үзләре агуланачак!

—Ничек?

—Хәзер күрерсең.

Булатның күзләре кинәт әчетә башлады. Йөткертәсен китереп әллә ниткән әче нәрсә тамак төбен кытыкларга тотынды. Кульяулыгы белән борынын томалаган иде, тыны кысылды. Ярдәм сорап кычкырмакчы булды, тавышы чыкмады.

... Кычкырырга азапланып ыңгырашуыннан уянып китте Булат. Таң аткан, кояш чыккан. Чыклы чирәмнәр өстендә күлгә таба аяк эзләре сузыла. Шул эзләрдән Булат та су буена төште. Күл өстеннән аксыл пар күтәрелә. «Төтен тавы өстендәге болытлар шикелле». Булатның тәне кинәт эсселе-суыклы булды. Ул куркуыннан калтырана ук башлады.

Күп хафалы, хәвефле томан эчендә калгандай тойды ул үзен...

# КАЛӘМДӘШЕБЕЗ, КОРДАШЫБЫЗ

*Журналыбыз үзенең битләрен тугандаш әдәбиятларга, бигрәк тә шагыйрьләренә, аларның шигъри бәйләмнәренә гел юмарт, киң ача килде дип әйтә алабыз. Шул исәптән—башкорт дусларыбызга. Узган гасырда—инде шулай дип язарга да күнегергә кала!—«Дуслар җыры» һәм юбилейларына багышланган сәхифәләрдә журналны даими укучыларыбыз С. Кудаш, М. Кәрим, Н. Нәҗми, М. Гали, Ш. Биккол, Г. Рамазанов, Ф. Чанышева, Ә. Атнабаев, Р. Бикбаев һ. б. иҗаты белән яхшы ук тулы танышып барды дип уйлыйбыз. Татар шагыйрьләре дә Башкортостан—Уфа матбугатында, җөмләдән «Агыйдел» журналында әсәрләре белән күренделәр. Соңгы елларда бу иҗади дуслык китап нәшриятлары эшчәнлегендә дә чагыла: Казанда—электән татарча китаплары басылмаган Х. Гыйләҗев, Ш. Биккол, М. Гали, һәм кордашларыбыз Р. Бикбаев, К. Аралбаев, С. Әлибай, Ә. Таһирова, Ә. Әхмәтхуҗиннарның сайланма томнары дөнья күрсә («Каләмнәр туганлыгы» дип атала бу серия!), Уфада—урта буын шагыйрьләребездән Р. Фәйзуллин, Р. Миңнуллин, Г. Рәхим, Р. Харис, Р. Гаташ, Р. Мингалим, Рәш. Әхмәтҗанов һ. б. китаплары «Кардәшлек киштәсе» сериясендә башкортча дөнья күрде. Һәм бу әле дәвам итәчәк.*



*«Казан утлары»нда очрашу. Сулдан уңга: (утырганнар) Рәдиф Гаташ, Сафуан Әлибай, Равил Фәйзуллин,(арткы рәттә) Мөдәррис Әгъләм, Рашат Низамиев, .*

*Югарыда телгә алынган, татарча китабы «Язлар көтәм» исемле булган башкорт шагыйре Сафуан Әлибай—журналыбызның күптәнге дусты. Үзе дә Уфадагы башкортча басма туганыбыз—«Агыйдел»нең баш мөхәррире булган бу шагыйрь татар дөньясында шигырьләре белән дә, З. Исмәгыйлев, Р. Хәсәнов, Р. Газизов һ. б. күренекле композиторлар көй язган күпсанлы популяр җырлары («Коен», «Унсигездә кебек», «Мәхәббәт» һ. б.) белән дә таныш. Тормышта да, иҗатында да ул—халыклар, әдәбиятлар, шагыйрьләр туганлыгы илчесе, җырчысы һәм ихлас, самими, сыналган дустыбыз булып калды. 60 еллыгы белән котлап, без бу санда укучыга тәкъдим иткән шигырьләр бәйләме дә шушы сүзләрне бөтен тулылыгында раслый дип уйлыйбыз. Әйе, яңа гасырда да матур традицияләребез дәвам итсен, тарихи дуслык җыры да әүвәлгечә көчле яңгырасын иде!*



# Сафуан Әлибай

## БЕРГӘ–БЕРГӘ ИДЕЛ КИЧӘЕК

*Агыйделкәйләрне кичәек,*
*Кичалмасак, атлар мичәек.*
Халык жырыннан.

**Мизгелләрем—кичәр Иделләрем,**
**Йотлыгып ла эчәр суларым;**
**Артта калган күпме кичүләрем,**
**Күпме икән алда узарым?**
**Ничәнче кат инде суга керәм,**
**Тәч-тәч иткән сабый кебекмен.**
**Чиркандырып куя дерелдәтеп,**
**Ә чумдыммы—барыбер күнектем.**

**Кичү бирми, язгы сулар ташты,**
**Сынамакка микән яшьлекне?—**
**Түземлек лә дигән баулар белән**
**Бәйләп алдым уңай кәшмәкне[1].**

**Йөздем әле, йөздем ишкәксез дә**
**Яшел генә Идел—җаемә;**
**Былбыл моңы, чалгы чыңы булып**
**Сеңгәндер ул җырлар җаныма.**

**Баш очымда торна кычкырганы,—**
**Өзелә лә язын үзәгем.—**
**Сабыр гына сары Иделемнең**
**Кичәсем бар алтын үзәнен.**

**Ярларыннан сары Иделемнең**
**Җаннарыма үтә салкын җил.**
**Чыдамлыклар бирсен: ак дулкынын**
**Чайкарга ла тора ак Идел.**

**Ак Иделкәйләрне кичәек тә,**
**Кичалмасак, атлар мичәек.**
**Берәм-берәм безне дулкын йотар,**
**Бергә-бергә Идел кичәек!**

---
[1] Кәшмәк—сал.

Ә нигә соң таркау-тәртипсез без?..
Сылтамыйкчы кыргый заманга!
Шушы хакта искә алмасакчы
Ябышыр чакта гына саламга.

Зурламасак та без—хурламыйкчы,
Чын Иделләр җире—үз илем!
Иңнәрдәге йөгем саллы әле,
Алда булсын кичәр Иделем!..

## Үкенеч

*Кордашларым Габдрахман Кадыйров
белән Илфак Смаковны соңгы юлга озаткач.*

Үкенечләр тулы бу гомернең,
Бер карасаң, чиге юк сыман.
Сез дә киткәч, асыл кордашларым,
Чикләр җуеп йөрәк юксына.

Синең чигең, әҗәл,—билгесезлек,
Үз сәгатең бардыр, үз көнең,
Үтерәсең, диеп аһ орабыз—
Тудырасың күпме үкенеч?!

Килгәнемә, язмыш, үкенмимен,
Йомгакларың сүтеп баш катса;
Үз бәхетем эзләп, мин чыкмадым,
Бүтәннәрнең бәхете аша атлап.

Бигрәк лә артык югалтулар,
Мишеньнәрдән яза ук атсам.
Тугрылыгы өчен мәхәббәтнең
Үкенмәмен, башым югалтсам.

Ә бит әүвәл бер күз сирпүемдә
Күрмәсәләр,—булды, үкендем;
Өермәле гомер мизгелләре
Чуалдырды юлны—үкендем.

Мин үкендем, кемдер как җилкәмә
Аударганда нахак-битәрне,
Әл дә иңем бәла-казаларны
Үкенмәслек итеп күтәрде.

Баш очымда булса Ай-Кояшым,
Кызыктырмас ялган ялтырау.
Үкенмимен, язмыш, табаныңда
Мин булмадым юеш олтырак.

Үкенечләр бары артта сыман,
Коточыргыч яшен яшьнәмәс;
Инде кыя җанны бер үкенеч—
Яшәлгәне кадәр яшәлмәс...

## Сафлык

Саф күңелле булып туа бәндә,
Яралгысы булса саф сөю;
Җан-тәнеңне сафлар иреннәрең
Анаң күкрәгенә чак тию.

Бу дөньяда сафлык күбрәктер,
Саф йөрәкле булсаң, саф намус;
Саф уйларың белән пакъ юллардан
Хак уңышың килер шатланып.

Сафлык чишмәсендә җанын чайкап,
Гаделлеккә кеше атлыккан,—
Тамчылардан карлар яралгандай,
Сафлыкларың туа хаклыктан.

Күңелеңә пычрак ягылмасын,
Намусыңа таплар төшмәсен;
Гомер буе тау-таш актарырсың
Табар өчен сафлык чишмәсен.

Алларыңа сафлык, пакьлек үзе—
Өерелеп ява карлар тын;
Тап ягылса, нәфис ак карларны
Булырмы соң кабат агартып?!

## Дуслык җыры[1]

Дуслык җыры тынмый яңгырасын,
Җиребезне айкап мең урасын,
Иң матур җыр бездә—дуслык җырлары.
Күңелләрдән күчкән күңелләргә,
Җәйгор булып төшкән киң җирләргә,
Иң матур юл бездә—дуслык юллары.

Саубуллашып, ерак китсәк тә,
Без кайларга гына җитсәк тә,
Дуслык, җыр калыр йөрәктә!

Авырлыклар җиңдек бергәләшеп,
Торган җирләр безнең—башка, уйлар—бер.
Бер хыяллы, бер теләкле итеп,
Мәңгелеккә куш йөрәкле итеп,
Тоташтырган безне олы Туган җир.

Саубуллашып, ерак китсәк тә,
Без кайларга гына җитсәк тә,
Дуслык, җыр калыр йөрәктә!

Әле керде ярсып ут-суларга,
Әле менде ерак йолдызларга,
Еллар агышында дуслык чыныкты.
Сагындырып кына очраштырып,
Очраштыргач, тагын хушлаштырып
Сыный икән вакыт безнең дуслыкны.

Саубуллашып, ерак китсәк тә,
Без кайларга гына җитсәк тә,
Дуслык, җыр калыр йөрәктә!

## Яз килгәнен синә карап беләм...[2]

Яз җитәрен сиңа карап беләм,
Әллә каян сизәм килүең;
Челтәр бозга сугылып чыңлап яткан
Елгачыктай синең көлүең.

Яз килгәнен сиңа карап беләм,—
Буй-сыныңа сафлык ягылган;
Күгәрчендәй гөрләп куясың син
Үткән чакта минем янымнан.

Яз килгәнен сиңа карап беләм,—
Тәрәзләргә гөлләр тезелгән;
Битләреңә чәчкән гөлләреңнең
Орлыклары әллә сибелгән.

Яз килгәнен сиңа карап беләм,
Хисләр ташсын тагын ярлардан;
Синең өчен мин барсына риза,
Мәхрүм генә итмә язлардан...

---

[1] Рим Хәсәнов музыкасы.
[2] Роберт Газизов музыкасы.

## БУСТАНАЙДАН БАШЛАНГАН ҖЫР

*Мөхәррәм Каюмов—минем якташым. Әйе, Башкортстанның Борай районыннан, миңа бик шигъри, матур тоелган Бустанай исемле авылдан (мөгаен, Бостанайдыр ул: Ай бостаны, бакчасы, дигән сүздәндер!). Бу авылдан чыккан башка шагыйрьләр дә барын беләм. Ә инде аннан ерак түгел Чалкак авылы—композитор Солтан Габәшиебезнең*



*газиз сөякләре соңгы төяк тапкан җир... Атаклы «Кәккүк» җыры шул якта—гүзәл табигатьтә дә яңгырап, күп йөрәкләрне—шагыйрьләрне олы иҗатка кузгаткандыр: Илдар Юзеевны, Саҗидә Сөләймановны, яшьлек кумирым Әнгам Атнабаевны... яшьрәкләрне... Гали Чокрыйларның изге эзләре, догалары калган төбәк бу! Җыр-моңга да бай ул: Хәмдүнәләр, Хәнияләр, Нәфкатьләр, Салаватлар туган як! «Ярсу Танып буйларым», дип язды аны үсмер чагында ук Мөхәррәм дустым. Ләкин, яшьтән үк шигырьгә гашыйк Мөхәррәм Казанга ир-егет булгач кына килде, соңлап танылды ахры... Әмма шигырьгә соңлады дигән сүз түгел бу! Көндәлек матбугатта басылган шигырьләре белән үк күпләрнең хөрмәтен казанды ул. Бер генә мисал: «Казан утлары»нда 80 еллар башында басылган «Казанымда шундый чатлар бар» дигән шигыренә чит илләрдә дә игътибар иткәннәр икән: Гайшә ханым Азадә-Рорлихның мәгълүм китабында бу шигырь тулысынча китерелгән... Юкка түгелдер: Мөхәррәмгә милли рух, тарихилык хас иде. Ул чакта да, диюем. Бу бабта ул каләмдәш дусты, якташы Эдуард Мостафинга охшаш: табигый, гади чаралар белән шигърилек, милли колорит, сурәт һәм халыкчан фикергә ирешү... Мөхәррәмнең, әле китабы чыкмастан элек үк, Язучылар берлегенә алынуы да аңа ныклы ышанычны сөйли иде бит! Ә инде озак көттереп дөнья күргән «Торналар чылбыры» исемле шигырь җыйнамасы—тиз онытыла торган китаплардан түгел дип уйлыйм—иманым камил моңа! Үзенчәлекле, төпле, акыллы шигырьләр мәҗмугасе ул.*

*Әйе, шагыйрьләрнең, шигырьләрнең язмышы төрле-төрле. Мөхәррәм дус та җиңел язмышлы булмады—язганнарында ул бу турыда кат-кат уйлана, фикерли, нәтиҗәләр ясый. Әмма, тормышындагы төрле сынаулар, авырулар, авырлыклар—аның өчен шәхси кичерешләр генә кебек. Соңгы язган шигырьләрендә дә аның гаменда—Идел-йорт, халык язмышы үе, киләчәгебез турында борчылу-әрнүләр бит. Алтмыш яшьлек моң иясе ирнең эчендә күп утлар яна шул, әлеге дә баягы—«иярле-йөгәнле ат ята» чын егетләр йөрәгендә! Яшьтәшемнең шигъри моңына сез дә битараф калмассыз дип уйлыйм, хөрмәтле укучыларыбыз!*

Радиф ГАТАШ

# Мөхәррәм Каюмов

## Дастан

Буыннардан күркәм буыннарга—
Бабайлардан калган бу дастан.
Бүген аны бөтен дөнья укый,
Ә исеме аның— Татарстан.

Шул дастанның һәр битендә—Тарих,
Канлы алыш. Мәхшәр. Зилзилә.
Яу чабалар болгар яугирләре—
Кемдер җиңә. Кемдер җиңелә.

Тирә якта—кара хәрабәләр,
Әйтерсең җир киткән ишелеп,
Байрак булып Кояш күтәрелә,
Исән әле, димәк, кешелек.

Ялкын йоткан халык,
Җанын һәрчак
Тырнап торган әрсез шөбһә-корт.
Йөрәгенә иман терәк булгач,
Исән-имин калган Идел-йорт.

Күрелмәгән матур бәйрәм кебек
Тыныч торса тормыш аз гына.
Дастан ләкин ук һәм кылыч белән,
Язмышларга манып языла.

...Дөрли Казан.
Ялкын җитмеш телле.
Җәһәннәм ул менә шул була.
Кала уртасында тәре калка,—
Буйсынмыйча халык кол була...

Татарстан!..
Укып туймас дастан—
Җиңеп чыккан хаклык. Дөреслек.
Кемгәдер ул—мавыктыргыч кыйсса,
Безнең өчен исә—Дәреслек.

## Әнкәй

*«Анам. Аннары... анам. Аннары—тагын анам.*
*Соңыннан гына—атам...»*
Хәдисләрдән

Беренчесе—Тәңре, аннан әнкәй,
Камил моңа минем иманым.
Әнкәемнең бөеклегенә мин
Инандым да, чиксез куандым.

Ул ерактан гел күзәтә мине,
Кыек басмый, калам тыелып.
Кыенлыкка очрап, җебеп төшсәм,
Кинәт арта миндә кыюлык.

Үз-үземне аямыйча яшим,
Мең сыгылсын язмыш, мең сынсын!
Тик мин аңа түгел, бу тормышның
Кагыйдәсе миңа буйсынсын!

Шатлыкларым әле канат ярыр,
Кайгыларым җанны яралар.
Күпме кушса Ходай, шулкадәрле
Афәтләрдән әнкәм аралар...

## Печәнче

Ничәмә ел үткәч, табып алдым
Иске чалгымны мин чормадан.
Киерелеп менә печән чабам
Пакус булып яшел җыр ага.
Болыннарда быел печән уңган,
Димәк, яңгыр яуган җитәрлек.
Уйнап-уйнап күбәләкләр оча
Канатында җәйне күтәреп.
Нинди генә чәчәк юк соң монда,—
Болын гүя матур рәсем.
Зур сәнгатьнең мәңге тынмас җаны
Безнең табигатьтер, күрәсең...
Әйтерсең лә усал җил исмәгән,
Котырынып давыл узмаган.
Вакыт җитәр: бу гүзәллек сүнәр,
Әнә шуңа әчтән сызланам...
...Сабанчы да булдым, печәнче дә,
Тынычланыр идем мин-бәндә,
Җирдәге бар кайгыларны чабып
Өеп куйсам әгәр кибәнгә...

## Ашыгам

Бу дөньяның һәрнәрсәсе якын,
Кайгысын да аның олылыйм.
Яхшылык һәм гүзәл яктылыкның
Күпне күргән үксез улы мин.
Юлда үтте гомер...
Каршы җилләр
Усал булды.
Булды юаш та.
Сәлам бирдем кичен мин яшь Айга,
Башым идем иртән Кояшка.
Йолдызларга чишмә серен чиште,
Кошлар җыры нурга кушылды.
Яшел җәем эреп җанга сеңде,
Акшарлады карлар кышымны...
Ашыгам мин килер көннәремә,
Юк, чалынмый күзгә ак-кара.
Үткән юлым һаман озыная,
Барачагы, сизәм, кыскара...
Горур тотып башны атлый бирәм,
Әйтерсең мин дөнья тоткасы.
Чабам...
Гүя, кирәк өлгерергә—
Ябылганчы оҗмах капкасы...

## Былбыл-кош

Язлар, җәйләр үтте. Күзләр җитте.
Сәлам бирде менә салкын кыш.
Сискәндереп сулган чәчәкләрне
Тәрәзәмә кунды былбыл-кош.

Ул җанымда минем туган иде
Яшәү көче биреп торырга.
Канатларын ныгытты да очты
Үзенә бер оя корырга.
Мәхәббәт, дип атаганнар аны,
Асылында һич юк үч, ялган;
Яшьлек белән бергә ярала да,
Кеше белән китә дөньядан.
Һәркемдә дә ул үзенчә була:
Кемдә кыю, кемдә бик юаш.
Чәчәкләргә барып табына да,
Кояш нурларына куя баш.
...Чиртте кошым күңел тәрәзәсен,
Йөрәк капкаларын шакыды.
Тик гомерлек урын табалмады,
Кемгә барса, шуңа ят булды.
Бүген миңа очып кире кайтты,
Әй үзгәргән—Вакыт аяусыз.
Тәңре биргән гомер үтеп бара,
Былбыл-кошым һаман оясыз.

## Янды

Синең белән очрашуым—хата,
Яратам, дип юкка җан ордым...
Синнән башка үткән елларымны
Өем-өем итеп яндырдым.

Янды, янды очкынланып, балкый
Елларымның иң-иң затлысы:
Бүләр иде татлы төшләреңнән—
Төшмәгәндер төнлә яктысы...

## Гомер

Яшәрмен дип шушы яшькә кадәр
Кем уйлаган инде, кем белгән?..
Йөрәгемдә һаман вулкан ата,
Гейзер бәреп тора күңелдән.
Алар тынар, беләм...
Кояшта да
Сүнеп кала кинәт активлык.
Буйга үстем әллә кыя хәтле?—
Чәчләремә кунды ак болыт.
Дөнья миңа кырынрак бакты,
Буш итмәде ләкин назыннан.
Нектар җыйган бал кортлары кебек,
Акыл җыйдым еллар таҗыннан...
Мин мәңгелек түгел.
Бер китәрмен...
Шушы хакыйкатьне белгәнгә,
Йолдыз белән исемемне язып
Калдырасы килә галәмгә...

### Ләбибә Ихсанова

## СЕЗ КАБЫЗГАН УТЛАР

Хәсән ага Туфанның чит җирләрдә озак еллар михнәт чигеп, сагынылган Казанына кайткан айлары иде. Әлегә аның көннәре очрашулар, күрешүләр, әчкерсез мәҗлесләрдә үтә... Көннәрдән бер көнне ул үзе дә тыйнак кына бер мәҗлес җыеп, Шәрәф белән мин дә анда чакырулы идем. Кичерәк кенә бакча артына посып утырган Иске дигән тыкрыктагы таш йортка унайсызланып кына кердем мин. Яшь идем әле, андый зур шәхесләр белән аралашырга өйрәнмәгән идем. Әмма читенсенүемнең төп сәбәбе башка иде. Чөнки бу өйнең хуҗабикәсе, кунакларны кочак җәеп каршы алырга тиеш кешенең юклыгын белә идем. Шатлык белән хәсрәт бергә йөри диләр бит. Хәсән аганың кайтуына ике-өч ай гына калды, менә-менә күрешү көннәре килә дигәндә аның гомерлек юлдашы, Татар академия театрының үзенчәлекле һәм талантлы артисткасы, сөекле Лулуы (шагыйрь аны шулай дип атап йөрткән) Луиза Салигаскәрова авырып дөньядан китә. «Болай да күпне күргән шагыйрь йөрәге шул чакларда ничек түзде икән, төсе-бите белән әнисенә ошаган кызы Гөлгенәне кочагына алганда ниләр кичерде икән?» дип уйлап куйган чакларым була иде. Беренче каттагы иркен бүлмәдә утырганда да шул халәттән аерыла алмадым.

Мәҗлестә матур-матур тостлар әйтелде, изге теләкләр теләнде, шаян сүзләр сөйләнде. Ләкин кунакларның күңелендә калганы, шагыйрьнең ярала йөрәген аеп, әйтми калдырганнары барлыгы да сизелә иде. Мине дулкынландырганы тагын шул булды—Хәсән ага үзәкләрне өзәрлек итеп, мандолинада уйнады. Аннан кинәт кенә бию көенә күчте. Олыгаеп килгән хатыннарга хас булганча тулырак гәүдәле, кара чәчләрен уртадан аерып, артка төйнәп куйган, мөләем аксыл чырайлы ханым, янында утырган зифа буйлы кыз белән баһадир гәүдәле яшь егетне кулларыннан алып, биергә чыгып басты. Алар өчәүләп, кульяулыкларын болгый-болгый, Әстерхан татарларының биюен биеделәр. Кавказ якларына тартым әкрен, салмак, сыгылмалы бию иде ул.

Хәсән ага Туфан мәҗлеснең башында ук ханымны олы галим Галимҗан Нигъмәтинең хатыны Жанна ханым, аның кызын Йолдыз, улын Энгель дип таныштырган иде. Ул чакларда мин география факультетын тәмамлаган кеше буларак әдәбият тарихыннан шактый ерак идем. Бу серле, сихерле дөньяга әкренләп, еллар буе килдем. Галимҗан Нигъмәтинең дә татар әдәбиятында тирән эз калдырган филология фәннәре докторы, Казан педагогия институтында абруйлы профессор булганын шунда белдем. Жанна ханымның мулла кушкан исеме Маһиҗиһан булуы да шул елларда мәгълүм булды. Гасыр башында дөньяга килеп, катлаулы, каршылыклы, шул ук вакытта яшьлек дәрте белән матур булган ашкынулы еллар кичеп, мәдәниятыбызның якты маяклары булган бер төркем кызыклы шәхесләрнең гомере күз алдымнан үтте.

---

Ләбибә ИХСАНОВА *(1923)—әдибә, балалар өчен язылган «Көмеш елга», «Нияз», «Робинзоннар лагеренда»,«Саралан малайлары» һ.б. повесть-хикәяләр авторы. Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге бүләге лауреаты. Казанда яши.*

Унтугызынчы гасыр ахырындагы яман ачлыктан качып, Әтнә ягының гайяр ире Җәләлетдин ишле гаиләсе белән Әстерхан шәһәренә килеп төпләнә. Чинар һәм каштан агачларының хуш исле күләгәсендәге урамда Мелькумов дигән әрмән баеның иске һәм кысан флигелендә яшәп китә. Тиз арада уылдык ясау һөнәренә өйрәнә һәм осталыгы белән тирә-якта атаклы кеше була. Уллары да балыкчылар әртилендә үз кеше. Кечкенә балалар да аунап-тәгәрәп үсеп киләләр. Маһиҗиһанны әнә абыстайга укырга бирер вакыт житеп килә. Ләкин бу чая кызның әлегә укуда кайгысы юк. Әрмән бистәсендәге малайлар, кызлар белән баш бетереп уйнап йөрүе. Нинди генә телләрдә сөйләшмиләр алар! Бигрәк тә, бәхәсләшә, кычкырыша башласалар татарча да, русча да, әрмәнчә йә әзәрбайжанча, казахча сиптерәләр генә! Милләт төшенчәсе юк алар өчен. Үзләрен дус һәм бик үк дус булмаганнарга гына аералар.

Гамьсез балачак таң алдыннан күргән төш кебек, иң кызык җирендә уянасың да китәсең. Маһиҗиһанның да гимназиягә керер вакыты житкән лабаса. Әнә аңа таныш бай кызларының бер-икесе гимназистка формасын һәм рәсемле китапларын күрсәтеп, мактанып та алдылар инде. Ә Маһиҗиһан кеше бәхетенә кызыга торганнардан түгел. Абыстайда дүрт ел сабак алып, укуның кызыгын белгән, яңалыкка дәртле уенчан чая кыз көн дә әтисен йөдәтә: гимназиядә укыйсым килә! Җәләлетдин үзе дә кызын укытырга бик тели. Ләкин анда мөселман балаларын алмыйлар икән шул. Уйлый торгач, җае табыла тагын. Бай белән кат-кат сөйләшә торгач, тегесе Маһиҗиһанны үз фамилиясенә яздырырга риза була (балалыкка ала янәсе). Һәм кыз Мелькумова булып гимназиядә укый башлый. Ләкин әрмән баеның киң күңелле булуы түгел бу. Шәһәргә атаклы останы югалтудан куркуы гына. Үтәр берничә ел, байчура үзенекен итәр, эшчән гаиләне бик шәп итеп төпсез чуманга утыртыр әле!

Бу эш болай була: Җәләлетдиннең балалары исәя башлаган саен флигельнең тарлыгы нытырак сизелә башлый. Яхшырак, зурырак торакка күчү мәсьәләсе алга килеп баса. Мелькумов аңар үз йортларының берсен тәкъдим итә. Дөрес, әлегә анда ерак кардәше яши икән. Әгәр Җәләлетдин ай саен акча биреп барса, тиешле хакы җыелгач, туганын чыгарачак һәм өй остага булачак. Бер юлы күп акча чыгарып бирәсе булмагач, Җәләлетдин килешә. Әмма яңа өйгә күчәбез дип торганда гына Мелькумов карарын үзгәртә һәм түләнгән акчаның бары йөз сумын гына кайтарып бирә. Ләкин Маһиҗиһанның әнисе, дөнья күргән горур хатын:

—Хәрам акчаң үзеңә булсын! Аңа калмаган әле без,—дип, йөз сумны байның битенә ташлый.

Холкы белән әнисенә ошаган, гаделсезлеккә артык сизгер Маһиҗиһан да шулай итеп тормышның ни икәнен аңлый башлый. Гимназиядә бик тырышып укый, рус әдәбиятын өйрәнә. Алдынгы фикерле яшьләрнең күңел ачу кичәләренә йөри. Шуларның берсендә адвокат Борһан Бадамшин белән таныша. Аның ярдәме белән татар зыялылары арасыннан да күп дуслар таба. Татар әдәбияты белән ныклап кызыксына башлый. Ул бигрәк тә Фатих Әмирхан әсәрләрен яратып укый. Әдипнең «Хәят» дигән хикәясендә кыз үзен күргәндәй була. Әсәрнең төп герое Хәят белән тормыштагы Маһиҗиһанның ошашлыгы—аларның яшьлеге. Патриархаль кысалардан котыла алган яңа фикерле яшьләрнең белем алуга, яңалыкка омтылулары, рус һәм европа культурасына тартылулары, күңел ачу кичәләрендәге иркенлек, кызлар, егетләр арасында мәхәббәт уеннары Маһиҗиһанга да ят түгел. Әмма әсәрнең герое белән ошашлык шунда тәмамлана да инде. Хәятның хыялы яшь, чибәр, акыллы һәм бай кияүгә чыгудан ары китә алмый. Ә Маһиҗиһан башка. Аны мондый тынчу тормыш канәгатьләндермәс иде. Ул әз генә бунтарь йөрәкле дә бит әле. Килер бер вакыт, Галимҗан Нигъмәти дигән галим аның чаялыгын, бәйсез холкын яратып, французларның легендарь герое Жанна д, Аркка тиңләп, «син Маһиҗиһан түгел, син Жанна!» дип әйтер. Һәм шуннан башлап галимнең дус-ишләре дә аны Жанна дип атарлар. Ә хәзергә әле ул бар җиһанны кочып алырга теләгәндәй яшәгән Маһиҗиһан гына.

Ул елларда Әстерхан шәһәренең, Казан кебек үк, көчле бер мәдәният учагы булып танылган чоры була. Татар яшьләреннән күп кенә драма түгәрәкләре оеша. Фатих Әмирханның «Тигезсезләр» пьесасы, Галиәсгар Камал әсәрләре уйнала. Репертуар сайлауда, актерлык осталыгына өйрәнүдә яшьләргә Зәйни Солтан, Сара Байкина, Габдулла Уральскийлар булыша. (Соңга таба бу түгәрәкләрдән үсеп чыккан талантлы яшь артистлардан Әстерхан татар театры барлыкка килә). Маһиҗиһан да драмтүгәрәккә яратып йөри, җырлы-биюле спектакльләрдә гармунчы малай булып

сәхнәгә дә чыккалый. Ләкин кызның иң олы хыялы—югары белемле укытучы булу. Әдипләр белән очрашуларны, шигърият кичәләрен берсен дә калдырмый. Ул елларда шагыйрь Сәгыйть Рәмиев тирәсенә бер төркем шигырь сөючеләр тупланган була. Казаннан, Уральскийдан, Оренбургтан танылган шагыйрь һәм әдипләр килеп йөри. Бу очрашулар кызнын хыялын тагын да үстереп җибәрә. Ә шундый бер очрак анын тормышында тирән эз калдыра. Әстерханга атаклы язучы Фатих Әмирхан килгән чак була ул. Бу көннәр Маһиҗиһан өчен тоташ бәйрәмгә әйләнә. Әдип белән очрашу җир читендә була дисәләр ул анда бару әмәлен дә табар иде. Бу кичәләрнен берсен дә калдырмыйча йөргән, һәр сүзне йотардай булып тыңлап утырган, ара-тирә кызык кына сораулар да биреп куйган кызга Фатыйх Әмирхан да игътибар итә. Шәһәр паркында булган шундый бер кичәдә Борһан Баламшинга:

- Әнә теге ак күлмәкле кыз белән сөйләшер идем,—дип әйтә.

Калын толымнары биленә төшеп торган зифа буйлы ак күлмәкле кыз каушый төшеп, коляскада утырган әдип янына килә. Калын пыялалы күзлек аша сирпелгән тыныч, ягымлы караш белән очрашкач, бу унайсызлану, җил исеп тараткандай, юкка чыга. Шактый озак сөйләшәләр алар. Әдипкә кызнын фикер йөртүе, укымышлы булуы, кыюлыгы, ихлас күңеле ошый. Әңгәмәнен ахырында:

—Сезгә Казанга барырга кирәк. Анда мәйдан киңрәк,—дигән киңәш бирә.

И, Казан, Казан! Кемнәрнен генә хыялында түгел дә син, кемнәрне генә үзеңә чакырып тормыйсын. Шагыйрь дә бит синең хакта «И, Казан, нурлы Казан, моңлы Казан», дип җырлаган. Кызарып кояш чыккан сәгатьләрдә Әстерхан кызы Маһиҗиһан утырган пароход та Казанга якынлашып килә. Кызнын таң йокысына киңәнеп ятар чагы да бит, ул инде күптән палубада. Иртәнге су җиленең салкынлыгын да тоймыйча, йотылып, шәһәр панорамасын күзәтә. Пароход шәһәргә түгел, ә шәһәр үзе анын каршына йөзеп килә дип әйтерсең. Тиздән, бик тиздән алар кавышырлар һәм нурлы Казан аны үзенең җылы, мәрхәмәтле кочагына алыр сыман.

Буш вагоннарын шалтыратып килеп туктаган трамвайга утырмады ул. Кешеләрдән сорашып, үзенә кирәкле урамнын кайдалыгын белгән иде инде. Ашыкмыйча гына җәяү китәргә булды. Ярый әле күтәреп барырлык әйбере юк, пароходта килгәндә аферист хатын талап качты. Әлләни кызыгырлык нәрсәсе дә юк иде үзе, әнисе биреп җибәргән Оренбур шәле генә кызганыч. Урлаттым дип әйтсә әнисе үпкәләр инде, бигрәкләр дә кадерләп тота иде ул аны.

Шәһәр читендәге ярым җимерек агач йортларга исе китмәде анын. Бу җирләр туган шәһәре бистәләрен хәтерләтә иде. Ә менә шәһәр уртасына күтәрелгән саен кызнын йөрәге ешрак тибә башлады. Икешәр-өчәр катлы таш пулатлар бик борынгыдан калгандыр, әллә ниткән серләрне яшереп яталардыр кебек тоелды. Тукай яшәгән шәһәр бит бу! Галиәсгар Камал үтеп йөргән урамнар. Фатыйх Әмирхан кайсы йортта яшәде икән? Маһиҗиһан аны күрә алмас инде, шәһәр тормышына ияләнә төшкәч каберенә чәчәкләр генә китереп йөрер.

Көнчыгыш педагогия институты аны ишекләрен киң ачып көтеп тормый иде инде. Кабул итү сынаулары тәмамланган. Киләсе елны ничек көтеп алмак кирәк. Үзе бер озын гомер бит ул. Инде ни эшләргә дип аптырап йөргәндә Әстерхандагы танышы Борһан Баламшин исенә төшә. Ул анар үзенең адвокатлык тәҗрибәсеннән бик мавыктыргыч вакыйгалар сөйли иде бит. Күрәсең тәэсире аз булмагандыр. Маһиҗиһанга ул читтән торып киңәш биргән кебек була һәм кыз юристлыкка укырга була. Юрист та педагог кебек үк кеше язмышы өчен җавап бирә лабаса. Аларнын осталыгына кемнәрнеңдер бәхетле, йә бәхетсез булуы бәйләнгән, дип уйлый ул.

1926 елда кызнын язмышына бәйле тагын бер әһәмиятле вакыйга була. Шул елның декабрендә Галимҗан Нигъмәти дигән әдәбият белгече Мәскәүдән кайтып төшә һәм Маһиҗиһанга күрше фатирга урнаша. Үзәк Башкарма комитетының милли матбугат бүлеге аны «Кызыл Татарстан» гәзитенә баш редактор итеп җибәргән була.

Маһиҗиһанны Казаннын мәдәни тормышы бөтереп алган чак була бу. Лекцияләрдән буш вакыты, нәкъ Әстерхандагыча, шигырь кичәләрендә үтә. Ул елларда яшьләрнен табыну дәрәҗәсенә җитеп яраткан шагыйре Һади Такташ була. Сәхнәгә чыгып бастымы—зал тулы яшьләр гөрләтеп кул чаба башлый. Шагыйрь алкышлар тына төшүне көтеп ала һәм башын чөеп, озын сары чәчләрен артка ташлый да шигырьләрен күңелдән бер-бер артлы сөйли башлый. Ә бер көнне Җиһан аны университет янындагы арзанлы ашханәдә очрата. Студентлар йөри торган ашханәгә

шагыйрьнең узып барышлый гына керүе булдымы, әллә яшьләрнең күңелле рухы тартып китергәнме, әмма бу бәхетле очрак икесе өчен дә гомерлек дуслыкның башы була. Шагыйрьнең хатыны Гөлчирә дә Әстерхан кызы, шигырь кичәләрендә Маһиҗиһан белән очраштыргалыйлар иде. Такташ Сәгыйт Рәмиевнең хатыны Бану ханымның да Казанда икәнен әйтә. Бу очрашудан алар күптәнге танышлар кебек аерылалар.

Такташ «Күмелгән кораллар» драмасын язган чагында кайбер киңәшләр алу өчен Галимҗан Нигъмәтигә килгәч, алар тагын очрашалар. Татар академия театрында әдәби бүлек мөдиренең урынбасары да булып эшләгән Нигъмәти белән Такташ алларына куе чәй куеп, озак кына эшләп утыралар. Ишек шакыган тавышка баш күтәрсәләр нинди дер йомыш белән кергән кызны күреп бераз уңайсызланып калалар.

—Кереп бик яхшы иттегез. Якын дустым белән таныштырыйм әле,—дип Галимҗан кызның каршына килеп кулыннан ала.

Әмма кыз тыйнак кына елмаеп, башта Такташка кул суза.

—Исәнмесез, Һади!

—Сез танышлармени?—ди Галимҗан исе китеп. Һәм шунда ук өстәп куя.—Хәер, шигърияткә гашыйк яшьләрнең Такташны белмәве мөмкинме соң?!

Әдәби бүлектә эшләгән елларында Нигъмәти Жанна туташны еш кына театрга чакыра торган була. Бигрәк тә премьераларны бергә карыйлар. Шулай итеп, ул кызны театр дөньясына алып керә. Дуслары Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев, Әсгать Мәҗитов, Галия Булатоваларга туташны, кәләшем Жанна, дип тәкъдим итә.

Озакламый Пассаж йортында аларның тыйнак кына туйлары була. Жаннаның фатир хуҗасы Самат әби (ирләрчә нык холыклы, гадел карчык Газизә Саматованы күршеләре шулай дип йөртә) туй бүләге итеп шау чәчәкле роза гөле бүләк итә.

—Гөлләр кебек яшәгез,—ди тәмле телле карчык.

Жанна бу кадерле бүләкне ике тәрәзә арасына куйганда Такташның яраткан урыны буласын белдеме икән? Кайчан гына килмәсен шагыйрь шушы гөл янына утыра, вакыт-вакыт нәрсәдер яза, сыза, төзәтә. Шундый чакта йорт хуҗалары аңар комачауламаска, сүз әйтеп игътибарын алмаска тырышалар. Нигъмәти үзе дә эш белән мәшгуль була, илаһи тынлыкны саклап Жанна чыгып ук китә.

Өйдә ачык йөзле хуҗабикә булгач, дус-ишләрдән килеп йөрүчеләр күбәя. Тукай һәм Фатыйх Әмирхан белән якыннан таныш булган адвокат Гани Абызов, «Атака» журналының редакторы Кави Нәҗми, Гомәр Гали, Сәләх Атнагулов та еш була бирәдә. Кай төннәрне театрдан ук җыелып кайталар. Жанна зур таба тутырып, тиз генә тәбә куырып ала. Барсы да өйләрендәге кебек үзләрен иркен хис итәләр.

—Эх, егетләр, белмисез бит ат урлауның тәмен!—дип, учын учка ышкып, Сәлимҗанов хатыны Галия Нигъмәтуллина янына килеп утыра.

—Аның каравы, Жанна ханым чәенең тәмен әйбәт тоябыз,—дип, калын иреннәрен җәеп Камай елмая.

Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасы гөрләп барган чак була ул. Тамашачы телендә шул гына. Әсәрдәге үткен сүзләрне әйтеп көлешүме, андагы типлар булып кылануы, барсын да күрергә, ишетергә була. Дөрес булса, хөкүмәт җитәкчеләре төнге утырышларын бүлеп, спектакльнең ат караклары җыелып утырган урман күренешен генә булса да карау өчен театрга килә торган булганнар. Ата карак ролендә Шакир Шамильскийның осталыгына исләр китәрлек була. Ә Салих Сәйдәшевнең пьесага язган унлап көе инде сәхнәдә генә түгел, радиода, концертларда, мәҗлесләрдә яңгырый.

Ал яулык, зәңгәр шәл,
Узган гомерем бигрәк җәл...

Кызганыч, Галимҗаннарда пианино юк. Сәйдәшев шул көйләрнең берсен генә дә дусларына уйнап күрсәтә алмый. Шул чакларда Нигъмәти ярым шаярып:

—Тукай турында монографиямне язып бетерим әле, иң элек пианино алырмын, аннан соң Жаннага манто,—дип әйтә торган була.

Шундый чакта Хәсән Туфан коткара. Аның җитез бармаклары мандолинада былбыл тавышлары чыгара башлый. Кайчагында алар хуҗабикә белән парлап уйныйлар: Жанна тальян гармунда, Туфан мандолинада. Салих Сәйдәшев Жанна ханымның тальянда үзе уйнап, үзе җырлавын тыңларга ярата. Әстерхан кызлары гомумән җырга биюгә оста булалар. Шаян холыклы Жанна исә көлке җырларга

маһир. Иренең эшләпәсен башына кыек салып кия дә, гармун күреген беткәнче тартып, карлыкканрак тавыш белән никрут булып жырлый башлый. Алай да булмый, бер жырның башына икенчесенең ахырын, анысына өченчесен, дүртенчесен ялгап жибәрә. Монысы Сәйдәшкә тагын да ошый төшә. Тыйнак кына елмаеп:

—Жанна ханым, шул өч этажлы жырыгызны жырлагыз әле,—дип үтенә.

Шулай да бу очрашуларда сүз күбрәк әдәбият турында бара. Такташ, йә Туфан шигырь укыса бәхәс тагын да куера төшә. Биредә, һәркем үз фикерен тартынмыйча әйтә ала. Ләкин үпкәләшү дигән нәрсә кабул ителми. Хәсән Туфан «Урал эскизлары» дигән поэмасын укыгач, бәхәс төн уртасына кадәр бара. Урал заводларында эшләп, андагы тормышны үз күзләре белән күреп кайткан шагыйрьнең беренче зур әсәре була ул. Аның турында матбугатта да күп язалар. Мәжлестәгеләрдән берәүләр поэманың кыю язылган заман әсәре икәнен әйтәләр. Характерларны бирү өчен уңышлы алым сайланган диләр. Икенчеләре исә әсәрнең артык гади, урам теле белән язылуын яратмыйлар. Поэзия юк, лирик жылылык житми, диләр. Барсы да кайнарланып, берсен-берсе бүлә-бүлә сөйләгән арада хужабикә телгә килә:

—Бар нәрсәгә дә Хужа Бәдигый күзлегеннән карамагыз әле,—ди шаярып, һәм чәй тәкъдим итә,—рәхим итегез, күңелләрегез йомшап китәр.

Шулай ел арты ел үтә. Дуслар да ишәя. Жанна ханым да инде университет тәмамлап, юрист-экономист булып эшли башлый. Көнчыгыш педагогика институты профессоры Нигъмәти башы-аягы белән Тукай турындагы монографиясенә чумган. Алма кебек кыз белән уллары үсеп килә. Өйдә тынычлык, бәхет-сәгадәт. Әмма тормыш жилләре жылы яктан гына исми икән шул. Күп вакыт аның кай якка борылганын да сизми каласың. Дуслар кичергән беренче зур кайгы—Такташның үлеме була. Зәңгәр күзле дуслары, суга төшеп югалгандай, дөнья белән хушлаша. Бу афәтне барысы да бик озак, бик авыр кичерәләр. Шул еллардан башлана да инде төрле борчулар, эреле-ваклы мәшәкатьләр, күңелсезлекләр. Әйтерсең лә Такташ аларның жан тынычлыгын үзе белән мәңгелеккә алып киткән. Жыелып утырулар сирәкләнә, кайнар бәхәсләр сүрелә. Бер төркем талант ияләренең шулай берләшеп, кинәшеп яшәүләре кайберәүләрнең эчен пошырган икән, бу да сизелә башлый. Кемдер шәһәрдән китеп үк бара, кемнәрнедер мәжбүри алып китәләр. 1936 елны Нигъмәтине партиядән чыгаралар. Жанна да эшсез кала. Шушы авыр көннәрдә Галимжан Нигъмәти хатынына:

—Син көчле кеше, югалмассың. Мин сиңа ышанам, бу мине тынычландыра,—дип әйтә торган була.

Ниһаять, алар алдына дәһшәтле сынау көннәре килеп баса. Кызы Йолдыз һәм улы Энгель белән яшь хатын ялгыз кала.

Законнарны яхшы белгән, тәжрибәле юрист янына ирләре кулга алынган хатыннар киңәшкә, төрле оешмаларга гариза яздырып алырга килеп йөриләр. Жанна ханым үзе дә алар хәлендә. Кайгылары, борчулары уртак. Ләкин өмет дигән нәрсә дә бар бит әле. Шул хәрәкәт иттерә кешене. «Ник аларга булышасың, ник гариза язасың, халык дошманнарының хатыннары бит алар», дип әйтүчеләр табыла. Андыйларга Жанна ханым кырыс кына:

—Мин үзем дә халык дошманының хатыны,—дип жавап бирә.

Халык дошманының хатыны буларак аңар Казанда яшәргә ярамый булып чыга.

Бик авыр чакларында Жанна ханым ире Нигъмәти сүзләрен дога урнына кабатлый торган була: син көчле хатын, югалмассың, бу миңа юаныч бирә. Андый чаклары күп була аның. Сугыш һәм аннан соңгы елларда ил белән бергә күргәннәре өстенә «халык дошманы хатыны» дигән тамганы йөртүнең ни икәнен ул үзе генә белә. Башны ташка орып еларлык чакта да сынатмаска, балаларына сиздермәскә тырыша. Аларның гына өмете өзелмәсен дә күңелләре катмасын, яшәү уты сүрелмәсен. Йокысыз озын төннәрдә, күзләрен билгесезлеккә төбәп, бакый дөньядагы ире белән күңеленнән сөйләшеп ятканда шулай дип теләк тели ул. Һәм жиңеп чыга.

Еллар үтә тора. Тормыш та әкренләп жайга салына. Йолдыз белән Энгель инде югары белемгә ия. Икесе дә әтиләре юлыннан китә, әдәбият белгечләре. Галимжанның тормышка ашмый калган хыялын хәтерләтеп, яңа фатирдагы бүлмәләрнең берсендә пианино тора. Яше житмешкә якынлашып килгән Жанна ханым, музыка укытучысы яллап, нота белән пианинода уйнарга өйрәнә. Тормыш дилбегәсен бик теләп, кызы белән улына тапшырган инде ул.

Шулай тыныч кына яшәп яткан көннәрнең берендә элекке дуслары Гани Абызов белән урамда очрашалар. Аяк өсте генә сөйләшкәндә дә күп кенә дусларны искә алалар, ләкин сөйләшеп сүзләре бетмәгәнне тоялар.

—Мәхмүдә белән килеп чыгыгыз әле, Гани,—ди Жанна ханым,—әвәлгечә, чәй янында сөйләшеп утырырбыз.

Шунда ук вакытын билгеләп, сүз дә куешалар. Нигъмәтиләр бу очрашуга Хәсән Туфанны да чакыралар. Хәсән ага яшь чагындагы танышы, Галимҗан дустында күп тапкырлар әңгәмә корып утырган, чын зыялы адвокат Гани Абызовны элек тә хөрмәт итә иде. Аның белән очрашуга шатланып ризалашты.

—Ба! Гани белән күрешәбезме!

Хәсән Туфан Жанна ханым гаиләсендә үз кеше. Себердән кайткач, аралары тагын да якынаеп китә. Элекке дуслардан санаулы гына калган кешеләрнең берсе бит ул. Шагыйрь биредә күңеленә ял таба. Дөрес, дуслары аны ялгыз калдырмыйлар. Туфанның көннәре Язучылар союзында, редакцияләрдә, шигырь кичәләрендә үтә. Әмма өендә аны салкын бушлык каршы ала. Аның сөекле хатыны, Лулуы юк инде. Монсу карашлы талчыккан йөзе генә күз алдыннан китми. Бердән-бер якын кешесе кызы Гөлгенәгә караган саен хатынын күргәндәй була. Тик Гөлгенә башка шул. Озак еллар әтисеннән башка үскән, заманча яшь кеше. Кайбер мәсьәләләрдә аңлашып та җитмиләр. Луизаны өзелеп сагынган чакларында шагыйрь төннәр буе утырып шигырь яза:

Синсез үтә, тинсез үтә
Иртәләрем, кичләрем...
Айлар буе, еллар буе
Сагындырсаң нишләрем?!

Нигъмәтиләргә тартылуы да аның элекке дуслык хакына гына түгел, гаилә җылылыгын тансыклаудан күрәсең. Аларга килсә үткән гомеренең бәхетле мизгелләре белән очрашкандай була. Кайвакытларда, иркенләп килгән чакларында күңелендәге шигырьләрен кәгазьгә төшерә. Шуларның берсен Йолдыз белән Энгельгә укып күрсәтә. Әмма яшьләргә ул ошап бетми: фикер ачылып җитмәгән, ди Йолдыз. Энгель исә, артык интим, кысасы тар дигән фикерне әйтә. Туфан бу шигырьнең берничә вариантын яза.

Атларымның тезләрендә
Иске яра эзләре:
Без шуларда гизгән идек
Сездә, дала җилләре.
Без шуларда кичкән идек
Сезне, бәла җирләре...
Атларымның тезләрендә
Иске яра җөйләре.

дигән вариантын почта белән Нигъмәтиләргә җибәрә. «Нәфрәтем һәм мәхәббәтем» дигән бу шигырь Йолдыз Нигъмәтуллинада кадерле истәлек булып саклана.

Төрле сәбәпләр белән читтә яшәгән әдәбият-сәнгать әһелләренең, туган якларына әйләнеп кайткан кошлар кебек, Казанга омтылган еллар була бу. Туфан гына түгел, Бакый Урманче кайта. Гомәр Гали күзгә күренеп китә. Ул бичара гаиләсе янында санаулы көннәр генә яшәп кала. Хезмәт иткән җирендәге эшләрен төгәлләп кайтырга дип, кире киткәндә, әҗәле тартып юлга чыгарган дип әйтерсең, бандит пычагыннан һәлак була. Бакый Урманче һәм Жанна ханымның яшь чагындагы танышы Борһан Бадамшин белән бергә Соловкида урман кискән Бәдәйле дә инде Казанда.

Ләкин ни генә әйтсән дә Тельман урамындагы 7 йортның Галимҗан Нигъмәти белән Жанна ханым яшәгән фатирдагы тормышны инде сагынып сөйләргә генә кала.

Тик мәңгелек ут дигән нәрсә дә бар бит әле дөньяда.Һәм ул батырлар кабере өстендә генә түгел, фидакарьләрнең йөрәгендә дә саклана. Мирас булып, буыннан буынга күчә. Озын-озак еллардан соң Жанна ханымның яңа фатирында җыелып утырулар, сүнә башлаган учакның яңадан кабынып китүе сыман була.

Бу елларда ул инде олыгайган, үзе дә кадерле кунак булып утыра. Мәҗлеснең хуҗалары инде Йолдыз белән Энгель. Кунакларның да күбрәге аларның хезмәттәшләре: Мөхәммәт Мәһдиев, Альберт Яхин, Азат Әхмәдуллин кебек яшьрәк галимнәр.

Ике буын кешеләре бу мәҗлестә бер-берләрен тулыландырып, Хәсән ага һәм Бакый Урманченың аксакалларга хас хикмәтле сүзләрен тыңлап, Бөдәйленең шаян мәзәкләренә күнелләре булып, яшьләрнең бүгенге әдәбият һәм сәнгать турындагы фикерләренә кушылып, Нигъмәтиләр вакытындагыча утыралар. Әлбәттә, мондый кичәләрне Жанна ханымның тальянда уйнап җырлавыннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Тезләренә гармунны китереп куюлары була, каешларын җайлап иннәренә сала да ул, күрүген беткәнче тартып, карлыкканрак тавышны тамак төбеннән чыгарып, борынгы никрут җырларын җырлый. Кешеләрне тыңлап күбрәк сүзсез утырырга яраткан Энгель шулай бер вакыт чәч төпләренә кадәр кызарып:

—Шундый булуың өчен рәхмәт, әнием. Йөрәгеңдәге яшәү утын сүндермәвеңә рәхмәт,—дип, әйтмичә түзалмый. Аның сүзен Йолдыз дәвам итә. Әйтерсеңлә ул да шул фикерне әйтергә уйлап торган. Күңеле белән яшь чакларына киткән, Нигъмәтиләрне, Сәйдәшләрне уйлап утырган Хәсән Туфанга карап:

—Хәсән абый, Сез кабызган утлар бит алар,—дип өсти.

Шагыйрь исә чал башын иеп, елмаеп кына куя. Ул дәшми. Бу мизгелдә сүзләр артык, күңелдә туган манзараны төссезләндерү генә булыр иде ул. Ә үткәннәр аның күңелендә һәркайчан сагышлы моң тудыра. Бөтен дөньясын онытып шул моң иркенә биреләсе, барлык вөҗүде белән шул серле дулкында тирбәләсе килә аның. Ул дулкыннар бере арты бере тәгәрәп киләләр дә яшьлекнең әле бер, әле икенче сәхифәләренә алып китәләр. Жанна ханымның җырын тыңлаганда Аксакалның шундый дулкыннар кочагында йөзгән чагы иде күрәсең. Ул дәшмәде.

Бер генә минутка тын калган мәҗлескә кайдандыр күкләрдән ингән кебек, әкрен генә җыр авазы килеп керде. Ире Наил Курамшинга сыенып утырган җырчы Хәдичә Гыйниятова Кәрим Тинчуринның «Кандыр буе» спектакленә язылган мәгълүм җырның көен әкрен генә, үз алдына гына көйләп куйгач, барсы да аның җырлавын үтенә башлады. Азат пианинога барып утырды, бүлмәдә Салих Сәйдәшев музыкасының көчле аккорды яңгырады. Хәдичә ханым җырның беренче сүзен генә үзгәртеп:

Сез кабызган утлар сүнми алар,
Сүнми алар хәтәр җилләрдә...

дип җырлап җибәрде. Кунаклар анар кушылды. Җыр озак дәвам итте.

Еллар уза тора. Шул гомердән бирле күпме сулар акты, ничәмә буын алышынды. 2000 елның декабрь аенда Салих Сәйдәшев, Хәсән Туфан һәм Галимҗан Нигъмәтинең сөекле хатыны, замандашларының дусы, фикердәше Жанна ханымның тууына 100 ел тулды. Бер үк елның бер үк аена туры килүен кара син аның! Дустанә мөнәсәбәтләре язмыш дәфтәренә алдан ук язылып куелган дип әйтерсең. Димәк, юллары кисешү очраклы гына булмаган. Алардан килгән матур традицияләр, иҗади дуслык, эчкерсез сөйләшүләр әле булса дәвам итә.

Мәҗлеснең хуҗалары инде Нигъмәтиләрнең варислары Йолдыз белән Энгель. Табындашлары да күбесе хуҗаларның шәкертләре, яшь галимнәр. Заманында Жанна ханымның кадерле кунаклары булган Альберт Яхин, Азат Әхмәдуллин, журналистлар Әминә Сафиуллина, Венера Ихсанова, Асия Гыйниятуллиналар да мәҗлеснең күрке булып утыралар. Ихлас дуслык булган җирдә, Туфан Миннуллин әйтмешли, дуслар җыелган җирдә, җитди сүзләр дә, уен-көлке дә күп була. Сәбәбе дә табылып тора бит аның. Менә мәсәлән, 1997 елда «Фән» нәшриятында Йолдыз Нигъмәтуллинаның «Татар һәм рус әдәбиятларының үсеш тарихында культуралар һәм цивилизацияләрнең типлары» дигән зур күләмле фәнни хезмәте аерым китап булып басылып чыкты. Күп еллык эзләнүләрдән туган бу хезмәтен галимә әтисе Галимҗан белән әнисе Маһиҗиһан Нигъмәтиләрнең якты истәлегенә багышлый. Татар әдәбиятының үсеш баскычларын яңача ачкан бу хезмәт 1999 елда Татарстан хөкүмәтенең еллык бүләгенә лаек була. Аның белән рус галимнәре генә түгел, Франция һәм Кытайда да кызыксыналар. Бу зур шатлыкны ничек итеп дуслар белән уртаклашмыйсың ди инде! Шушы мәҗлеснең тагын бер күркәм ягы булды, анда тын гына, тыйнак кына булып, Энгельнең улы, тарих фәннәре кандидаты Искәндәр белән филология фәннәре кандидаты Дениза да утырды. Галимнәр династиясенең яшь вәкилләре бабалары һәм аларның фикердәшләре кабызган дуслык утын сүндермәсләр әле.

**Вил Ганиев**

# XX ЙӨЗ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

## ТАРИХИ-БИБЛИОГРАФИК КҮЗӘТҮ

XX йөз башы татар әдәбиятының язмышына хәлиткеч үзгәрешләр кертә. Милли мәдәниятнең йөзе үзгәрә башлый, аның үсеш кыйбласы мәшрикътән мәгърибкә авыша. Әйтик, Төркиянең аурупалашуы француз теле һәм мәдәнияте аркылы барса, безнең әдәбият, безнең мәдәният Аурупаның әдәби формаларын рус теле, рус мәдәнияте аркылы үзләштерә. Ә инде Төркиядә укып кайткан яки Сорбоннада белем алган әдипләр, әлбәттә, француз телен дә беләләр.

XX йөз башында мөселман төркиләрнең үзара мәдәни бәйләнешләре көчле була. Татар язучылары аеруча төрек әдәбияты алдында баш ияләр; Төркиядә чыккан газета-журналларны, ул илнең әдипләре язган яки французчадан тәрҗемә иткән китапларны Казан, Уфа, Әстерхан, Оренбург һ. б. мәдәният үзәкләрендә яратып укыйлар. Төрки халыклар мәнфәгатен кайгырткан «Тәрҗеман» газетасының да файдасын әйтеп бетергесез; ул газета 1883 елдан чыга башлый; наширләре Исмаил бәй Гаспралы (1851-1914) һәм аның җәмәгате, мәшһүр сәүдәгәрләр нәселеннән чыккан Зөһрә Акчура (1862-1903) була. Төрки халыкларның аралашуына, бер-берен аңлауга, әлбәттә, уртак гарәп графикасы да, телләрнең тугандаш булуы да нык ярдәм итә. XIX йөздән XX күчкәндә әле фәнни тел сыйфатында гарәп теле сакланып килә. Мәшһүр тарихчы һәм дин белгече Шиһабетдин Мәрҗанинең (1813-1889) әсәрләре гарәп телендә. Тик инде Каюм Насыйри (1825-1902), гәрчә аның замандашы булса да, фәнни хезмәтләрен дә гарәп яки төрек телендә язмыйча, үз халкының җанлы сөйләм телендә яза, фәнни-популяр календарьларын да саф татар телендә нәшер итә. Авторның бу адымын тарихчы әдип Габделбари Баттал (1883-1969) яклап чыга: аның хезмәтләре татар теленең фән өчен дә яраклы булуын исбатлый, диган бәя бирә *(«Йолдыз» газетасы, 1912)*.

Шул заманның алдынгы фикер ияләре (гәрчә аларның күбесе руханилар нәселеннән чыккан булса да), дини хорафатлардан арынмый торып, фән һәм дөньяви белем юлына басмый торып, милләтнең алга китүе һәм аурупалашуы мөмкин булмаганын аңлыйлар. Шуңа күрә төрле буын вәкилләре арасында низаг та килеп чыккалый. Боларның берсен Зәки Вәлиди (1890-1970) үзенең «Хатирәләр»ендә тасвирлый. Юл уңаенда шунысын да әйтергә кирәк, галим булaрак Зәки Вәлиди иң әүвәл Казанда таныла: монда укый, аннары укыта, монда ук зур күләмле «Төрки-татар халкының кыскача тарихы» дигән тәүге фәнни хезмәтен дә чыгара (1915, 1917).

---

Вил ГАНИЕВ *(1934)—шагыйрь-тәрҗемәче, әдәбият галиме. Тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган теоретик мәкаләләр авторы. Мәскәүдә яши.*

Прогресска омтылган милли хәрәкәтне әйдәп баручыларның берсе, мәшһүр әдибебез Гаяз Исхакый (1878-1954) «Мусульмане России» (1915) дигән русча язган мәкаләсендә татар җәмәгатьчелегендәге үзгәрешләрнең тизлегенә һәм киң күләмдә баруына карата болай дип яза (тәрҗемә): «XX йөзгә кергәндә без нык укмашкан милли-мәдәни берәмлек хәлендәбез, ә инде җәмгыятьтәге җимереш-корылыш мәйданына үзебезнең рухани һәм матди үзенчәлекләребез, тирән милли үзаңыбыз булган милләт сыйфатында аяк бастык. Соңгы унбиш ел эчендә без ясарга мәҗбүр булган реформалар чын мәгънәсендә тарихи каһарманлык булды».

Гаяз Исхакыйның замандашы, мәшһүр педагог һәм журналист Шәриф Сүнчәләй (1885-1959) Парижда рус телендә чыга торган «Мусульманин» дигән журналда бездәге үзгәреш һәм реформаларның асылын болай дип аңлатып бирә (тәрҗемә): «Рәсәй мөселманнары гаҗәеп дәрәҗәдә алга киттеләр. Ни гомердән бирле мөселманнарны томалап торган караңгылык пәрдәсе, ниһаять, сүрелә башлады, шуннан алар, дәртләнеп, гүя әрәм киткән вакытларын кире кайтарырга керештеләр. Һәммә җирдә яңа ысул белән укыту өчен кыз балалар һәм ир балалар мәктәпләренең, уку залларының, басмаханәләрнең ачылуы, яшьләрнең урта һәм югары рус уку йортларына агылуы, спектакль куюлар, әдәби һәм музыкаль кичә уздырулар, яңадан-яңа оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләр нәшер итү—болар барысы да мөселманнарның белемгә сусавын, мәгърифәтле халыкларга тиң булырга омтылуын раслый».

Татар халкының милли үзаңы үсеп китүенә шәркыят галимнәре Агафангел Крымский (1871-1942) белән Владимир Гордлевский (1876-1956) теләктәшлек күрсәтәләр, ошбу халыкны мөселманнар дөньясын әйдәп баручылар дип кабул итәләр. Мәшһүр җәмәгать эшлеклесе, әдип Садри Максудиның (1880-1957) газетага язган публицистик мәкаләләренә һәм Дәүләт Думасындагы дәртле-дәлилле чыгышларына В. Гордлевский бик югары бәя бирә һәм Рәсәй мөселманнарының таләбе чамадан ашмаганын, бары тик гадел таләп булуын аңлата: «Мөселманнар бит фәкать үзләренә куелган чикләүне бетерергә йөриләр»,—ди.

Шуны да әйтергә кирәк, 1913 елның февралендә, Романовларның патшалык итүенә 300 ел тулу уңае белән Петербургта һәм Мәскәүдә тантаналы бәйрәм уздырганда, татар шагыйре Габдулла Тукай (1886-1913) «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» дигән шигырен иҗат итә. Анда автор, үзенең гадел таләп куюына инанган хәлдә, падишаһ хәзрәтләренә:

Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?—
Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!—

дип, катгый төстә рәнҗүен белдерә.

Казанда «университетлар»ны кичергән һәм Идел буенда яшәүче татар халкын якыннан белгән А. М. Горький: «Инородец» (чит-ят) дигән халыкларны рәнҗетү—XIX йөз һәм XX йөз башындагы Рәсәй тарихында аеруча хурлыклы сәхифәләр»,—дип яза. Патша хөкүмәте, барлык татар халкыннан, барча мөселманнардан күпме налог җыеп та, әлеге дә баягы «чит-ят» халыкларга һич югы мәгариф өлкәсендә матди ярдәм күрсәтүне үзенең бурычы санамый, ул халыкларның мәдәниятен үстермәве белән аларның киләчәгенә балта чаба.

Әнә шундый шартларда Гаяз Исхакыйның 1915 елда әйткән сүзләре— «тарихи каһарманлык» дигән бәяләмәсе бигрәк тәңгәл килә: үзенең мәдәниятен һәм рухи байлыгын яңадан торгызырга ниятләгән милләт, гасыр белән бердәм рәвештә алдынгы һәм дә мәгърифәтле булырга карар кылган халык ошбу вазифаны үз белдеге белән, хөкүмәтнең рәсми сәясәтенә каршы килеп, аңардан бернинди ярдәм алмыйча, фәкать үз маясына, үз мөмкинлекләренә таянып башкара. Мая дигәне шул заманда тернәкләнеп килгән яшь-яшь буржуазиядә бар икән ләбаса! Әйтик, җәдитчеләр алга сөргән мәгариф ысулын, уку-укытуны яңача корып җибәрүне мәгъкуль күреп, милли буржуазия тормыш итү өчен кирәкле фәннәрне, урыс телен, төрки халыкларның тарихын өйрәтә торган ысул җәдит мәктәпләрен ачарга ярдәм кулы суза; шулай итеп, фәкать мәктәпләрдә реформа үткәрү буларак кына башланып

киткән җәдитчелек иҗтимагый хәрәкәткә әверелә. Исемнәре бүгенгәчә халык телендә йөргән иганәчеләр булышлыгы белән китаплар һәм газета-журналлар чыгарыла, яңа мәдәни казанышлар булдырыла; әдипләр һәм шагыйрьләр халык мәнфәгатен яклау, халыкның үзаңын үстерүгә йогынты ясау мөмкинлегенә ирешәләр. Әлеге иҗтимагый хәрәкәттән руханилар да читтә калмыйлар; әйтик, Фатих Кәриминең әтисе Гыйльман ахун руханилыктан ваз кичә һәм, сәүдәгәр Гани Хөсәенов иганәсенә таянып, 1900 елны Оренбургта басмаханә сатып ала, китаплар нәшер итү белән шөгыльләнә башлый. Аның бу изге эшен улы—язучы Фатих Кәрими дәвам иттерә.

1905-1907 еллардагы революция тәэсирендә дөрләп киткән милли үзаң, якты өметләр татар халкының рухи-мәдәни үсешенә китерә, моңа хәтта реакция еллары да комачаулык итә алмый. Пушкиннар заманында рус әдәбияты өр-яңадан туган булса, татар әдәбиятында да нәкъ шундый хәл кабатлана. Татар галимнәре аны «алтын чор» (Резеда Ганиева) һәм «ренессанс» (Мансур Хәсәнев) дип бәялиләр.

Алтын дәвердә ирешелгән казанышлар яңа әдәбиятның йөзен-дәрәҗәсен билгели, бөтен XX гасырга юл сыза. Һәм аның эстетик кыйммәте бүгенгәчә саклана. Шигърият өлкәсендә әйдәп баручы—юл салучылар: Габдулла Тукай (1886-1913), Дәрдмәнд (1859-1921), Мәҗит Гафури (1880-1934), Сәгыйт Рәмиев (1880-1926), Шәехзадә Бабич (1895-1919); прозада: Гаяз Исхакый (1878-1954), Фатих Әмирхан (1886-1938), Шәриф Камал (1884-1942), Фатих Кәрими (1870-1937), Закир Һади (1863-1933), Шакир Мөхәммәдев (1865-1923); драматургиядә: Гафур Коләхмәтов (1881-1918), Галиәсгар Камал (1879-1933), Мирхәйдәр Фәйзи (1891-1928), Кәрим Тинчурин (1887-1947), Фәтхи Бурнаш (1896-1946).

Алардан бераз калышрак шагыйрьләр дә актив иҗат итә, Нәҗип Думави (1883-1933), Сәгыйт Сүнчәләй (1889-1941), Миргазиз Укмасый (1883-1946), Зариф Бәшири (1888-1962), Зыя Ярмәки (1887-1965), Ибраһим Башмаков (1893-1913), Габдулла Харис (1893-1931), Габдрахман Сәнгати (1893-1917), Фазыл Туйкин (1888-1939); прозада: Риза Фәхретдин (1859-1933), Мөхәммәт Гали (1893-1952), Садри Җәлал (1891-1943), Фәйзи Вәлиев (1882-1914), Шәһит Әхмәдиев (1888-1930), әдәби тәрҗемә өлкәсендә мәшһүрлек казанган Солтан Рахманкулов (1888-1916) һ. б.

Гасыр башындагы әдәбиятта үз сүзләрен шагыйрәләр дә әйтәләр. Менә алар: Маһруй Мозаффария (1873-1945), Заһидә Бурнашева (1895-1977), Мәхмүдә Мозаффария (1893-1969), Галимәтелбәнат Биктимерова (1876-1906), Галимә Рәхмәтуллина (яшәгән еллары билгесез) һ. б. Арада Заһидә Бурнашева дигәне аеруча талантлы була. Шигырьләрен «Гыйффәт туташ» псевдонимы белән чыгаручы бу шагыйрә Рязань губернасында гаять иске карашлы сәүдәгәр гаиләсендә туа, кече яшьтән шигырь яза, Пушкин белән Лермонтовны тәрҗемә итә, шигырьләре Мәскәүдә Гаяз Исхакыйның «Ил» газетасында чыккалый. Әтиләре шигырь язудан туктатырга карар кылгач, Мәскәүгә күчеп китә. 1915-1917 елларда Мәскәүдә Гыйффәт туташның өч шигырь китабы дөнья күрә.

Гаҗәеп дәрәҗәдә тиз һәм кыю рәвештә үзенә юл ярып килгән яңа әдәбиятта Габдулла Тукай белән Гаяз Исхакыйларның иҗаты аеруча зур тәэссоратка ия була.

Үткән йөзләрдәге татар шагыйрьләренең казанышын зур осталык белән бергә туплап, Габдулла Тукай чынбарлыкны, милләтебез кичергән бөтен хәлләрне реалистик рухта сурәтләргә, һәртөрле холык-характерны күрсәтергә сәләтле, һәркемгә аңлаешлы үз стилен китереп чыгара. Аның шигырь, поэма, әкиятләрен татар халкы яратып укый, төрле даирәләрдә шулчаклы мәшһүрлек казану аңа кадәр бер генә шагыйрьгә дә насыйп булмаган була. Әдәби тел буларак халыкка бик үк аңлашылып бетмәгән борынгы татар-төрки тел генә рәсми рәвештә яшәп килүгә карамастан, Габдулла Тукай, үзеннән алдарак аз-маз телне гадиләштерергә тырышкан әдипләр тәҗрибәсенә таянып, барча халыкка да аңлаешлы яңа әдәби тел китереп чыгара һәм әнә шул яңа телдә иҗат итеп, бу телнең искиткеч шәп үрнәкләрен бирә—әдәби телебезнең мөмкинлекләре чиксез икәнен исбатлый. Шагыйрь үзе әдәбият өлкәсендәге демократик юнәлешне кулай күрә һәм әйдәп баручыга әверелә. Нәкъ менә

Тукай йогынтысына бирелеп, бөтен милли мәдәниятебез демократик юл ала: гап-гади авыл кешесе әдәби әсәрләрнең каһарманына әверелә (Тукай үзе, үтемлерәк булсын өчен, еш кына русның «мужик» сүзен куллана). Фольклорны шагыйрь «халык әдәбияты» дип атый һәм аңа соклануын белдерә.

Гаяз Исхакыйның иҗаты да татар халкының иҗтимагый тормышындагы зур үзгәрешләрне чагылдыра. Аның «Зөләйха» пьесасын җәмәгатьчелек патша хөкүмәтен гаепләү акты буларак кабул итә, һәм Фатих Әмирхан шулай бәяли дә. Рәсәйдә татар халкын көчләп чукындыруны тасвирлаган бу пьеса Казанда 1917 елның мартында сәхнәгә куела. Шул заманда язган роман, повесть, хикәя һәм пьесаларында олуг талант иясе милли хәрәкәтнең аеруча кискен якларын, андагы каршылыкларны, характерлар чарпалашуын җәмгыятьнең барлык даирәләре тормышында чагылдыра. Әдипкә милләтебезнең яңадан тууы да, хатын-кыз эмансипациясе дә, рухи таркаулык та, халыкның киләчәге дә тынгылык бирми. Кайчандыр булачак дәверләрдә татар халкының язмышы нинди буласын күз алдына китерергә омтылу нәтиҗәсендә язучы «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән повестен иҗат итә (повесть 1904 елны дөнья күрә). Газиз халкының 200 елдан соң булса да һәлакәткә, бетүгә дучар ителү мөмкинлеген хыялында күзаллагач, коты алынган әдип бу хәлне үзенең замандашларына җиткерергә, аларны кисәтеп куярга ниятли. Г. Исхакый милли проблемаларны хәл итәргә талпыну белән генә чикләнми, бәлки әле, шәхси тәҗрибәсеннән файдаланып, 1907 елда «Зиндан» повестендә һәм «Бер поткынның саташулары» дигән романында укучыны патша төрмәсенең камераларына да алып керә.

Гаяз Исхакый үзенең иҗатын XIX йөздә хөкем сөргән мәгърифәтчелек реализмы традицияләренә таянып башлап җибәрә; мәгълүм булганча, мәгърифәтчелек әдәбияты чынбарлыкта акны карадан аерырга өйрәтә, әдәпинсаф ияләрен хуплап, намуссыз, көнче, ялганчыларны фаш итүе белән укучының игътибарын яулап ала. Тора-бара Гаяз Исхакыйның иҗатында кискен борылыш барлыкка килә: әсәрләрендә киң колачлы тасвирлау, табигатьнең матурлыгын сурәтләү, каһарманнарның образларында эчке каршылык, катлаулы һәм тирән хисләр өстенлек ала. Талантлы әдипнең иҗади казанышлары татар прозасын бер баскычка күтәрә. Язучының йогынтысы драматургия өлкәсендә дә гаять зур була. Чынбарлыкны тәнкыйтьләү аның иҗатында төп юнәлешкә әйләнә.

Мәгәр мондый шәхесләр көтмәгәндә килеп чыккандай тоелса да, алар кисәктән һәм бөтенләй буш урында барлыкка килми, бәлки гасырлар буена, бигрәк тә XIX йөздә әзерләнгән әдәби җирлектә барлыкка килә. (Рус әдәбиятында шундый ук вазифаны XVIII йөз үти.) Димәк ки, татар әдәбиятындагы «алтын гасыр» алдыннан килгән дәвергә дә күз салып үтү зарур.

Татар мәдәнияте XIX йөздә басмаханәле булып ала һәм европалашу ягына борыла. Әмма шул ук вакытта гарәп хәрефләрен матурлап сырлаучы хәттатлар әле кулдан күчереп язу һөнәреннән дә ваз кичмиләр.

Патша хөкүмәте нинди генә киртәләр куймасын, цензорлар ничек кенә тыярга тырышмасын, XIX йөздә милли китапларыбызны чыгару эше ярыйсы ук тернәкләнеп китә. Галимебез Әбрар Кәримуллин мәгълүматларына караганда, XIX йөз урталарына ел саен 50-60 исемдәге, ә инде гасырның азагына таба 160-170 исемдәге китап дөнья күрә. Шуларның өчтән бер өлеше халык иҗаты белән матур әдәбиятка туры килә. Беренче басмаханәне Казан каласында 1801 елда Габделгазиз Бурашев ачып җибәрә.

1804 елда Казанда университет эшли башлый (аны ачу тантанасы 10 елга соңгара). Бу хәл рус мәдәнияте һәм фәненең Шәрык дөньясына үтеп керүе буларак бәяләнә. Шундый зур уку йортының галимнәре Идел-Чулман төбәгендә яшәгән халыкларның тарихын, этнографиясен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен ныклап өйрәнергә керешәләр. Мәдәниятне һәм телләрне өйрәнү эшенә мәшһүр Шәрык факультеты аеруча зур өлеш кертә (1854 елда аны Санкт-Петербург университетына күчерәләр); XIX йөз уртасында Казан университетының китапханәсендә искиткеч зур кыйммәткә ия булган борынгы кульязмалар һәм әдәбият ядкарьләре тупланып өлгерә. Тик шунысын да әйтеп

үтәргә кирәк, Рәсәйдә «чит-ят халыкның» мәдәни-тарихи үсешенә тоткарлык ясауга юнәлдерелгән рәсми сәясәт аркасында Октябрь революциясенә чаклы бу мактаулы уку йортына безнең миллә вәкилләренә ишекләр, нигездә, ябык була.

Шуңа да карамастан, Казан университеты XIX йөздәге татар әдәбиятына зур файда китерә: аның Азия типографиясе дип йөртелгән басмаханәсендә билгеле бер түләү бәрабәренә шактый гына китап басыла. Ә инде мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасы ел саен диярлек чыгып тора (XII йөзнең ахыры—XIII йөзнең башында иҗат иткән шагыйрь Кол Галинең туган-үлгән еллары билгесез, фәкать аның әлеге поэманы 1223 елда тәмамлаганы мәгълүм).

XIX йөзнең азагына таба бездә инде басмаханәләр саны хәтсез була, гарәп шрифтының матурлап-бизәп ясалган үрнәкләре ишәя, китапны күпләп чыгару белән бергә аны сату эше дә җайга салына. Әйтик, Мәкәрҗә ярминкәсенә китапны күпләп илтү гадәткә әйләнә. Гарәп хәрефләре белән татарча язылган әдәби китапларны һәм дәреслекләрне Урта Азиядә һәм бүтән төбәкләрдә яшәүче төрки халыклар да бик яратып алалар. Бездә китап басуның гөрләп алга баруына әйләнә-тирәдәге бүтән халыклар да кызыгалар һәм, чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, үзләрендә дә бу эшне акрынлап кына кузгатып җибәрәләр. Чуаш халкының атаклы мәгърифәтчесе И. Я. Яковлев (1848-1930) Казан университетында укуын 1879 елда тәмамлаганнан соң үз халкына китаплар бүләк итү дәрте белән яши башлый: рус хәрефләренә таянып яңа алфавит булдыра, чуаш халкының авыз иҗатын җыеп, шуны китап итеп чыгара. Казандагы басмаханәләрдә башка телләрдәге китаплар да шактый басыла.

XIX йөздә Казан, Санкт-Петербург һ. б. шәһәрләрдәге басмаханәләрдә үз телебездә басылып чыккан матур әдәбият әсәрләренең күпчелеген шигырь китаплары тәшкил итә. Бу безнең халыкның борын-борыннан шигърияткә хирыслыгыннан килә. Габдерәхим Утыз Имәнинең (1756-1834) үзе үлгәннән соң да, 1840-1900 елларда 5 китабы дөнья күрә. Үткән йөздәге мәшһүр шагыйрьләрдән Гали Чокрыйга да шундый ук хөрмәт күрсәтелә. Әхмәт Кормашиның (1855-1883) «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» поэма-дастаны да күп тапкырлар басылып чыга, халык аны яратып укый. Ә инде Яков Емельянов (1848-93, керәшен татары, дьякон), Ибәтулла Салихов (1794-1867), Габделҗаббар Кандалый (1797-1860), Акмулла (1831-95) кебек, шул заманда яшәгән шагыйрьләрнең берәр китабы чыга, яки инде әсәрләре җыентыкларда дөнья күрә.

XIX йөз башындагы поэзиягә дини (суфичылык) белән дөньяви карашларның үзара чарпалашуы хас. Шагыйрьләрнең күбесендә әле ачыктан-ачык дини дидактизм өстенлек итә, кайчагында ул караш дөньяви хәлләрне сурәтләү белән үрелеп бара. Тик инде Г. Кандалый, Акмулла, Я. Емельянов һ. б. шагыйрьләрнең иҗади эзләнүләре безнең поэзиягә дөньяви юнәлеш бирә, яңача фикер йөртүгә һәм бөтен әдәбиятны җәмгыятькә хезмәт итүгә китерә.

XIX йөзнең икенче яртысында прозаның үсеп китүенә дә шартлар тудырыла. Муса Акъегетзадә (1864-1923) Казан университеты басмаханәсендә 1886 елда «Хисаметдин менла» дигән романын чыгара (бер елдан китап янә дөнья күрә). Татар әдәбиятында бу әсәр шул жанрда беренче карлыгач булып санала. Автор үзе аны «милли роман» дип атый һәм шуның белән үз милләтенең яшәешен-көнкүрешен күрсәтү өчен Европада нык таралган роман формасын куллануына ишарә ясый. Бу романда автор феодализмнан һәм мәгънәсез сүз куертудан арынырга омтылган җәмгыятьтә барган, шул заман өчен аеруча кискен, бәхәсле мәсьәләләрне, зур конфликтларны тасвирлап бирүгә ирешә. Хисаметдин мулла үзенең мәгъшукасына:

—... Безем ихтыяр вә хөрриятемезне ала алмаслар. Җаным! Инсан мәгыйшәтендә (кешенең яшәешендә.—В. Г.) бер баһалы вә яхшы шәй хөрряттер»,—дигән фикер әйтә. Ул заман өчен андый сүзләр гаять кыю булып яңгырый. Китапның бер елдан кабат басылуы тикмәгә түгелдер, күрәсең...

Икенче мәшһүр прозаигыбыз Заһир Бигиев (1870-1902) иҗади эзләнүләрендә тагын да тирәнгәрәк үтеп керә һәм «Мөңнәр, яхуд гүзәл кыз Хәдичә» һәм «Гөнаһе кәбаир» дигән романнарында гасыр азагында

халкыбызның тормыш-көнкүрешен реалистик буяулар белән сурәтләп бирә. Ул иҗат иткән образларга укучы ышана, аларга мөкиббән китә, аларны тормышчан дип кабул итә. Бу ике әдипкә гасыр очланганда Гаяз Исхакый килеп кушыла. Шунда инде безнең әдәбиятыбызда Аурупа халыклары әдәбиятларына хас зур күләмле чәчмә әсәрләр иҗат итүгә сәләтле көчләр пәйда булуы тәгаенләнә.

Бу елларда драматургиябез дә канат җилпергә әзерләнә. Габдрахман Ильяси (1856-95) Казанда 1887 елда «Бичара кыз» дигән пьеса чыгара. Тәүге драма әсәрен халкыбыз хуплап каршылый, 1888 елда аны өйдәге театрда гына уйнап та карыйлар, соңра ул һөнәри театр труппаларының репертуарында да урын ала.

Яңа гасырга аяк басканда проза жанры шактый гына тернәкләнеп өлгерә: Шакир Мөхәммәдевнең (1865-1923) «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай» (1901), «Яфрак асты, яхуд Мәкәрҗә ярминкәсе» (1902), «Яңа бәдәвам» (1903) повестьлары, Закир Һадиның «Бәхетле кыз» (1904) повесте, Галиәсгар Камалның (1879-1933) «Сабир хәзрәт» (1903) хикәясе, Мәҗит Гафуриның (1880-1934) прозада көч сынап каравы («Фәкыйрьлек белән үткән тереклек», 1903) һ. б. авторларның чәчмә әсәрләре дөнья күрә. Чәчмә әсәрләрне яратып укучылар да табыла: милләтнең хәл-әхвәлен дөрес чагылдырган һәм укучыга җитди караган өчен алар авторларны олылыйлар, хөрмәт итәләр. Әдәбият, гомумән, тормыш китабына әверелә. Чөнки әдәбият милли кимчелекләрне рәхимсез рәвештә сурәтләп күрсәтә һәм бүтән халыклар белән аралашуда үз урыныбызны катгый рәвештә билгеләргә өнди. Хәер, тәнкыйть уклары катып калган, хорафатны алга сөргән дин әһелләренә дә каршы юнәлтелә.

XX йөз башындагы янә дә бер күренеш игътибарны үзенә җәлеп итә. Зыялы яшьләрнең билгеле бер өлеше төркичелек белән мавыга башлый. Бу әдәби-иҗтимагый юнәлешкә искелекне яклау, гомумтөрки тарих бәрабәренә үз тарихыбызны борынгырак итеп күрсәтү, ислам динен алга сөрүчеләр вәхшилек дип күрсәтергә маташкан заманнарга, ягъни ислам динен кабул иткәнче булган дәвергә йөз тоту, шундагы мәдәниятебезне кире кайтарырга омтылу хас. Төркичелек яклылар төрки халыкларның мәдәни бердәмлеген яклыйлар, үз телләрендәге фарсы һәм гарәп сүзләреннән баш тартып, төркиләрнең үзләрендә элек-электән яшәп килгән сүзләрнең мәгънәсен ачыкларга, төрки телләр байлыгына таянып, яңа сүзләр ясарга тәкъдим итәләр. Төркичелекнең аеруча актив тарафдарларыннан берсе—әдип, җәмәгать эшлеклесе һәм галим Йосыф Акчура (1876-1936) була. Бу өлкәдә шулай ук Зәки Вәлиди (1890-1970), Садри Максуди (1878-1957) кебек күренекле шәхесләр дә активлык күрсәтәләр. Әмма татар һ. б. милләт зыялыларының төрки мәдәният һәм әдәбиятларны берләштерү нияте белән оешкан төркичелекне тора-бара сәяси агым дип бәялиләр һәм «пантюркизм», «пантуранизм» дигән ярлыклар да тагалар; шулай ук төркичелек идеяләрен үз мәнфәгатьләренә файдаланырга маташучылар да табыла. Тик инде төрки нигезләргә омтылуның файдасы да тимичә калмый: борынгы язма ядкарьләребез һәм тарихыбыз белән кызыксыну уяна, шулай ук төрки телләрнең сафлыгы өчен көрәш башлана, төрки сүзләр тамырыннан шактый гына яңа сүзләр ясала һ. б. Төркичелек юнәлешендә җиңүгә ирешүнең бер эстетик дәлиле моннан гыйбарәт: ислам динен кабул иткәнче яшәп килгән, төрки телләрнең яңгырашына якын торган силлабик шигырь төзелешен гарәпнең гарузы (дин белән бергә кергән мәдәни йогынты бар бит әле) кысып чыгарган булса, XX йөз башында ул ныграк кулланыла.

Гәрчә халык авыз иҗатында төрки телләрнең табигатенә якын силлабик шигырь төзелеше тулысынча саклана да, ислам динен кабул иткәннән соң язма шигъриятебездә гаруз (квантитатив үлчәм) хакимлек итә. Шагыйрьләребез читтән кергән әлеге алымны үз телебезгә яраклаштыру юлында бик күп көч куялар һәм еш кына гаҗәеп камил әсәрләр иҗат итүгә ирешәләр. Тик инде XIX йөзнең азагында шигъриятебезнең яңаруы, шигъри алымнарның күбәюе таләп ителә башлый. Шигырь төзелешендә басымны һәм рифманы игътибар үзәгенә куйган гаруз таләпләрен үтәү йөзеннән шагыйрьләр еш

кына рифма белән мавыгып, эчтәлекне бирүдән ваз кичәргә мәҗбүр булсалар, яңа шигъри формалар исә төрки телләрнең музыкаль яңгырашыннан оста файдалану мөмкинлекләрен бирә. Шул ук вакытта гарузның казанышлары поэзиябездән бөтенләй үк чыгарып ташланмый, әле бүгенгәчә (мәсәлән, архаикага охшатып язган очракларда) кулланыла.

XX йөзнең башында милли тәрҗемә мәктәбенә нигез салына. 1899 елда А. С. Пушкинның тууына 100 ел тулу уңае белән даһи юбилярның китапларын үзебезнең укучыларга саф ана телендә уку мөмкинлеген булдыру зарурияте көн тәртибенә килеп баса. Аның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү эшенә С. Рахманкулов (1888-1916) һәм М. Өметбаев (1841-1907) шикелле зур тәҗрибә туплаган шагыйрьләр алына, һәм аларның хезмәтләре гасыр башында ук дөнья күрә. Әдәби тәрҗемәнең искиткеч зур вә камил үрнәкләрен поэзиядә Г. Тукай, С. Сүнчәләй, С. Рәмиев, проза өлкәсендә Г. Исхакый, драматургиядә Г. Камал белән Ш. Камал бирәләр.

1917 елгы Октябрь революциясеннән соң татар әдәбиятының кыйбласы үзгәрә: совет чоры башлана...

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Рәсәйдә булган революцияләрнең өчесе дә татар халкының язмышына да, мәдәниятенә дә бик нык тәэсир итә. 1905-07 еллардагы революция вакытында безнең әдәбият бик тиз үсеп китә: поэзиядә Г. Тукай белән М. Гафури, прозада һәм публицистикада Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан революция ачкан мөмкинлекләрне әдәбиятның үсешенә файдалануга өмет баглыйлар. Милли юнәлештәге вакытлы матбугатка да юл ачыла: ана телендә шактый газета-журнал чыга башлый. 1917 елның Февраль революциясе татар зыялыларының күңелендә милләтебез язмышын нигездән үк үзгәртүгә өмет уята, мөстәкыйльлек яулап алу мөмкин булачагына ышанычын тагы да ныгыта. 1917 елның 1-11 маенда Мәскәү каласында Бөтенроссия мөселманнарының I корылтае уза. Анда татар, башкорт һ. б. төрки халыклардан 800 ләп вәкил җыела; депутатлар милли мәсьәләне хәл итүдә бердәм программа эшләп чыгаруны күздә тоталар. Мәгәр аны булдыра алмыйлар: моңа фикер каршылыгы комачаулык итә. «Федераллар» (Г. Исхакый, М. Бигиев һ. б.), татар халкының төрле төбәкләргә таралып, таркау яшәгәнен, мәдәният үзәкләренең төрле җирдә булуын күздә тотып, милли-мәдәни автономияләрне ил күләмендә төзүне яклап чыгалар. «Автономиялеләр» исә (З. Вәлиди җитәкчелегендә) милли автономияләрне татарлар, башкортлар һ. б. халыклар яшәгән төбәкләрдә төзү фикерен куәтлиләр. Корылтайдагы капма-каршы фикерләр 1917 елның җәендә Санкт-Петербургта аерым китап булып татар телендә басылып та чыга. Г. Исхакый белән З. Вәлидинең әнә шул фикер каршылыгы бөтен гомерләре буена сузыла: әүвәл үз теләкләрен Рәсәйдә гамәлгә ашырмакчы булып талпынып карыйлар, берни дә майтара алмагач, һәр икесе чит җирләргә китәләр (ә бу инде сөрген белән бер), анда да татулаша алмыйча, ике даһи Төркиядә дөнья куя...

Октябрь революциясе татар халкының язмышында кискен борылыш хасил итә: 1920 елда Совет хакимияте барча милләтләргә дә автономия биргән булып, бөтен дөньяны таң калдыра; ә инде автономия белән генә милли мәдәниятне алга этәреп булмаганы еллар узгач кына аңлашыла. Союздаш республикалардан аермалы буларак, автономиялесенең бөтен мәдәнияте бердәнбер нәшриятка сыеп бетәргә тиеш, ә инде кинематография ише нәрсә хыялда гына кала икән... Рәсәйдә яшәгән, әле кайчан гына татар мәдәниятеннән белем алган, рухи азык алган төрки халыклар (казакъ, төрекмән, үзбәк, кыргыз) союздаш республика статусы алганнан соң тиз арада китап басу эшен дә, кинематографияне дә һ. б. җайга салалар.

1917 елның Октябреннән соң татар әдәбиятының үсешен аның эчке закончалыгы (тел, традицияләр, образлар системасы, дөньяны күреп аңлауда милли вә эстетик үзенчәлекләр) һәм ул яшәгән объектив шартлар (мәдәниятнең идеологик кысалардан, билгеле бер сыйнфый юнәлештән читкә тайпылмаска тиешлеге һ. б.) билгели.

Октябрьдән соңгы әдәбиятыбыз өчен шунысы характерлы, аның үсешеннән иң олуг әдибебез Гаяз Исхакый читтә кала: 1918 елда үз-үзен

читкә сөргәннән соң ул ничек тә булса әдәби хәрәкәткә тәэсир итүдән мәхрүм була, аның иҗаты мәктәптә дә, югары уку йортларында да өйрәнелми, гомумән, ул ХХ йөз әдәбиятыннан сызып ташлана... Сыйнфый яктан пролетариат җырын җырламаган Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Г. Баруди, М. Бигиев, З. Вәлиди, Й. Акчура һ. б. мәшһүр әдипләребез, мәдәният әһелләребез дә шундый ук язмышка дучар ителә. Проза һәм драматургиядә бәйге тоткан олуг талант иясе Ф. Әмирханга да сан бетә. Һәр шәхескә сыйнфый күзлектән чыгып, ягъни пролетариат кавеменә файдалы булу-булмавына карап бәя бирелә. Әмма әдәбиятны авызлыклап алу артык зур нәтиҗә бирми. Идеологик чаралар нинди генә каты булмасын, иҗатның табигый һәм мәдәни агылышын тоткарлый алмый. Кызык бер хәл: 20 нче елларда шагыйрьләр шагыйре, миниатюраларны коеп кына куючы (элегрәк алтын приискалары тоткан) Дәрдмәнднең иҗаты дан казана. 1928 елда чыккан шигырьләр җыентыгы тиз арада таралып бетә.

Октябрь революциясенә кадәр милли зыялыларыбыз өчен дә үрнәк булган язучыларыбыз халыкның язмышын хәл итүгә актив катнашып та, демократлыктан ваз кичмиләр. Милләтебезне мәгърифәтле Аурупа халыклары дәрәҗәсенә күтәрү ниятеннән чыгып, иҗтимагый прогрессны алга сөрсәләр һәм җәдитчелекне якласалар да, ислам диненә каршы килмиләр, фәкать дин әһелләрен тәнкыйтьләү белән чикләнәләр. Бу хәл Октябрьгәчә шулай дәвам итә. Габдулла Тукай вафат булганнан соң (1913) прогрессив язучылар үзләренең әйдәп баручылары дип Мәҗит Гафурины таныйлар. Шунысы кызык, большевикларга уңай караштагы мәшһүр язучы «Дин вә әдәб» журналында ислам диненә мәдхия җырлаган шигырен бастыра. Чөнки ул, милләтнең алга баруына диннең дә, әдәпле булуның да йогынтысы зур, дигән фикердә тора.

Язучыларның күбесе революцияне яңа эраның башлануы дип кабул кыла һәм ничәмә-ничә гасыр дәвамында изелгән милләтебезнең рухи яңарыш кичерүенә өметләнә. Октябрьне хуплап Г. Камал, М. Гафури, С. Рәмиев, Ш. Бабич һ. б. шигырь язалар. Бу елларда Г. Ибраһимов күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе булып таныла (юл уңаенда шунысын да әйтү кирәктер, ул В. И. Ленин белән кабинетына кереп сөйләшкән бердәнбер татар әдибе). 1919 елда ул Октябрьнең икенче елы уңае белән:

«...милли тел, милли әдәбият, милли мәдәният өчен, боларның үсүе өчен дөнья кадәрле киңлек, азатлык һәм мадди чаралар алдык»,—дип язып чыга.

Эмиграциягә киткән әдипләрне искә алмаганда, илдә яшәп калган барлык татар язучылары да яңа хөкүмәткә ризалык белдерәләр. Фатих Кәрими, Мәскәүгә күчеп, Коммунистик университетта (КУТВ—Шәрык хезмәт ияләренең коммунистик университеты) укыта. Риза Фәхретдин Уфада Диния нәзарәте мөфтие вазифаларын үтәү өстенә әдип вә галим буларак та иҗатын дәвам иттерә. Фәкать Дәрдмәнд кенә соңгы елларын Орскида ялгызлыкта уздыра. Ихтимал, бу аның ил эчендә «эмиграцияләнүе» булгандыр... Элекләре мәшһүр ике шагыйрьнең генә поэзиядә эзләре суына: С. Рәмиев Совет хакимиятенең Уралдагы бер оешмасында чиновник хезмәтен үти һәм әдәби тәрҗемә (проза) белән мавыга; Н. Думави исә мулла булып китә, 1926 елда «Хәзерге татар руханилары һәм аларның эшләре» дигән китап чыгара. Тарихның бормалы юлларыннан барганда иртәгә үзеңне нинди язмыш көткәнен әйтүләре кыен шул!..

Ватандашлар сугышы дәверендәге әдәбиятта гүя төрле буын вәкилләре үзара фикер алышалар, гәп куерталар. Бер яктан алганда, ХХ йөз татар әдәбиятына нигез салучылар әле иҗат итә: прозада Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, М. Гали, Г. Газиз, Ш. Әхмәдиев, С. Җәлал, Г. Рәхим, Я. Кәрим; шагыйрьләр М. Гафури, Ф. Бурнаш, С. Сүнчәләй, Д. Гобәйди, С. Рәмиев, М. Укмасый; драматурглар М. Фәйзи, Г. Камал (шагыйрь дә), К. Тинчурин һ. б. Икенче яктан, әле яңа иҗат юлына аяк баскан, озакламый татар совет әдәбиятын җигелеп тартачак яшь язучылар: шагыйрьләр М. Җәлил (1906-44), М. Максуд (1900-62), Ш. Фидаи (1902-20), И. Йосфи (1896-1921), Б. Рәхмәт (1897-1957), К. Әмири (1893-1962; драматург та), Н. Исәнбәт (1899-

1993; драматург та), Т. Ченәкәй (1893-1959), Ә. Сәгыйди (1895-1939); прозаиклар К. Нәҗми (1901-57; шагыйрь дә), А. Шамов (1901-90), Д. Юлтый (1893-1938), А. Таһиров (1890-1938); драматурглар Ш. Усманов (1898-1937; прозаик та) һ. б. Әдәбиятка әле кереп кенә килә торган язучыларның күбесе яуларда катнаша, ә кайсыберләренең гомере һәм иҗат юлы артык кыска булып чыга...

1918 елның гыйнварында «Олуг Төркестан» газетында (Ташкент) бөек шагыйрь һәм новатор Һади Такташның (1901-31) исеме күренә. Яшь шагыйрь Казан каласына күчеп килгәч, аның беренче китабы чыга (1923). Авторның ул җыентыгына дингә (һәм Аллага) каршы тезмә юллар белән язылган «Җир уллары» трагедиясеннән тыш әле тагын үзенең иҗади программасы да урын ала. Дәртләнеп язган бу программада автор поэзияне яңартырга, заманча язарга кирәклеген исбатлый, барча шагыйрьләр белән бергә үз алдына да куйган новаторлык таләпләрен аерымачык билгели. Шул ук 20 нче елларда япь-яшь шагыйрь Гадел Кутуй (1903-45) үзен татарның футуристы дип игълан итә: аның «Көннәр йөгергәндә» (1924) дигән тәүге җыентыгында футуристларга ияреп язган шигырьләре урын ала. Эксперимент ясау белән генә берни майтара алмаганын аңлагач, шагыйрь үзе үк ул юлдан ваз кичә.

Татар әдәбиятында 20 нче елларда, Гаяз Исхакый булмагач (1918 елда эмиграциягә китә), икенче бер олуг талант иясе—Галимҗан Ибраһимов алга калкып чыга. Бу әдипнең 20-30 нчы еллардагы иҗаты мәдәни һәм иҗтимагый тормышыбызда әйтеп бетергесез зур роль уйный. Ул иң беренчеләрдән булып яңа кешене тәрбияләү, димәк ки әдәбиятта да яңа каһарман образын иҗат итү зарурлыгын «Яңа кешеләр» драмасы (1921) белән раслый. Ә инде мәшһүр «Безнең көннәр» романы (1919) ачыктан-ачык революцион эпопея булып яңгырый, фетнә һәм фетнәчеләрне китереп чыгарган сәбәпләрне фәнни дөрес, сәнгати ышандырырлык итеп исбатлый. Г. Ибраһимовның иҗади эзләнүләрен әдәби тәнкыйть замана таләпләренә җавап бирә торган новаторлык дип бәяли. Әйтик, Фатыйх Сәйфи-Казанлы (1888-1937) «Яңа кешеләр» пьесасына карата, автор үзенең каһарманы сәяси яктан ни рәвешле үскәнне тамашачының күз алдында алып бара, дип яза. Мондый «тәти» сүзләр әдәби әсәргә турыдан-туры сәяси күзлектән чыгып, социологик бәя бирү буларак яңгырый. Әдәбият дөньясындагы әлеге күренеш 20 нче елларда башлана һәм аннан соңгы елларда бик нык чәчәк ата.

20 нче елларда, пролетар әдәбияты әле туып кына килгәндә, Г. Ибраһимов яңа сәнгатьнең нинди юнәлештә барырга һәмниләр эшләргә тиешлеген билгеләүче идеологка әверелә. Революциядән соң аеруча актив рәвештә әдәбият теоретигы һәм галим сыйфатында чыгышлар ясый: филология һәм тарих мәсьәләләрен (аерым алганда, татар халкының революцион хәрәкәте тарихын) өйрәнә. 1926 елның 25 феврале—6 мартында Бакуда барган Беренче Тюркология корылтаенда төрки халыкларның яңалифкә (латин графикасына) күчүенә багышланган доклад белән чыга. Үзенең сыйнфый дошманнары дип караган кешеләргә ул һич тә рәхим-шәфкать күрсәтми: 1924 елда Мәскәүдә чыккан «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» дигән китабында элегрәк үзенең көрәштәшләре булган, соңрак сәяси эмиграциягә китеп, баррикаданың аргы ягында калган шәхесләрне гаять нык тәнкыйтьләп чыга.

20 нче елларда бер Г. Ибраһимов кына түгел, бүтән галимнәр дә үз әдәбиятыбызның үткәнен һәм үсеш юлын ачыклау юнәлешендә баш ваталар. Кайсыбер эзләнүләр әле бүген дә әһәмиятен югалтмаган. Җамал Вәлидинең (1887-1932) Петроград дәүләт нәшриятында 1923 елда рус телендә чыккан «Очерк истории образованности и литературы поволжских татар» һәм Габдрахман Сәгъдинең (1889-1956) Казанда 1826 елны дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» дигән хезмәтләре әнә шундыйлардан.

*Дәвамы киләсе санда*



# 6—ӘНГАМ (МАЛ-ТУАР) СҮРӘСЕ

**53.** Без аларны сынар өчен шулай чагыштырдык. Алар:

—Без түгел, шушы фәкыйрьләрме Аллаһның рәхмәтенә ирешәчәк?—дип әйтсеннәр өчен.

Шөкер иткәннәрне Аллаһ бик яхшы белеп тормыймыни?

*(Рәхмәтләрнең иң олысы, шөкер итүнең дә иң зурысы—Исламча яшәү.)*

**54.** Аятьләребезгә иман китергәннәр синең янга килгәндә син:

—Әссәләмүгәләйкем,—диген.—Сезгә рәхмәтле булуны Аллаһ Тәгалә үз өстенә алды. Әгәр дә арагыздан берәү абайламыйча яманлык кылса, соңра тәүбә итсә, төз юлга басса, Аллаһ аны гафу итәр, Ул бик тә миһербанлы, ярлыкаучы,—дип әйт.

**55.** Гөнаһ кылганнарның юлы ачык күренеп торсын өчен, аятьләребезне шулай тәфсилләп аңлатабыз.

**56.** Әйт:

—Аллаһтан башка, сез табына торганнарга *(сыннарга, ташка, бүтән ялган ходаларга)* баш ору миңа тыелган,—диген.—Сез хыялланган, сез һәвәсләнгән нәрсәләргә мин иярмәм. Ияргән тәкъдирдә мин тугры юлдан язган булырмын.

**57.** Тагын әйт син:

—Мин Раббыбыздан ап-ачык дәлил китердем вә сез аны ялганга чыгардыгыз. Сез бик тиз килүен теләгән җәза минем кулда түгел, хөкем бары тик Аллаһ хозурында. Ул хакыйкатьне аңлатыр. Ул дөрес хөкем бирүчеләрнең иң гаделедер,—диген.

*(«Кяферләр Аллаһка инанмаганнарына күрә, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең күктән таш яудыруын теләделәр яки, могҗиза буларак, үзләренә шундый бер җәза бирелүен сорадылар. Әле ул вакытта Ислам дине яңа гына керә башлаган иде. Шуңа күрә, кешеләр арасында Ислам Пәйгамбәренең рәхимсезлеге турында хәбәр таралмасын өчен, Аллаһ Пәйгамбәргә андый җәза бирү могҗизасын иңдермәде».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**58.** Шулай дип әйт:

—Бик тиз килүен сез теләгән җәза, минем ихтыярымда булса иде, эшне шундук сезнең янда бетерер идем, залимнәрне иң яхшы белүче бер Аллаһтыр,—диген.

**59.** Яшерен серләрнең ачкычлары Аллаһ хозурындадыр, аларны Аллаһтан башка һичкем белмәс. Ул коры җирдә, дингездә ниләр бар, һәммәсен дә белер. Аның ихтыярыннан башка хәтта бер генә яфрак та өзелеп төшмәс. Ул туфрактагы тузан бөртеге хәтле нәрсәләрне дә белеп тора. Китапта булмаган яшь яки корыган бер генә нәрсә дә дөньяда юк. *(Барысы турында да Ләүхел Мәхфүздә язылып куелган.)*

**60.** Төннәрен сезне *(вакытлыча)* үтергән дә *(йоклаткан)*, көндезләрен ни

---

Дәвамы. Башы 1 санда.

**Журнал өчен Рабит Батулла әзерләде.**

кылганыгызны белгән дә, иртәләрен җаныгызны тәнегезгә кайтарып терелткән дә *(уяткан да)* Улдыр. Сезгә тигән гомерне тәмам итәр өчен. Соңыннан Аның хозурына кайтарылачаксыз. Соңра дөньяда кылганнарыгыз турында Ул хәбәр бирәчәк.

**61.** Коллары өстеннән Ул гына мотлак хакимдер. Сезгә Ул сакчы фәрештәләр күндерер. Ниһаять, берәрегезгә әҗәл килсә, илчеләребез *(махсус вазифа башкаручылар)* аның җанын алыр. Бу эштә алар *(җан алучылар)* хилафлык кылмаслар. *(Ягъни, Газраил үлемгә дучар ителгәннең җанын алмыйча калмас.)*

**62.** Соңыннан кешеләр чын хуҗа—Аллаһ хозурына китерелер. Белеп торыгыз, хөкем бары тик Аллаһның эше, Ул хисап алучыларның иң житезедер.

**63.** Әйт:
—Коры җирдәге вә дингезләрдәге караңгылыктан *(куркыныч дәһшәттән)* сезне кем коткарыр?—дип сора.
Аллаһка эчтән генә ялварып:
—Әгәр безне коткарсаң, хактыр ки, без шөкер иткәннәрдән булырбыз,—дип догалар укыгыз,—дип әйт.

**64.** Әйт:
—Алардан вә бөтен бәлаләрдән сезне бары тик Аллаһ кына коткарачак,—диген.—Соңра сез Аңа тиң зат эзли башлаячаксыз,—диген.

**65.** Әйт:
—Аллаһ сезнең өстегезгә *(күктән давыл, буран, зилзилә)*, аяк астыгыздан *(җирдән корылык, мур кырылышы)* җәза җибәрергә дә, бер-берегез белән сугыштырып, берегезгә икенчегезнең мәкерен, әшәкелеген татытырга да кодрәтле,—диген. Бакчы, алар төшенсен дип, аятьләребезне ничек тәфсилле аңлатабыз.

*(«Әүвәлге кавемнәр үзләренә күндерелгән пәйгамбәрләрне кабул итмичә, аларга каршы баш күтәрделәр, тыелгысыз бу гыйсъяннар вакытында Аллаһ аларның кайберләрен башларына күктән таш яудырып, һәлак итте, мәмләкәтләрен таш астында калдырды, башкаларын да дәһшәтләргә дучар итте, илләрен хәрабәләр хәленә китерде. Кайберләрен үзара талаштырып, бер-берсен кырдырды. Бу аять Мөхәммәд өммәтенә кисәтү рәвешендә иңдерелде».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**66.** Коръән—ул Хакыйкатьнең үзе, ләкин синең халкың аны инкарь итте. Әйт:
—Мин сезнең вәкилегез түгел!—диген. *(Сезнең теләкләрегез, үгетләрегезне үтәүче түгелмен мәгънәсендә.)*

**67.** Һәр хәбәрнең тормышка ашачак бер вакыты була. Озакламый сез Хакыйкатьне күрерсез.

**68.** Аятьләребез турында урынсыз бәхәсләшә торган кешеләрне очратсаң, сүзләре башка нәрсәгә күчкәнчегә чаклы, алардан ерак тор. Әгәр шайтан сиңа моны оныттырса, һич югында исеңә төшкәч, залимнәр белән рәттән утырма.

**69.** Тәкъва кешеләр кяферләр өчен җаваплы түгел, ләкин:
—Бәлки тугры юлга басарлар,—дип искәртү кирәктер.

**70.** Дин белән уйнаучы, динне бер көлке чыганагы итүчеләрдән, дөнья тормышына алданган *(азган)* кешеләрдән ерак тор. Ләкин син бары тик аның белән *(Коръән белән)* вәгазь ит, аларга Ахирәттә Аллаһтан башка ярдәм итәрлек дус та, ярлыкаучы да булмасын әйт, тәмугка эләкмәс өчен алдан ук хәзерлек күрсеннәр өчен. Бар булган мөлкәтен бирсәләр дә, *(соңарган тәүбәләре)* кабул кылынмас. Алар дөньяда кылган гөнаһлары аркасында җәзага тартылачак. Көферлек итеп, *(Аллаһны)* инкарь иткәннәре өчен, аларга кайнар су вә хәтәр газап булачак.

**71.** Әйт:
—Аллаһны инкарь итеп, безгә файда да, зарар да бирми торган сыннарыгызга табыныйкмы? Аллаһ безне тугры юлга бастырганнан соң да үкчәләребезне кире таба борыйкмы? *(Яңадан кяфер булыйкмы?)* Шайтаннар юлдан яздырып, чүлгә кертеп адаштырган бичаралар хәлендә калыйкмыни? Адашмаганнарның: безнең янга килегез, *(тугры юлга басыгыз)* дип чакырганнарын көтикме? Аллаһ күрсәткән тугры юл, шөбһәсез, иң дөрес юлдыр ки. Без галәмнәрнең Раббысына буйсынырга әмер ителгән,—диген.

**72.** Безгә:

—Намазны дөрес укыгыз һәм Аллаһның җәзасыннан куркыгыз,—диеп боерылган.

Ул—Үз янына безне җавапка туплаячак Аллаһтыр,—диген.

**73.** Ул Үз хикмәте белән күкләрне, Җирне яралткан. Ул:

—Бар бул!—дип әйтүгә бөтен нәрсә пәйда булачак. Аның сүзе Хакыйкатьтер. Сур *(быргысына)* өргән көн дә *(ягъни, Кыямәт көне дә)* Аныкы. Күренмәгәнне дә, күренгәнне дә Ул белеп торучы. Ул, шөбһәсез ки, хикмәт иясе, һәр нәрсәдән Аның хәбәре бар.

**74.** Бервакыт Ибраһим атасы Азәргә әйтте:

—Син сыннарны тәнре итәсенме? Чынлыкта, мин сине дә, халкыңны да юлдан язган буларак күрәмен,—диде. **(75)** Без Ибраһимга, *(Аллаһка)* инанычы нык булсын дип, күкләрнең вә Җирнең бөек могҗизаларын шулай итеп күрсәттек. **(76)** Энгер-менгер төшкәч, бер йолдызны күреп алды да *(Ибраһим)* әйтте:

—Менә бу—минем Раббым,—диде.

Йолдыз сүнгәч, тагын әйтте:

—Мин болай сүнә торганнарны *(тәңре дип сөймәм)* танымам,—диде. **(77)** Ай туганын күргә ул *(Ибраһим)*:—Бу минем Раббым,—диде. Ай баткач та, ул:—Бу Раббым да мина тугры юл күрсәтмәсә, мин юлдан язган кеше булачакмын,—диде. **(78)** Кояш чыкканда ул:—Шушымы әллә минем Ходам?—диде. Бусы тегеләреннән дә зур. Кояш баткач, әйтте:—Әй, халкым, чыннан да, сезнең уйдырма ходаларыгызга ышанудан ерак торамын икән. **(79)** Шөбһәсез ки, мин бер Аллаһны таныймын, күкләрне, Җирне яралткан Аллаһка йөзем белән борылдым. Мин мөшрик *(күп ходайларга инанучы)* түгелмен,—диде.

**80.** Халкы аны ачулана башлады. Ул кардәшләренә әйтте ки:

—Хак Аллаһ тугры юлга бастырган кеше белән сез бәхәсләшергә җөрьәт итәсезме? Аллаһның җәзасыннан башка, мин сезнең Аллаһ дип табына торганнарыгыздан һич курыкмыймын. Раббымның гыйлеме бар нәрсәгә дә житәрлектер. Шул турыда уйлап, нигә сез гыйбрәт алмыйсыз? **(81)** Һәм мин ни өчен әле сез табынган сыннардан куркырга тиеш? Аллаһ тарафыннан:

—Сез Аллаһка тиңдәштерелгән сыннарга, потларга *(кояшка, йолдызларга)* табыныгыз,—дип Аллаһтан боерык бирелмәгән килеш, сез шул сыннарга *(теләсә нәрсәгә)* табынудан курыкмыйсыз бит әле. Аңласагыз әйтегез инде: шушы ике төркемнең кайсысы Аллаһның рәхмәтенә лаектыр?—диде.

**82.** Иман китерүчеләр һәм иманнарына гаделсезлек катыштырмаганнар гына Аллаһның рәхмәтенә лаек, алар гына тугры юлдадыр.

**83.** Ибраһимның денсез халкына каршы китергән дәлилләребез шулдыр ки. Теләгән кешебезне Без олы дәрәҗәләргә күтәрербез. Шөбһә юктыр ки, Раббың бөек хикмәт иясedер, чыны белән барысын да белүчедер.

**84.** Без аңа Исхак белән Ягъкубны бирдек, аннан элек тә Нухны, аның токымыннан Даутны, Сөләйманны, Әйюбне, Йосыфны, Мусаны вә Һарунны тугры юлга куйдык. Без игелекле булганнарны әнә шулай шатландырабыз. **(85)** Зәкәрияне, Яхъяны, Гайсәне, Ильясны *(шулай шатландырдык)*, чөнки аларның барысы да изгеләрдән иде. **(86)** Исмәгыйльне, Әльясаны, Лутны да тугры юлга күндердек. Һәрберсен дөньядагы барлык кешеләрдән югары дәрәҗәләргә мендердек. **(87)** Аларның аталары, балалары вә кардәшләренең кайберләренә дә *(өстенлек бирдек)*. Аларны сайлап алдык вә тугры юлга бастырдык.

**88.** Менә бу—Аллаһның һидаятедер *(тугры юлыдыр)*, Ул теләгән колларын шул юлга бастырыр. Әгәр алар да Аллаһка тиңдәш әзли башласалар, кылган гамәлләре, әлбәттә, юкка чыгачак.

**89.** Менә шулар инде үзләренә китап, хикмәт вә пәйгамбәрлек бирелгән шәхесләр. Әгәр алар *(кяферләр)* шушыларны инкарь итсә, шөбһәсез, алар урынына боларны инкарь итмәстәй башка бер кавемне китерербез.

*(Үзләренә китап иңдерелгәннәр—«пәйгамбәр», китап иңдерелмәгән илчеләр исә—«нәбиләр» була.)*

**90.** Пәйгамбәрләр алар—Аллаһ тугры юлга бастырган кешеләрдер. Син дә алар юлыннан кит. Әйт:

—Мин моңа *(пәйгамбәрлек вазифама)* сездән түләү сорамыймын. Бу *(Коръән)*—халыклар өчен бары тик бер вәгазьдер.

*(**«Алар юлыннан кит»** гыйбарәсе күчермә мәгънәдә, үз эчендә ул гыйбарә киная тота. Ягъни, моннан алда килгән пәйгамбәрләрнең тормышы бик тә кыен булды. Алар җәберләргә дучар ителде, алар янаулар, куркынычларга күкрәк киереп каршы бардылар һәм юлларыннан читкә тайпылмадылар, гонаһ кылмагыз, гадел булыгыз, дип кешеләрне тугры юлга өндәүдән туктамадылар. Юкса, сезне тәмуг көтә, дип кисәтүдән туктамадылар.)*

**91.** Алар *(кяферләр)* Аллаһны кирәгенчә танымадылар.

—Аллаһ һичбер кемгә берни дә иңдермәде,—диделәр. Әйт:

—Алайса, инсаннарга Муса алып килгән нурлы вә тугры юл күрсәтүче китапны *(Тәүратны)* кем иңдерде соң? Сез аны кәгазьгә күчереп яздыгыз, теләгәнегезне ачыклап, күбесен яшердегез. Сез дә, аталарыгыз да белмәгән нәрсәләр турында язылган иде анда; сез шуннан өйрәндегез,—диген.

*(Рәсүлем)* син:

—*(Сезгә)* Аллаһ *(җибәрде ул китапны)*,—диген дә, аларны ташлап кит, кереп баткан гөнаһлы сүз сазлыгында уйный калсыннар.

**92.** Бу Китап *(Коръән)* шәһәрләребезнең анасы *(Мәккәдә)* һәм аның тирәсендә яшәүче кешеләрне кисәтер өчен, сиңа иңдерелде вә ул—үзеннән элек килгән китапларны дөресләүче мөбарәк Китаптыр. Ахирәткә инанганнар моңа да *(Коръәнгә)* ышанырлар шәт һәм алар намазларын дөресләп укуларын дәвам итәрләр. **(93)** Аллаһка каршы ялган уйдырмалар чыгарып, үзенә һичбер нәрсә төшерелмәгән килеш:

—Миңа да *(Аллаһтан)* вәхий иңде,—дип әйтүче:—Мин дә Аллаһ иңдергән аятьләр кебек аятьләр иңдерәчәкмен,—дигәннән дә залим кеше булырмы икән!

Ул залимнәр котылгысыз үлем дәрьясына элэгеп, фәрештәләр аларга таба кулларын сузып:

—Тизрәк җаныгызны коткарып калыгыз, Аллаһ турында булмаганны сөйләгәнегез аркасында вә Аның аятьләренә каршы тәкәббәрлек күрсәткәнегезгә күрә, бүген мескенлек газабы белән җәзаланачаксыз,—дигән чакта аларның хәлен күрсәң!

*(«Мусәйләмәтул-Кәззаб белән Әсвәт-и Анси кебек ялганчы пәйгамбәрләр: безгә дә вәхий киләчәк,—дип пәйгамбәрлек дәгъвасы чыгардылар. Бу аять шул сәбәпле иңдерелде».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**94.** Хактыр ки, иң башта яралтканыбыз кеби, сез берәм-берәм *(ялгызыгыз)* Минем янга килерсез. Вә *(дөньяда)* сезгә бирелгән нәрсәләрне *(мал-байлыкны дөньяда ук)* калдырып килерсез. Сез уйлап чыгарган *(Аллаһка тиңләштерелгән)* яклаучыларыгыз да сезнең янда күренмәс. Хактыр ки, алар *(ул сынымнар, ялган ходалар)* белән арагыз киселде, сез тәнре дип санаган нәмәстәләр юкка чыкты. **(95)** Шик юк ки, Аллаһ *(үсемлек үстерер өчен)* орлыкларны, *(агач үстермәк өчен)* чикләвек төшләрен яралтучы. Җансыздан җанлыны ясаучы—Ул, җанлыдан үлене булдыручы да Ул. Менә Аллаһ шундыйдыр. Шулай булгач, ничек итеп сез *(Хактан)* йөз чөерәсез? **(96)** Таңнарны яктыртучы да Ул. Төннәрне Ул ял итәр өчен, Кояш белән Айны Ул *(вакыт үлчәме өчен)* хисап өчен яралтты. Менә бу нәрсәләр мотлак акылга ия, һәр нәрсәне белеп торучы кодрәтле Аллаһныкыдыр. **(97)** Ул коры җирдә һәм диңгездә юлыгызны турылар өчен йолдызларны яралтты. Хактыр ки, мәгълүматлы халык өчен аятьләрне тәфсилләп аңлаттык. **(98)** Ул сезне бары тик бер җаннан яралтты. Сонра *(сезнең өчен)* яшәү урыны һәм дә иминлек җире хәзерләде. Аңлый торган кавемнәр өчен аятьләребезне бәян иттек.

*(Бу аятьне тәфсирчеләр төрлечә шәрехли. «Яшәү урыны» гыйбарәсен «тормыш итәрлек җир», дип тә тәрҗемә итәләр. Җөмләнең азагындагы «иминлек җире» исә аналык, бала ярала торган урын яки мәет кереп ята торган кабер мәгънәсендә дә аңлатыла. Башкача алганда, бу аятьнең икенче өлеше менә шушы мәгънәдә яңгырар иде: соңра сезнең өчен Җир йөзендә яшәү урыны бирде һәм Җир астында Кыяматкә кадәр ятар өчен кабер куенын хәзерләде.)*

**99.** Күктән су койдырган да Ул—Аллаһтыр. Менә шулай итеп, Без төрле үсемлекләрне сугардык. Ул яшел үсемлекләрдән бер-берсенә тыгыз урнашкан орлык бөртекләре чыгардык. Хөрмәнең ботакларыннан асылынып торучы тәлгәшләр, йөзем

баглары, бертөрлесе бер-берсенә охшаган, икенчеләре бер-берсенә охшамаган зәйтүн вә нар бакчаларын булдырдык. Тулып өлгергәндә җимешләрен татып карагыз. Шикләнмичә иман китергәннәр өчен монда гыйбрәтләр бардыр.

**100.** Мөшрикләр җеннәрне Аллаһка тиң күрделәр. Гәрчә җеннәрне дә Аллаһ яралтты. Моннан тыш, алар ни сөйләгәннәрен белмичә, Аның *(Аллаһның)* угыллары, кызлары булганлыгы турында уйдырмалар сөйләделәр. Әстәгъфирулла! Алар сөйләгәннәрдән Ул өстен тора.

*(«Гарәпләр арасындагы кайбер потпәрәстләр, ягъни сыннарга табынучылар, җеннәрне Аллаһ белән тиң күрәләр иде. Ләкин алар җеннәрнең дә Аллаһ тарафыннан яралтылган затлар икәнен һәм Аллаһ яралткан нәрсәләрнең Аллаһка тиң була алмаганлыгын башларына да китермиләр иде. Бигрәк тә яһүдләр Гозәер пәйгамбәрне Аллаһның углы, дип таныдылар, христианнар исә Гайсә пәйгамбәрне Аллаһның углы, диделәр. Мөшрикләр дә фәрештәләрне хатын-кыз җенесле дип, Аллаһның кызлары, дип уйлыйлар, шул сәбәпле Аллаһ бу аятьне иңдерде».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**101.** Ул тиңдәше булмаган күкләрне вә Җирне юктан бар итте. Каян килеп аның баласы булсын. Аның хатыны юк бит. Һәрнәрсә—Ул яралткан әйбер. Вә Ул—һәрнәрсәне белүчедер. **(102)** Раббыбыз булган Аллаһыбыз менә шулдыр. Аннан башка һичбер тәңре юктыр. Ул бар нәрсәне дә яралтучы. Бәс, Аңа гына инаныгыз. Ул бар нәрсәдән дә өстен бер вәкил. **(103)** Ул күзгә күренми. *(Гыйлеме белән)* Ул *(барча)* күзләрне *(нәрсәләрне)* күрүчедер. *(Бәндәләре хакында)* барысын да үтәли *(күреп)* белеп торучы, һәр нәрсәдән хәбәрдар.

*(«Аллаһны күрер өчен безнең күзләребез җайланмаган, фикер-аң белән дә Аллаһның нинди икәнен без күз алдына китерә алмаячакбыз. Әмма җәннәттә мөэминнәр Аллаһны күрәчәк. Аллаһ барча күрүчеләрне дә күрә».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**104.** *(Мөхәммәд әйтте):*

—Сезгә Раббыгыздан чын басыйрәтләр килде. ***(Басыйрәт****—күңел күзе, мантыйкый фикер йөртеп, нәтиҗәләргә ирешү, дигән мәгънәдә.)* Күңел күзе ачылган *(Корьән белән гамәл кылган)* кеше файда күрер, кемнең *(күңел)* күзе сукыр калса, зыяны үзенә булыр. Мин *(Мөхәммәд)* сезнең өстән каравылчы булып тора алмыймын.

*(«Аллаһ инсаннарга ике төрле күз биргән. Маңгай күзе һәм күңел күзе. Маңгай күзләре белән кеше матди әйберләрне күрә. Күңел күзе белән, мантыйк белән, акыл белән, абстракт фикерләве белән күзгә күренмәгән нәрсәләрне дә күрә ала».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**105.** Аятьләрне Без әнә шулай тәфсилле итеп аңлатабыз.

Тагын алар:—Син моны башкасыннан өйрәнгәнсең,—дип әйтмәсеннәр өчен. Белеме булган кешеләргә Без аятьләрне шулай төрлечә аңлатабыз. **(106)** Аллаһтан иңгән вәхий *(Корьән)*гә ияреп, артыннан бар. Аллаһтан башка тәңре юк. Мөшрикләрдән аерыл. **(107)** Әгәр дә Аллаһ ихтыяр итсә иде, алар *(Аллаһка)* тиң зат әзләмәс иде. Без сине аларның өстеннән күзәтче итеп куймадык. Син алар өчен бер *(җавап тотучы, хөкемдар)* вәкил дә түгелсең. **(108)** Мөшрикләрнең Аллаһка тиң күреп табына торган сынымнарын ачуланмагыз. Юкса, алар *(мөшрикләр)* наданлыклары аркасында хәттин ашып, Аллаһны сүгә башлар. Шулай итеп, Без һәр өммәтнең кылмышларына юл куеп, яхшы итеп күрсәттек. Соңыннан алар бары тик Аллаһ хозурына киләчәк. Аллаһ алар кылган гамәлләрне үзләренә күрсәтәчәк.

*(Риваятьләргә караганда, Мөхәммәде Рәсүлулла (с.г.с.) мөшрикләрнең потларын яманлап-хурлап йөри иде. Мөшрикләр: яки син тәңреләребезне хурлаудан туктыйсың яки без синең Тәңреңне хурлый башлаячакбыз,—диделәр. Шуннан соң бу аять төште.)*

**109.** Мөшрикләр:

—Әгәр дә безгә Аллаһтан берәр могҗиза *(аять)* килсә, без Аңа иман китерер идек,—дип Аллаһ исеме белән бик каты ант иттеләр. Әйт:

—Могҗиза иңдерү Аллаһ ихтыярында, теләсә,—иңдерер,—диген.

И-й, мөэминнәр, аларга могҗиза иңдерелсә, иман китерәчәкләрен каян беләсез? **(110)** Әүвәл иңдерелгән *(аятьләргә)* могҗизаларга да инанмаган кебек, *(алар монысына да)* инанмас иде; шуңа күрә, Без аларның күңелләрен *(аңламас)* вә күзләрен *(хакыйкатьне күрмәс итеп)* сукырайттык, үзләрен азгын юлда адашып йөрергә мәхкүм

иттек. **(111)** Әгәр дә Без аларга фәрештәләр иңдерсәк, мәетләр алар белән сөйләшә башласа, барча нәрсәне туплап, каршыларына китереп салсак, алар, *(Аллаh теләмәс, барыбер)* янадан иман китерәчәк түгел. Ләкин аларның күбесе бу турыда белми. *(Чөнки алар—надан.)* **(112)** Шулай итеп, Без һәр пәйгамбәргә кеше вә җен шайтаннарын дошман кылдык. Алар бер-берсен юлдан яздыру өчен ләззәтле сүзләр пышылдарлар. Раббың теләсә, алар шулай эшләмәгән булырлар иде. Син аларны үзләре уйлап чыгарган нәрсәләре *(ялганнары)* янында калдырып кит. **(113)** Ахирәткә ышанмаган кешеләрнең күңелләре аңа *(вәсвәсәле, ләззәтле өндәүләргә)* бирелсен, аннан хушлансыннар вә гөнаһ кылуларын дәвам итсеннәр, *(дип шулай эшлиләр)*. **(114)** Әйт син:

—Аллаhтан башка бер хаким эзлиммени? Гәрчә, сезгә Китапны ачык итеп иңдергән Улдыр,—диген.

Үзләренә китап иңдерелмеш кешеләр *(кяферләр)* Коръәннең чынлыкта Раббыбыз тарафыннан иңдерелгәнен беләләр. Сак бул, шикләнүчеләрдән булма.

**115.** —Дөреслек вә гаделлек белән Раббымның сүзе тәмам булды. Аның сүзләрен беркем дә алыштыра алмый. Ул ишетеп, белеп торучы,—диген. **(116)** Җир йөзендәгеләрнең күбесенә иярсәң, сине Аллаh юлыннан яздырырлар. Алар үз уйдырмаларыннан башка һичбер нәрсәгә табынмас, ялганнан башка сүз сөйләмәсләр. **(117)** Хактыр ки, синең Раббың, әлбәттә—Аллаh; юлыннан тайпылган-ны яхшы күреп-белеп торучы. Ул тугры юлдан киткәннәрне дә яхшы белеп тора. **(118)** Аллаh-ның аятьләренә инансагыз, Аллаh исеме белән бугазланган хайваннарның итен генә ашагыз.

*(Аллаhтан башка берәрсенең исеме белән чалынган мал итен яки үлгән мал итен ашау харам. Мал суйганда: бисмилләhи Аллаhу әкбәр, диеп әйткәндә генә мал ите хәләлдер.)*

**119.** Аллаhның исемен әйтеп чалган мал итен ашаудан сезне кем тыя? Юкса бит, Аллаh сезгә *(ирексезләп ашатыла торганнардан башка)* нәрсәләрнең харам икәнлеген ачык аңлатты.

Әлбәттә, күпләр наданлыклары аркасында, нәфес азгынлыклары белән абайламаган кешеләрне туры юлдан яздырдылар. Шик юк ки, хәттин ашканнарны иң яхшы белүче Аллаhтыр. **(120)** Ачык рәвештә гөнаh кылудан да, яшерен гөнаh кылудан да баш тартыгыз. Чөнки гөнаh кылганнар, һичшиксез, җәзасын алачак. **(121)** *(Чалганда)* өстендә Аллаh исеме әйтелмәгән ризыкны ашамагыз. Чөнки бу, һичшиксез, гөнаh эш-тер. Чынлыкта шайтаннар үз ишләрен сезгә каршы көрәшергә котырталар. Әгәр дә аларга иярсәгез, һичшиксез, сез дә Аллаhка тиң башка тәнре эзләүчеләрдән булырсыз. **(122)** Мәетне терелтеп, нур таратып йөрсен өчен, аны кешеләр арасына җибәрсәк, ул чыгар юл табалмаслык караңгылыкка кереп адашканнар белән бер дәрәҗәдә булырмы? Кяферләрнең кылган яманлыклары үзләренә әнә шулай гүзәл булып күренер. **(123)** Шулай итеп, Без һәр шәһәрдә бозыклык *(мәкер)* кылсыннар өчен, гөнаhлы кешеләрне *(башкалар өстеннән)* җитәкче иттек. *(Власть, өстенлек биреп, сынар өчен.)* Алар *(бозыклыклары, мәкерләре белән)* бары тик үзләрен генә алдый, әмма шул турыда үзләре белми.

**124.** Аларга *(мөселманнарга)* аять килсә, алар *(кяферләр)* әйтә:

—Аллаhның пәйгамбәрләренә иңдерелгән кебек, безгә дә шундый ук могҗиза иңдерелмәсә, без катгыян иман китермәячәкбез,—ди. Аллаh кемгә пәйгамбәрлек бирергә кирәклеген бик яхшы белә. Гөнаh кылганнарга, кылган мәкер-хәйләләренә түләү Аллаh тарафыннан биреләчәк мәсхәрәле авыр җәза булыр.

**125.** Тугры юлга күндерергә теләсә, Аллаh ул кешенең күкрәген Ислам өчен киң кыла; юлдан яздырырга теләсә, аның күкрәген тап-тар итәр; *(ул кеше)*, Күккә очкандагы кебек, *(чыдый алмыйча)* интегер. Аллаh иман китермәгәннәр өстенә менә шундый мордарлык *(нәҗеслек)* җәзасы иңдерер.

*(«Тавыш тизлеген узып, Җирдән күп чакрымнарга өскә күтәрелгәндә басымның үзгәрүе, махсус скафандрлар гына күкрәкне сытылудан саклаганы күз алдына килә түгелме? Очкычка утырып, һавага күтәрелгәндә дә күкрәк тарайган кебек хис кешене били».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**126.** Һәм бу *(Коръән, Ислам дине)* Раббының тугры юлыдыр. Без аятьләребезне

башында акылы булган *(фикерләү сәләте булган)* кешеләр өчен ап-ачык аңлаттык. **(127)** Раббыбыз катында иминлек йорты бар. Кылган *(гүзәл)* гамәлләре аркасында Аллаһ аларның химаячеседер.

*(**Иминлек—Сәлам йорты**—мөселманнарның бер-берсенә сәлам бирә торган йорты—җәннәт. **Химаяче**—дус, ярдәмче, яклаучы.)*

**128.** Аларның бөтенесен бер урынга туплаган көнне Аллаһ:

—Әй, җеннәр өере, сез инсаннар белән күп булаштыгыз,—дип әйтер.

Җеннәргә дус булганнар әйтер:

—Әй, Раббыбыз, без бер-беребездән файда күрдек вә безгә бирелгән дәвернең ахырына килеп җиттек,—диярләр.

Аллаһ боерыр ки:

—Аллаһ сезне коткарырга теләмәсә, сезнең урыныгыз мәңге чыга алмас уттыр. Шөбһәсез, Раббыгыз—хикмәт иясе, белүчедер. **(129)** Менә шулай итеп, кылган гөнаһлары өчен залимнәрнең бер өлешен икенчесенә хаким итеп куябыз. *(Гөнаһ кылуда бер-берсе белән ярышсыннар өчен, шуннан соң кылган гөнаһлары өчен Аллаһ каршысында җавап тотсыннар өчен.)*

**130.** Әй, җен кавеме һәм инсаннар җәмгате, сезгә аятьләремне аңлатучы вә шушы Көн *(Кыямәт)* белән кавышачагыгызны кисәтүче пәйгамбәрләр арагыздан чыкмадымы?

Алар *(кяферләр)* әйтер:

—Без үз зарарыбызга шаһитлек кылабыз,—диярләр.

Алар дөнья тормышына алданды вә кяфер булганнарына шаһитлек кылдылар.

**131.** Хакыйкать шулдыр ки: халкы гафил *(хәбәрсез)* булган илләрне хаксыз рәвештә һәлак итмәс өчен, Раббы алдан ук пәйгамбәрләр җибәрде.

*(«Аллаһ Тәгалә пәйгамбәрләр җибәрелмәгән халыкны, ягъни хәбәрсез, гафил халыкларны җавапка тартмас. Пәйгамбәрләр килеп, Корьәнне аңлатканнан соң, Аллаһны инкарь иткәннәр гөнаһлы саналып, җәзага тартылыр».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**132.** Һәркемнең кылган гамәлләренә күрә дәрәҗәсе булыр. Раббың алар кылганнардан хәбәрсез түгел. **(133)** Раббың байдыр *(Ул беркемгә дә, бернигә дә мохтаҗ түгел)*, миһербан ияседер. Теләсә, Ул сезне юк итәр, һәм сезне башка кавем балаларыннан бар иткән кебек, сезнең урынга үзе теләгән затларны яраттыр иде. **(134)** Сезгә вәгъдә ителгән нәрсә, һичшиксез, киләчәк һәм сез аны берничек тә булдырмый кала алмассыз.

*(**«Вәгъдә ителгән»**—гыйбарәсе: Кыямәт көне, үлгәннән соң терелү, гөнаһлар өчен җавап көне кебек мәгънәләрне үз эченә ала.)*

**135.** Әйт син:

—Әй, халкым, кулыгыздан килгәнне кылыгыз. Мин дә үземчә эшләячәкмен. Шуннан соң сез җәннәтнең кемгә булачагын белерсез. Хактыр ки, залимнәр аңа ирешмәячәк,—диген.

**136.** Аллаһ яраткан игеннәрдән, хайваннардан үз уйдырмалары буенча Аллаһка өлеш чыгаралар да:

—Бусы Аллаһка, бусы уртакларыбызга *(сыннарга, потларга)*,—диләр.

Сыннарга бирелгән Аллаһка ирешми; Аллаһка аталган сыннарга ирешер. Нинди дә әшәке фикер йөртәләр алар.

**137.** Аларны һәлак итмәк өчен, аларның динен боздырмак өчен шушындый уртаклары мөшрикләрнең байтагына үз балаларын корбанга чалу эшен саваплы итеп күрсәттеләр. Аллаһ ихтыяр итсә, алар моны эшләмәс иде дә. Син аларны үзләре уйлап чыгарган ялганнары янында калдырып кит.

**138.** Алар яман уйдырмалары белән әйттеләр:

—*(Сыннарга, потларга бирелгән)* бу маллар белән игеннәрне ашау бездән башкаларга харамдыр. Рөхсәтебездән башка шул малларга атланырга да, йөк төяргә дә ярамас,—диделәр.

һәм алар мал суйганда, Аллаһ исемен телгә алмыйлар. Аллаһ турында ялган сөйлиләр. Аллаһ аларны шушы гайбәтләре өчен җәзага тартачак.

*(«Җаһиллек заманасында гарәпләрнең бер кавеме игеннәрнең, тере малларның бер өлешен—Аллаһка, икенчесен үзләре табына торган сыннарга бүлеп бирәләр иде. Сыннарга китерелгән мал югалса, үлсә, потларны, сыннарны карап торучылар Аллаһка дип бирелгән малларны гыйбадәтханәләрдән үзләренә алалар. Безнең сыннарыбыз мохтаҗлыкта, Аллаһ исә бернигә дә мохтаҗ түгел, дип, Аллаһ өлешен дә алалар иде. Аллаһка бирелгән маллар юкка чыкса, сыннар өлешеннән алар мал бирми иде. Сыннарга диеп бирелгән малларга үзләреннән башкаларга атланырга, йөк ташырга харам, дип үзләре генә файдалана иде»).*

**139.** Әйттеләр:

—Шул хайваннарның карынында булган токым бары тик ирләребез өчен генә яралтылган, хатыннарыбызга харамдыр. Әгәр үле туса, ул вакытта икесе өчен дә тигез, хәләлдер—диделәр. Шушы гамәлләре өчен Аллаһ аларга җәза бирәчәктер. Шик юк ки, Ул—хикмәт иясе, барысын да төгәл белеп торучыдыр.

**140.** Наданлыклары аркасында абайламаенча балаларын үтергәннәр вә ялган сөйләп, Аллаһ биргән ризыкны харамга чыгаручылар, чынлап та, адашты, алар тугры юл табалмас.

*(«Җаһиллек заманасында гарәпләр арасында байтак кешеләр: кыз балаларыбыз әсир төшәр, фәкыйрьлектә үсәр, башка кешегә килен булыр дип, тереләй җиргә күмә торган булганнар».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**141.** Агачта һәм куаксыз өлгерә торган җимеш бакчаларын, җиләк-җимешләрне вә татлары төрле-төрле хөрмәләрне, иген-ашлыкларны, зәйтүннәрне, нар җимешләрен бер-беренә охшаш та, бер-беренә охшамаган итеп тә Ул яралтты. Уныш-җимеш биргән вакытта һәрберсеннән авыз итегез. Урып-җыйган көнне хакын *(садакасын, зәкятын)* бирегез. Исраф итмәгез. Аллаһ исрафчыларны сөйми. *(Аллаһ ризыкны максатсыз әрәм-шәрәм итүгә катгыян каршы.)*

**142.** Йөк ташый торган хайваннарны да, йоннарыннан түшәк ясый торганнарын да Ул яралтты. Аллаһ тарафыннан сезгә бирелгән ризыкларны ашагыз, шайтанга иярмәгез; шөбһәсез ки, ул сезнең иң хәтәр дошманыгыз.

*(Аятьнең гарәпчәсендә кулланылган **«хамулә»** сүзе йөк ташучы хайван, дигән мәгънәдә килә; **«фәрш»** сүзе исә атланып йөри торган һәм йоныннан, кылыннан, тиресеннән сырма, түшәк ясала торган хайваннарны күз уңында тота.)*

*(Америка, Лондон нөсхәләрендә «йөк ташучы һәм суеп ашарга тиешле» хайваннар хакында әйтелә. Ногманида һәм төркия галимнәрендә исә «йөк ташый торган һәм йоннарыннан түшәк ясый торган хайваннар» диелә, без шунысын хуп күрдек.)*

**143.** *(Гарәпләр кайбер хайваннарның ата җенеслеләрен, кайсыларының теше (ана җенесле) булганнарын яки шушы хайваннарның бозауларын ашарга харам саный иде. Бөек Аллаһ аларның бу йолаларын җимерер өчен шулай боерды:)*

*(Ана вә ата җенесле итеп)* сигез пар яралтты: сарыктан—ике, кәҗәдән—ике...
Әйт син:

—Ул шушы хайваннарның атасынмы, анасынмы яки аларның карыннарында булган бәрәннәрен харам иттеме? Әгәр дә сез хаклы икән, миңа гыйлем аша яхшылап аңлатып бирегез,—диген.

**144.** Дөядән—ике, сыердан да икене (яралтты).
Әйт син:

—Ул шушы хайваннарның аталарынмы, аналарынмы яки карыннарындагы бозауларынмы сезгә харам кылды? Әллә сез Аллаһ шулай кушканлыкка шаһит булдыгызмы? Наданлыгы аркасында абайламаган кешеләрне саташтырган, Аллаһка каршы котырткannardan да яман залим кем бар? Шик юк ки, Аллаһ андый залимнәрне тугры юлга чыгармас.

**145.** Әйт син:

—Миңа иңдерелгән вәхийдә: үләксә яки *(суйган вакытта)* аккан кан яки дуңгыз ите шакшылыкның үзедер, диелгән. Аллаһтан башкага *(бер ялган илаһка)* атап чалынган нәҗес хайваннан башка, ашый торган кешегә харам кылынган бүтән берни

дә тапмадым. Кем шушы харам ризыкларны ашарга мәҗбүр хәлдә калса, үзе кебекләргә зарар китермичә, зарурлык микъдарында гына ашаса, белсен ки, Раббың кичерер вә гафу итәр,—диген.

*(«Дуңгыз ите, бугаз каны, үлгән хайван-үләксә, Аллаһ исеменнән башка чалынган хайван ите, Аллаһтан башка берәр зат исеме белән суелган хайван ите һәр заманда, һәр җирдә мөселманнар өчен харам кылынды. Кеше ачка үләр дәрәҗәдә булса яки ниндидер башка сәбәпләр аркасында, башка ризык булмаганда: солдатта, төрмәдә, адашканда бу харам ризыкларны җан саклар өчен ашый ала. Һәм бу эш гөнаһка саналмас».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**146.** Яһүдләргә Без бөтен так тояклы хайваннарны харам иттек. Сырт майларын, эчәк маен, кимек-сөяк маен хәләл кылдык. Сыер белән куйларның *(пар тояклыларның)* корсак маен аларга харам кылдык. Бу аларның гаделсезлекләре өчен бер җәзадыр. Шик юк ки, Без дөресен сөйлибез.

*(«Яһүдләрнең гаделсезлеге будыр ки: алар пәйгамбәрләрне үтерде, фәкыйрьләрне изде, харамны—хәләл, хәләлне харам дип күрсәттеләр. Бөек Аллаһ аятьтә искә алынганнарны ашаудан аларны тыйды. Гәрчә, асылда мөэминнәр өчен боларның берсе дә харам түгел».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**147.** *(Ий, Мөхәммәд)* Әгәр дә сине ялганчы дисәләр, әйт:

—Раббыбыз чиксез миһербан ияседер. Шуңа да карамастан, Ул бирәчәк җәза гөнаһлылар өстеннән алыначак түгел,—диген.

**148.** Мөшрикләр әйтәчәк:

—Аллаһ ихтыяр итсә, без *(Аллаһка)* тиңдәш эзләмәс идек, аталарыбыз да *(башка тәңрегә)* табынмас иде; һичбер нәрсәне дә харамга чыгармаган булыр идек,—диярләр. Алардан элек килгәннәр дә нәкъ шулай итеп ялганладылар вә соңыннан җәзабызны татыдылар. Әйт син:

—Сезнең безгә аңлатачак берәр гыйлемегез бармы? Әгәр булса, безгә күрсәтегез. Сез уйдырмалардан башка нәрсәгә иярмисез вә сез бары тик ялган таратасыз, диген.

**149.** Әйт син:

—*(Хактыр ки, сезнең кулда андый исбат юк)* Андый исбат бары тик Аллаһта гына. Аллаһ ихтыяр итсә, шиксез, һәммәгезне дә тугры юлга бастырган булыр иде,—диген.

*(«Кайбер кешеләр: яманлык та, яхшылык та Аллаһтан килгәч, безнең яманлык кылуыбызда гаебебез юк, диләр. Алайса, нигә соң, Аллаһ барыбызны да тугры юлга бастырмый?*

*Шулай итеп, андыйлар һәр яманлыкларын Аллаһ өстенә өеп калдырмак булалар. Ләкин Аллаһ кешене үз ихтыярына куя. Менә синең алда ике юл бар. Аллаһны танымау, Кыямәттән курыкмау. Болардан курыкмаган кеше яманлык кыла, хәмер эчә, фәхешлек кыла, алдый, урлый, көчли. Һәм тугры юл бар—Аллаһ күрсәткән юл. Бер Аллаһны тану, Кыямәттән курку, гаделлек, саф әхлак, хәләл мал туплау. Бар булганына разый булып, Аллаһка гыйбадәт кылу.*

*Бу ике юл каршысында ирексезләү юк. Телисең икән, нәфесең күрсәткән кыек юлдан кит. Аннан китәргә теләмисең икән, тугры юлдан йөр. Аллаһ Тәгалә гөнаһлы вә савaплы эшләрне кешенең үз намусына, үз ихтыярына тапшыра. Һәр кылган игелегең өчен сиңа савап—җәннәт булыр. Һәр гөнаһың өчен сиңа җәза—җәһәннәм булыр».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**150.** Әйт син:

—Аллаһ шуны тыйды, дип ышандырырлык шаһитләрегезне күрсәтегез,—диген.

Әгәр дә алар шаһитлек кылса, син алар белән бергә шаһит булма. Аятьләребезне ялганга чыгарганнарга вә Ахирәт көненә ышанмаганнарга иярмә. Алар Раббыдан башка ялган тәңрегә табына.

**151.** Әйт син:

—Килегез, мин сезгә Раббының нәрсәләрне харам кылганлыгы турында укып бирәм,—диген.

Аллаһка һичбер нәрсәне тиң күрмәгез. Ата-анага игелек кылыгыз. Фәкыйрьлектән куркып, балаларыгызны үтермәгез. Сезгә дә, аларга да ризыкны Без бирәбез. Кеше каршысында да, яшерен рәвештә дә яманлык кылмагаз. Аллаһ рөхсәтеннән башка, мәҗбүрият булмаганда Аллаһ мөхтәрәм кылган җанны хаксызга кыймагыз *(гаделсезлек илә кеше үтермәгез).* Менә Аллаһның сезгә булган боерыклары шулдыр ки. Уйлый торгач, бәлки, аңларсыз,—диген.

**152.** Балигълыкка ирешкәненә чаклы ятимнең малына кагылма, яхшы ният белән генә кагыл *(ул малны ятим кирәгенә тотканда гына, үзеңә алсаң, кайтарып бирү шарты илә яки ул малны арттырыр булсаң гына)*. Гадел итеп үлчәгез, гадел бүлегез. Без һәркемгә йөкне үзе күтәрә алган кадәр генә төйибез. Якыннарыгыз турында да гаделлек белән шаһитлек итегез. Аллаһка биргән сүзегездә торыгыз. Менә шулай итеп, яхшы аңларсыз дип, Аллаһ шуларны сезгә әмер итте. **(153)** Шөбһәсездер ки, бу минем дөп-дөрес юлым булыр. Шул юлдан китегез. Башка юлдан китмәгез. Чөнки ул юллар сезне Аллаһ юлыннан аерыр. Гөнаһлардан сакланырсыз дип, Аллаһ сезгә шушыларны әмер итте. **(154)** Сонра игелек кылганнарга нигъмәтебезне аңлатыр өчен, һәрнәрсәне ачыклар өчен, тугры юлга күндермәк өчен вә рәхимлек кылу максаты илә, Мусага да Китап *(Тәүрат)* бирдек. Өмет ителәдер ки, *(Кыяматтә)* Раббы хозурына барачакларына иман китерерләр. **(155)** Менә бу *(Коръән)* Без иңдергән изге Китаптыр. Аңа иярегез вә (бу дөньяда гөнаһ эшләүдән) Аллаһтан куркыгыз. Сезгә Ул *(Кыямәт көнендә)* мәрхәмәтле булыр.

**156.**—Китап бары тик бездән элек яшәгән халыкларга *(христианнарга, яһүдләргә)* иңдерелде, без исә аларны укый алмавыбыз сәбәпле, хәбәрсез,—дип әйтмәсеннәр өчен. **(157)** Яки:

—Безгә дә китап иңдерелсә иде, без алардан да тугры юлда булыр идек,—димәсеннәр өчен *(Коръәнне иңдердек.)* Менә сезгә дә Аллаһтан ачык бер дәлил, һидаят вә рәхмәт килде.

Аллаһтан йөз чөереп, Аның аятьләрен ялганга чыгарырга тырышучылардан да залимрәк кем бар? Аятьләребездән йөз чөергәннәре өчен аларны җәзаның да иң хәтәре белән җәзалаячакбыз.

**158.** Алар *(кяферләр)* фәрештәләр килгәнен көтәме, Раббының килгәнен көтәме, Раббының галәмәтләрен көтәме? Алдан ук иман тотмаган килеш, иман тотып та, кабул ителмәгән килеш, Раббының галәмәте иңгән көнне *(Кыяматтә)* генә файда булмас. Әйт син:

—Көтегез, без дә көтәбез,—диген аларга.

**159.** Диннәрен вак кисәкләргә *(төркемнәргә)* аерганнар да бар, синең аларга һичбер мөнәсәбәтең юктыр. Алар фәкать Аллаһ хөкемендәдер. Соңыннан Аллаһ аларга *(нинди яманлык)* эшләгәнлекләрен күрсәтәчәк.

*(«Рәсүлуллабыз шулай әйтте ки: яһүдиләр җитмеш бер төркемгә аерылды, берсеннән башкасы җәһәннәмдәдер. Минем өммәтем дә җитмеш өч төркемгә аерылачак, берсеннән башкасы җәһәннәмдә булыр, диде. Котылуга ирешкән ул төркем кемнәрдер, ий, Рәсүлулла?—дип сораганнарына каршы җавап: алар минем шәкертләрем юлыннан киткәннәрдер,—диде».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**160.** *(Аллаһ хозурына)* кем игелекләр белән килә, аның игелекләре ун тапкыр арттырылыр. Кем исә яманлыклар белән килә, ул бары тик шул яманлыклары өчен генә җәза алачак. Алар хаксызлыкка дучар булмаячак. **(161)** Әйт син:

—Шик юк ки, Раббым мине тугры юлга, дөрес дингә, Аллаһны бер дип таныган Ибраһим тоткан дингә юнәлтте. Ул Аллаһка тиң эзләүчеләрдән түгел,—диген. **(162)** Әйт син:

—Шик юк ки, минем намазым, корбаным, тормышым вә үлемем—барысы да галәмнәрнең Раббысы Аллаһ өчендер,—диген. **(163)**—Аллаһның тиңе юктыр. Мина бары тик шул гына әмер ителде вә мин беренче мөселманнарның берсе булдым,—диген. **(164)** Әйт син:

—Бар нәрсәнең хуҗасы Аллаһ икән, нишләп әле мин аннан башка тәнре эзләп маташыйм, ди? Һәркемнең казаначагы үзенә генә баглы. Беркем дә башка кешенең гөнаһысын үз җилкәсендә ташымас. Ахырда Раббы хозурына киләчәксез. Ул сезнең ни өчен *(дин эчендә)* гаугалашканыгызны төшендереп бирер,—диген. **(165)** Сезне Җир йөзенең хәлифәләре иткән, сезгә биргән *(нигъмәтләр)* хосусында сезне сынар өчен бер-берегез өстеннән дәрәҗәләр биргән Улдыр. Шик юк ки, Раббының җәзасы соңламас вә, чыннан да, Ул кичерүче миһербан ияседер.

صدق الله العظيم

# ҖЫРЛЫЙК ТӨМӘН КӨЙЛӘРЕНӘ

Биш ел инде мин Төмән өлкәсе авылларына экспедициягә йөрим. Шул төбәктә яши торган татарларнын музыкаль фольклорын жыям, өйрәнәм. Казан дәүләт консерваториясенен татар музыка сәнгате факультетын тәмамладым, музыка белгече—фольклорчы исеменә лаек булдым. Себер татарларынын традицион мәдәниятенә игътибарым тиккә түгел—чыгышым Төмән өлкәсенен Яркәү районындагы Тархан авылыннан. Шунда ук унъеллык мәктәпне тәмамладым. Аннары Казанга укырга килдем. Татар халкынын мәдәниятенә, туган жиремә булган мәхәббәт шушы һөнәрне сайлауда сәбәпче булды.

Консерваториядә укыган чакта ук мина Төмән өлкәсенен унөч авылында булырга туры килгән иде. Менә алар—Яркәү районынын Карбан, Кортъегән, Тархан, Кала, Карагай авыллары, Ялутор районынын Яна Атъял авылы, Төмән районынын Шыкча, Явыспы, Талмы, Турай, Ямбай, Талымхан һәм Каскара авыллары. Бу төбәктәге татар авыллары тарихы унжиденче гасырдан башлана.Минем туган авылым Тархан тарихыннан кайбер мәгълүматлар китерик. Халыкнын яшәү рәвешен белү анын музыкаль фольклорын анларга ярдәм итәр.

Авыл турында беренче искә алулар «Ревиз экиятләре»ндә («Ревизские сказки») XVII гасырнын икенче яртысына карый—1685 ел. Суяр исемле кечкенә генә авыл турында сүз бара, ул урман эчендә, Суяр елгасы буенда, хәзерге Тархан авылы урыныннан ерак түгел урнашкан булган. Шушы төшләр авылнын беренче урыны булып санала.

Авыл исеме турында күп кенә легендалар бар. Менә шуларнын берсе: «Элек-элек заманда Калмаклар (Ялутор районы) авылында усал бер хан яшәгән. Ул үсмер кызларнын барысын да харап иткән. Анда яшәүче Чичекә исемле картнын тирә-якка матурлыгы белән даны таралган кызы була. Ул, кызын кызганып, безнен якка качырып алып килә һәм Суяр суы буена урнаша...» Чечкино авылы исеме шушы Чичекә карт белән бәйле.

Тархан—XVII гасыр өчен зур гына авыл. «Ревиз экиятләре»ндә ул Ялутор округындагы ике татар авылынын берсе булып искә алына; авылда 20 йорт булган, 109 кеше яшәгән. 1782 елдагы исәп буенча, инде монда 152 кеше яшәгән (74 ир кеше һәм 78 хатын-кыз, бер болгар кызыннан башкалары барысы да татарлар). 1852 елда авыл халкынын саны 295 кеше була (145 ир кеше һәм 150 хатын-кыз).

1842 елдан Тархан авылына зыряннар (коми халкы) килеп урнаша башлый. Ике халык арасында жир өчен тарткалашу чыга. Шул чакта безнен авыл ягы татарлары патшага прошение яза. Ул Тобол губернаторына жибәрелә.[1] Ләкин зырян халкы, патша аларнын китүләрен таләп итсә дә, бу жирләрдән китми.[2]

XIX гасырнын ахырында авыл зурая һәм халкы шактый ишәя. Узган гасырнын сиксәненче еллары ахырында авылда мәчет төзелә. Төп авыл кешесе Уразаев Ризагетдин абый (1917—1998): «Урам як кыекчасында 188... дигән чукылган язу бар иде»,—дип исенә төшерә. Мәчет өчен агачны Бурбардан, Осиновкадан ташыганнар (Яркәү районы авыллары). Мәчетне авыл халкы үзе төзегән, Ямбай тимерчесе Нигъмәтулла Хажи килеп кинәшләр биргән. 1892 елда авылда беренче мәдрәсә ачыла. 1921-22 елларда иске мәдрәсә совет мәктәбенә әйләнә. Анын беренче укытучысы Камалов Таштимер Чамалетдин улы

---

[1] Петр I әмере буенча 1708 елның 18 декабреннән Себер губерниясе оештырыла, аның үзәге Тобол шәһәрендә була, аңа Себер, Ерак Көнчыгыш һәм Урал керә. Өлкәнең административ-территориаль бүленеше берничә тапкыр үзгәртелә, ләкин Тобол губерниясе 1918 елның 5 апреленә чаклы яши. Шул вакыттан губерния үзәге Төмәнгә күчерелә һәм Төмән губерниясе дип исемләнә.


[2] Бу хактагы мәгълүматлар: «Авыл хужалык учреждениесе һәм жир төзелеше. Жир асты төзелеш партиясе» дигән документта Төмән Дәүләт архивында (Фонд 8.49.) бар.

була. Ул 1923 елда авылда беренче Октябрь революциясе демонстрациясе оештыра, трибуна ясата. Укучыларны икмәк, прәннек белән сыйлаганнар иде, дип искә төшерә өлкән авылдашлар.

Тарханда совет власте тиз генә урнаша алмый. Халык аерым хуҗалык булып яшәгән: итен-сөтен саткан, бала-чагаларын яшьтән эшкә өйрәткән. Тәүлеккә житмеш потлап сөт жыелган. Сөт жыю урынын русча «Молоканка» дип йөрткәннәр. Ул башта Тарханда булган, аннары Молоканканы бездән ерак түгел Карагай авылына күчерәләр, ә Карбан авылында сөт заводы ачалар.

Авылыбыз гражданнар сугышында «аклар» кулына да, «кызыллар» кулына да эләгә; авылдан егермеләп кеше сугышка китә, шуларның дүртесе кире кайтмый. Блюхер күрсәтмәсе буенча, авыл халкы Тобол елгасы буйлап окоп казыган. Безнен авылга зыряннар да булышкан икән. Окоп эзләре хәзер дә саклана.

1922-23 елларда Тарханның үзендә авыл советы һәм ликбез ачыла, сонрак кулакларга каршы көрәш кампаниясе башлана, аларның әйберләре, торак йортлары алына һәм сатыла. Хәрәкәтнен житәкчесе Корбанов Хәбибулла абый була, ул гражданнар сугышы герое, коммунист, заманасына күрә Хәбибулла абый сәясәтне дөрес алып бара, ләкин халык телендә ул «яман» булып кала.



*Яркәү районының Тархан авылы мәчете.*

1928 елда шул тирәдәге татар халкы арасында[3] дүрт ячейка оеша, яна алфавитны үзләштерә торган шул ячейкаларның берсенә Тархан авылы халкы да керә.

1929 ел. Коллектив хуҗалык төзү безнен авылга да житә һәм беренче коммуна төзелә. Анда башта уникe гаилә була, аннары, жидегә кала, соныннан коммуна таркала. Озакламыйча колхоз оеша, төбәктә ин беренчесе ул була. Исемен «Путь Ленина» дип кушалар, рәисе—Карбан авылыннан килгән Сәгыйтов Айзәт. Колхозның чәчү мәйданы—420 гектар. Авыл өч бригадага бүленә. Фермада йөздән артык сыер һәм мен сарык асралган. Кул белән чәчкәннәр, урганнар, сукканнар, ындыр табагыннан, капчыкларга салып, атка төяп югарыга чыгарып киптергәннәр. Орлыкны, өйдә утырган балалы хатыннарга таратып, чүбеннән чистарттырганнар. Еллык хезмәтләре өчен, ашлыкны яулыкка гына салып биргәннәр. Ләкин, бөтен Себер авылларындагы кебек, тормыш үз юлы белән барган: балаларны мәктәптә укытканнар[4], радио тынлаганнар (1931 елда районда 34 радио-нокта була), авыл советына беренче булып телефон кертәләр. 1930 елда 25 менчеләрне каршы алалар (бу якка алар бишәү килгән), стахановчылык хәрәкәтендә катнашалар, үзләренен стахановчылары да була, мәсәлән, Хисаметдинова Сәгыйрә апа. 1940 елда бригадалар ярышында жинүчеләр Авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә баралар, Садыйкова Куйшан апага һәм Бәширов Уразмөхәммәт абыйга Мәскәүдә бирелгән дипломнар әле дә мәктәп музеенда саклана.

Бөек Ватан сугышы алдыннан колхозда балык тоту артеле оештырыла. Бу артель сугыш вакытында күп кешене ачлык үлеменнән алып калган, колхоз казнасына акча китергән. Көндез балык кермәсә, төнге суыкларда да балыкка чыкканнар. Бозлы авыр елымны хатын-кызлар ялан куллары белән өстерәп йөргәннәр, дип искә төшерә Шәяхмәтова Закирә апа. 1942 елда «Хәрби иптәшләр» дигән танк колоннасын, «Омск комсомолы» дигән авиаэскадрилиясен төзергә акча жыялар, 1943 елда «Омск колхозчысы» дигән танк колоннасына акча жыюда ярдәм итәләр. Колхоз 1965 елда совхоз итеп үзгәртелде.

---

[3] Районда, татарлардан тыш, нигездә урыслар, чувашлар, зыряннар яшиләр.

[4] Кызыклы факт - 1930 елда Яркәү районында 48 мәктәп булган: 34 урыс (12315 укучы), 12 татар (805 укучы), 1 мәктәп зыряннар өчен (95 укучы) һәм 1 мәктәп чувашлар өчен (52 укучы).

Хәзер Тархан авылында 179 хуҗалык[5]. Авылда күбесенчә өлкәннәр яши, яшьләр шәһәргә китә. Рәсәй Федерациясе президенты әмереннән соң, 1992 елда совхоз «Төзүче» исемле ярдәмче хуҗалыкка һәм өч фермер хуҗалыгына таркалды[6]. Авылда тулы булмаган урта мәктәп эшли, 1997 елның 1 гыйнварына мәктәптә 120 укучы, 15 укытучы санала иде[7]. Монда татар теле һәм әдәбияты укытыла. Авылда балалар бакчасы, фельдшер-акушерлык пункты, мәдәният йорты, китапханә бар. Халык тырыш, хуҗалык көчле, терлекне күп асрыйлар, житкелекле яшиләр.

Соңгы ун елда милли азчылыкны тәшкил итүче Себер татарларының яшәү рәвеше тамырдан үзгәрде.

Традицион тормышның күп кенә үзенчәлекләре бары тик картларның хәтерләрендә генә саклана. Бүген Төмән ягындагы татар авыллары хәзерге чорның алга киткән, заманча авылларыннан һич тә калышмый. Һәр хуҗалыкта машина яки мотоцикл, гараж бар, өй эчен кыйммәтле җиһазлар бизи...

Ә традицион музыкаль поэтик культура, Себер татарларының бүгенге яшәү рәвеше белән чагыштырганда, күпкә тотрыклырак. Бүгенге көндә заманча электрон коммуникация чараларының өстенлек итүенә карамастан, халык иҗаты үзенең йөзен югалтмаган.

Төмән өлкәсенең татар авылларында яздырып алынган фольклор материаллары бай һәм төрле. Монда бәетләр, мөнәҗәтләр, лирик көйләр, такмаклар һәм бию көйләре җыелды. Бу як татарлары арасында популяр кайбер көйләр Идел буе татарларында да киң таралган. Мондый көйләр, жанры буенча, лирик озын көйләр. Мәсәлән, «Кара урман»; «Зиләйлүк»; «Тәфтиләү»; «Сарман». Шунысы кызыклы, бу әсәрләр музыкаль теле ягыннан катлаулы һәм җырчыдан үзенчә осталык таләп итә, алар Идел буе татарларының көнкүрешендә бөтенләй җырланмый диярлек. Андыйлар профессиональ җырчыларның репертуарына кереп, концерт эшкәртелүендә төрлечә башкарыла, ә аларның фольклор вариантлары Татарстан территориясендә уздырылган экспедицияләрдә елдан-ел сирәгрәк табыла. Төмән өлкәсендә язрып алынган лирик җырларның үрнәкләре шактый күп, аларның башкару осталыгын югары культура аерып тора: көйләр бай орнаментлашалар, киң сулышта һәм зур күләмле строфалар белән җырлана, саны бастырылган вариантлардан еш кына артып китә. Озын көйләрне, гадәттәгечә, өлкән яшьтәге кешеләр генә түгел, ә урта яшьтәгеләр дә башкара, күп очракта бу көйләр оригиналь текстка җырлана. Мәсәлән, танылган «Тәфтиләү» көенә җырлана торган поэтик текст Ялутор районының Яна Атьял авылында Кучәхмәтова Мәрхәбә ападан (1927 елда туган) язрып алынды[8].

Сантугач паласы кара,
Сәхрәтәге комлык(ы)та.
Минем әнкәм, әй йөзәр инде лә,
Дәрь(е)я кебек(е) мон(ы)лыкта.
Минем әнкәм, әй йөзәр инде лә,
Дәрь(е)я кебек(е) мон(ы)лыкта.

Ничә еллар пу пинада,
Ялгыс утыра пашым.
Пер(е) телем икмәк(е), пер йотым су—
Минем аш(а)кан ашым.
Пер(е) телем икмәк(е), пер йотым су—
Минем аш(а)кан ашым.

Ат(ы)лап парам, ерлап парам,
Ер(ы)ласам, елап парам.
Ер(ы)ласам(ы), еламасам ла,
Ут(ы)ларга янып парам,
Ер(ы)ласам(ы), еламасам ла,
Ут(ы)ларга янып парам.

Болар исә Себер татарлары арасында озын көйләрнең башкарылу осталыгының

[5] Тарханга күрше безнең фольклор кыр эзләнүләре үткән авылларда хуҗалыклар саны: Карбанда—101, Кортегәндә—70, Карагайда—64, Калада—45 һәм Нусукта—23.

[6] Районның совхозларын үзгәрткәннән соң, Кортегән авылында «Аскар» АХК һәм бер фермер хуҗалыгы, Зырян авылында «Заря» АХК, Карбан авылында «Карбан» АХК һәм бер фермер хуҗалыгы төзелә.

[7] Зырян авылында урта мәктәп, Карбанда тулы булмаган урта, Кортегән, Кала һәм Карагай авылларында башлангыч мәктәпләр эшли.

[8] Җырларның текстлары әдәби нормага китерелмичә, аларның фонетик һәм морфологик үзенчәлекләре сакланып бирелә. Күп очракта җыр текстларында сүзнең фонетик әйтелешенең үзенчәлекләре интервокал позициясендә тартык (к), (п), (с), (т) авазларының яңгыраулашуы һәм билгеле очракларда (г), (б), (з), (д) авазларының, аерым алганда сүзнең башында, саңгыраулашуы белән бәйле: яңгырау тартык аваз парлы саңгырау аваз белән алмаштырыла (мәсәлән, «гомер»—«комер», «бара»—«пара», «боз»—«пос»).

югары дәрәҗәдә сакланып калуы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Лирик озын көйләрдән тыш, Төмән өлкәсендә бүтән жанрдагы көйләр дә киң таралган. Әйтик, лирик кыска җырлар («Күбәләк»), бәетләр («Сак-Сок», «Кирпечләр», «Ямщик бәете») һ. б. Әмма, һичшиксез, төмән татарларының музыкаль традициясе Идел-Кама татарлары бәйләнешләре нәтиҗәсенен үрнәкләре белән генә чикләнми. Бу регионда оригиналь, төп, шушы төбәккә генә хас көйләр яши, шундый көйләр өстенлек итә.

Төп Себер музыкаль традицияләре иң элек «сөйләмә текст» жанрында—бәетләрдә һәм такмакларда чагылыш таба. Шулай, экспедиция вакытында язып алынган бәетләр жирле халык тарафыннан иҗат ителгәннәр. Чөнки аларда авыл халкының үз башыннан узган вакыйгалар сурәтләнә. Мәсәлән, «Катица» бәете Яркәү районындагы Карагай авылыннан Катица исемле кызга багышланган. Ул иптәш кызлары белән урманга җиләк җыярга бара. Кайтканда, урманнан чыгып килгәндә, аларның каршысына бүре очрый. Ул куркудан авырый башлый, соныннан үлә. Бәет Катицаның авылдашлары тарафыннан иҗат ителгән, моны һәм куркудан үлгән кызның тарихы турында күрше авылларда белмиләр. Бу күптәнге бәетне сиксән өч яшьлек әби башкарган, аны яздырып алуны зур уңыш итеп санарга кирәк. Башкаручының әйтүе буенча, бәетнең поэтик тексты күп куплетлы булган. Кызганычка каршы, башкаручы барлык куплетларны да хәтерләми. Сүзнең уңсигез яшьтә үлгән кыз турында баруы гына ачык:

Катицакай тинтәшләре
Сөяркә ашларында,
Кара туфраклар япынды,
Унсигез яшьләрендә.

Бәетнең сюжет үзенчәлекләрен информатор белән сөйләшкәндә ачыклап булды. Яркәү районының Кала авылында Әлмәтова Алимә ападан (1914 елда туган) язып алынды.

«Талымкан бәете» Төмән районының Талымхан исемле авылында булган хәл—анда Хәлбиҗамал исемле кызны урлау турында сөйләнә.

Иртә пуран, кич тә пуран,
Талымканның урамы.
Кәлпицамалны урлап кацты,
Талымканның пурлары.

Талымканның урамында
Каслар гакылташаты.
Каслар гакылташкан саен,
Пурлар якынлашаты.

Башкаручының әйтүенчә, бәетне Хәлбиҗамалның авылдашлары иҗат иткән. Яркәү районының Тархан авылында Шәрәпова Мөршидә ападан (1917 елда туган) язып алынды.

«Борынгы бәет» (беренче заттан сөйләнә)—егерме тугыз яшендә вакытсыз үлеп китеп, ике кечкенә баласы һәм карт әнисе калган ир-ат турында монолог[9].




[9] Билгеләп үтик, «Борынгы бәет» вакыйганың датасын күрсәтеп башлана. Белгечләр фикеренчә, мондый башлаулар жанрның борынгы икәнлеген күрсәтә.

Тарих ментә тугыс(ы) йөс(е)тә
Егерме етенце елта
Кәсис(е) пашым вабат пулты
Егер(е)мә тугыс яшемтә.

Әчәл вакыт(ы) йетә, тиләр,
Сәхәр, тиеп уяттылар.
Егерме тугыс(ы) яшемтә
Ләгет эченә салтылар.

Яркәү районынын Тархан авылында Шәрәпова Зөбәрә ападан (1930 елда туган) язып алынды.

Түмән татарларынын такмаклары Идел буе такмакларына охшамаган. Анын интонацион үзенчәлекләре рус частушкаларына якын. Әлбәттә, бу көйләрне, аларнын жанр функциясенә һәм шигырьнен слогоритмик структурасына карап, такмак дип әйтергә мөмкин. Такмакларнын текстлары төрле һәм заманча. Берсендә, әйтик, авыл тормышынын уңайсыз якларыннан көлү һәм колхоз фермасындагы начар эш шартлары турында бара.




Паш өстәге куккә читә,
Ферманын кайгылары.
Ямасыннан утә алмый,
Районнын турәләре.

Савымчы гыслар эшлиләр,
Кара галатлар белән.
Төшләрентә йөриләр, имеш,
Ап-ак калатлар белән.

Яркәү районынын Тархан авылында Юнысова Гайния ападан (1935 елда туган) язып алынды.

Икенче такмакта ике гашыйк арасында мәзәк сәхнә уйнала: ударница кыз унмаган егетне яратмый башлый:

Синме чибәр, минме чибәр,
Көскегә карап жибәр.
Мине кыслар арасынта,
Бик чибәр егет, тиләр.

Чибәрлекне, матурлыкны,
Үлчәмиләр төс пелән.
Егетләрнен чибәрләре,
Мактау ала эш белән.

Сантугачым, күгәрченем,
Сөям, тигән итен бит.
Синең өчен генә янам,
Көям, тигән итең бит.

Сөйгән итем, көйгән итем,
Прогулчы пулмаганта.

Егетем ударник тигәнтә,
Син чыктын уңмаганка.

Хәзер инте элеккечә
Сөймисең мени инте?
Элеккечә матур итеп,
Карачы күзләремә.

Пес сөяпес егетләрнен,
Эш пелгән, уңканнарын.
Заданияны артык утәп,
Ударник пулганнарын.

Пир кулыңны, мин тә пирәм,
Һич прогул ясамам.
Пир(е)гән вәгъдәнтә торсаң,
Мин тә сине ташламам.

Тархан авылында Ваһапова Мөршидә ападан (1930 елда туган) язып алынды.

Төмән өлкәсендә яздырып алынган музыкаль-поэтик фольклор материалларының жанр рәсеме, «Авыл көйләре» турында әйтмәсәк, тулы булмас иде. Авыл көйләрен күпләр беләләр һәм теләп жырлыйлар, экспедициядә яздырылган язмаларнын яртысы диярлек—авыл көйләре. Менә «Цүгәй көе». Цүгәй—кушамат. Төмән районынын Талымхан авылында элек-элек заманда бер гаилә яшәгән, һәм авыл кешеләре бу гаиләне нигәдер «Цүгәйләр» дип йөрткән. Бернинди авырлыкларга карамастан, Цүгәйләр һәрвакыт күнелле, жырлап яшәгәннәр. Бераздан аларнын көйләрен—«Цүгәй көйләре» дип атый башлаганнар.




Тимәтеммә(тей) мин сиңа шул,
Тимәтеммә(тей) мин сиңа.
Өселеп сөймә(в), айрылар(ы)быс,
Тейммәтеммә мин сиңа.

Сары сантык тей нигә кирәк,
Сабын салырга кирәк.
Ней күрсән, ней ишетсәң тә,
Сабыр итәргә кирәк.

Сабыр ит күнелем, сабыр ит,
Сабыр итсәң, уң пулыр тей,
Сабыр итмейчә саташсан,
Үкенерсен тей суң пулыр.

Сары төбе тей, сары төбе,
Сабыр бит ул - сары алтын.
Сабыр итмичә саташып,
Шушы көннәргә калтың.

Төмән районынын Каскара авылында Бәширова Мәгъсумә ападан (1909 елда туган) язып алынды.

Экспедицияләрдә мин алты йөздән артык көй яздырып алдым. Бу—тулаем Себер буенча түгел, ә Төмән өлкәсе буенча тупланган музыкаль-этнографик материал фонды. Әлбәттә, монын өчен мин бу кешеләргә чиксез рәхмәтлемен. Шулай ук мине яхшы каршы алулары, ярдәм кулларын сузулары, кырык эшләрен кырык якка ташлап, элекке жырларны белүче кешеләр янына алып барулары өчен чын күнелдән рәхмәтлемен. Сөенечле хәл—гади авыл кешесе, бу эшнен кирәклеген яхшы анлап, халык мәдәниятенен һәйкәлләрен үзендә саклый алган.

Мина авылларда инде вафат кешеләрнен кассеталарын бүләк иттеләр. Бер ханым хәтта Казанга хат язып салган һәм анда ул этисенен кассетага язылган жырлары барлыгын әйткән. Мин теге яки бу авылга барып төшкәч, бик шатланып каршы алалар иде, әйтерсен лә мине көтеп торганнар. Консерваториядә укыганымны бу авылларда беләләр икән инде. Минем эшемдә ярдәм иткән кешеләргә зур рәхмәтем кабат ирешсен, бигрәк тә Шәрәпова Зөбәрә, Уразаева Хәлбичамал, Усманова Фәрхичамал, Юнысова Гайния, Бәширова Мәгъсумә, Фастуллина Хәлилә, Усманова Сачитә һәм башка күп апаларга!

Себер ягы татарларынын музыкаль поэтика фольклоры үзенен өйрәнүен көтә. Аларнын көйләрен тикшерү, интонацион үзенчәлекләргә анализ ясау—алдагы эш. Шулай ук Төмән татарлары белән якыннан аралашып яшәүче күрше халыкларнын да фольклор традицияләрен өйрәнү кирәклеге ачыкланды. Себер татарлары көйләреннән жыентык төзергә вакыт житте. Минем хезмәтем—шушы юнәлештә тик беренче адым.

**Луиза ИЛЪЯСОВА,**
*Казан дәүләт консерваториясе аспиранты*

# ГАЛИШЕР НӘВАИ— ТӨРКИ ШИГЪРИЯТ ЙОЛДЫЗЫ

Кешелек җәмгыяте мәдәниятенең югары үсеш дәверендә күтәрелгән бөек һәм кабатланмас затларның берсе Галишер Нәваи турында сүз алып бару җиңелдән түгел. Нинди генә мактау, олылау сүзе дә аңа карата аз булыр һәм аның алдынгы кешелек дөньясына күрсәткән хезмәтенең колачын иңли алмас кебек. В. Белинский да А. Пушкин алдында шундый хәлдә калып уйлангандыр һәм аны ахырда ике сүз белән рус поэзиясенең кояшы дип атый. Бу образлы сүзләр аша Пушкин инде безнең күз алдыбызга иҗатының бөеклеге белән килеп баса, ул кояш һәрвакыт якты, балкып нур биреп, кешелекнең рухи дөньясына зәвык һәм илһам өреп тора.

Галишер Нәваи да—үзбәк поэзиясенең мәңге сүнмәс якты йолдызы, үзбәк халкының мактанычы, горурлыгы һәм барлык төрки халыклар шигъриятенең остазы, юл күрсәтүчесе, байрак йөртүчесе ул. Нәваи—бүген дә халыкларның күңелендә: ул аларны яктылыкка, хөрлектә рәхәт яшәргә, кешене чын кеше санаган, гармонияле сафлык дөньясына чакыра. Ул Гомер, Фирдәүси, Низами, Руставели, Дантелар рәтендә. Нәкъ шушы урында зур җәмәгать эшлеклесе, Көнчыгыш шагыйрьләре әсәрләрен оста тәрҗемә итүче Н. Тихонов сүзләрен кабатлыйсы килә. Әйе, Нәваи— «...бөтен дөнья поэзия даһиларының иң киң мәҗлесендә үзләренә генә хас булган аерым урын алып торучыларның берсе... [1] ».

Быел Галиҗәнаб Галишер Нәваиның килер буыннарга якты көннәр теләп, мәңгелеккә күзен йомуына—500 һәм кешелекне җирдә бәхетле итү өчен дөньяга килүенә—560 ел тула. Юбилей тантаналары ЮНЕСКО комитеты карары нигезендә 2001 елның февраль башында бөек фикер иясенең туган көне унае белән дөнья күләмендә үткәрелә.

Шагыйрь гомерен халык файдасына хезмәт итүгә багышлап, үлемсез иҗат җимешләре калдырып киткәннән соң үткән дәверләр эчендә күп үзгәрешләр булган, җәмгыять тәртипләре берсе икенчесе белән алмашынган, кешелек цивилизациясе тагын да югары үрләргә күтәрелгән, яңа буыннар барлыкка килгән. Әмма Галишер Нәваи иҗат итеп калдырган мирас байлыгы һаман бөтен кешелеккә хезмәт итә, аның якты идеаллары һәркемне канатландыра, җәмгыять шартларын савыктырырга өнди, яшәүнең матурлыгын бәяли белергә, кешенең чиксез акыл көченә ия булган бөек зат икәнлеген аңларга өйрәтә.

Дәүләттә югары дәрәҗәләр биләгән Нәваи заманында киң катлау халыкта, җәмгыятьтәге алдынгы көчләр арасында зур ихтирамга ия булган, ул илнең намусы саналган. Аның алдында баш игәннәр, сәҗдә кылганнар. Халыкның Нәваига булган мәхәббәте гасырлар үткән саен тирәнәя барган һәм ул—хәзер дә һәр үзбәк кешесенә иң якын изге зат.

Үзбәкстанда булганда моны Ташкентта гына түгел, илнең һәр кышлагындагы һәр гаиләдә сизәсең. Гади саналган мәҗлесләрдә дә анда катнашучылар сүзне Нәваи шигырьләре белән башлыйлар, аның газәлләрен яттан беләләр, көйләп әйтәләр. Бу— үзе бер зур куаныч һәм шагыйрьнең халык күңелендә яшәү көче. Мин мондый хәлләрне үз күзләрем белән күреп, күңелем белән сизеп һәм йөрәгем белән кабул итеп сөендем.

[1]Тихонов Н. Низами һәм Нәваи « Совет әдәбияты».— 1947.— № 9. 108.

Миңа Галишер Нәваиның тууына 525 (1966) һәм 550 (1991) ел тулуга багышланган халыкара тантаналарда шагыйрьнең татар әдәбияты үсеше юлындагы роле һәм урыны турында чыгышлар ясарга насыйп булды. Татар әдәбият белгечләре Нәваи турында татар, үзбәк һәм рус телләрендә дистәләгән мәкаләләр бастырды, фәнни конференцияләрдә чыгыш ясалды.

Хәзер Нәваи татар халкына яхшы таныш икән, ул элек тә аңа шулай якын, үз кеше булган. Ул татар әдәбияты, шигърияте үсешенә гасырлар буена тәэсир итә килгән. Моның бик ераклардан килә торган тарихи нигезе бар. Нәваины дөньяга биргән һәм кешелекнең югары мәдәниятенә ия булган бөек үзбәк халкы белән Идел буе төрки-татар халкы бик борынгыдан үзара якын икътисади, сәүдә һәм мәдәни мөнәсәбәтләрдә яшәгән. Хәтта Идел буенда рәсми кабул ителгәнчегә кадәр үк ислам дине Урта Азиянең Бохара, Харәзем-Үргәнеч кебек цивилизация үзәкләре аша үтеп кергән. Югары ислам мәдәнияте тәртипләре халыкка юл алган. Ә Алтын Урда заманына килсәк, бәйләнешләр тагын да дустанә булган. Харәзем, Сыр-Дәрья төбәкләре Идел буе Болгар иле җирләре белән бер дәүләт тәшкил итеп, Җучи улусында яши. Һәм биредә гомум бер тел, әдәбият барлыкка килә. Бу мохиттә Насреддин Рабгузиның «Кыйссасел-әнбийа»сы (1304—1305), Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се (1353) кебек уртак әдәби ядкарьләр иҗат ителә. Хәйдәр Харәзминең «Мәхзанел-әсрар» поэмасы (XV йөз башы), Мәҗлисинең «Кыйссаи Сәйфелмөлек» дастаны (XVI йөз башы) шулай ук ике халыкның уртак әдәби мирасы санала. Шуңа да бу әсәрләр кульязмаларының татар халкы арасында яшәп килүләре һәм аларның башлап Казанда нәшер ителүләре очраклы күренеш түгел.

Үзбәк һәм татар әдәби бәйләнешләренең тарихы бик ерактан килә. Казан ханлыгы яшәгән вакытта—XV йөздә Урта Азиядә зур Яңарыш-Ренессанс чәчәк ата. Габдрахман Җами (1414—1492) һәм Галишер Нәваи (1441—1501) югары гуманлы, кешелеклелек идеяләре, дөньяга алдынгы карашлары белән сугарылган иҗатлары бу Яңарышның нигез ташы һәм аның байрак йөртүчеләре булалар. Нәкъ шул вакытта Урта Азиядә мәдәният үсешенең Мәвараэннәһер үзәге—Сәмәркандта һәм Хорасанныкы—Һиратта фән, сәнгать, архитектура, музыка, рәсем-нәкыш, художест-во киң мәгънәдә күрелмәгән дәрәҗәдә чәчәк ата. Бу үзәкләрдә яңа сарайлар, мәчетләр төзелә, бай китапханәләр барлыкка килә.

Олугбек үзенең ачышлары, галимлеге, акыллы дәүләт җитәкчесе булу белән үзбәк халкының таянычына, горурлыгына әверелә. Урта Азиянең Рафаэле саналган Кямаледдин Бәһзад үзенең бизәкле рәсемнәре, нәкышләре белән дөньяны таң калдыра.

Үзбәк ханлыкларында барлыкка килгән бу мәдәни яңарыш Казан ханлыгындагы мәдәният үсешенә дә көчле йогынты ясаган. Бу бигрәк тә XVI йөзнең беренче яртысында Мөхәммәд Әмин ханның дәүләт эшчәнлегендәге акыллылыгы, кешелеклелек идеяләре, дөньяга айнык карашлары белән бәйләнгән. Югары интеллектуаль көчкә ия, үзе әдип һәм шагыйрь бу хөкемдар илнең эчке һәм тышкы яктан бик катлаулы, каршылыклы көннәрендә дә әдәбият, сәнгать үсешенә аеруча ярдәм иткән. Хан сарае каршында музыкантлар, җырчылар, рәссамнәр-нәкъкашлар сәнгатьнең төрле юнәлешләре буенча шөгыльләнгән. Шундыйларның берсе нәкъкаш Оста Насыйр эшләгән гарәп язуындагы кувшин-чәйнек—хәзергә кадәр сакланган кыйммәтле хәзинәләрнең берсе. «XVI йөздәге патша архивы тасвирламасы» дигән китапта шундый рәссамнәрдән Оста Касыйм исемле нәкъкаш та телгә алына. «Казан тарихы» авторы (1560 нчы еллар) татарларның шәһәр якынындагы тугайларга чыгып төрле музыка коралларында уйнап-җырлап күңел ачу җыеннары турында яза. Ул вакыттагы Казан Кремлендә мәчет, мәдрәсә һәм бай китапханәләрнең булганлыгын да әйтергә кирәк.

Шундый җанланыш алган социаль шартларда Мөхәммәд Әмин хан үзбәк ханлыклары белән тыгыз бәйләнештә була, алар белән дустанә якын мөнәсәбәтләр урнаштыра. Бу турыдан-туры үзара ярдәм итешүләрдә ачык күренә. Заһиреддин Мөхәммәд Бабур (1483-1530) үзенең истәлекләрендә кызыклы тарихи фактларны теркәгән. Анда мондый юллар бар: «Шәйбани ханның яхшы саутлары—яхшы тавышлы җырчы-башкаручы вә хуб нәкъкашлары бар. Ул заманда анчә саут вә нәкъкаш баглар юк иде. Ахыр Шәйбани хан Казан ханы Мөхәммәд Әмин ханга йибәрде»[1].

[1]«Бабер-намэ» или записки Султана Бабера. - Изд. Н. Ильминского. - Казань, 1857. - С. 230.

Татар әдәбияты тарихында бу сүзләргә беренче булып Каюм Насыйри игътибар итә һәм аларны «Фәвакиһел-Җөласа фил әдәбият» (1880)—«Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре» дигән билгеле әсәрендә китерә.

«Бабурнамә»нең соңгы басмаларының берсендә[1] Казанга җибәрелгән сәнгать осталарыннан Голәм Шади турында сөйләнә. Ул музыка иҗатчысы, хәзерге тел белән әйткәндә, композитор, оста башкаручы һәм рәссам-нәкъкаш. Бабур үзе аны Җырчы Шадиның улы[2], дип атый.

Биредә телгә алынган җырчы Шади, яисә Устад—Остаз Шади белән без йәнә Нәваига килеп терәләбез. Бабур язуынча, Нәваи үзе музыка коралларында оста уйнау белән бергә, күп җырлар язган, көйләр чыгарган. Аның җитәкчелегендә һәм ярдәмендә сәнгатьнең төрле белгечләре—музыкантлар, җырчылар, оста башкаручылар тәрбияләнгән, шулар арасында Остаз Шади да булган[3].

Әгәр дә Казанга үзбәк халкының оста музыкантлары, җырчы-башкаручылары, рәссам-нәкъкашлары килгән икән, алар белән бергә Нәваи көйләре, җырлары, әсәрләре дә килгән дип шикләнмичә әйтә алабыз. Шушы мәсьәләгә якынрак килсәк, без Казан ханлыгының авыр, бик катлаулы чорында яшәп иҗат иткән бөек шагыйрь, гуманист, философ-утопист Мөхәммәдьярга булган Нәваи тәэсиренең мәгънәви тирәнлеген тагын да яхшырак аңларбыз.

Русның күренекле галиме, Көнчыгыш Азия һәм Көнбатыш цивилизацияләре тарихының зур белгече академик Н. Конрад фикерләренә таянып әйткәндә, XV йөздә Урта Азиядә колач җәеп чәчәк аткан Яңарыш Г. Җами һәм Г. Нәваи вафатларыннан соң гасыр ахырында сүнүгә бара, торгынлык башлана. Нәкъ шул дәверләрдә Казан ханлыгы җирлегендә XVI йөзнең башларыннан рухи җанлану, мәдәни күтәрелеш үсүгә юл ала, үзенә бер Яңарыш—ренессанс барлыкка килә. Бу гаделсез социаль тәртипләргә каршы чыгу, күпчелек хезмәт халкының авыр тормышын җиңеләйтергә тырышу, һәм гомумән, җәмгыятьне савыктырырга теләү карашлары белән бәйләнгән. Мондый таләпләрне алга куйган заман кирәк шәхесләрне һәрчак вакытында мәйданга чыгара. Азәрбайҗанда—Низами, Гөрҗестанда—Руставели, Италиядә—Данте, Урта Азиядә—Җами һәм Нәваи. Ә Казан ханлыгында—үзенең элгәрләре—әнә шул титан гуманистларның эшләрен лаеклы дәвам иттерүчеләрдән Мөхәммәдьяр була. Ул Урта Азиядәге Яңарыш чорының рухын Казан ханлыгы җирлегендә җанландырып, аның таләпләрен тормышта чынлыкка ашыру өчен көрәшүче, Казанда барлыкка килгән Яңарышның байрак йөртүчесе, аның җаны була.

Теләсә кайсы чордагы Яңарышның үзәгендә Кеше иң югары яратылыш хисаплана һәм аның җир тормышын яхшы якка үзгәртеп корырга сәләтле акыл көченә ия булганлыгы мактала. Шунлыктан илгә, халыкка хезмәт итү алга сөрелә һәм ул чын ир-егетнең төп вазифасы санала. Нәваи «Мәхмубел-колүб» («Күңелләрнең сөйгәне») әсәрендә:

Ирәнләр хезмәтедин чикмәгел баш,
Әгәр гәрдундин башыңга йагар таш,—

Ягъни башыңа күктән—гәрдундин таш яуса ла, илгә-халыкка ир-егетләрчә хезмәт итүдән баш тартмаска дисә, Мөхәммәдьяр «Төхфәи Мәрдан» («Егетләргә бүләк») поэмасында:

Мән тәкый фәрман биләдер һәр эшем
Куймагам ил күнле чөн гәрдешем...

һәм:

Бу эшдә (сән) йөрәкенни даглагыл,
Мәрданәләр дик биленни баглагыл,

дип, илгә хезмәт күрсәтүдә нәкъ Нәваичә килә: ил күңеле өчен ул эшчәнлеген (гәрдешен) куймаячак, ягъни туктатмаячак, тик мәрданәләрчә—ир-егетләрчә йөрәгеңне дагларга—яндырырга кирәк.

---

[1] Бабур. 2 кн. Ташкент. —1982. —Бабур-наме. С. 139. -Л. 182 а.

[2] Соңгы мәгълүматларга караганда Голәм Шади Көнчыгышта атаклы музыкант, башкаручы Дәрвиш Шади (Хәбәши ?) ның улы. Бабурда: ул— «Җырчы Шадиның улы». Әмма бу мәсьәләнең кайбер яклары әле ачыклауны сораганлыктан, автор бу хакта сүзне хәзергә озайтмаска булды.

[3] История узбекской литературы. т. I. С древнейших времен до XVI в. Ташкент, 1987— С. 219.

Пәйгамбәрләр кебек дөньяны төзәтергә, жирдә кеше яшәешен матурларга, рәхәтлек урнаштырырга, иминлек тәэмин итәргә чакырылган бөек шагыйрьләрнең халык мәнфәгатьләрен яклаудагы фикерләре һәрвакыт бер-берсенә якын, охшаш һәм аларның бөеклеге дә гуманлылык идеяләренең уртаклыгында.

Нәваи «Вәкъфия» әсәрендә үзенең яшәү мәгънәсен икеюллык бәеттә әйтеп бирә:

Колларга үземне һәмдәм иттем,
Коллыкта билемне мәхкәм иттем.—

Ягъни: колларга—барлык кешеләргә, халыкка дуст саный һәм аларга хезмәт итәр өчен—коллыкка билен ныгытып бәйли. Бу юллар Нәваиның «Фәрһад вә Ширин» дастанында да урын алган. Шагыйрь Әхмәт Исхак аны болай биргән:

Мин колларның ихласлы дусты булдым—
Аларның хезмәтенә билем будым.

Пушкин да «Мин үземә һәйкәл торгыздым» шигырендә:

Кара елларны мин ирек мактап,
Изелгәнне яклап жырладым,—дип горурланды.

Мөхәммәдъяр:

Кем егылганда кулын тот бер монлының,
Ул тәкый тотай кулың бер көн сәнен,—

дип, түбән катлау халыкка ярдәм итәргә чакырды. Борынгы төрки телдә «монлы» сүзе изелгән күпчелек халыкны аңлата.

Мөхәммәдъяр иҗатындагы гаделлек, гадел хөкемдар, гадел идеаль дәүләтнең булган кебек итеп сурәтләнүләре нәкъ Нәваи яисә Низамида тасвирланган картиналар кебек.

Нәваидагы гаделлек идеяләренең Мөхәммәдъяр аша Тукайга кадәр килүе хакында әдәбиятыбыз белемендә моңа чаклы басылган хезмәтләрдә шактый тәфсилләп сөйләнелде инде.

Шик юк ки, татар әдәбияты үсеше тарихында Галишер Нәваиның роле зур булды. Аның әсәрләре безгә Казан ханлыгы вакытында ук килеп керде һәм аларның XVI йөзләргә караган кульязмалары Казан китапханәләрендә бүгенгә кадәр саклана, ә кульязма әсәрләр фондларында Нәваи шигырьләренең, газәлләре һәм җыентыкларының урын алуын да әйтергә кирәк. Алар татар укымышлылары тарафыннан кадерләп күчерелгән һәм буыннан-буынга саклана килгән. Нәваи иҗаты татарның күп шагыйрьләренә һәм шулардан Дәрдмәнд, Хәсән Туфан кебек бөек илһам иясенә дә үрнәк булган. Шуңа да татарның күренекле әдәбиятчылары, фикер ияләре Нәваи иҗатына һәрвакыт югары бәя бирделәр. Нәваи заманының бөек шагыйрь, фикер ияләреннән булган, һәм ул шулай булып кала да. Шиһаб Мәрҗани аңа гаять зур бәя биргән. «Вәфийятел-әсляф вә тәхийятел-әхляф» әсәрендә *(IV т.—Б. 212-213)* Нәваига махсус мәкалә багышланган, һәм андагы сүзләрне бирәдә Хәй ага Хисмәтуллин тәрҗемәсендә китерәм: «...Галишер Хорасан илендәге галимнәрнең иң бөекләреннән—мәшһүрләреннән, үз заманындагы әдипләрнең иң югары идеалы-үрнәге иде... Мохтажларга булышучы, олуг галимнәрнең таянычы, атаклы әдипләрнең ярдәмчесе иде... Галишер Нәваи үтә юмарт, кешеләр өчен һиммәтле, тырыш, сохбәте, утырышы татлы. Мәжлесләре әдипләр, галимнәр, шагыйрьләр белән тулы булып торган...» һәм Нәваи турында сүзне Г. Ибраһимов фикерләре белән тәмамлыйсы килә. Ул: «...Үзбәк әдәбияты Урта Азиядәге бер мәдәниятнең җимеше булып, безгә дә, госманлыларга да, азәрбайҗан әдәбиятына да зур тәэсир ясады. Моның алтын дәверендә житешкән шагыйрьләреннән Нәваи кебекләре Төркестанда ничаклы кадерле булса, Анатолиядә дә шул кадәр мәшһүр иде», диюе белән хаклы иде.

Нәваи иҗаты—бик киң, ул тулы бер диңгезне хәтерләтә. Шагыйрьнең төрки телне зурлавы, шигъри осталыгы, образларның гаять канатлы булулары, гомумән, әсәрләре турында бирәдә сөйләнмәде. Сүз билгеле бер дәрәҗәдә Нәваи иҗатының татар әдәбиятына йогынтысы, бәйләнеше турында гына барды.

**Шакир АБИЛОВ**

Kitap kuzətu
Китап күзәтү

# ЧОРЛАР КИЧЕП КАЙТТЫ БЕЗГӘ ШАГЫЙРЬ

Әйе, кайтты. Китап булып кайтты! Сүз Урта гасыр төрки-татар шигъриятенең күренекле вәкиле Сәйф Сараиның (1321-1396) 1999 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Гөлестан. Лирика. Дастан» исемле җыентыгы турында бара. Дөрес, шагыйрьнең әсәрләре Казан матбугатында XX йөзнең алтмышынчы еллар уртасыннан бирле күренә килә. Әмма бу соңгысы—тулы җыелма. Аңа шагыйрьнең фәнгә әлегә мәгълүм булган барлык әсәрләре тупланган.

Җыентыкны матбугатка әзерләүче—филология фәннәре докторы, КДУ профессоры Хатыйп Миңнегулов—Сәйф Сараиның иҗади мирасын ике кулъязма чыганактан алган. Алардан беренчесе—«Китабе Гөлестан бит-төрки» («Төркичә Гөлестан китабы»)—XIV гасыр азагында Мисырда төзелгән һәм хәзерге вакытта Голландиянең Лейден университеты китапханәсендә саклана. 373 битлек бу кулъязманың 3-356 битләрендә «Гөлестан» әсәре һәм шагыйрьнең төрле жанрларда язылган 18 шигыре урын алган. «Ядгярнамә» дип аталган икенче кулъязма XIV йөздән соңрак күчерелгән булырга тиеш. Аның бүгенге саклану урыны—Үзбәкстан фәннәр академиясенең Кулъязмалар институты. Ядкярнең 4-12 битләрен Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны һәм 5 шигыре алып тора. Менә шушы кулъязмалардагы текстларны уку, гарәп графикасыннан гамәлдәге язуыбызга күчерү, бүгенге укучыларга аңлашылмый торган сүзләрне һәм юлларны татарчага тәрҗемә итү, тиешле шәрехләр, кереш һәм ахыргы мәкаләләр язу кебек ифрат кыен, җаваплы эшләрне башкарырга туры килгән китапны төзүчегә.

Һич икеләнмичә әйтә алабыз: бу зур эш яхшы сыйфат белән башкарылган! Башкача булуы да мөмкин түгел. Чөнки Хатыйп әфәнде бу өлкәдә инде 30 ел эшләп килүче галим. Рецензияләнә торган китапның 35-36 битләрендә бирелгән «Сәйф Сараи иҗатына мөнәсәбәтле кайбер хезмәтләр» исемле библиографик белешмәдә Х. Миңнегуловның 16 тикшеренүе күрсәтелә. Үзенең бу юнәлештәге беренче мәкаләсен («Гөлестан бит-төрки кулъязмалары») ул әле 1971 елда—Казан университетында аспирант чагында ук бастырып чыгара. Шул вакыттан бирле галим, Урта гасыр әдәбиятының башка житди мәсьәләләрен өйрәнү белән беррәттән, Сәйф Сараи иҗатын һәрдаим игътибар үзәгендә тота. 1972 елда ул университет нәшриятында шагыйрь иҗатына багышланган беренче китабын бастырды. Шул ук елны «Переводы и оригинальные произведения Саифа Сараи» дигән темага кандидатлык диссертациясе якланды. 1976 елда шагыйрь турындагы беренче китабын бик нык кинәйтеп, тирәнәйтеп житди монография рәвешендә мәйданга куйды. Бу хезмәт фәнни даирәләрдә, вакытлы матбугат битләрендә югары бәя алды.

Әлбәттә, бу чорда Сәйф Сараи иҗаты белән башка танылган галимнәр һәм әдипләр дә актив шөгыльләнде. Профессорлар Х. Госман, Ә. Нәҗип, венгр тюркологы А. Бодрочлигети, төрек әдибе Феридун Нафир Узлукуп һ. б. ларның китаплары шул хакта сөйли. Хәлбуки, соңгы 15-20 елда бездә Сәйф Сараи иҗатын эченә алган бер генә басманың да профессор Х. Миңнегулов катнашыннан башка дөнья күргәне юк. Галимнең «Татарская литература и восточная классика» дип исемләнгән һәм 1991 елда якланган докторлык диссертациясендә Сәйф Сараи иҗатын анализлауга житди урын бирелә. Бу хезмәт ике елдан соң шул ук исем астында зур монография төсендә дөнья күрде. Ул галим иҗатының мөһим бер йомгагы булды: авторга, филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә белән бергә, фән һәм техника өлкәсендә Татарстанның дәүләт бүләген дә алып килде.

Әнә шундый юллар үтеп килде Хатыйп Миңнегулов «Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан» дигән китапны чыгаруга. Беренче карашка бар да бик гади һәм җиңел шикелле. Күптән танылган, әсәрләре дә билгеле булган олы шагыйрь. Китап итеп төзе дә чыгар!.. Әмма реаль күзаллап карасаң, бу басманы матбугатка әзерләү өчен төзүчедән никадәр киң эрудиция, махсус күнекмәләр, төгәллек, тырышлык таләп ителә. Сүз XIV гасыр азакларында Мисырда гарәп графикасында иске төрки-татар телендә иҗат ителгән шигырьләр турында бара бит! Аларны ничек итеп бүгенге татар кешесе укырлык һәм аңларлык дәрәҗәгә китерергә? Х. Миңнегулов алдында торган иң четрекле сорауларның берсе, һичшиксез, шушы булгандыр.

Төзүче төп чыганак итеп алда күрсәтеп үтелгән ике кульъязманың фотокүчермәләрен алган. Алардагы гарәпчә язуда бирелгән текстларны хәзерге татар графикасына күчереп чыккан. Бу— текстологик эшнең беренче иң җаваплы этабы.

Сәйф Сараи әсәрләренең теле иске төрки-татарча дидек. Әгәр фонетик ачкычын тапсаң, алардагы сүзләрнең зур күпчелеген аңлап була. Әмма арада архаик сүзләр һәм сүзтезмәләр, чит телләр лексикасы, хәтта гарәпчә-фарсыча озын-озын өзекләр дә житәрлек. Аларга сүзлек бирсәң, укучыга тексттан бик еш аерылырга, фикер эзлеклелеген жуярга туры киләчәк. Тоташ тәрҗемә итеп чыксаң, оригиналның үзенчәлекле йөзе югала, фәнни-документаль кыйммәте кими. Шуңа күрә Х. Миңнегулов сайлаган юл мондый шартларда иң отышлысы булып тора: ул тәрҗемә-аңлатмаларны, жәяләр эченә алып, төп текст эчендә, оригиналлары белән янәшә биреп бара. Борынгы текстлар белән эш итүче башка галимнәребез дә бу тәҗрибәне киңрәк үзләштерсәләр иде.

Шушы рәвешчә текстологик киртәләрне үткәннән соң да, төзүче алдында әле башка җаваплы бурычлар кала. Аеруча мөһиме һәм авыры—китапка кереш мәкалә язу. Аңлашыла ки, мондый мәкалә укучыларның әсәрне аңлап, яратып, тәмен белеп укуларын тәэмин итәргә тиеш. Монда автор Сәйф Сараиның әсәрләренә әдәби анализ бирү белән генә чикләнә алмый: аңа шул чор тарихын, ил һәм халык яшәгән иҗтимагый-социаль шартларны, мәдәни мохитне, шагыйрьнең нинди традицияләргә таянып иҗат итүен, аларны ничек үстерүен, баетуын тикшереп-ачыклап чыгарга кирәк була. Сәйф Сараи заманы—Алтын Урда тарихының һәм шул тарих белән турыдан-туры бәйләнгән төрки-татар әдәбиятының ифрат катлаулы, каршылыклы, шул ук вакытта билгеле бер дәрәҗәдә чәчәк аткан, байтак илләрдә танылу тапкан чоры. Мәсьәләнең бу ягына кагылып, Х. Миңнегулов бик хаклы рәвештә болай яза: «Алтын Урда башкаласы Сарайның (сүз Сарай-Бәркә турында бара) сәяси мәркәз генә түгел, ә Урта гасыр мөселман дөньясының мөһим гыйльми, мәдәни үзәге дә булуы бәхәссез. Шуңа күрә Сәйф Сараиның биредә укуы, шагыйрь буларак өлгерүе, үзенә Сараи кушаматын алуы табигый һәм мантикый күренеш... Кыскасы, шагыйрьнең тумышы, яшьлеге, гомеренең зур өлеше Идел-йорт, төрки-татар язмышы белән тыгыз бәйләнешле...» *(7 бит).*

Иҗтимагый-сәяси тарихтан билгеле булганча, XIV гасырның алтмышынчы елларыннан Алтын Урда язмышының аеруча катлаулы дәвере башлана. Нәкъ әнә шул елларда төрле ханнарның һәм әмирләрнең ызгыш-талашлары, үзара сугышлары куерып китә. Академик В. М. Жирмунский язганча, 1360-1380 еллар арасында, ягъни нибары 20 ел эчендә Алтын Урдада 14 хан алмашына, эре феодаль олыс әмирләре мөстәкыйльлек өчен көрәшәләр, үзәк хакимияткә буйсынудан баш тартмакчы булалар. Ил өчен нәкъ әнә шундый куркынычлы еллардан соң акыллы, хәйләкәр, нык ихтыярлы мәшһүр Идегәй морза күтәрелеп чыга һәм нигездә ул хөкем сөргән 1395-1419 елларда илдә билгеле бер тәртип урнаштырыла *(В. М. Жирмунский. Мелиоранский и изучение эпоса «Едигей» // Тюркологический сборник. 1972.—М., 1973.—Б. 156.)* Әмма Урдада хәлләр инде бик авыр була. Иҗади хезмәт турында уйлап торырга да урын калмый. Шуңа күрә дә аерым шагыйрьләр һәм әдипләр Мисыр-Сүриягә, Кече Азиягә күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Х. Миңнегулов язуын-ча, «70-80 елларда Сәйф Сараи да Идел Йортны калдыра. Ул үз ватаныннан аерылып, башка жиргә күчүне бик авыр кичергән:

Туфрагым өстендә сөңгеләр үскәч
(ягъни сугыш булгач),

мин өйдән (илемнән) аерылдым,
Ватаннан мәхрүм булдым да, башка
йорт (ил) кешесенә әверелдем.
Язмыш мина ни кадәр җәбер китерде,
нинди гөнаһым бар?!
Иляһым, кимет җәберенне (ярлыка),
мин бит илгә тугрылыклы ул идем.

*(Х. Миңнегулов тәрҗемәсе, 7 бит).*

Шул рәвешчә, туган иленнән аерылырга мәҗбүр булган шагыйрь сиксәненче еллар азагында—туксанынчы еллар башында Мисырда яшәп иҗат итә. Аның әсәрләре арасында күренекле урынны «Гөлестан бит-төрки» («Төркичә Гөлестан», 1391) алып тора. Ул Иранның бөек шагыйре Сәгъдинең (XIII йөз башы—1292) фарсыча «Гөлестан» әсәренә нигезләнеп язылган. «Төркичә Гөлес-тан»,—дип күрсәтә Х. Миңнегулов,—тәржемә әсәр... Төрки авторы оригинал-ның төп эчтәлеген, төзелешен, рухын саклый, Сәгъдине үзенең остазы итеп таный. Әмма биредәге «тәрҗемә» төшен-чәсе әле хәзер без күнеккән мәгънәсен-нән үзгә буларак, гаҗәеп күптөрле күре-нешләрне үз эченә ала. Биредә без төгәл һәм ирекле тәрҗемә үрнәкләре, ориги-наль юллар, шигъри җаваплар, версия-вариантлар һәм башка төр мисаллар белән дә очрашабыз» *(21-22 битләр).*

Урта гасыр дөнья әдәбиятының төп таләпләренә тулысынча туры килгән әсәр буларак, шактый зур күләмле «Гөлестан бит-төрки» Х. Миңнегулов җыентыгында төп өлешне тәшкил итә *(37-246 битләр).* Әсәр зур күләмле һәм эчтәлеге белән күпкырлы булса да, аны уку һәм аңлау кыен түгел. Беренчедән, без биредә күптәннән таныш сюжетлар һәм герой-персонажлар белән очрашабыз. Икенчедән, төзүче, инде алдарак та әйткәнебезчә, әсәрнең асылына һич зыян китермичә, аны кабул итүне нык җиңеләйткән, тексттагы бик күп урыннарга тәржемәләр, шәрехләүләр өстәгән. Аннан, «Гөлестан»да без яхшы белә һәм еш куллана торган татар мәкаль-әйтемнәре байтак очрый. Фарсыча оригинальдәге афористик гыйбарәләргә үз халкы фольклорында тәңгәлләр булса, Сараи өстенлекне соңгыларына бирә. Аларны бик ипле генә итеп, текст тукымасына үреп җибәрә. Үз нәүбәтендә, шагыйрьнең тәржемә яки үзе иҗат иткән афоризмнары соңыннан халык телендә мәкальләр сыйфатында кулланыла башлыйлар. Моның мисаллары дистәләрчә.

С. Сараи сүзләре:

Йимәс эт саркытын килеб арслан,
Гар (мәгарә) эчендә ачин үләр булса.

Халык мәкальләре:

Эт саркытын арыслан җимәс.
Эттән калганны арыслан җимәс.

С. Сараи сүзләре:

Елан башын дошман әле белән яньчегел.

Халык мәкальләре:

Кеше кулы белән елан тот.
Еланны үтерергә дошманына куш һ. б.

Китапның нәүбәттәге зур булмаган бүлеге «Нәзыйрә әсәрләр. Лирика» дип атала (247-268 битләр). Хәзерге әдәбиятта шактый сирәк очраучы «нәзыйрә» атамасының мәгънәсе «әдәби җавап, охшатма, бер әсәргә нигезләнеп, икенче әсәр язу» дигәнгә туры килә. Шәрык сүз сәнгатендә күп кенә әсәрләр нәзыйрә белән иҗат ителгән. Мәсәлән, Г. Нәваиның (1441-1501) «Хәмсә» («Биш поэма») шәлкеме Низами Ганҗәвинең (1141-1209) һәм Әмир Хөсрәү Дәүләвинең (1253-1325) шул циклдагы һәм сюжеттагы әсәрләргә нәзыйрә булып торалар.

Сәйф Сараи заманында нәзыйрәләр язу иң популяр иҗат ысулларыннан берсе була. Табигый ки, талантлы шагыйрь үзе дә мондый «шигъри ярышлардан» читтә тормаган. Күзәтелә торган җыентыкта аның каләмдәшләре Мәүлә Казый Мөхсин, Мәүлана Исхак, Мәүлана Гыймад Мәүләви, Әхмәд Хуҗа Сараи, Харәзми, Габделмәҗид, Туглый Хуҗаларның аерым шигырьләренә язган нәзыйрәләре китерелгән. Шунысы да бик мөһим: китапта югарыда исемнәре аталган шагыйрьләрнең Сараига нәзыйрә язу өчен нигез, этәргеч булып хезмәт иткән әсәрләре үзләре дә урын тапкан. Димәк, безгә, өлешчә булса да, Алтын Урданың XIV йөздә яшәгән башка күренекле шагыйрьләре, ул чордагы иҗади зәвыклар, әдәби-эстетик идеаллар һ. б. ш. белән танышырга мөмкинлек туган. Бу мәсьәләләр С. Сараиның «Фи әүсафи-ш-шөгара» (Шагыйрьләрне сыйфатлау) исемле оригиналь шигырендә дә күтәрелә. Оригиналь әсәрләрдән биредә аның тагын 4 газәле, 4 робагые һәм мондый бер икеюллыгы бар (266 бит):

«Нәдер ул кем сукыб-тартып бөнелмәс,
Башы зәхме дәва берлән уңалмас».

Безнеңчә, бу елан турындагы табышмак булырга тиеш. Традицион рәвештә «Ул нәдер кем?» дигән сорау белән башланучы мондый әдәби табышмаклар соңгырак дәверләрдә татар шагыйрьләренең иҗатында шактый еш очрый торалар. Ягъни, Сараилар традициясе дәвам итә. Менә бер генә мисал. Аны без 1861 елда Чистай Каргалысында язылган бер кульязма буенча китерәбез (җавабы: ел, айлар, тәүлекләр, төн, көн):

«Ул нәдер кем, бер йыгач яратты хак,
Ул йыгачта бардыр унике ботак,
Ул ботакта бардыр утыз яфрак,
Ул яфракның тышы кара, эче ак».

Шигърият әсәрләре «Ядгярнамә» кульязмасыннан» дигән өченче бүлектә дә *(270-290 битләр)* дәвам иттерелә. Монда да Сәйф Сараи замандашларыннан берничә шагыйрьнең иҗат өлгеләре тәкъдим ителә. Аннан автобиографик эчтәлекле 3 робагый һәм бер икеюллык (фәрд) килә. Бу бүлектәге (һәм гомумән шагыйрь иҗатындагы) аеруча әһәмиятле әсәр—«Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны. Сюжеты һәм эчтәлеге буенча ул тулысынча диярлек халык дастаннары традицияләренә нигезләнгән: Аксак Тимернең Үргәнечкә һөҗүме һәм бик күп явызлыклар кылуы; Сөһәйл исемле бер гаскәриненң әсир төшүе һәм зинданга ташлануы; шаһ кызы Гөлдерсеннең әсир Сөһәйлгә гашыйк булуы; ике гашыйкның бергәләп качып китүе; аларның ачлыктан һәм сусаудан һәлак булулары... Хатыйп Миңнегулов, бу әсәрнең тарихи нигезләрен өйрәнеп, аның сюжеты конкрет тарихи шәхесләр: Туктамыш хан улы һәм Аксак Тимер кызы арасындагы фаҗигале мәхәббәткә корылган булуы мөмкин, дигән фикер әйтә.

«Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны бүгенге татар укучыларына электән дә таныш иде. Чөнки шагыйрь Нури Арсланов аның хәзерге телгә әдәби тәрҗемәсен эшләп, «Казан утлары» журналының 1972 елгы 6 нчы санында бастырып чыгарган иде. Шагыйрьнең җыентыгына бу тәрҗемәне дә кертеп, төзүче дөрес эшләгән. Моннан китап тагын да байый төшкән. Укучыларга Сараи оригинален Арсланов тәрҗемәсе белән чагыштырып укырга мөмкинлек туган...

Кыскача йомгак шундый. Мәкаләбезнең исемендә әйтелгәнчә, XIV йөзнең күренекле шагыйре Сәйф Сараи, чорлар кичеп, безгә яңадан кайтты. Әсәрләренең тулы җыелмасының чын фәнни басмасы булып кайтты. Мондый академик басмаларны, озакка сузмыйча, Котб, Харәзми, Хисам Кятиб кебек башка олы шагыйрьләребез иҗатлары буенча да әзерлисе иде. Борынгы әдәбиятыбызның зур белгече Хатыйп Миңнегулов бу изге эшләрдә дә әйдәп баручы булсын иде.

**Фатих УРМАНЧЕ,**
**Хуҗи МӘХМҮТОВ,**
филология фәне докторлары.

# САФТА КАЛЫР, САКТА КАЛЫР!

*Җир кадерен саклап булыр*
*Тәрбияләп һәм ашлап.*
*Шигырь кадерен кем саклар*
*Наҗар да китсә ташлап.*
Рим Идиятуллин.

Гасырның соңгы елында әдәбиятыбыз гаять зур югалту кичерде. Наҗар Нәҗмисез калды. Озакламый аның кайтавазы булып газиз халкына, миллионнарча укучыларына васыяте сыман «Күңел сәхифәләре» китабы дөньяга чыкты.

Дөрес, мәрхүм шагыйрь үзе исән чакта бу язмаларны матбугатта бастырган, үзе күргән—алар тиешле бәя дә алгандыр. Әмма болай билгеле тәртипкә салып, җыентык-кулланма итеп чыгару, безнеңчә, бәяләп бетергесез хәзинә.

Китапка багышламада әйтелгән-

чә, анда ил язмышы, әдәбият дөньясы, мәдәни бәйләнешләр хакында уйланулар, истәлекләр тупланган.

Сәхифәләрне кайта-кайта укыгач, шагыйрьнең җанлы образы күз алдына килеп басты.

—Бәй, Нәҗар агай, сине «дөньядан китте», дип яздылар түгелме соң? Ә син әдипләр сафында гына түгел, шигърият сагында да торасың ич!—диясе килде.

Язмамның бисмилласы шигырь сафлыгы турында. Ике милләтнең бөек шагыйре һәр сәхифәсендә диярлек шул хакта сүз алып бара. Аңа нисбәтле шигъри даирә бик киң: Тукай, Дәрдмәндләрдән башлап, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Мариус Макъсутов кебек яшьрәк каләмнәрне, хәтта шигырь язучы кызларны да игътибарсыз калдырмый Нәҗар ага.

Алай гына да түгел. «Зур корабка зур дәрья» дигәндәй, шагыйрь милли әдәбият кысаларында гына «йөзми», дөнья һәм урыс әдәбиятындагы Бальзак, Гюго, Гете, Пушкин, Лермонтов, Маяковский, Фадеев, К. Кулиев, Р. Гамзатов, кебек бөек затлар белән бәйләнешкә керә.

Юк. Андый шәхесләр алдында да шагыйрь егылып ятмый, иҗатларына дифирамб укымый, ә җае килгәндә үрнәк итеп кенә туктала, йә булмаса бәхәскә керә, хәтта кире дә кага.

Менә мисаллар:

А. Пушкин 1836 елда «Азатлык» сүзен баш хәреф белән «Восславил я Свободу» дип язса да, 15 ел алдарак: «Смирись, Кавказ, идет Ермолов!» дип сөрән салган һәм «Азатлыктан баш тарт, кол булып яшә!» дип өндәгән *(189 бит)*.

Икенче урында автор В. Маяковскийның «Тот, кто постоянно ясен, тот по-моему, просто глуп» дигән сүзләрен ала да, Пушкин, Лермонтов, Тукай, Есениннарның һәрвакыт ап-ачык булуларын икърар итә. *(13 б.)*

Популярлык һәм дан мәсьәләсендә дә шагыйрьнең үз карашы. Берчак автор Р. Гамзатовның соңгы шигырьләрен мактавын әйткәч, тегесе рәхмәт әйтә һәм «но ты пиши об этом» дияргә дә онытмый *(174 б.)*.

Ә инде милли әдәбият дөньясында «кагылгысыз» дип кабул ителгән Мостай Кәрим, Гайса Хөсәенов, Рәшит Нигъмәти кебекләрнең һәм башка эрелеваклы әдипләрнең яхшы сыйфатларын, иҗади уңышларын күрсәтү белән бергә, җитешсез якларын да «ярып» сала.

Әдәбият язмышы, шигырь сафлыгы—Н. Нәҗминең Мәккәсе. Кем хакында гына сөйләмәсен, нинди мәсьәлә күтәрмәсен ул үз язмышына бәйләп иҗат, шигърият осталык чытырманлыгына кыю килеп керә һәм аныңча әйткәндә, «табышларга», «ачышларга» юлыга. Сәхифәләрнең исемнәренә генә игътибар итегез: «Шигърият йолдызы (Тукай), «Шагыйрь эзләгәндә» (Атнабай), «Шигърият һәм язмыш» (Х. Назир), «Галимлек һәм язучылык» һ. б. ш.

Нәҗар Нәҗми өчен Татарстан белән Башкортстан, татар белән башкорт арасында чик һәм аерма юк. Ул икесенә дә берүк карашта, берүк хезмәттә. Шуның өчен дә «Ике көймәнең койрыгын тотарга маташучы» ярлыгына «лаек» булган.

Алай гынамы?! Халтурага рәхимсез, туры сүзле булганы өчен «ахмак», «явыз», «Унтер Пришибеев» тәхәллүсләре дә ябыштырганнар аңа. Әмма язмаларына караганда (аларның иң соңгысы 1996 елга карый) аксакал шагыйрьнең бөртек чәченә дә зыян килмәгән, үткер күзле, туры сүзле «туры Тукай» булып калган. Сәхифәләр авторын сокландырган шәхесләр байтак. Нәҗар аганың Тукай иҗатына мөкиббән булуын күрә килдек. Монда да четерекле мизгелләрдә аңа сыена, иҗатына таяна, осталыгына соклана. Әйтергә кирәк: «күңел сәхифәсен»дә «Шигърият йолдызы» Тукай белән ачып җибәрә.

«Габдулла Тукай—шигырь өчен туып, шигырьдә яшәп, шигырьдә үлгән җан. Тукай һәм шигырь—ул аерылгысыз бер бөтенлек, бер дөнья»,—ди автор Максим Горькийның Есенин хакында әйткән сүзен куәтләп *(50 б.)*.

Мәшһүр шагыйрь Хәсән Туфан хакында моңа кадәр дә күп язган иде. Әмма үлгәннән соң ун ел үткәч дөнья күргән «Гүзәл гамь» китабына карата да битараф калмаган. Киресенчә, бу бөек затны тагын да зурлаган, югарырак күтәргән, иҗат лабораториясенә үтеп кергән.

«Ул—Пушкиннар, Лермонтовлар, Есениннар, Тукайлар кебек шигърияттән тукылган җанлы материя» дип бәяли. «Туфанчылык—ул чын шагыйрьлек, саф күңеллелек, табигыйлек, кешелеклелек дигән сүз», дип нәтиҗә ясый. Арытаба бу изге затның үз тормышына һәм иҗатына игътибарын, йогынтысын бәян итә.

Татар халык язучысы Гомәр Бә-

широв шигырь язмаган. Әмма һәр татар-башкорт кешесе белгән һәм жырлаган «Жидегән чишмә» жырын иҗат иткән. Бу хәлне Г. Башировка багышланган сәхифәсендә «Нажар энекәше», уенынчынын бергә кушып, А. Эйнштейнның бердән-бер ачышы—«нисбәт теориясе» белән чагыштыра (1886). Мәкалә ачык хат шәкелендә язылган, аксакал әдипнең гадилеге, кечелекле булуы, жимешле иҗаты сокландыра авторны.

Н. Нәжми табынып яшәгән шагырьләрнең тагы берсе—Сибгать Хәким.

Һәр мәртәбәле татар өчен «кендек әбисенең» газиз зат булганын истә тотып, Нажар ага аны «татар шигъриятенең «кендек бабасы» дип атый. Шигырьләренең серле, арбау куәтле булуын, һәм халыкчан, табигый иҗат итүен күрсәтә.

Сәхифәләр авторы шагыйрьләрне аерым алып та, төркемләп тә тикшерә. Соңгысы чагыштырулар, охшашлыклар, каршы куюлар аша язмаларның эчтәлеген кинәйтә, укучының кызыксынуын көчәйтә. Анын, мәсәлән, өлкән буыннан Кадыйр Даян—Сәләх Кулибай—Гайнан Әмири, үз тиңнәреннән Х. Гыйләжев—Г. Рамазанов—Ш. Биккол—«өч таган», яшьрәкләрдән М. Кәримов—Р. Сафин—А. Игебаев—Р. Гарипов төркеме (Н. Нәжми аларны Мостай Кәрим язган «Каләмдәшләргә хатлар»дан соң килеп чыккан төркем», ди) кызыклы һәм мавыктыргыч итеп тасвирлана. Тәүге төркемдәге шагыйрьләрне «өчесе өч төрле» дип бәяләсә, икенче «өч таганны» башкорт әдәбиятында төпкә жигелгән шигърият атлары, дип атый.

Шуңа куанасың: яхшы шагыйрьме ул, уртакулмы, Нажар ага күбрәк алардан асыл сыйфатлар, кыйммәтле жәүһәрләр эзли. Эзли һәм таба. Үзенчәлекле холык-гамәлләрен ачып күрсәтә, тормыш, жәмгыять, власть һәм хакимият тарафыннан кыерсытылганнарны яклап чыга.

Мондый вәзгыятьләрдә үзе дә катнашкан очракларны да читләтеп үтми, «соң булса да ун булсын», дигәндәй, үкенеч белдерә. Монда, әлбәттә «сәхифәләр» авторының да күңел сафлыгы ялтырап ала. «Сафлык» дип сүз кузгаткач, шуны да өстик: Н. Нәжми каләмдәшләре каршында гарьләнү, якты көнләшү хисләреннән дә мәхрүм түгел. «Шагыйрьне «эзләгәндә» (Көнләшү) мәкаләсендә, мәсәлән, Атнабай шигырьләрен югары бәһалап, «минекеләрне бәреп екты», ди. Үз драмаларының да бу автор әсәрләреннән күпкә кайтыш, кыска гомерле булуын таный. Үзеннән шактый түбән торган яшьрәк шагыйрьләрнең дә иҗади табышларына жирекүге белән шатлана. Күренекле әдипләр арасында мондый ихласлык һәм кечелеклелек күренгәне юк иде әле.

Кеше шатлыгына, уңышына ихлас сөенү, аның кайгысын, кичерешләрен йөрәк аша үткәрү кебек асыл сыйфатлар Н. Нәжми кебек олы затларга гына насыйп буладыр. Аның үткер күзеннән, әхлакый сизгерлегеннән берни дә читтә калмый: Заманында жырлары белән дан казанган («Шәйморатов генерал» жырын гына искә алыйк) Кадыйр Даян дигән шагыйрьнең онытыла баруы, пенсия яшенә житкәндә генә рәсми язучы булган Әхмәт Гайсин белән Хәсән Назар, партиядән куылып, иптәшләре тарафыннан кыйналып, сукбай тормышы кичергән Динис Исламов, каләмдәшләре тарафыннан «типкәләнеп» яшәгән Мәхмүт Хөсәен, әдәби-мәдәни мохиттә хөкем сөреп килгән тискәре күренешләр, үзара начар мөнәсәбәтләр, кайбер шәхесләрнең тискәре гадәтләре—һәммәсе сәхифәләргә кергән һәм хөкем ителгән.

Шагыйрь йөрәген әрнеткән нәрсәләрнең берсе—милләт, милли әдәбият һәм туган тел язмышы.

Бу жәһәттән ул кыю полемист булып чыгыш ясый: шовинистик рухлы А. Руцкой, академик А. Яковлев кебек сәясманнар белән көрәшкә чыга. Милләтнең тинлеген, азатлыгын даулый, «сазлыктан» чыгу юлларын газапланып эзли.

Бу яклап ул бушбугаз сәясмән булып түгел, үткер телле, туры сүзле көрәшче шагыйрь булып кала. Татар шагыйре Рәшит Әхмәтжановның гаделлек, азатлык даулап йөрәге ярылып үлүен хәбәр итә дә, үз каләме белән «һөжүмгә» күчә.

Акыл теле, йөрәк теле,
Шагыйрьнең йөрәк көче.
Шул коралы белән чыга
Сугышка шагыйрь кеше...

Сәхифәләрнең күбесендә автор шигъриятнең һәм милли әдәбиятның чүпләнүе хакында сүз кузгата: берсендә әрсез графоманнарның, сәхнә шылгаякларының, жинел-жилпе «шигырь язучыларның» үрчеп-күбәеп китүе хакында әйтсә, икенче язмада чын шагыйрьләрнең табышлары, уңышлы язылган әсәр-

ләр игътибарсыз, бәясез калуын бәян итә.

«Шагыйрьләребездә поэтик күренешләрне анализлый алырлык тәнкыйть юк... Сирәк-саяк теге яки бу шагыйрь китабы хакында мәкалә чыккалый башлады, әмма аларда шигырь турында фикер йөртүләр—ташка үлчим» *(123 б.)* дип борчыла ул.

«Байтак еллар инде,—дип дәвам итә бу фикерен Нәҗми ага Р. Миннуллинга багышланган сәхифәсендә,—шигырьне укымыйлар, шигырьнең кадере китте, дигән сүзләр шигырь язучыларның (чын шагыйрьләрнең әлбәттә) йөрәгенә ут булып тама... «Шигырь язып гомер заяга үттеме икән әллә?»—дип уйлап куясың. Ә соң шигырь кадерен кем җибәрде?»—дип эндәшә дә, шигырь кадерен үзебез җибәрәбез, дигән сыгымта ясый *(220 б.)*.

Н. Нәҗми—атаклы «Татар теле» әсәренең авторы буларак безгә аеруча кадерле. Шушы бер яктан «назлы», «моңлы», «ачык йөзле», «гайрәтле», «зindанnarны ярып чыккан», икенче яктан «чукынмаган», «дөньяда күп нәрсә күргән», «янган», «туңган» телебезнең кадерен белергә һәм сафлыгын сакларга омтыла ул.

Моның өчен Х. Туфанның иҗат лабораториясенә кереп, шагыйрьнең тел өстендә ничек «интегүләренә» күзәтү ясый. «Тик сәлам бу» исеме астында утыз юлга да тулмаган бу шигырьне Туфан дүрт ел дәвамында өч вариантта язган. Шигыренең һәр юлына , сүзенә, хәтта ки авазы белән тыныш билгеләренә кадәр сак һәм игътибарлы булган шагыйрьгә хас сыйфат бу. Монда аның үз иҗатына таләпчән булуы да ярылып ята. «Бу таләпчәнлек,—ди сәхифә авторы, күпләребезгә зур сабак».

Халык шагыйре Н. Нәҗминең «колач салып йөзә» торган мәйданы—драматургия һәм театр.

Дөрес, ул бу юнәлештә зур уңышка ирешмәвен, «януын» таныса да, бу өлкәдә эшләүчеләрнең дә «үзәгенә үтәрлек» сүзләр әйтә. Ул, мәсәлән, заказ буенча» пьеса язуны хупламый: шундый юл белән Н. Гаетбайның 14 көндә «Аты барның—дәрте бар» әсәренең язылуы, драматургларның аны классик комедия дәрәҗәсенә күтәрүләре хакында әйтеп, тамашаның киләчәк язмышына шик белдерә.

Дөрестән дә, зур шау-шу кузгаткан, лауреатка дәгъвә иткән бу тамаша озын гомерле булмады, сүнде.

Туган телгә, мәдәнияткә, шигърияткә бәйләп автор әдәбиятыбызның киләчәге өчен дә бик борчыла.

«Китапны үтерүчеләр барлыкка килде,—ди ул алама китаплар чыгуын күз уңында тотып.—Аларны үтерүдә иң беренче урта куллы шагыйрьләр һәм язучылар булса, икенчесе—иң куркынычлысы булып милләтнең урыслашуы, димәк, урыс теле тора. Туган телдә китап укучылар саны елдан-ел кими, әгәр дә киләчәктә дә тормыш шулай барса, озакламый милли телдә язучылар да, китап укучылар да булмаячак» *(127 б.)*.

Гыйбрәтле сүзләр. Әдип китап бетә дип зарланмый. Һәм аның беткәне дә юк. Җитмәсә, өр-яңа басмалар (журнал һәм газеталар) күбәя. Ә соң тиражы? Укучылары? Әһле каләм үз казанында гына кайнаша түгелме соң?

Әдәбиятыбызның сафлыгын һәм гомерен саклап калу өчен моңа кадәр яшәп килгән бер-беренне мактауга корылган тәнкыйтьтән ваз кичеп, әнә шул Нәҗәр ага кебек тәвәккәл, аяусыз адымнар да ясарга кирәктер.

Югыйсә, кустарь чабатасы сыман арзанлы әсәрләр белән дөнья тула: шуларга тиешле бәя бирелми, кире кагылмый.

Сүзем озынга китсә дә, яшьрәкләр өчен «кустарь чабатасы»на аңлатма биреп үтим: Ул «продукция», күрүегезчә, кияр өчен түгел, сату өчен тәгаенләнә. Әмма анда Такташның Шәхми бабасы кебек чабатачының хәйләсе катнаша. Хәйлә бик гади: межан юкәсен (беренче сортлы дисәк тә була) янга калдыру максатында сату чабатасы башта алам-салам юкә, кабык белән тугыла да, межан юкәсе белән йөзләп куела. Ялтырап торган, әмма кыска гомерле чабата килеп чыга.

Әйтәсе сүзем шул: әдәби әсәрләр дә «тыштан ялтырап, эчтән калтырап» торган «продукция» булмасын иде. «Күңел сәхифәләренә» кайтып, шуны әйтәсе килә: шигъриятнең, драматургиянең, публицистиканың, җыеп әйткәндә, тоташ әдәбиятның сафлыгын саклауда, үсү юлында бу китап яңа гасырда да кыйммәтле кулланма булырлык, күпләр аңардан сабак алырлык.

**Шәйхелислам ШӘЯХМӘТОВ,**
*Эстәрлебаш*

*Сатира һәм юмор*

## Фәнзаман Баттал

# САБАКТАШЛАР

хикәя

Лифт төймәсенә терәгән бармагын, ток сугудан курыккандай, кире алды Морза. Куркуын-курыкмаса да, күңелен икеләнү, югалып калу галәмәте биләп алы. Әнә бит, үз кадерен белгән сабакташы Казанның үзендә яши, башкаланың тап уртасында тора, дөньяны күкнең җиденче катыннан хозурланып күзәтә, йокыдан торгач, затлы халатын киеп, якты бүлмәләр буйлап йөренә, кофены да алтынланган калак белән болгатып эчә! Ә мин кем?.. Яшәгән йортым ни сала, ни кала диярлек шәһәрчектә, аның да бер сазлы читендә. Каты-этажы да берәү генә. Анысы да җиргә иңеп бара. Иртән торуга чәчбикәсе караватка терсәге тишелгән телогрейка ыргыта: «Күзләреңне эш беткәч уарсың, театрыңа киткәнче малларга азык сал, Морзакаем. Алар акчаны синең спитәкелеңнән күбрәк бирә.»

«Маллар» дигәне—алты дуңгыз. Әгәр дә баракта озын ул йортның ишек алдында абзар салырлык урын булса, хатыны кырык чучка симерттерү әмәлен дә табар иде дә бит—урын юк. Ә утын сараена алтыдан артыгы сыймый. Хатынга сүзсез баш иеш яшәүчеләрдән түгел инде анысы Морза. Ләкин нужа абзыкайга буйсынмый хәлең юк—үзе шикелле зур авызлы өч баласы күзенә карап тора. Чучка түгел шайтан да симертерсең бу дөньяда! Тәнгә исләре дә сеңеп бетте бугай инде шул мырыкбайларның...

Бармак битен лифтның чучка күзедәй бер янып, бер сүнеп торучы төймәсенә куйган килеш, Морза тагын уйга калды. Керми дә булмый шул сабакташына. Өч көн буе кунакханә бүлмәсендә ятар идең дә бит, айлык хезмәт хакың караватка түләү өчен чыгып бетәчәк. Белә, бик белә ул Альбертның кем икәнен! Театр училищесында укыганда ук башкаларга түбәнсетеп караганын да белә бу күркәнең. Ләкин кемдер уйлап тапкан бу семинар көннәрендә аңа сыенмыйча, һич югы идәнендә йокламыйча булмый. Куып чыгармас әле... Шунысы да бар бит, иншалла, бәләкәй шәһәрдә урнашкан булса да, Морза эшли торган театр да дәүләт театры дип йөртелә. Үзе дә ким-хур түгел—сәхнәгә чыгуы саен, камыт аяклы бу, кылыйрак күзле дип тормыйлар, гөрләтеп кул чабалар. Шәһәрнең бер сылу хатыны хәтта: «Бу тиклем оста уйнаган өчен шул Морзаның бияләй авызын суырып үбәр идем, билләһи!» диган, имеш. Әйе, төшеп калганнардан саналмый Морза. Телевидениедән дә ул катнашкан спектакльләрне күрсәткәләп торалар. Кайда барып чыкса да, кешеләр карап-карап торалар да: «Туктале, бу бит теге кем... кызыклы артист», дип, танышырга, сүз башларга чамалыйлар.

Морза тәвәккәлләде—кызыл төймәне сытардай итеп бармагын терәде. Лифт коесы эчендә нәрсәдер гөпелдәп куйды, ишек ярыгындагы яктылыкка күләгә төште һәм лифт, рәхим ит, дигәндәй, кочагын ачып җибәрде.

Капка баганасыдай төз, озын гәүдәле Альбертны күргәч, тагын бер кат кимсенеп куйды Морза. Ник дисәң, моның алдында маймыл да—маймыл, Морза да маймыл. Чибәрлеген дә бирә бит әле Ходай шушындый мәһабәт затларга! Алтын җепләр белән чигелгән түбәтәе, укалы башмагы бөтенләе белән хан иткән Альбертны. Мех якалы бизәкле халаты да тәхеткә утыруын сорап тора сыман.

Сабакташы Морзага ниндидер кәмитский балага караган акыл ияседәй башын иеп текәлде дә, көлә-көлә кулларын җәйде:

—Ба-а-а!.. Мырзый әфәнденең үзе түгелме соң бу! Күпме сулар, күпме

гомерләр аккач бит инде бу, ә! Нинди генә җилләр юк та, кемнәр генә юк бу дөньяда... Аякларыңны паласка ышкып җибәр дә, түргә уз, Мырзый туган. Авылча гадилегеңә авыл һавасын да ияртеп килгәнлегең сизелеп тора.

Аның тел төбен аңлап алган Морза да киң итеп елмайган булды.

—Соңгы атналарда авыллар тарафына чыккан юк-югын. Шулай да «авыл һавасы» өчен зур рәхмәт.

Альбертның елмаюы тагын да төчеләнде:

—Соңгы вакытта үз ягыңда булмадыңмыни? Әллә берәр зур шәһәрдән кайтып барышыңмы?

—Туры үзебезнең шәһәрдән килеш әле болай...

—Һи, малай, сезнең шәһәр үзе авыл инде ул, берничә таш бинасын санамаганда. Екатерина бикәгә рәхмәт инде, жәлләмәгән, өләшкән шәһәр статусын авылларга.

Кухняга үткәч, Альберт плитә өстендәге кәстрүл-мискеләргә күз төшереп алды, аннары суыткычтан бер җамыяк карабодай боткасын тартып чыгарды:

—Хурлап йөрисең дип әйтимме соң... Хатын иртән антрекот белән манты әзерләгән иде дә бит—беткәннәр. Башкала кешеләренең шул бит инде аларның... Бер ашарлык, песигә дә калмаслык итеп әзерлиләр дә, савыт-сабаларын да юып куялар. Авыл кешесенең гадәте яхшы, ичмасам! Бер пешергәнен хет атна буе ашап куан! Кара уылдык та беткән, ахрысы...

Эченә җылытылган карабодай боткасы кереп урнашкач, аны бәллүр стаканга салынган салкын чәй белән бастырыклап куйгач, Морза, кулындагы алтын калакны өстәлгә куеп, урыныннан торды:

—Гаҗәп яхшы булды бит бу, рәхмәт. Берне төтәтеп тә җибәрсәк әле!..

—Балконга чыгабызмы, лоджиягәме?

—Минем өчен барыбер.

Альберт, уйланып алгандай итеп торды да, тагын бер тәкъдим кертте:

—Көн кызу, күләгә яктагы лоджиягә чыгыйк әле без. Анда аякка да йомшаграк булыр—хатын үткән атнада гына яңа келәм җәйде.

Чыгып киттек кенә дигәндә, Альберт трильяж алдында тукталды һәм, кәнәфи аркасына эленгән галстукны кулына алып, аны ашыкмыйча бәйли-бәйли, көлемсерәп куйды:

—Казан халкы танылган шәхесләрен күз уңыннан чыгармый. Лоджиядә яки балконда чакта да күзәтәләр... Галстуксыз килешеп бетмәс.

Хәтта күзлеген дә алтын читлесенә алыштырып чыкты Альберт.

Чыгуга ук ике кулы белән дә култыксага сөялгән Морзага карап торгач, үз сынының һәйкәлдәй төгәллегенә, төзлегенә әз генә дә хилафлык китермәгән Альберт зажигалкасын кабызды. Аны әкрен генә авызындагы сигаретка якынайтканда лоджиядә Америка гимны яңгырады. Әйтерсең лә шат чикерткәләр биешә, бихисап вак кошчыклар сайраша! Күз алдында көр куаклыклары белән сокландыручы иксез-чиксез болын манзарасы ачылып киткәндәй була.

—Да-а, синең зажигалкаң да үзе бер оркестр!—димичә түзмәде Морза.

—Шәбен шәп тә бит, кыйбатрак булды түлке,—диде сабакташы сүрән генә.— Шушында да миллионны әрәм иткәнсең дип үпкәләмәкче идем дә хатынга, ләкин, асылташлар белән бизәлүенә игътибар иткәч, тыелып калдым инде.

—Синең хатының шундый әйберләрне дә үзе аламыни? Һәй, минеке шушы «Идел» сигаретын да алып кайта белми...

—Минем хатын ул яктан бик нәзәкатьле, таләпчән ул. Чөнки җәмгыять алдындагы абруемны тирән аңлый. Мин үзем, мәсәлән, «Аполлон», «Монтана» кебек сигаретларга да риза. Ә хатын андый гадилеккә юл куймый. «Син бит тамашачыларның иң сөекле сәнгатьчесе, Зур театр артисты», дип, кисәтеп тора, иртә саен кесәмә «Майльборо» тыга. Хур була күрмә, дию инде үзенчә...

Бу кадәресенә анализны тиз дә, гадел дә ясады Морза: Зур театрда эшләсә дә, Альбертны сәләтлегә санаучылар ни сәнгать әһелләре арасында, ни тамашачылар мөхитендә һич тә сизелми. Дөрес, аңа һәрвакыт диярлек йә гөрнадир, йә генерал кебек ыспай рольләрне бирәләр. Ләкин бу «геройлар» күп вакыт сүзсез, хәрәкәтсез була. Режиссерларча әйтсәк, җанлы декорация булып кала сабакташы. Ә менә Морзага андый ял иттерердәй рольләр тәтеми: үкереп еларга да, елый-елый җырларга да, тальянын киереп-киереп уйнарга да туры килә. Кайбер персонажлар әле аунатa-аунатa кыйныйлар да. Идән чүпрәгенә әйләнеп бетә кайбер тамаша

барышында. Кайткач, хатыны янына да ятасы килми кайчак. Дәрт—сүнгән, дәрман беткән була. Хәтта бер спектакльдә үрле-кырлы сикереп, чинап йөрүче маймыл ролен дә уйнарга туры килде. Мактап туймады халык шул көннәрдә, иң уңышлы тудырган образың шушыдыр, мөгаен, дип...

Уйларын Альбертның сабыр гына кисәтүе өзде:

—Шырпың белән саграк кылан әле син, Мырзый.

—Ә-ә-ә... шырпыны әйтәсеңме? Сүндердем мин аны...

—Сүндерүен сүндердең дә бит, ләкин аска төшереп җибәрдең.

—Юк, ул җиргә—чирәм арасына төште.

—Кайда төшүдә түгел хикмәт. Халыкның игътибар итүе бар. Альберт Шаһбаз лоджиясеннән чүп-чар коела дип, бөтен Казанга гайбәт таратырлар. Көлеңне дә тышка чиртерәсең. Теге банканы мин нәкъ менә көл төшерү, төпчек ташлау өчен элеп куйдым.

Киселеп үк чыкмаган капкачы култыксага уралган котелок хәтле калай банканы күргән иде инде күрүен Морза. Тышындагы матур алма, әфлисун рәсемнәренә дә сокланып торган иде. Ләкин—гадәт, шайтан алгыры—көлне дә уйлап тормыйча аска каккан икән шул.

Әле яңа гына кырыс тоелган сабакташы гөлдерәп кенә көлеп җибәрде:

—Шулай да кызыгам мин авыл кешеләренә, Мырзый дус. Культура хакында да уйлап торасы юк, итагать-тәртип тә саклыйсы юк—рә-хәт! Казан малайларыча җиффәрсәк, лафа!—Кулын Морза җилкәсенә дустанә салгач, өстәп тә куйды.—Бәхетле кеше син, Мырзый, валлаһи. Кем әйтмешли, йоның агара башласа да, бала-чага кебек беркатлы адәм син. Саладагы бәләкәй театрда эшләгәч, сәләт-талант, чын иҗат турында да уйларга туры килмидер сезгә, әйе бит? Тамаша-чыларыгыз—гыйбатлар, Сезгә гөрләтеп кул чабалардыр. Бәхет!

Сабакташының сүзләре күңеленә генә түгел, җанына ук төртелсә дә, хәтере калуын төсенә чыгармады Морза. Киресенчә, үзе башкарган җиңел акыллы бер героеча ихлас күңелдән көлеп җибәрде.

—Әйе, интегеп уйнамыйбыз, Альберт әфәнде, көчәнмибез. Гади итеп, үзебезнең тамашачыга охшарлык итеп уйнарга тырышабыз—шул гына. Ләкин безнең дә көзгеләребез, үрнәкләребез бар. Шәүкәтләрдән, Шәрәләрдән, Җәләйләрдән үрнәк алабыз. Шулар биеклегенә менү дәрте белән хыялланабыз. Баһманны алыштырырга хыялланучы җегетебез дә бар... Булдырып бетерә алмыйбыздыр, билгеле, ләкин омтылыш бар.

Альбертның учына, әйтерсең лә, өмет ителгән миллион сум урынына сукыр бер тиен салдылар. Ул, гүя, шул кулын сыек кына алга сузып, ниндидер нечкә, мескен тавыш белән пышылдау дәрәҗәсендә мыскыллы ыңгырашты:

—Кемнәрдән үрнәк алабыз дисең?! Һе-һи... Кем дип беләсең соң син аларны? Алар үткән гасыр әртисләре бит... Вакытында яраганнар инде, бөтенләй үк булмаган ише булмаганнар. Хәзер, Мырзый дус, яңа, заманча буыннан үрнәк алу вакыты җитте. Йоклап кала күрмәгез үзегезнең провинциягездә. Шәрә дип исең китә синең. Әле белмисеңдер, нәсел кушаматы да Тавык бит аның...

Артында басып торучы сабакташына борылганда Морза йөзендәге үртәлү галәмәтенең әсәре дә калмаган иде. Әле бер секунд элек кенә аның нинди хисләр утында булганлыгын Альберт түгел, иң тәҗрибәле психологлар да абайлый алмас иде бу мизгелдә. Борылган мәлдә үк диванaларча көлү белән көлеп җибәрде.

—Беләм, Тавык аның кушаматы, Тавык!

—Син дә беләсеңмени?—дип гаҗәпләнгәндәй итте Альберт.

—Беләм. Чөнки ул хакта һәр очрашуда тамашачыларга үзе сөйләп йөри.

—Оялмый да микән?

—Шулайдыр инде,—дигән булды Морза, тагын да тинтәкләнебрәк көлә-көлә. Ә күңеле белән бала чакта ук укыган шигырь кисәген барлады. Нәрсә дигән әле Смирнов? «В грязь попал кристалл, Однако никакой грязи к нему не пристал», дигәнме? Әйе, мондыйлар күпме генә пычрак чәчмәсеннәр, кабилиятле шәхесләргә тап төшми!

Күңелендәге шул тантананы һәр күзәнәге белән тойган, ныгыган Морза урамдагы халык та ишетерлек тавыш белән яңадан шаркылдады. Альберт исә аны үзенә теләктәшлек белән көлә дип, ихлас күңелдән сөенеп торды.

«Уйныйм булгач, ахырга кадәр уйныйм, барыбер түзәм!» дип кабатлады эченнән Морза һәм... кытыкланган сыман янә көлеп җибәрде. Ә кытыклануы хак

иде. «Түзәм! Барыбер дүрт йөз сумны янга калдырам!» дигән шайтани нияте дә кытыклый иде аны хәзер. Башын юләргә салмыйча ярамый иде аңа. Хәзер Альберт белән кылычка-кылыч килсә, барлы-юклы акчасын кунакханә администраторының өстәленә салса, нәрсә ашап яшәргә тиеш ул бу Казанда?! Әле бит монда Морзаны гомере буе гашыйк иткән әлеге талантлар түгел, яхшымы-начармы, сабакташы Альберт Шәһбазетдинов тора. Беләә, бик белә: Альберт сөйми аны, элек-электән яратмый. Ләкин Морзаны үртәштереп, сүз җае чыккан саен кыерлаштырып үзенә ямь табу, ләззәт алу, үз «бөеклеген» таныту хакына булса да, ике-өч төн кундырачак, чәен эчертәчәк. Нишләмәк кирәк, хәзер күпләр җайлаша, тормышын рәтләү, капитализм таңында ук баеп калу өчен тәнен дә, намусын да сата. Әнә, яшь-яшь сылулар тән сата, заманча сауналарда акчалылар белән «арка ышкыша». Чөнки көн саен тамак әпәй сорый, киләчәктә дә сатылачак тәннәрен каплаштыру, затлы итеп күрсәтү өчен дә матур чүпрәкләр кирәк. Эш урыны таба алмагач, ачтан үлсеннәрмени... Алар әле бер хәл, каләм әһелләре дә, галимнәр дә сатыла хәзер! Бигрәк тә сәләтсезләре. Фани дөньяда адәмчә яшәп калыйк, ичмасам, диләрдер инде. Тик шунысы аяныч, гомер-бакый михнәт, коллык дәрьясында михнәт чиккән милләтне бу юлы да ярык тагарак янында утыртып калдыру, алдау, талау исәбенә байыйлар...

Әнә шундый ямьсез вакыйгалар диңгезенә артык тирән керә баруын аңлаган Морза, йөрәгендәге ачынуларыннан арыну өчен, һәр сулышын барлап-күзәтеп торучы Альбертның хәтерен саклау өчен, тагын көлеп җибәрде. Әйе, артист кеше башын ташка орып елыйсы килгән чакларында да көлә белергә тиеш. Кайчак, кулуарларда, ягъни сәхнә артларында, сәхнәгә кабат чыгу чиратың җиткәнне көткән минутларда, тагын бер кат уйнау түгел, гәүдәңне дә күтәрә алмассыңдыр сыман тоела: мәктәп юлында йөрүче балаларың иске-москыга төренгән, яши торган фатирың салкын, дымлы, ягарга утын чамалы, әлеге дуңгызларга азык төткәзеп булмый—акча җитми... Шул тормышның сизгер барометрыдай хатының еш кына кәефсезләнә, кәҗәли, төртмә сүзләр дә ычкындыра. Алай-болай салып та кайтсаң, чырае кара болытка әверелә. Барысын да йөрәктән үткәреп, үртәлеп утырасың сәхнә артларында. Авыр, бик авыр бу тормыш... Әмма, чиратың җиткәч тә, сәхнәгә очып чыгасың. Гәүдәң мамыктай җиңеләйгән, күңелең һәрвакыт рәхәт вә ләззәт кенә чигеп яшәгәндер сыман: режиссер, әсәр таләп иткәнчә көләсең, теркелдисең, җанлы диалогларга керәсең, кайныйсың, кирәк урында мәтәлчек тә атасың әле!..

Морзага кушылып, Альберт та көлеп куйды:

—Шулай, Мырзый дус, һәр замана үз талантларын барларга тиеш. Күрәм, син дә килештең бу фикер белән. Безнең буын җилкәсенә күчте хәзер сәнгать...

Морзаның сүзендә түгел, йөзендә дә ризасызлык галәмәте сизелмәвенә тәмам инангач, лоджиядән кереп китте һәм, кулына ике банан тотып, әйләнеп тә чыкты:

—Бая синең тамак туеп җитмәде сыман. Аксымы күп бу маймыл ризыгының. Урынына кереп урнаша торсын әле. Кабыгын җиргә ташлый күрмә түлке. Хатын кайткач, бифштекс яки пицца әзерләтербез.

—Хатының яхшы тәрбияле, ахры, үзеңне?—дип сорап куйды Морза шундук. Аны сәнгать турында гайбәтләр, кинаяле сүзләр, ясалмалыклар шактый туйдырган иде инде.

Ләкин ясалмалык дигәне кабат калкып чыкты.

—Тәрбияләргә тиеш тә!—дип елмайды Альберт, бердәнбер креслога чумып, һәм, шул ук вакытта, бер аягы аксаган иске табуретканы Морза тарафына шудыра-шудыра.—Утырып җибәр... Әйе, тиеш тә! Үзең күреп торасың, фатирның бүлмәләре генә дә дүртәү. Ике кешегә бит ул! Рәхәтләнеп сәйран кыл, соклан, куан, кадерен бел, дигәндәй... Сәрия шуларның кадерен белми түгел. Димәк, минем кадерне дә белә дигән сүз. Әгәр минем кебек сәләт иясенә чыкмаган булса, мондый җәннәттә яши алыр иде микән әле ул! Мебельне күр тагын. Бүлмә саен, хәтта кухняда да, гарнитур. Келәмнән генә йөрибез...

Һай, күзгә карап алдый бит сабакташы! Нәрсәне-нәрсәне, бу кадәресен, дөресрәге, бөтенләй киресен яхшы белә Морза. Фатирны Сәриянең обкомда эшләгән абыйсы алып биргән коммунизм төзегән елларда. Хак булса, ордеры да Сәрия исемендә. Әле Морза йомыш белән бер килүендә кала артистлары белән сөйләшеп торган иде. Сүз фатир, аңа чират тору темасына кергәч, җор телле берсе:

—Альберт кебекләр күбрәк булса, безгә дә чират тизрәк җитәр иде,—дип көлеп куйган иде.

—Нәрсә, ярдәме, йогынтысы зурмы әллә?

—Ул әзер фатирлы кәләшкә йортка керде, дип әйтүем инде. Чират бер кешегә булса да кыскарды бит...

... Банан кабыкларын шактый җыелган төпчекләр янына салгач, хатынының совхозда директорлык итүче атасы алып биргән мебельнең дә «үз хәләл көче белән» алынуын исбатлап утырды әле Альберт. Анысын да үзенең «кемлегенә» китереп бәйләргә онытмады:

—Әле бит аның заманасы нинди иде! Акчаң булган суәттә дә мебеле юк иде бит аның. Ярый әле сәүдәгәрләр арасында да чын сәнгатьне танучылар бар. Таныш түрәгә үтенеч белән баргач, «синең кебек сәхнә йолдызлары да ялангач фатирда яшимени соң», дип гаҗәпләнде. Хәер, үпкәләрлек урын калдырмады—ни кирәк, барысын да төяп китерде...

Морза, бөтенләй сүзсез калуның ярап бетмәвен абайлап:

—Хәзер рәхәт инде, җаның нәрсә тели—шул бар. Тик акчаң гына бер капчык булсын,—дип, сабакташының сүзен җөпләгәндәй итте.—Дөресен әйткәндә, синдәге гарнитурларның берсе дә кирәкми миңа...

—Нәрсә, ошамыймыни?—дип гаҗәпләнде Альберт, бераз хәтере калгандай.

—Минем сәләмә фатирга берсе дә сыймый аларның. Сыйса да алмас идек. Ни өчен дигәндә, сәләмә хәерчегә патша таҗы кидергән кебек булыр иде алар.

Тагын икәүләп көлделәр. Морза—үз тормышының фәкыйрьлегеннән (елаудан ни файда!) көлде, ә Альберт бу җәһәттән дә өстен булуын тоеп, шул хистән ләззәт алып көлде. Аннары ул, бераз моңсу чырай ясап:

—Нишлисең инде, Мырзый дус, Ходай адәм балаларын тигез итеп яратмаган шул...—дип куйды.

Бу сүзләрнең төбенә дә: «Кешеләрнең барысы да зур талантлы булмый, лаеклык та тигез түгел» дигән мәгънә җәелгәнлеген Морза аңламый калмады. Әйтер иде бер сүз!.. Юк, ярамый—әлеге дә баягы, кесә сай, кунар урын кирәк.

Ләкин бу салмак кыйссаның авторы алдан ук әйтеп куюны кирәк тапты: кунарга насыйп булмады Морзага бу фатирда. Үзе гаепле, кабат ярты сәгатьтән нинди яңалык булачагын алдан белмәде. Алдан чамаларлык хәлдә түгел иде шул ул... Телен тыйган булсачы, Альбертның сафсаталарын, фальшларын ипле генә тыңлап утырган булсачы! Теленә шайтан төкерүе булгандыр, мактанып утыручы сабакташына тәкъдим иңдерүне кирәк тапты бит, юләр!

—Карале, Альберт, монда килгәндә йортыгыз артындагы бер матур бакча аркылы үттем. Шундый җиләс, рәхәт анда!.. Әллә, Сәриең кайтканчы, шунда чыгып утырабызмы соң?

Альберт та сөенеп риза булды:

—Бу фатирга ризалыгымны биргәндә, шул бакчаның барлыгын да истә тоттым шул мин! Чын иҗаттан, зур мәшәкатьләр, гамьнәр сорый торган бинйһая сәнгатьтән бушанып тору өчен аның да кирәк булачагын алдан уйладым.

... Бакчага чыккач, әз генә гапләшеп утыргач, Альберт каршы яктагы эскәмиягә, дөресрәге, шул эскәмиядә утыручы фырт кына киенгән, карашы тирә-яктан бигрәк күккә юнәлгән бер адәмгә карап, бернichә мәртәбә төче елмаеп куйды. Аннары, тирән генә сулыш алып:

—Син, Мырзый дус, утыра тор. Мин теге шәхес янына барып килим әле. Үпкәли торган гадәте бар. Күрмәмешкә салынды, дип, тәки бөтен Казанны тутырып йөрер. Бик тә зур галим ул...

—Бергә барсак та ярыйдыр, бәлки.

—Юк-юк, үз дәрәҗәсен белә торган зат ул, гадиләр белән утырудан кыенсына.

Альберт теге адәм янына барып, ике-өч минут та сөйләшмәде сыман, Морзаның колагына үз исеме керде:

—Морза түгелме соң бу! Үзем барам, үзем икеләнәм.

Тавыш килгән якка борылып караса, исәнләшү өчен кулын алга сузып, ниндидер чал чәчле ир килә. Кем соң әле бу?.. Әһә, Татарстан телевидениесенең хуҗасы түгелме соң? Шул, Акбашев үзе ләбаса! Ул һәрвакыт сүз уйнатырга, нияте изге чакта да төрттереп сөйләшергә, кинаяләр кыстырып алырга ярата. Монысы—бер-ике очрашудан калган фикер...

Акбашев, исәнләшүгә үк, янына утырды Морзаның. Уч төпләрен тез башына ышкып алгандай итте дә, Морзага текәлде. Бу арада ашыга-ашыга килүче

Альбертны да шәйләде Морза. Акбашев аның биргән кулын, ничектер, тәкәллефсез генә, сузган кулны кире борырга ярамый инде, дигән кебегрәк кенә итеп кысты, карашын Морзадан аермады.

—Димәк, Морза әфәнде, Указ чыкканчы ук килим әле Казанга, дидең инде, ә? Сизгер икәнсең, сиз-герр!—Ул, үз кинаясенә үзе соклангандай, гөлдерәп көлде.—Ярый әле килеп җиткәнсең, барыбер китерергә туры килер иде үзеңне.

Нинди Указ? Нинди сизгерлек? Морза Акбашевның ни әйтергә теләвен аңламады. Шуңа күрә зиһенендә туган сорауларын теле белән дә кабатлады.

Акбашев тагын көлде. Мыскыл итә дияр идең, карашы якты, шат.

—Әллә, чыннан да, белмичә килдеңме? Көн үтеп, Указны да укымадыңмы? Сиңа бит Халык артисты дигән исем биргәннәр! Вәт, юләр, бөтен кеше белә, үзе белми! Каяле, беренче булып үзем кысыйм әле кулыңны, болай булгач. Исеңдә калдыр, онытма. Хәер, оныта калсаң, менә бу иптәшең шаһит, исеңә төшергәләп торыр. Бергә килдегезме әллә, якташыңмы? Район хакимиятендә эшләмидер бит алай-болай, бик ыспай күренә?..

—Ул да минем кебек үк артист. Танылган артист,—диярга ашыкты Морза. Ләкин икенче җөмләсен Акбашевның хозурланып гөлдерәве күмеп китте:

—Яхшы, артист булуы шәп анысы. Танылу дәрәҗәсенә ирешсә, халык таныса, без дә танырга тырышырбыз. Үссен, синең кебек үк милләткә файда китерсен.

Үтерде, бөтенләй бетерде бу Альбертны, дип нәтиҗә ясарга өлгермәде Морза, Акбашев капыл гына урыныннан калыкты:

—Давай, иртәгә үк студиягә! Редакторга да, режиссерга да бүген үк әйтеп куям, синең белән әңгәмә оештыру өчен бөтен шартларны тудырсыннар. Бер-ике спектакльдән фрагментлар да ялгап җибәрсәк, ярты сәгатьлек менә дигән тапшыру килеп чыгар. Шәп уйныйсың бит син, сабакы! «Сабакы»га үпкәләмә тагы, мин аны иң яраткан кешеләрне мактаганда гына әйтәм. Сокланганда әйтәм...

Альбертның да, нәрсәдер әйтәсе килеп, авызы берничә мәртәбә ачылып ябылды, Морза да бер-ике сүз булса да кыстырырга, Альбертка игътибар иттерергә талпынып карады, ләкин ТРТ хуҗасы үз сүзен сөйләп бетерде дә, капыл гына борылып, тырт кына китеп тә барды. Хәтта:

—Иртәгә тугызда көтәбез!—дигән сүзен дә ун-унбиш адым ераклашкач кына борылып кычкырды.

Акбашев китеп баргач, сөенеч белән көенеч икесе берьюлы кереп урнашты Морзаның эченә. Артист халкы юләр бит ул, беркатлы: аз-маз акчага да чегән кебек дөнья буйлап гастрольдә йөри—туңа,чылана, пешә, сазлы юлларда машина этеп җәфалана, кайчак, тамагын да ялгамаган килеш, сәхнәгә чыга, атналар буе йөреп, ерак юлдан кайтканда игәр этенә охшап кала... Һәрхәлдә, Морза үзе хакында шулай уйлый. Артистның тагын да зуррак юләрлеге бар тагын: кул чабуларга, мактап сөйләүләргә, чәчәк бәйләме биргәнгә дә, нинди дә булса «атказанган» исемнәргә хирес була. Морза да шулай. Сөенеч зур инде, зур! Әмма кабыргаң белән Альбертның хәлен аңлап утыруы бик кыен бит әле... Бөтенләй тынып калды бу, тын да алмый сыман. Димәк, беренче сүзне Морза башларга тиеш.

—Да-а-а,—дип сузды Морза, Акбашев киткән якка күз төшереп,—үз сүзенең һичшиксез үтәлергә тиешлегенә инанып яшәүче кеше бу. Хәтта вакытны да килешеп торуны кирәк тапмады—әйтте дә, китте дә...

—Көнчелегеннән мине танымаганга салынды бит әле...—Бу юлы Альбертның тавышы хәлсез дә, мескен дә иде. —Шундый алар Казан кешеләре, хөсетлеләр.

Фатирга кайтып керү белән Альберт туп-туры әлеге лоджиягә юнәлде, кайсыдыр төштән «Астра» сигареты чыгарып кабызды, гасабиланып, төпчек, банан, кыяр кабыгы, шырпы төпләре һәм тагын әллә нинди чүпләр белән түбәләмә тулган әлеге консерв савытын каерып алды да, ике кулы белән дә учлап тотып, аска томырды.

Тагын телен тыеп кала алмады Морза. Провинциядәге ихласлык белән:

—Кеше өстенә төшә күрмәсен тагын. Культурасызлыкта гаепләр өчен менеп җитмәгәйләре...

—Кайгырма, хәзер караңгы инде, күрмиләр,—диде Альберт, тешен кысып, аннары, Морзаны тәүге мәртәбә күргәндәй, борылып, йөзенә текәлде.—Бар әле, син, ыслушай, юлыңда бул. Яратмыйм минем хатын синең кебек вак-төякләр, этрәгәләмнәр белән аралашканымны! Тизрәк тай, әмма бер сүз дә әйтәсе булма!

*Нәниләр дөньясы*

# Рафис Корбан

## Ватан

Нәрсә ул Ватан?
Ул—тыныч ал таң.
Ул—болын, гөлләр,
Елгалар, күлләр.
Ул—торган йортың,
Мәктәбең, бакчаң.
Бакчага илткән
Сукмак ул Ватан!

Ватан ул—дуслар,
Һавада кошлар.
Дуслар торган җир,
Кошлар сузган җыр!
Ул—әби-бабаң,
Ул—анаң, атаң.
Ватан—ярату,
Тугрылык—Ватан!

Нәрсә ул Ватан?
Ул—тыныч ал таң.
Яңа көн белән
Башлана Ватан.
Яхшы эш белән
Яклана Ватан.
Йөрәк түрендә
Саклана Ватан!

## Куян

Куян ак карда
Эз салып үткән.
Шул кадәр күп эз,
Буталып беткән.

Төлкене шулай
Алдаган куян.
Эзләрнең очын
Чуалткан, җуйган.

Төлке иснәнеп
Йөри эз буйлап.
Мескен куянны
Тотарга уйлап.

Ә куян кырдан
Урманга киткән,
Чыршы астында
Ял итә күптән.

## Кояш белән болыт

Күктә кояш көлеп
Нурын сибә иде.
Җирдә эти чапкан
Печән кибә иде.

Исеп куйды җилләр
Шунда шаян гына.
Килеп чыкты болыт
Әллә каян гына.

Ә кояш болытка:
—Кит, каплама!—диде.
Бу чак инде җиргә
Тамчы тама иде.

Кояш үпкәләсә,
Болыт ачуланса,
Җәйге зәңгәр һава
Кабат ачылмаса?!

Шул чагында күктә
Үпкәләрдән өстә
Хасил булды күпер
Балкып җиде төстә.

Читкә китте болыт,
Кояш ачты күзен.
Салават күпере
Балкытты күк йөзен.

## Йөзьяшәр имән

Бүген урманда
Күп йөргәч, арып
Агач төбенә
Утырдым барып.

Өстәл хәтле бар—
Шулкадәр зур төп!
Торам шаккатып,
Исләрем китеп.

Ә бит кайчандыр
Урманда бу төп
Зур агач булып
Утырган үсеп.

Бәлки йөз яшьлек
Имән булгандыр.
Һәрбер яшеннән
Төпкә калган сыр.

Көчле җилләрдә
Шаулаган урман.
Аңа бу имән
Көч биреп торган.

Аугач та калган
Имәннән торып
Юлчылар өчен
Ял итәр урын.

## Туган якта

Сулап туялмаслык
Чыңлап торган һава!
Туган якның эчкән
Сулары да дәва.

Тирәкләрдә кошлар
Концерт бирә монда.
Тавыклары җырлап
Йөри урамында.

Чирәм, бәбкә үлән—
Яшел хәтфә келәм.
Шул келәмгә ятып
Бер ауныйсы килә!

# Басыйр Рәфыйковка 80 яшь



Басыйр Шаһинур улы Рәфыйков Мамадышта туган (1921 елның 10 февралендә). Әмма тоталитар система җилләре аны да—әтисе, гаиләсе белән—туган туфрагыннан яшьли кубарып, Уралга, Магнитогорск якларына илтеп ташлый. Нәкъ менә яшьтәше, олуг шагыйребез Гамил Афзал язмышы!.. Шунда уку, соңыннан Троицк шәһәрендә татар-башкорт педагогия техникумын тәмамлап, Әлмән авылында урыс теле укытучысы булып эшләү. Ә сугыш елларында ул хезмәт армиясенә алына, Магнитогорск металлургия заводында эшли. Читтән торып укып, педагогия институтын (тарих факультетын) тәмамлагач, озак еллар Троицкида татар-башкорт педагогия училищесында укыта, директор урынбасары була; аннары башка мәктәпләрдә завуч, директор вазифаларын башкара. Гомере буе туган телгә, әдәбиятыбыз, Шигърият-Әнкәгә гашыйк Басыйр ага яшьтән үк шигырь язса да, бастырырга ашыкмый. Аны өлкән язучыбыз Гомәр Бәширов дәртләндереп, кереш сүз язып, «Совет әдәбияты» («Казан утлары») битләрендә бер бәйләм шигырьләрен чыгарырга булыша. Аннан—«Җырым сиңа булсын» (1968) исемле беренче китабын... Менә шуннан соң Басыйр Рәфыйков исеме матбугатыбызда еш күренә башлады. Үзе яши торган төбәктә күмәк җыентыкларда урысча шигырьләре дә басылды, соңыннан аерым китап булып та дөнья күрде.

Татар телендә исә янә «Калерле минутлар» (1971), «Туган тупсалар» (1981) һ.б. шигырь китаплары басылды, шагыйрь 1974 елда Язучылар берлегенә кабул ителде. Иҗатында Б. Рәфыйков, барыннан да бигрәк, лирик-фәлсәфи планда ачылды. Татар мәдәнияте, әдәбияты тарихында якты эзе булган, Тукай, Гафури, Бабичлар хатирәсен саклаган Троицк, аның киләчәге турында уйланулар хас бу иҗатка, һәм анда тирән әрнүле, борчулы мотивлар да күп. Туган тел, халык язмышы мәсьәләләре «тар шигырьләр үлчәве»ннән чыга: шагыйрь мәкалә-очерклар да яза, тарихи документларга таянып, шул төбәк һәм атаклы кешеләр тормышын бәян итә. Халык иҗаты җәүһәрләрен җыю һәм бастыру эшендә дә өлеше бар аның; милли хәрәкәттә дә бик теләп катнаша—җөмләдән, соңгы Татар конгрессында да күрдек аны. Кыскасы, инде өлкән яшьтә булуына карамастан, шагыйрь яшьләрчә дәрт һәм мәхәббәт белән иҗат итә. Ул үзенең кыйбласына—халыкка хезмәт юлына тугры булып яши.

*«Казан утлары» юбилярны олы бәйрәме белән чын күңелдән котлый, аңа иҗат уңышлары, исәнлек тели.*

# ҖӘЛИЛНЕҢ БИЛГЕСЕЗ РӘСЕМЕ



Бу фотосурәтнең кулыма ничек килеп кергәнен анык кына хәтерләмим. Ул композитор Җәүдәт Фәйзи кәгазьләре арасында сакланган. Шуңа күрә, рәсемне дә йә Җәүдәт ага үзе, йә аның туганнары тапшырган булса кирәк.

Сурәтнең артына Җәлил кулы белән дүртьюллык шигырь язылган:

Җәүдәт!

Һәр вакытта үзгәрәдер
Тормышның картинасы,
Тик шушы рәсемдә калыр
Ял итү хатирәсе.

«Башкорт кызы».

Башта бу юллар Җәлилнең шул исемдәге шигыреннән алынган дип уйлаган идем. Ләкин, Мусаның андый исемдәге шигыре юк. Һәрхәлдә, андый шигырь аның иң тулы дүрттомлыгына кермәгән. Димәк, бу үзенә күрә экспромт кына, ягъни бер селтәнүдә язып ташланган шигъри юллар. Почмакларына шул ук кул белән «Башкортстан, 17.X.1930 ел» дип язып куелган. Ләкин бу—рәсемгә төшү датасы түгел —фотоны бүләк итү датасы булса кирәк, чөнки рәсем җәй көне төшерелгән, рәсемдәге кешеләр дә җәйгечә киенгән.

Иң аста икенче кул белән (Җ. Фәйзи булса кирәк) «Кара Якуп, 1930, режиссер Арсланов» дип язылган.

Хәзер инде Җ. Фәйзинең үз хатирәләренә мөрәҗәгать итик.

Атаклы композитор Җәүдәт Харис улы Фәйзи (1910-1973) Муса белән утызынчы еллар башында Казанда таныша. Бу вакытта Җәлил Мәскәү, Җ. Фәйзи Казан университетында укыйлар. Муса шактый еш Казанда була, Татар мәдәнияте

йортында (хәзерге ТЮЗ) оештырылган әдәби кичәләрдә актив катнаша. «Шундый кичәләрнең берсендә,—дип яза Ж. Фәйзи,—миңа беренче тапкыр Муса Жәлилне күрергә туры килде. Соры костюм кигән һәм ул вакытта модада булган ботинкалары өстеннән гетрлар каплаган кечерәк буйлы Муса Жәлил сәхнәгә чыгып үзенең шигырьләрен укыган иде». Аларны Гадел Кутуй таныштыра. Алар ара-тирә очраштыргалап торалар һәм шактый якынаялар. Хәтта алдагы каникул вакытында бергәләшеп ял итәргә дә сүз куешалар.

«1930 елны,—дип дәвам итә Ж. Фәйзи,—без Муса белән алдан сөйләшү буенча Башкортстанның Чишмә районы Кара Якуб авылындагы ял йортында очраштык. Айга якын бергә тордык. Урманда йөрдек, волейбол уйнадык, кичләрен танцыларга йөрдек. Безнең иң яраткан эшебез, кичләрен үз тирәбезгә яшьләрне җыеп, әдәбият турында сөйләшү, бергәләшеп җырлап утыру иде. Клубта пианино бар. Мин уйныйм, Муса җыр башлап тора, ә яшьләр аңа кушылалар»... Шуны да искә төшерик: Мусага ул вакытта 24, Жәүдәткә—20 яшь. Икесенең дә өйләнмәгән, студент чаклары...

Шул ук ял йортында ул чорның данлыклы артисткасы Зәйтүнә Илбаева да була. Ул да 1930 елны ире һәм кызы белән ял итеп, кымыз эчеп йөри, шунда Муса белән очраша. «Муса һәрвакыт төскә яшь күренгәнлектән, аңа ничә яшь булуын дөрес кенә белә алмадым. Миңа ул япь-яшь кенә бер егет кебек күренде». Жәлил исә аңа чын күңелдән гашыйк булып йөргән—бу турыда ул соңыннан Зәйтүнәгә үзе яза. Менә аның З. Илбаевага язган хатыннан бер өзек:

*«Зәйтүнә!*

*Мин тормышта тирән һәм ялкынлы сөя беләм. Мин табигатьне дә, кошны да, чәчәкне дә, музыканы да, һәм намуслы хезмәтне дә, ялкынлы иҗатны да, тыңдәшсез илемне дә шулай ук янып, кайнарланып сөям. Бу минем эчке тирән бер сыйфатым инде.*

*Мин хатын-кызга да шундый ук саф, кайнар сөю бүләк иттем»*

Хат берничә ел үткәч, 1935 елның мартында язылган.

Әлеге рәсемдә дә Жәлил белән янәшә утырган кыз—Зәйтүнә Илбаева булса кирәк. Икенче ягында утырганы аның ире (режиссер Арсланов?) булуы ихтимал. Ләкин шулаймы-юкмы—төгәл итеп әйтүе кыен. Мусаның альбомын әзерләгәндә без бу мәсьәләгә ачыклык кертерлек кеше тапмадык. Шуңа күрә бу рәсем дә альбомга кертелми калды.

Бәлки журнал укучылары арасында рәсемдәге кешеләрне белүчеләр табылыр? Редакция исеменә хат язуыгызны көтеп калабыз.

**Рафаэль МОСТАФИН**

# ДИНИ БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

Мөселман календаре буенча
1421—1422 (һиҗри) еллар

**4 март (якшәмбе), Гарәфә көне.** Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**5 март (дүшәмбе), Гайделһадха, Корбан бәйрәме**. Иң зур мөселман бәйрәме. Бу, ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме һәм ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**6-8 март (сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе), Тәшрикъ көннәре.** Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһ Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**21 март (чәршәмбе)—Нәүрүз, ягъни Яз бәйрәме.**

**26 март (дүшәмбе) Мөхәррәм ае башланган көн.** 1422 ел, Яңа мөселман елы башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зякят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**4 апрель (чәршәмбе), Гашура көне.** Сөнниләр тарафыннан Аллаһ Тәгалә үзенең ун пәйгамбәренә күндергән изгелекләре хөрмәтенә, ә шиитлар тарафыннан Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы, Гали хәлифәнең улы имам Хөсәенне (626—680) җәзалап үтерү көне хөрмәтенә билгеләп үтелә.

**10 апрель (сишәмбе), Болгар бабаларыбыз Ислам динен кабул иткән көн.**

**25 апрель (чәршәмбе), Сәфәр ае башланган көн.**

**20 май (дүшәмбе), Һиҗрәт кичәсе көне.** Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, Һиҗрәт иткән көн. Шушы төннән, ягъни 622 елның 16 июль көненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни Һиҗри ел исәбе башлана.

**3 июнь (якшәмбе), Мәүлид бәйрәме.** Иң зур бәйрәмнәрнең берсе—Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер сәдака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факелләр һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**19 сентябрь (чәршәмбе), мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне.** Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайса пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

**20 сентябрь (пәнҗешәмбе), Рәгаиб кичәсе.** Мөхәммәд пәйгамбәрнең әтиәнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе.

**14 октябрь (якшәмбе), Мигъраҗ бәйрәме.** Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә—Аллаһ Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 60 ай яки 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**15 октябрь (дүшәмбе), Хәтер көне.** Казанны саклап каһарманнарча һәлак булган бабаларыбызны искә алу көне.

**19 октябрь (җомга), Шәгъбан ае көне.** Дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча, сигезенче ай—Шәгъбан ае башлану көне.

**1 ноябрь (пәнҗешәмбе), Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт».** Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһ Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**17 ноябрь (шимбә), Чират изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн.** Рамазан аенда иң кадерле кичә—Кадер кичәсе.

**13 декабрь (пәнҗешәмбе), Кадер кичәсе.** Бу төндә язмышлар хәл ителә. Бу төндә Мөхәммәд пәйгамбәргә Коръән Кәрим иңә башлый.

**17 декабрь (дүшәмбе), Гайделфитыр, Ураза бәйрәме.** Ураза тәмамлангач, авыз ачу бәйрәме башлана.

**Хаҗи Абдулла ДУБИН.**

*Хатлардан юллар*

* * *

Хөрмәтле Равил әфәнде!

Кулыбызга «Казан утлары»ның унынчы саны килеп эләккәч, бик куандык. Зур рәхмәт Сезгә Рафаэль Мостафинның «Татар Зоргесы» исемле очеркын баскан өчен. Укыгач та, Шамил Хәмзинның тол калган хатыны Бибииран ханымга шалтыраттым. Ул журналны алдырмый, укымаган булган икән. Бибииран да танышып чыкты, бик сөенде. Ул да Рафаэль Мостафинга зур рәхмәт әйтергә кушты. Ул бик күп эшләде, халкыбызга Муса Җәлил исемен гайбәтләрдән чистартып кайтарган иде. Хәзер инде бөтенләй яңа каһарманны—татар Зоргесын күтәреп чыкты.

Бибииран ханым әлегә исән-сау. Өлкән яшьтә булуына карамастан язучылар, журналистлар белән очраша, Хәмзинның нинди зур шәхес булуы турында сөйли. Рафаэль Мостафин да аның сөйләгәннәренә таяна. Югыйсә, кайдан белер идек татар халкының күрсәткән батырлыклары турында.

Хәзер менә яңа татар исемнәре—Алсу, Марат Сафиннар күренә башлады. Алар турында да журнал битләрендә укыйсыбыз килә. Күптән түгел Әбрар Кәримуллин үлеме турында зур кайгы белән укыдык. Ул да халкыбызның бер каһарманы.

Күп сәлам белән, Мәскәүдә яшәүче өлкән яшьтәге укучыгыз.

**Разия Габдрахман кызы ХӘСӘНОВА**

* * *

«Казан утлары» журналының 2000 елгы 8, 9, 10 нчы саннарында шагыйрь Марс Шабаев тәрҗемәсендә минем «Иртәләгән сагыш» исемле романым татар укучыларына барып иреште.

Тәрҗемә тулысынча яхшы, бик яхшы эшләнгән. Мине бигрәк тә куандырганы һәм гаҗәпләндергәне—роман эчендәге шигъри текстларның искиткеч матур тәрҗемәсе булды—аларны укыгач, күземә яшьләр килде.

Рәхмәт, рәхмәт! Мине шулай сөендергәнегез өчен гомергә бурычлымын. Равил Фәйзуллинга, Флүс Латыйфига, романымны дөньяга чыгарышкан барлык хезмәткәрләргә рәхмәтлемен.

Ышанам, романны татар укучылары да яратып кабул итәр. Тәрҗемә күнелгә якын, аһәңле—әсәрнең ритмы да, интонациясе дә төгәл сакланган, заман рухы, шул чорның исе-тәме, төсе-буяулары аңкып тора.

Рәхмәт!

**Рауль МИРХӘЙДӘРОВ.**
*Мәскәү*

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ГАСЫР УЛЫН ОЛЫЛАУ

Татарстан Республикасының Дәүләт Зур концерт залында бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең тууына 100 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булды. Президент М. Шәймиев кичәне ачканда бүгенге көндә Русиядә генә түгел, ә бәлки чит илләрдә дә танылган Дәүләт Зур концерт залына Салих Сәйдәшев исеме бирелүе турындагы Указны игълан итте. Ул композиторга нинди һәйкәл куелачагы турындагы соңгы карарның әлегә кабул ителмәгәнлеген һәм моның борчу тудыруын, әмма бүгенге көндә аның Кабан күле буендагы мәйданда, Г. Камал исемендәге театр бинасы каршына куелачагы мәгълүм булуын әйтте. Күл буенда бер якта—Тукай, ә икенче якта Сәйдәш һәйкәле торачак.

Татарстан Фәннәр академиясе президенты М. Хәсәнов композиторның шәхесе, иҗаты турында сөйләде. Ул Тукай кебек үк, XX гасырның ренессанс мәдәниятеүзеген гәүдәләндерә. Сәйдәш татар музыкасын профессиональ дәрәҗәгә күтәрде, диде ул.

С. Сәйдәшев язган һәм аның хөрмәтенә иҗат ителгән әсәрләрне Татарстан Дәүләт симфоник оркестры, Татарстанның танылган җырчылары З. Сөнгатуллина, В. Ганиева, Г. Ибушев, яшь башкаручылар—2000 елда С. Сәйдәшев исемендәге вокалчылар конкурсы лауреатлары Р. Талипова һәм А. Шаһиморатова һ. б. башкарды.

### ТУФАН ТАНТАНАСЫ

Камал театрында шагыйрь Хәсән Туфанның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Президент М. Шәймиев үз чыгышында шундый бөек затлар тудыра алган халык һәм, XX гасырның бөтен авырлыкларын кичереп тә, йөзен, намусын ак килеш саклап калган Хәсән Туфан белән горурлануын зур дулкынлану белән әйтте. Мондый шагыйрьләр тудырган халыкның киләчәге ышанычлы.Зур намуслы, халкына хыянәт итә алмый торган кеше ул Хәсән Туфан. Ул үз юлыннан беркайчан да тайпылмады. Аның кешелек батырлыгы Җәлилләр батырлыгы белән тиңләшерлек, диде ул.

Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин шагыйрь Х. Туфанның тормыш һәм иҗат биографиясе турында сөйләде. Х. Туфан турындагы уй-фикерләре белән драматург Т. Миңнуллин һ. б. уртаклашты.

Кичәне күренекле әдип Р. Батулла алып барды.

### ТАКТАШ ВАТАНЫНДА

Декабрь аеның соңгы көннәрендә Мордовия республикасында татар әдәбияты классигы Һади Такташның тууына 100 ел тулуга багышланган юбилей тантаналары булып үтте. Анда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ф. Галимуллин җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә катнашты. Делегация составында язучылар Р. Харис, Г. Зәйнашева, А. Хәлим, Ш. Мостафин һәм журналист Э. Кудрецкая бар иде.

Татарстан кунаклары шагыйрьнең туган авылы Сыркыдыда булдылар, Такташ исемен йөртүче авыл хуҗалыгы кооперативында эшләүчеләр, мәктәп балалары һәм мөгаллимнәр белән очраштылар. Шул ук көнне язучылар Мордовия республикасы башкаласында, А. Пушкин исемендәге республика китапханәсендә Һ. Такташның 100 еллык юбилеена багышланган тантаналы җыелышта катнаштылар. Биредә Мордовия республикасы җитәкчесе Н. Меркушкинның һәм Русия Президентының Идел буе федераль округы буенча вәкаләтле вәкиле С. Кириенконың Һ. Такташның юбилее уңаеннан котлаулары игълан ителде.

Һ. Такташ юбилее уңаеннан үткәрелгән тантаналарда Мордовия республикасы җитәкчесе киноәшчесе Ш. Бикмаев, мәдәният министры Ю. Юшкин, Язучылар берлеге идарәсе рәисе А. Доронин, матбугат һәм мәгълүмат министры А. Лузгин һ. б. катнашты.

### 2001 ЕЛ—ЯШЬЛӘР ЕЛЫ

Президент М. Шәймиев Татарстан республикасында 2001 елны Яшьләр елы дип игълан итү турында Указ чыгарды. Анда «Татарстан дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру бурычларыннан чыгып, республиканың күпсанлы җәмәгать берләшмәләре башлангычын хуплап, яшьләрнең җәмгыять тормышындагы ролен күтәрү, буыннар арасында элемтәләрне һәм рухи кыйммәтләр алышуны ныгыту максатында: 2001 елны Яшьләр елы дип игълан итәргә»,—диелә.

Бу уңайдан шәһәр һәм район хакимиятләренә Яшьләр елын уздыру өчен оештыру комитетлары төзергә, тиешле чара-

лар планын эшләп расларга, аларны жирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар исәбенә финанслауны тәэмин итү бурычы куела.

## БӘЙГЕ ДӘВАМ ИТӘ

1552 елда Казанны саклап һәлак булучылар истәлегенә һәйкәл урыны һәм аның гәүдәләнешен билгеләү буенча бәйгенең өченче туры башланды. Мәдәният министрлыгы, Казан шәһәре хакимиятенең архитектура һәм шәһәр төзелеше баш идарәсе бу тур киләсе елның 6 мартына хәтле дәвам итәчәген белдерде.

## ЖУРНАЛ ЮБИЛЕЕ

Камал театры бинасында «Татарстан» журналының 80 еллыгына багышланган тантаналы кичә узды. Редакция коллективын һәм журналистика ветераннарын юбилей белән тәбрик итеп, Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин журнал алдына житди бурычлар һәм игелекле максатлар куелуын билгеләп узды. Ул Ә. Фәйзрахманов һәм Л. Әхмәтованы Татарстанның мактау грамотасы белән бүләкләү, ә журналның баш мөхәррире Р. Фәттаховка «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турындагы Указны игълан итте.

Редакция коллективын Татарстан матбугат, телерадио тапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министры З. Вәлиева, Фәннәр академиясе президенты М. Хәсәнов, Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин һ. б. тәбрик итте.

## ОЛУГ ШӘХЕСЛӘРНЕ ЗУРЛАУ

Бөек композитор Салих Сәйдәшев һәм мәшһүр шагыйрь Хәсән Туфанның тууларына 100 ел тулу уңаеннан Магнитогорск шәһәрендә әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Анда үзешчән артистлар, музыкантлар, театр актерлары, жырчылар, биючеләр, Ләлә Идрисова житәкләгән «Тамчылар» бию ансамбле дә катнашты. Бу кичәдә ике олуг шәхеснең әсәрләре башкарылды. Тормышлары, ижади казанышлары турында сөйләнде.

## ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

* * *

1 декабрьдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең утырышы булды. Анда Абдулла Алиш исемендәге бүләкнең быелгы лауреатлары Рәшит Бәшәр һәм Ләбиб Леронга дипломнар тапшырылды. 19 яшьлек шагыйрә Луиза Янсуар, прозаик Сәмига Сәүбәнова, тәржемәче Нияз Әхмәровлар берлекнең әгъзалары итеп кабул ителде. Шушы елның август аенда язучылар белән очрашу вакытында Татарстан Президенты Аппараты житәкчесе Ә. Гобәйдуллин китап чыгарган өчен гонорар түләүне үз кузәтүе астына алырга вәгъдә биргән иде. Бу вәгъдәнең үтәлүе, бүгенге көндә Татарстан китап нәшриятының авторлар белән исәп-хисапны тулысынча диярлек ясавы турындагы хәбәрне утырышта катнашучылар зур канәгатьлек белән каршылады.

* * *

20 декабрьдә әдәби тәнкыйть һәм проза остаханәләренең (житәкчеләре Мансур Вәли һәм Солтан Шәмси) берләштерелгән утырышы үткәрелде. Анда язучы Вахит Имамовның «Могикан» исемле повесте турында («Идел», 2000, 10 сан) эшлекле сөйләшү булды. Яңа әсәрне тикшерү уңаеннан, гомумән, повесть жанрының бүгенге хәле һәм перспективалары турында кызыклы фикерләр әйтелде. Утырышта тәнкыйтьче Р. Свернгин доклад белән чыкты. Фикер алышуларда М. Хужин, З. Зәйнуллин, А. Әхмәдуллин, М. Хәбибуллин, Ә. Баянов, Н. Сафина, Р. Рахман, Р. Кәрами, К. Кәримов катнашты.

## «ЖИДЕГӘН ЧИШМӘ» ШАГЫЙРЬЛӘРНЕ ЖЫЙДЫ

Түбән Кама «Жидегән чишмә» ижат берләшмәсенең 19 нчы яңа сезоны Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим белән очрашудан башланды. Ижат кичәсендә шагыйрьнең әсәрләре буенча куелган аерым спектакльләрдән өзекләр, жырлар тәкъдим ителде, һәм әдәбият сөючеләр үзләрен кызыксындырган сорауларга әдипнең жавапларын да ишеттеләр.

Күренекле шагыйрь һәм жәмәгать эшлеклесе Мостай Кәрим белән очрашу кичәсендә Татарстан вәкилләре—шагыйрьләр И. Юзеев, М. Әгъләмов, Р. Миңнуллиннар катнашты.

## «АЛТЫН БИТЛЕК» ИЯСЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Марсель Сәлимжанов «Намуслылык һәм абруй өчен» номинациясендә «Алтын битлек» премиясенә лаек булды.

Узган ел йомгаклары буенча әлеге номинациядәге премияне аның белән бергә танылган актриса Алиса Фрейндлих та алды. Лауреатларга бүләкләр Мәскәүдә 2001 елның март аенда тапшырылачак. Мәгълүм булганча, Татарстанда «Алтын битлек»нең беренче иясе—Президент Минтимер Шәймиев.

## ӘДИП ИСЕМЕНДӘГЕ БҮЛӘК

Мамадыш районының Тулбай авылында ел саен 15 гыйнварда Шәйхи Маннур бүләген тапшыру тантанасы уза. Быел да бер төркем язучылар әдипнең туган авылында булып, аның каберенә зиярәт кылдылар, музей-китапханәдә булдылар һәм яңа мәдәният йортында шигырь бәйрәме үткәрделәр.

Ш. Маннур исемендәге бүләккә быел «Чулпан» күмәк хужалыгы комбайнчысы Илгизәр Хисматов, «Яңарыш» хужалыгы рәисе Фәрит Ситдыйков, Тулбай башлангыч мәктәбе укытучысы Фирдия Диярова, «Казан утлары» журналының жаваплы секретаре Алмаз Гыймадиев, Мамадыштагы «Агымсу» ижат берлеге әгъзасы Вахит Галиев лаек булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

# ТАТАР «ИЛИАДАСЫ» КАҺАРМАНЫ

Татарда һәм башка төрки халыкларда кин таралган "Чура батыр" дастанының төп каһарманы серле һәм әлегә кадәр тулаем ачылмаган реаль шәхесләрнең берсе. Әмма аның халкыбыз тарихында гаять зур роль уйнаганы бәхәссез. Румыниядән алып ерак Себер урманнарына кадәр таралган татар авылларында дастанның бик күп вариантлары йөрү шуның ачык мисалы. 1988 елда Бухарестта ул татар телендә "Бүз егет" дигән китапта басылып чыкты. Дастанны филология фәннәре докторлары, илленче елларда Казан университетында белем алган Нәдрәт һәм Әнвәр Мәхмүт Румыниядәге татар авылларында язып алганнар. Әлеге дастанны язучы Флүс Латыйфи Казан әдәби татар теленә күчереп, 1993 елда аерым китап итеп чыгарды. Дастанның Румыния варианты безнең өчен кайсы ягы белән кызыклы соң? Иң кызыклысы, аның теле әле бүгенге көндә дә Казан татарларына яхшы аңлаешлы. Димәк, төрле-төрле мәмләкәтләрдә яшәсәләр дә, татарның уртак теле, уртак авыз иҗаты, уртак горефләре һәм йолалары булган. Безнең борынгы тарихыбыз уртак. Дастан ерак бабаларыбызның йолалары, гадәтләре, кием-салымы, сугыш кирәк-яраклары, яшәү рәвеше хакында бай мәгълүмат бирә.

Тасмагер атына менгәнсең,
Койрыгы белән ялларын
Ефәкләр белән үргәнсең,
Агам, кая китәсең?
Ук-җәянне таккансың,
Ук алмаган калканыңны
Уң инсәнә аскансың,
Агам, кая китәсең?
Укалы кием кигәнсең,
Ук-садагың элгәнсең,
Сул кулыңа кош тотып,
Агам, кая китәсең?

Казан татарларында Чура батыр турындагы дастанның төрле вариантлары очрый, кайбер риваятьләрне картлар әле дә хәтерли. Ул гына да түгел, аерым төбәкләр тарихын тулаем Чура батырга бәйләп аңлату да яшәп килә. Яшел Үзән районы Олы Карагужа авылы зиратында, мәсәлән, язмалары инде шактый кыршылган ике кабер ташы бар. Авылдагы риваятьләр бу каберлектә авылга нигез салучы Кара Гужаның уллары («Идегәй» эпосында Туктамыш аңа: «Аргыннарның башы идең, Кара Гужа батырым»,—дип эндәшә) Чура би һәм Чура батыр күмелгәнлеген бәян итә.

Кара Гужа бу җирләргә Олы Мөхәммәт чорында, XV гасыр урталарында килгән. Ул—Казан ханлыгына нигез салучыларның берсе—Алтын Урда бәге Кара бинең улы булырга тиеш. Хәзер Караваево дип йөртелүче бистәнең исеме дә нәкъ менә аңа нисбәтле. Риваятьтә сөйләнгәнчә, Кара Гужа бу җирләргә килеп төпләнгәч ук аткан. Укның берсе—Олы Карагужа җиренә төшкән һәм ул бәкнең олы улы Чура би милегенә әверелгән. Икенче ук—хәзерге Җәке җиренә килеп кадалган. Ул—икенче улы—Җикнең биләмәсен тәшкил иткән. Өченче ук Күлбәш авылына төшкән... Картлар әйтүенчә, бәкнең үз йорты бүгенге көндә инде корыган, элек Чура би исемен йөрткән елга буенда булган...

Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, Казан ханлыгы өчен барган сугышларда Чураларның берсе ханга хыянәт иткән өчен җәзалап үтерелгән. Казанлылар аның авызына кайнар көмеш тутырганнар: «Менә сиңа җитмәгән иде, ал кирәгеңне!»— дигәннәр. Икенчесе (Чура-батыр) Явыз Иван Казанны алганда бик каты каршылык күрсәткән һәм дошманга терелә́й бирелмәс өчен аты белән бергә үз-үзен кыядан атып һәлак булган. Аның кабере Чура-би чокыры тирәсендә булуы ихтимал дигән фаразлар әлегәчә яшәп килә. Бу җирләр XVI гасырда Казан ханлыгының төп биләмәләренең берсе булган, башкаладан аңа «таш юл» сузылган. Ул тарихта «Сәет юлы» исеме белән билгеле. Фетнә заманында хәтта Сөембикә үзе дә шушы авылда сыену урыны тапкан. Авылның эпостагы Чура батырның ватаны булуы бик мөмкин. Бүгенге Карагуҗаның иң өлкәннәреннән саналучы 81 яшьлек Рөкыя апа үзенең нәсел шәҗәрәсен ун буынга кадәр белә һәм аны Казан карачыларыннан Аргын нәселенә—Чураларның бабасы—Кара бигә илтеп тоташтыра.

Әлеге таштагы язуларны инде укырлык түгел. Ләкин андагы бик катлаулы һәм зәвыклы бизәкләр, орнаментлар аларның Казан ханлыгы чоры шаһитләре булуларына шик калдырмый. Каберташларны ясалу һәм бизәлеш җәһәтеннән өйрәнеп, текстларын мөмкин кадәренчә укып, фәнни нигездә яңарту-торгызу тарихыбызны барлау юлында мөһим бер эш булыр иде. Гомумтөрки әдәби мирасына әверелгән эпосның каһарманы, Казанның “тимершыгы” (тимер калканы, сакчысы мәгънәсендә) Чура батыр әдәби герой гына түгел, ул тарихи сабак та, бүгенгеләргә гыйбрәт тә. Бүгенге цивилизация карашларыннан чыгып, тарихтан сабак алып без аны бөек “Илиада” каһарманнарына тиңли алабыз. Ул Ал һәм Ак Роза сугышларының геройлары кебек үк зур ихтирамга лаек... Шулай булгач, аңлашыла ки, гаять фаҗигале тарихи шәхеснең кабере дә халкыбызның тарихи ядкаре, уртак мирасыбыз. Реставрацияләп, тирә-юнен тәртипкә китереп аны халкыбыз өчен дә, Казанның мең еллыгы чорында башкалабызга күпләп агылачак туристлар өчен дә истәлекле бер урынга әйләндереп булыр иде. Ул тарихи-патриотик тәрбия өчен кызыклы һәм гыйбрәтле бер атрибутны тәшкил итәр иде.

**Иркә ШАҺИЕВА**


*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Ф. Халиков дастаннарда сурәтләнгән Чура Батырны әнә шундый итеп күз алдына китерә.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Себердә яшәп иҗат итүче өлкән язучыбыз Якуб Зәнкиев.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Мәгълүм булганча, 1999 елның 15 сентябрендә Татарстан Президенты М. Шәймиев «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» законга кул куйды. «Бу закон латин графикасы нигезендә татар алфавитын тагын да камилләштерү һәм аның дөнья коммуникация системасына керүе өчен уңай шартлар булдыруга юнәлдерелә,—диелә Законда. —2011 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан республикасында бер үк вакытта ике алфавит: латин графикасы нигезендәге һәм кириллица гамәлдә була». Шушы закон нигезендә үткән ел Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты латин графикасы нигезендә татар алфавитын гамәлгә кертү буенча Дәүләт Программасын эшләде һәм ул Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан расланды. Программа буенча 2001 елның 1 сентябреннән беренче сыйныфка укырга кергән балалар әлифбаны яңа имлада укый башларга тиеш.




2000 елда «Мәгариф» нәшриятында С. Вагыйзов һәм Р. Вәлитованың «Латин графикасы нигезендә әлифба» дигән эксперименталь уку ярдәмлеге дөнья күрде. Ул Татарстан Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителә.

Ярдәмлек рәссам Тавил Хажиәхмәтнең төсле рәсемнәре белән бизәлгән. Мөхәррире—язучы Флүс Латыйфи. Тиражы—10 мең данә.

Индекс 73210



Якуб Зәнкиев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)